# Казан утлары

10.1989



# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**1989**

**10**

**(804)**

КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН


## *Бу санда:*


**Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Указы** . . . . . . . . . . . . . . . . 3

ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР ҺӘМ ШИГЪРИЯТ

Ф. САДРИЕВ. **Шаһзаманов эше.** *Повесть* . . . 5
Э. ШӘРИФУЛЛИНА. **Эзләдек, исем эзләдек.** *Шигырьләр* . . . . . . . . . . . . . . 75
Р. ХАРИС. **Кәрван.** *Шигырьләр* . . . . . . 79
З. ФӘТХЕТДИНОВ. **Үлем элмәге.** *Роман* . . . 84
Н. ӘХМӘДИЕВ. **Васыять.** *Шигырьләр* . . . 132
Э. ГАДЕЛ. **Туган авылны сагыну.** *Шигырьләр* 132

М. Ю. ЛЕРМОНТОВНЫҢ ТУУЫНА 175 ЕЛ

М. Ю. ЛЕРМОНТОВ. **Болытлар.** *Шигырьләр* . 137

ЭСТОН ЯЗУЧЫЛАРЫ БЕЗДӘ КУНАКТА

А. ВАЛТОН. **Яшел биштәрле кеше.** *Хикәя* . . 139
П.-Э. РУММО. **Тыңлыйм болыт агышларын.** *Шигырьләр* . . . . . . . . . . . . . 147
Я. КАПЛИНСКИ. **Бик тә кысанайдың син, замана.** *Шигырьләр* . . . . . . . . . . . . 147
Д. ВААРАДНИ. **Кышкы төн.** *Шигырь* . . . 148
А. СИИГ. **Таш назы.** *Шигырь* . . . . . . 148
В. ЛУИК. **Ишекле көзгеләр.** *Шигырь* . . . . 149

ПУБЛИЦИСТИКА

Җ. РӘХИМОВ. **Аккошлар Чалпыда кала** . . 150

ОСТАХАНӘ

Х. БӘДРЕТДИНОВ. **Туфраксыз басу.** *Очерк* . 161
К. ТИМБИКОВА. **Өметләнеп көтәбез** . . . . 163

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Р. ЯГЪФӘРОВ. **Уйнагыз, нәниләр** . . . . . 164

КИТАП КҮЗӘТҮ

М. ӘХМӘТҖАНОВ. **Милли матбугатыбыз турында** . . . . . . . . . . . . . . . . 170

Ә. СӘХАПОВ. Гүзәллеккә тугрылык . . . . . 173

МӘДӘНИЯТЕБЕЗ ТАРИХЫНА

Җ. ЗӘЙНУЛЛИН. Н. Г. Чернышевскийның татарча кульъязмалары . . . . . . . . . . 174
Т. НӘҖМЕТДИНОВ. Бу эш ничек булды? . . . 178

КОТЛЫЙБЫЗ

Шәриф Хөсәеновка — 60 яшь . . . . . . . 183

ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕ

Икенче дәрес . . . . . . . . . . . . . 184
Гарәп әлифбасы нигезендә татарча уку күнекмәләре . . . . . . . . . . . . . . . . 187
Бер сорауга бер җавап . . . . . . . . . . 189
Китаплар дөньясында . . . . . . . . . . 190
Мәдәният тормышы көндәлеге . . . . . . . 191
Тышлыктагы сурәтләр . . . . . . . . . . 192

*Баш редактор*
РЕНАТ ХАРИС
*Редколлегия*
ГАРИФ АХУНОВ
МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ
МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ
АЯЗ ГЫЙЛӘЖЕВ
МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ
ФЛҮС ЛАТЫЙПОВ
*(җаваплы секретарь)*
МӘДИНӘ МАЛИКОВА
САЛИХ МАННАПОВ
ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН
ФЛҮН МУСИН
МАРАТ МӨЛЕКОВ
РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ
РАШАТ НИЗАМИЕВ
*(баш редактор урынбасары)*
ГӘРӘЙ РӘХИМ
КОЯШ ТИМБИКОВА
*(бүлек редакторы)*
РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИН
МӘХМҮТ ХӘСӘНОВ
МӨДӘРРИС ӘГЪЛӘМОВ
ТӘҮФИКЪ ӘЙДИ
*(бүлек редакторы)*
АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

Указ Президиума Верховного Совета ТАССР о внесении некоторых изменений в современный татарский алфавит.
Повесть Ф. САДРИЕВА «Дело Шахзаманова»; продолжение романа З. ФАТКУТДИНОВА «Петля смерти». Стихи Э. ШАРИФУЛЛИНОЙ, Р. ХАРИСА, Н. АХМАДИЕВА, Э. ГАДЕЛЯ.
«К 175-летию М. Ю. Лермонтова» — новые переводы стихов поэта.
В рубрике «У нас в гостях писатели Эстонии» — рассказ А. ВАЛТОНА; стихи П.-Э. РУММО, Я. КАПЛИНСКОГО, Д. ВААРАНДИ, А. СИИГ, В. ЛУИК.
«Публицистика» — очерк Дж. РАХИМОВА «Лебеди остаются в селе».
«Литературная мастерская» — очерк молодого публициста Х. БАДРУТДИНОВА анализирует писатель К. ТИМБИКОВА.
«Литературная критика» — статья Р. ЯГЪФАРОВА «Играйте, малыши».
«Библиография» — М. АХМЕТЗЯНОВ рецензирует книгу Р. Амирханова «Татарская демократическая печать (1905—1907 гг.)»; А. САХАПОВ — сборник стихов А. Махмудова.
«К истории культуры» — рукописи Н. Г. ЧЕРНЫШЕВСКОГО, написанные им на татарском языке; воспоминания Т. НАДЖМЕТДИНОВА об отце — известном татарском писателе К. Наджми.
В номере отмечается 60-летие Ш. Хусаинова.
Уроки татарского языка. Занятие 2-ое.
Навыки чтения на основе арабской графики.
Интервью ректора Казанского медицинского института Н. АМИРОВА.
«В мире книг».
«Дневник культурной жизни».
На наших обложках — малая пластика Р. Х. НИГМАТУЛЛИНОЙ. Вид Казанского монастыря. XIX век. Репродукция с литографии английского художника Э. ТУРНЕРЕЛЛИ.

Безнең адрес: 420066, Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар:
баш редактор — 53-07-60,
баш редактор урынбасары — 53-07-09,
җаваплы секретарь — 53-07-09,
*бүлекләр:*
проза, поэзия, очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать,
хатлар — 53-07-63.

*Бүлек редакторлары* Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин.
*Редакторлар* Нияз Акмалов, Шамил Маннапов, Җәүдәт Миңнулин, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Техредакция:* Р. Вафина, Г. Моратова, Ф. Сабирова, Т. Сибгатуллина, Р. Сөләйманова.

Производствога бирелде 4.08.1989 ел. Басарга кул куелды 25.09.1989 ел. ПФ 05309. Офсет ысулы белән басыла.
Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 77049. Заказ Б-341. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе,
Казан, Декабристлар урамы, 2.

С «Казан утлары», 1989 ел.

# ТАТАРСТАН АССР

# ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ

# УКАЗЫ

**Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының «Татар алфавитын латинлаштырылган алфавиттан рус графикасы нигезендәге алфавитка күчерү турында»гы Указына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы карар бирә:

1. Татар алфавитын һәм орфографиясен камилләштерү максатында, киң җәмәгатьчелек соравы буенча, татар алфавитына өстәмә „ҟ", „ғ", „ў" хәрефләрен кертергә; аларны сүзнең башында, уртасында һәм азагында калын сузыклар белән дә, нечкә сузыклар белән дә язуны билгеләргә.

2. Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының «Татар алфавитын латинлаштырылган алфавиттан рус графикасы нигезендәге алфавитка күчерү турында»гы 1939 ел, 5 май Указының беренче пунктындагы 2 нче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «41 хәрефтән торган бердәм дәүләт татар алфавитын түбәндәге тәртиптә, графикада һәм билгеләмәдә расларга (1 нче кушымта)».

3. Татар әдәби теле орфографиясенең Татарстан АССР Халык мәгарифе министрлыгы һәм СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты тәкъдим иткән нигезләрен расларга.

4. Уку йортларында һәм матбугатта татар әдәби теленең камилләштерелгән алфавитын һәм орфографиясен 1990 елның 1 сентябреннән кертә башларга.

5. Татарстан АССР Министрлар Советына 1989 елның 1 сентябренә кадәр камилләштерелгән алфавит һәм орфографияне кертү буенча практик чаралар эшләргә.

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы
Председателе Ш. МОСТАЕВ.

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы
Секретаре Д. ДӘҮЛӘТШИНА.

Казан, Кремль, 1989 ел, 27 июнь.

| Басма хәреф | | Язма хәреф | | Хәрефләрнең исемнәре | Басма хәреф | | Язма хәреф | | Хәрефләрнең исемнәре |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Баш хәреф | Юл хәрефе | Баш хәреф | Юл хәрефе | | Баш хәреф | Юл хәрефе | Баш хәреф | Юл хәрефе | |
| А | а | А | а | а | Ө | ө | Ө | ө | ө |
| Ә | ә | Ә | ә | ә | П | п | П | п | пэ |
| Б | б | Б | б | бә | Р | р | Р | р | эр |
| В | в | В | в | вә | С | с | С | с | эс |
| Ў | ў | Ў | ў | ўә | Т | т | Т | т | тэ |
| Г | г | Г | г | гә | У | у | У | у | у |
| Ғ | ғ | Ғ | ғ | ғы | Ү | ү | Ү | ү | ү |
| Д | д | Д | д | дә | Ф | ф | Ф | ф | эф |
| Е | е | Е | е | е | Х | х | Х | х | ха |
| Ж | ж | Ж | ж | жә | Һ | һ | Һ | һ | һә |
| Җ | җ | Җ | җ | җә | Ц | ц | Ц | ц | цә |
| З | з | З | з | зә | Ч | ч | Ч | ч | чө |
| И | и | И | и | и | Ш | ш | Ш | ш | ша |
| Й | й | Й | й | қысқа и | Щ | щ | Щ | щ | ща |
| К | к | К | к | ка | Ъ | ъ | | ъ | айыру билгесе |
| Қ | қ | Қ | қ | қы | Ы | ы | Ы | ы | ы |
| Л | л | Л | л | эль | Ь | ь | | ь | нечкәлек һәм айыру билгесе |
| М | м | М | м | эм | Э | э | Э | э | э |
| Н | н | Н | н | эн | Ю | ю | Ю | ю | йу |
| Ң | ң | Ң | ң | эң | Я | я | Я | я | йа |
| О | о | О | о | о | | | | | |

## ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

### Фоат Садриев

# ШАҺЗАМАНОВ ЭШЕ

ПОВЕСТЬ

## I



Мондый хәл килеп чыгар дип колхозда беркем дә уйламады.

Май азагында гына була торган тымызык иртәләрнең берсе иде. Авыл бакчаларын ямьләп катыктай чәчәктә утырган алмагачларның алсу таҗ яфраклары тын гына коелган чак. Әйтерсең лә, кәүсә тирәләренә таңкә карлар сибелә... Алма, шомырт, сирень чәчәкләренең хуш исен, язгы туфрак исен салкынча һава агымы Үрмәш урамнарына гына таратып калмый, ә бәлки ындырга теләп агучы Казлы елгасы буйларына китереп төшерә, аннары каршы яр өстендәге техника паркына алып менә, кыш буе тимер-томыр, машина мае исеннән туеп беткән ир-атларның борыннарын ярып керә, йөрәкләрен җилкендерә.

— Их, егетләр, бездән дә юләр кеше юк! — ди Бәчә Фәргате һәм тарта гына башлаган папиросын җиргә ыргыта.— Шушы исләрне тәмәке төтененә алыштырырлыкмы соң!

Барысы да елмаешып куялар, чөнки Бәчә Фәргате арада иң күп тартучы, биш минуттан ул әле генә әйткән сүзләрен онытып папирос кабызачак, кулы кесәсендәге «Беломор» кабын инде капшый да башлады. Күзләр Сәләхетдингә төбәлә. Ул бер сүзне дә җавапсыз калдырмый, ул хәзер Бәчәгә ни дә булса әйтәчәк. Сәләхетдин үз дәрәҗәсен белә, ашыкмый. Сигаретын ул юри озаклап суыра, төтенен ашыкмыйча гына авыз-борыныннан чыгара да төкереген көчле басым белән ике теш арасыннан җеп нечкәлеге генә итеп аска юнәлтә. Аннары Бәчә Фәргатенә карамыйча гына болай дип куя:

— Юләрлегеңне кичә танымасаң да, бүген таныдың бит, апай.

Бердәм көлү, хуплау авазлары яңгырый.

— Син нәрсә таяк белән бармакны бутыйсың?! — ди тегесе кызып.

— Әйе, әйе.— дип аңа да көч бирәләр.

Барысының да Сәләхетдин белән Фәргать арасында кичә булган бәхәсне күзгатасы килә.

---

Фоат САДРИЕВ *(1941) — әдип, драматург, «Их сез, егетләр», «Ач тәрәзәң», «Кондырлы кодачасы» һәм башка пьесалар, хикәяләр авторы. Мөслимдә яши.*

— Безнең колхозда тизләнеш. үзгәртеп коруларның мәңге булачагы юк! — дип кычкыра торгач. кичә Фәргать карлыгып туктаган иде.

Ә Сәләхетдин кызмыйча-ярсымыйча гына:

— Булачак кына түгел. әле үзең дә үзгәрәчәксең. тәмәке тартуыңны да ташламагаең.— дип тегене җай гына ирештерә торды...

Ләкин бәхәс бүген куера алмый калды. Бөтенесенең игътибары кара тузан болыты күтәреп бирегә якынлашучы сары тракторга юнәлде. Менә Илһам Шаһзамановның К-700 маркалы «кибәне» юлдан чыгып турыга гына элдерде. ул туктамас. бөтенесен изеп-сытып китәр кебек килә иде. Тракторның чокыр-чакырларны акрынаймыйча үтүендә. артына тагылган культиваторларының тимер капкага элә язып дөбер-шатыр керүендә үк ниндидер ярсу сизелде. Тракторын сүндергәч. Илһам тормозга басып та тормастан җиргә сикерде. Башка чакта булса. ул акрын гына кереп туктар. моторны сүндергәч. кабинада озаклап әйберләрен барлар. аласын алыр. саласын салыр. ишеген бикләр. аны тартып карар. ашыкмыйча гына төшәр. аннары. кырык бишенче размерлы кирза итекләре белән лас-лос басып. мастерскойга таба атлар иде. Ул чакта аның гөрес-мәрес гәүдәсе әз генә алга иелгән булыр. тузан кунган кара керфекләре арасыннан зәңгәр күзләре тыныч кына елмаер. Аннары мастерской янындагы кешеләрнең һәркайсы белән көрәктәй кулын биреп исәнләшер. читкәрәк басар да аларның сөйләшүен тавыш-тынсыз гына елмаеп тыңлар. сүз бетмичә ике аягының берсен дә атламас...

Әмма бүген ул мастерской ягына борылып та карамады. иптәшләренең күз карашыннан качкандай. парктан чыгып китте. Бу гайре табигый хәл иде. Моны Бәчә Фәргате генә шулай эшли ала һәм аңа беркем дә гаҗәпләнми. Ләкин ул Фәргать түгел ләбаса! Һәркемнең күңелендә бер сорау бөтерелде: ни булган? Ник Илһам бирегә килмәде?

Тынлыкны Сәләхетдин бүлде:

— Син мәнә. Фәргать апай. тизләнеш юк. ул безгә кагылмый дисең. Ә үзең күзгә терәлеп торган тизләнешне күрмисең.

— Я әйт. кайда ул. кайда?! — дип чәпчеде Фәргать.

— Әнә.— диде Сәләхетдин гомер буе сугылудан һәм кысылудан тырнагы ямьшәеп. каралып беткән чәнчә бармагы белән Илһамга күрсәтеп.

Фәргатьтән башкалар көлешеп куйдылар.

— Карагыз әле. валлаһи. безнең якка борылып та карамады. китте дә барды Тәтеле тәре.— диде берсе Илһамның кушаматын телгә алып.

— Хәерлегә булсын. үткән бишьеллыкта да. бусында да аның болай кабаланганын күргән юк иде әле.

— Эшләгәндә ашыксын иде ул.

Илһам. әлбәттә. аларның сүзләрен ишетмәде. ишетергә дә теләмәде. аның туктарга. гәп куертырга вакыты юк иде. Ул Казлы ярыннан төшеп китте. яшь кычыткан һәм үләннәрне ера-ера елга буйлап атлады. Эссе. тузанлы кабинадан соң бередәге салкынча дымлы һава бөтен тәнгә рәхәтлек бирә иде. Кәҗә сукмагы тар булганлыктан. әледән-әле ялгыш читкә басылды. елгага кызыл балчык. таш кисәкләре чупылдап төште. төнге йокысыннан уянып җитмәгән бакаларны. маймычларны өркетте. Каршы як яр сөзәк. аның буеннан-буена судан өч-дүрт метр ераклыкта өянкеләр тезелеп киткән. Аларның иң аскы юан ботаклары яфракларын суга тигерү өчен инеш өстенә сузылганнар. Бу ботакларда авылның ничәмә-ничә буын малае атынып үсмәгәндер! Бу ботакларга атланып Илһамнар ничәмә-ничә сыбызгы ясаганнардыр да. ничәмә-ничә төрле тавышлар белән сызгыртмаганнардыр. ничәмә-ничә мәртәбә шуннан инешкә сикермәгәннәрдер! Ул чакларда әллә суы тирән иде. әллә алар бәләкәй иде — белмәссең. Илһамның дүрт малае да шунда атына-тирбәлә үсте. Зурысы Айнур инде унынчы классны бетерде. зур егет булды. Кем белә. бу ботаклар әле аның балаларының балаларын да күтәләрдер. Өянкеләрнең сагызлы яшеллек каплап килүче ботакларына бүрек-бүрек оя корган каргаларның туктаусыз каркылдавыннан Казлы буе яңгырап тора. Аларның тавышларын-

да туган якларына исән-имин кайтып җиту, тагын шушы өянкеләргә оя кору, бала чыгару өчен йомырка сала башлау шатлыгы сизелә. Су буеннан үткәндә Илһам еш кына бу өянкеләргә туктап карап тора, яше кырыктан узган ир алар арасында качышлы уйнап йөргән балачагын да күрә, кечкенә үзенең шау-шуын да ишетә... Тик бүген ул туктамады, дөресрәге туктый алмады, аны ниндидер көч алга таба этте, ашыктырды, күңелен аңлаешсыз бер тойгы борчыды. Әйтерсең лә ул төне буе басуда эшләмәгән, ә бәлки кача-поса ниндидер ярамаган нәрсә белән шөгыльләнгән, вөҗданына хилафлык кылган.

Менә ул ат арбасы гына сыешлы тәбәнәк буадан чыкты, тыкрыкка кермәде, ындыр коймасыннан сикереп төшеп, ызаннан гына үзләре ихатасына атлады. Әнисе бәрәңге бакчасында тырма белән кантарларны ватып, бураана ярган урыннарны тигезләп йөри иде.

— И әнкәй, сәгать алты да тулмады бит әле, ник рәхәтләнеп ял итмисең? — диде Илһам.

Әнисе кеткелдәп көлеп, кулын гына селтәде.

— Шушы кара туфрак өстендә рәхәтләнеп йөрү — ял инде ул, улым.— Аннары өстәп куйды: — Газ плитәсе өстендә итле бәрәңге булыр, суытмыйча аша.

Илһам кабат бер сүз дә әйтмәде, рәшәткәле җиңел капкадан ишегалдына керде.

Халисә әле фермада, балалар йоклый иде. Башка көннәрне ул аларны бик озак күзе белән иркәли һәм ата-ана күзе нык тия дигән сүз исенә төшеп, куркып куя. Күз тиюгә ул, гомумән, ышанмый; шушы кадәр зур бәхетне хәвеф-хәтәрдән саклау җаваплылыгы сискәндереп куя, күрәсең.

Бүген ул балаларын карап тормады. Итекләрен дә салмыйча өйгә керде дә кухня шкафының астын ачты, анда шалтыр-шолтыр актарынганнан соң, бер ярты алды, стаканга аракы салды. Тирән итеп бер сулагач, эчеп тә җибәрде. Калак белән каерып варенье капты һәм шунда гына урындыкка утырды. Күзләрен йомып башын артка ташлады да шактый вакыт шул хәлендә хәрәкәтсез торды. Елыйсы килә иде. Тамагына килгән төерне көч-хәл белән йотып җибәрде. Аның әчелеге, кайнарлыгы тамак төбен көйдереп үтте. Төер туктаусыз килде. Илһам плитә өстендәге ит белән бәрәңгегә кызыгып карап куйды, ләкин үрелмәде. Аңа ашарга ярамый, исерергә кирәк, чөнки исермичә торып берни дә кыла алмаячагын ул яхшы белә. Илһам, стаканны тутыра язып, тагын аракы салды һәм тын да алмыйча эчеп җибәрде. Карашын бер ноктага төбәп хәтсез генә утырды. Егет чакта бик күп кызларның төн йокысын качырган серле күзләр. Кара керфекләре озын булгангамы, әллә дугайланып, ярым бөгелеп торгангамы, күз читләрен сөрмә тарткандагы төсле күләгәле, серлелек бөркеп торалар. Шул серле күләгә уртасында ашыкмыйча гына зәп-зәңгәр күзләр йөзә. Киң маңгай, озынча туры борын, елмаям-елмаям дип торучы калын иреннәр. Куәтле муен, киң җилкәләр — табигать бирсен дә җәлләп бирмәгән. Киндер күлмәк-ыштан, чабата кидереп, билбау бәйләт тә әкият батырлары арасына кертеп җибәр — әкиятне уйлап чыгаручы үзе дә танымас. Менә шундый кеше Илһам. Беркайчан да ашыкмас, кабаланмас. Тик менә бүген генә...

Инде елыйсы килү үтте, аңа көч-куәт иңгән кебек булды. Тәрәзә турысыннан әнисенең узып киткәне күренде. «Хәзер керәчәк тә ашарга кыстый башлаячак».— дип уйлады Илһам. Аңа бер минут та тоткарланырга ярамый иде.

Ул, шешәне урынына куйгач, кызулап ишегалдына чыкты. Әнисе җим савыты тоткан хәлдә кетәклеккә кереп бара иде. Илһам урам капкасына килде дә туктап калды. Койма өстеннән урамга күз төшерде. Сөт җыючы Талипның бидоннар салган арбасы якынлашып килә. Сул якта Мөфәриха карчык белән Гыйзденисa карчык нидер сөйләшеп тора. Юк, эчкән хәлдә кеше алдына чыгып булмый иде.

Илһам кайдан кайтып кергән булса, шуннан кире китте. Ләкин тех-

ника паркына менмәде, елга бөйлап аска таба ашыкты. Казлы, өч-дүрт чакрым үткәч, Ыкка килеп кушыла һәм нәкъ шул урынга колхозның үзәге булган Үрнәк авылы урнашкан. Әгәр Казлы Үрмәшне ындыр яклап ураса, Үрнәкне урталай ярып үтә. Шуңа күрә биредә елга аша күпер салынган. Күпер турында гына колхоз идарәсе. Хәзер иртәнге нарядтан чыгып, бөтенесенең шул тирәдә болганган чагыдыр. Яхъя да шунда булырга тиеш.

Илһам аны күпер буендагы кычытканлы сукмактан күтәрелгәндә үк күреп алды. Яхъя кара бөдрә чәчләрен сыпыра-сыпыра кешеләр белән сөйләшә иде. Кемнәрдер идарәгә керә, кемнәрдер чыга. Читтәрәк җиңел машиналар, мотоцикллар тора, аларның кайсы килеп туктый, кайсы китеп бара. «Әгәр Яхъяны бирегә чакырып алсаң?» — дип уйлады Илһам. Тукта, фургонлы яшел «Москвич»ына таба үзе килә түгелме соң? Булмады шай, бригадир Латыйпов белән агроном Мансур аны туктаттылар, тагын кемнәрдер килде, кызып-кызып сөйләшә башладылар. Көтеп тору файдасыз иде. Янына барырга, һәммәсен йөзенә бәреп әйтергә, аның оятсызлыгына чик куярга. Нәкъ менә башкалар карап торганда әйтергә! Ул эре-эре атлап әлеге төркемгә якынлаша башлады. Шул чак Яхъя башын артка ташлап рәхәтләнеп көлеп җибәрде. Ул, кемдер кытыклагандай, тыела алмыйча, бармагында машина ачкычын бөтерә-бөтерә көлде. Илһам бу көлүне көтмәгән иде, тәне эсселе-суыклы булып китте, күңелендәге рәнҗеш тыелгысыз ачуга әйләнде. Илһамның доп-доп басып, бик сәер кыяфәттә килүен күреп, барысы да аңа таба борылдылар. Бригадир Латыйпов, уңга тайпылып, уртадан юл бирде. Илһамның йодрыклары гына түгел, иреннәре, күзләре дә ачу белән кысылды, уң як яңагы дерт-дерт тартышты. Яхъя, нәрсәдер сизенеп, көлүеннән туктап калды, күзләре киерелеп ачылды. Ләкин соң иде инде: Илһам тимердәй йодрыгы белән аның яңагына китереп кундырды. Бу шул кадәр тиз, шул кадәр көтелмәгәндә булды ки, барысы да, аяз көнне яшен суккандай, катып калды. Яхъя мәтәлеп китте һәм, чәчәк газонын әйләндереп алган тимерчыбык бөкләмнәренә башы белән төртелеп, туктады. Читтәрәк торучылар да бу якка борылдылар, идарә алды «ах» итте. Биш-алты кеше Илһамны тотып алды. Ул карышмады да, кабат сугарга да омтылмады, ни булды соң бу дигәндәй, җирдә хәрәкәтсез яткан Яхъяга карап тик торды. Берничә кеше Яхъяны күтәреп торгызды. Аның өс-башы тузанга баткан, борыныннан аксыл шакмаклы күлмәгенә кан ага иде. Ул канын сөртмәде, нindидер әйбердән котылырга теләгәндәй, башын чайкап куйды, аннары аксый-аксый атлап Илһам каршына килде. Аларны халык уратып алган иде инде. Бер-бер артлы аптырашлы сораулар яңгырады:

— Ни булды?

— Кем сугыша?

— Кемне кыйнаганнар?

Яхъя Илһамның аяк астына канлы төкерек төкерде дә башын югары күтәреп:

— Син нәрсә?! — диде. Аның тавышы тамак төбеннән гырылдап чыкты.— Әллә тилердеңме?!

Алар еш-еш сулап бер-берсенә карашып тордылар. Яхъя тәбәнәк иде. Илһам өстән аның сыдырылган һәм тирләп чыккан маңгаен, агарынган чыраен, канлы авыз-борынының дерелдәвен күрде, әмма ни әйткәнен ишетмәде. Бая аны әйдәкләгән көч инде сүрелгән иде. Ул кинәт артына борылды, этә-төртә халык арасыннан чыкты да килгән юлыннан кире кайтып китте.

Кемдер әйттеме, әллә үзләре күрепме, идарәдән колхоз председателе Биккинин белән партком секретаре Солтанов йөгереп чыкты. Аларга икегә аерылып юл бирделәр. Уртада Яхъя канлы күлъяулыгы белән авыз-борынын сөртеп тора иде.

— Ни булды? — диде Биккинин килеп җитәр-җитмәс.

Солтанов дәшмәде, бары, тик биредәге кешеләрнең әле берсенә, әле

икенчесенә сораулы караш ташлап, аларның йөзләреннән соравына җавап эзләде, ләкин аптыраштан башка берни дә күрмәде. Бары тик бер кешенең кыяфәте генә аны сагайта төште. Бу — орлыкчылык буенча агроном Мансур Рафиков иде. Аның карашында, башкаларныкыннан аермалы буларак, аптыраш түгел, ә канәгатьлек билгесенә охшаш нәрсә кабынып алды, авыз читләрендә шатлыгын эчкә яшерергә тырышкандагы кебек сызыклар чалынды.

Биккининнең соравына Латыйпов хатын-кызларныкы кебек нечкә тавышын тагын да нечкәртебрәк җавап бирде:

— Үзебез дә берни аңлый алмый калдык,— диде ул, күз карашын әле бер, әле икенче кешегә күчереп.— Сөйләшеп тора идек. Илһам килде дә, бер сүз әйтмичә, тиктомалдан сукты да екты...

Аның сүзен башкалар җөпләде. Яхъяга якынрак килеп, Биккинин:

— Әллә әйткәләшкән идегезме? — диде.

Аның тавышы бик акрын, ягымлы чыкты. Председатель баш агрономны малае кебек ярата, һәм моны колхозда барысы да беләләр иде. Яхъя «юк» дигән мәгънәдә баш чайкады да машинасына таба китте, артыннан Биккинин иярде. Баш агроном машинасына кереп утырганда, председатель аның беләгенә кулын салды:

— Болай булмый бит инде...

— Дәүләт Хәсәнович...— Яхъяның тавышы өзелеп калды.— Өс-башны алыштырып килим, зинһар.

— Ярый алайса, көтәбез.

Яшел фургон акрын гына кузгалып китте.

Яхъя баш түбәсенең сулык-сулык килүенә кешеләр алдында тешен кысып түзде. Хәзер генә ул аны капшап карады һәм кулы канга буялды... Аяк, терсәк, тагын кайсыдыр төш авырта, ләкин аларның авыртуы йөрәкнең сыкравы белән чагыштырырлык түгел иде. «Ник? Ни өчен?» дигән сорауга да ул берничә минут эчендә җавап тапты. Мәсьәлә ике иең дүрт кебек ачык иде. Димәк, хатыны Гөлзаданың Илһам белән чуалуы хак. Йә тегене, йә моны белешкән булып, аның бухгалтериягә, Гөлзада янына, кергән чакларын үз күзләре белән күргәләсә дә, Яхъя аларның йөрүен исбатлый алмый, өйдә тавыш чыгарса да, Гөлзада бик ышандырып елагач, ялгышамдыр, ахрысы, дип, үз-үзен тынычландыра иде. Менә хәзер икеләнү бетте. Димәк, алар күптән элемтәдә, бер-берсен онытмаганнар. Илһам гомер буе алар арасына керәчәк, тормышларын бозачак... Аның Яхъяга сугуын шуның белән генә аңлатып була иде. Ләкин ни өчен бүген? Ни өчен биш-ун ел элегрәк түгел? Гөлзада белән аларның өйләнешкәненә унтугыз ел, шул гомер эчендә бер генә мәртәбә дә, ялгышып та кучәр башлары орынышмады. Илһам да берниндн үпкә-сапка белдермәде. Ни өчен нәкъ менә хәзер?

Соңгы вакытларда Яхъяны чәчүлек орлык артыннан ерак командировкаларда шактый йөрттеләр, әнисе Гөлзаданың эштән соңарып кайтуларын да әйткәләгән иде. Ул аны партком секретаре Солтановтан көнләде, ә алар, күрәсең, Илһам белән иске мәхәббәтләрен яңартканнар. Боларны уйлагач, Яхъяның сулышы кысылды. Ир кеше өчен үзен халык алдында мәсхәрәләнгән, кыйналган, намусы тапталган итеп тоюдан да зуррак бәхетсезлек бармы икән дөньяда?! Ул әле күңеле белән генә сиземләгән нәрсәләрне кешеләр инде күптән беләләрдер, аның артыннан бармак төртеп көләләрдер...

Хатынын ул шашып ярата һәм шундый ук кайнарлык белән көнли иде. Гөлзада алдан күкрәк турына, арттан калак сөякләренә кадәр ачык җиңсез алсу күлмәген кияргә ярата. Яхъя аның кояшта янган түгәрәк иңбашларына, нечкә сыгылма биленең килешле генә калынаеп китүләренә, шома тез башларына карый да өнсез кала: болар һәммәсе дә аныкы гына, боларга бары тик ул гына кагыла, аларны бары тик ул гына сөя, иркәли ала! Хатыны кибеттә, янсә күршеләрдә (эш турында әйтәсе дә юк) тоткарланса, хәтта сыер саварга яисә кар базына чыгып озаграк кермичә

торса да. Яхъяда ниндидер яшерен шик туа, җаны бәргәләнә башлый. Ул ерак басуга китсә дә, район үзәгендә булса да, кырыкмаса-кырык сәбәп табып, көненә берничә мәртәбә барыбер идарәгә кайта, бухгалтериягә кереп чыга. Гөлзаданың урында утырамы икәненә үз күзләре белән күреп инана. Аның ник болай йөрүен бухгалтериядәгеләр дә. Гөлзада да сизенә, чөнки Яхъя тыныч, салкын булып күренергә тырышкан саен аның күз алмалары ярсулырак сикергәли, хатынының өстәленнән күзләрен читкәрәк борган саен карашы шунда эләгеп кала. Яхъя болай ярамаганын, гомер буе болай яшәп булмаячагын бөтен тирәнлеге белән аңлый, һәркөн: «Моннан соң үз-үземне түбәнсетмим».— дип ант сулары эчә, әмма хатынынан ераккарак китү белән әлеге ант юкка чыга, келт итеп Гөлзада исенә төшә, аның янында бөтерелүче чит ирләр күз алдына килә дә баса... Турысын әйткәндә, шикләнерлек нигез дә бар иде. Күп мәртәбәләр аның янында ир-атларның, бигрәк тә урып-җыю чорына килгән шоферларның җорланып сөйләшүләрен, Гөлзаданың исә аларга кашын-күзен уйнатып утыруларын аз күрмәде Яхъя. Партком секретаре булып Солтанов килгәч, хатыны аның кабинетына керүен дә ешлатты. Боларны күрмәү өчен шыр тиле булырга кирәк иде һәм алар хакында ярым шаяртып Яхъяга әйткәләп, төрттергәләп тә тордылар. Иң аянычы шунда: һәммәсе ачык, күз алдында, ләкин моны берничек тә исбатлап булмый иде. Шуңа күрә Гөлзададан торган саен ныграк көнләште Яхъя, аны торган саен үҗәтләнебрәк саклады. Гөлзада аның бөтен уен били торган тормыш мәгънәсенә әверелә барды. Башка юл юк иде: хатынының бөтен кыяфәтенә, кыланмышына бәреп чыккан әшәке дәртен канәгатьләндерергә ирек бирмәү өчен аны сакларга, әгәр дә инде бу мөмкин булмаса, хыянәтен бөтен кеше күз алдында фаш итәргә кирәк иде. Фаш итү турында Яхъя бүгенге көнгә кадәр уйларга да куркып, сузып килсә, менә хәзер ул сәгать сукты. Нидер бар һәм ул Илһам белән бәйле. Аның шулай буласын Яхъя күп еллар элек шикләнеп көтте, инде онытa башлагач кына шиге раска чыкты. Ни эшләргә? Бу сорауга җавап бирү коточкыч кыен, баш җитмәс нәрсә иде. Тик шунысы ачык: Илһам аның җаныннан да якын, бөтен тормышына, яшәешенә мәгънә бирүче затка кул суза икән. Яхъя һәммәсенә әзер. Ул Илһамны «менә мин кем» дип яшәве өчен баштан ук күрә алмады, аның тормышта беркем сүзенә карамыйча үҗәтләнеп, тискәреләнеп, үзе теләгәнчә атлавына котырды. Яхъяның югары белеме, дәрәҗәсе, киләчәк омтылышлары бар һәм ул шушы өстенлегеп Илһамга һәрчак сиздерергә тырышты, аның үз алдында баш июен теләде. Ә Илһам, юри шуны сизгәндәй, аңа баш бирмәде. Иң хәтәре шунда иде: надан, максатсыз Илһамның үзенә караганда ниндидер бер өстенлеге барлыгын Яхъя яхшы тойды. Ничек кенә уйласаң да, бер нәрсә ачык: ниндидер олы бәрелеш башланып килә һәм ул аларның тормышын моңа кадәр көтелмәгән, билгесез юнәлештә алып киләчәк. Бусы көн кебек ачык һәм инде аңардан котылмак юк иде.

## 2

Дәүләт Хәсәнович кера-керешкә үк сигарета кабызды да йомшак креслосына чумды. Фәһим Солтанов аның каршысына утырды.

— Бер дә күңелле нәрсә түгел бит әле бу, Фәһим Солтанович. Кешеышанмаслык хәл...

Фәһим уң яклап маңгаена төшкән кара чәчләрен берничә мәртәбә артка сыпырды, ләкин алар тимерчыбык кебек каты, тыңлаусыз иделәр, кабат каш өстеп кытыклап тора башладылар. Ул чалбар кесәсен капшады — тарагы өйдә калган иде.

— Ник дәшмисез? — диде Биккинин эчкә алган төтенен авызыннан чыгаргач.

— Мин ни әйтим? Кешеләрне сез яхшы беләсез.

— Бөтен табышмак та шунда. Илһам малай чактан минем күз алдымда. Аның мин кешегә кул күтәрү түгел, тавыш күтәргәнен дә белмим. Нидер бар монда.

Фәһим председательгә туп-туры караган килеш билгесезлектә утырды. Дәүләт Хәсәновичның киң маңгае буйлап кашлары өстеннән бердәнбер җыерчык сузыла. Ул тирән, һәрчак күләгәләнеп тора, борын турында дулкын кебек аска бөгелеш ясап утә. Соры кашлары гаять калын, ябыштырып куелган төсле. Борын яфракларыннан башланып, авыз читләреннән иягенә кадәр тагын ике буразна ярып төшә. Вак җыерчыклар бөтенләй диярлек юк. Аның йөзе олы хәстәр, җитди мәшәкатьләр белән яшәвен күрсәтә. Бервакыт, Фәһим эшли генә башлаган көннәрдә ул:

— Председатель булганчы мин тавык күкәе кебек шоп-шома идем, битемдә бер генә җыерчык та юк иде,— дип сөйләде көлеп.— Тормыш сабаны йөзгә дә, йөрәккә дә үз буразналарын сызды, ә баштагы чәчләрне төпләп алып бетерә язды.

Фәһим инде күп мәртәбәләр аның йөз чалымнарыннан характерына ачкыч эзләргә тырышып карый, әмма бер генә дә тотрыклы бәйләнеш таба алмаудан гаҗиз кала. Биккининнең йөзе белән эчке дөньясын ниндидер зур нәрсә бик еракка аерып торадыр, аларны бәйләүче, тоташтыручы бер генә җеп тә калмагандыр шикелле.

Ишектә Латыйпов күренде.

— Дәүләт Хәсәнович, Бөгелмәгә кем бара?

— Үзегез хәл итегез.— Биккинин, аның нечкә тавышын куып җибәргәндәй, кулын селкеп куйды.— Әйт әле, нәрсәдән эләгешеп китте Яхъя белән Илһам?

— Әйттем бит инде,— диде Латыйпов үпкәләгәндәй.— Илһамнан аракы исе аңкый иде — бөтен белгәнем шул.

Өчәүләп күпме генә сөйләшсәләр дә, мәсьәләгә бернинди дә ачыклык кермәде. Ул арада өс-башын алыштырган Яхъя да килеп керде. Аның авыз-борыны бераз шешенебрәк киткән, маңгаенда кечкенә генә сыдырылган урыны бар.

— Утыр әле, Хаков,— диде Биккинин йомшак кына. Өчәүләп аңа текәлеп карап тордылар.— Сезнең арада ни булды?

Яхъя сүзсез генә җилкәсен сикертте. Ул, гаепле кеше кебек, карашын аларга күтәрмәде.

— Тора салып китереп сукмагандыр бит инде ул сиңа. Әйткәләшкән идегезме әллә?

— Юк.

Бүлмәдә тынлык урнашты. Биккининнең куәтле насос суыруын хәтерләтеп сулыш алуы гына ишетелеп торды. Аны Солтановның сак тавышы бүлде:

— Әйткәләшү генә димәгән. Кешегә бер сүз дә җитәргә мөмкин.

— Мин аңа бернинди дә авыр сүз әйтмәдем,— диде Яхъя, ниһаять, карашын күтәреп.— Кичтән алар тары чәчәсе басуны культивацияләргә кереп киттеләр. Рашат, Фәргать, ул. Берни юк, басуда сөйләшеп тордык...

Биккинин, сигаретын бармак арасына кыстырган килеш, маңгаен уч-лады. Зәңгәрсу сыек төтен аның пеләш башыннан күтәрелгәндәй күренә иде. Һәркайсы үз уен уйлады. Биккинин моның сәбәбен якынча чамалый. Җепнең очы Гөлзадага барып тоташырга тиештер. Берничә ел элек Яхъяның агарып-күгәреп килеп кергәнен онытмый ул.

— Йә мин, йә Илһам — икебезнең беребез! — дигән иде баш агроном ярсуын тыя алмыйча.

Шул чакта: «И эш өчен яна да соң!» — дип уйлап куйганы хәтерендә Дәүләтнең.

— Буйсынмыйммыни? Буйсындырырбыз аны! — дигән иде ул агрономны тынычландырырга теләп.— Бозылып тора ул механизаторлар...

Ләкин Яхъя тагын да ныграк ярсыды:

— Йә хатын белән без китәбез, йә Илһамны куасыз!

Сораштыра торгач. Яхъя сөйләгәннәрдән шул билгеле булды: Гөлзада белән Илһам яшь чакта йөргәннәр, хәзер менә бер атна инде Илһам идарәгә аның хатыны янына килә.

— Аңа дөрес тугламаган, шуңа килә бит ул,— диде Биккинин.— Минем янга да керде.

Ләкин Яхъяның дәлилләре шул кадәр күп иде. Биккинин үзе дә ышанып бетә язды. Шуңа да карамастан:

— Болар һәммәсе дә шикләнүдән генә, асылда берни дә юк, сиздермә, юк белән даныңны сатма,— дип акыллы киңәшләрен бирде.

Гөлзада белән дә, Илһам белән дә аерым-аерым сөйләшмәкче булды, әмма Яхъя моңа катгый рәвештә каршы килде. Биккинин үз сүзен куәтләде. Яхъя күпмедер вакыт кара коелып йөрде дә тынды. Хикмәт нәрсәдә булгандыр, Гөлзада да шуннан соң җитдиләнеп, хәтта олыгаеп киткән кебек күренде. Илһам да идарә тирәсендә күзгә башка чалынмады. Моны Яхъя председатель сөйләшкәннең нәтиҗәсе дип уйлады, ахрысы, аңа карата ничектер аеруча ягымлы, тыңлаучан булып китте. Тыштан карагандa барысы да әйбәтләнде кебек. Ләкин Биккининнең күңелендә бер сорау һич тә тынгылык бирмәде: ә чыннан да алар арасында яшерен элемтә булса? Мондый нәрсәләрне ходай үзе белмәсә дә, хатын-кыз белә. Чит кешегә әйтеп булмый, беркемгә дә сөйләмәскә ипи тоттырып ант иттергәннән соң, бу хакта ул үзенең хатынына тиште. Мөшәрәфәнең күзләре очкынланып китте, үзе ах-вах килде.

— Синең миңа ах-вахларың өч тиенгә дә кирәкми, шундый хәлне ишеткәнең юкмы? — диде ул, хатынының кубарыла башлаган кичерешләрен туктатырга теләп.

— Яхъяның көнләшә торган гадәте барлыгын ишеткәнем бар, колагыма башка берни дә чалынганы юк,— диде Мөшәрәфәсе.

Мөшәрәфә әйткәч, ышанмыйча ярамый иде. Чөнки ул, күп сөйләшү белән бергә, авылдагы барлык булган һәм булмаган хәбәрләрне түкмичәчми җыя, аларны хәтерендә кирәк вакытында эзләп-нитеп тормыйча алырлык итеп, сүлен-тәмен югалтмыйча, бозмыйча саклый иде. Ләкин Биккинин хатын-кыз психикасындагы анттан югарырак нәрсәләр барын, Мөшәрәфәнең бу кадәр серне күтәреп йөрерлек тәкате юклыгын исәпкә алмаган булып чыкты. Күпмедер вакыт узуга, аның кабинетына Яхъяның нәрсә киеп, ничек хәрәкәтләнеп керүе дә, аларның ниләр сөйләшкәне дә бөтен колхозга таралган иде инде. Биккинин хатынын сүгеп тормады, чөнки моны кем таратканны исбатлау өчен генә дә еллык нервыңны сарыф итәргә кирәклеген яхшы аңлый иде. Ә Яхъя шуннан соң Биккининга карата салкынайды. Әгәр элеккечә караса, бүген барысын да ачыктан-ачык сөйләп бирмәс идемени? Бер авызы пешкәч, өреп каба шул бәндәң. Һәрхәлдә, монда баш бетәрлек нәрсә юктыр. Яхъя көнләшеп берәр ярамаган нәрсә әйткәндер, Илһамга шул җитә калгандыр, дип уйлады Биккинин. Солтановның салмак тавышы аның уйларын бүлде:

— Мин хәзер Шаһзамановны чакыртам,— диде ул.— Бергәләп аңлашырбыз.

Моны ишеткәч, Яхъя урыныннан сикереп торды:

— Үзегез аңлашыгыз. Минем аның белән сөйләшер сүзем юк.

— Тукта әле, Хаков, ничектер килешергә кирәк бит инде.

— Килешергә?!

Яхъя кычкырып җибәрде, аның күзләре очкын чәчеп әле Биккининга, әле Солтановка, әле Латыйповка төбәлделәр.

— Сез мине юләргә санамагыз, Дәүләт Хәсәнович! Болай калдырырга, гафу итәргә? Юк инде! Бу үзеңне аның каршында гаепле итеп тану булыр иде.

— Ә нишләмәкче буласың?

— Берни дә эшләмим. Кайтып керү белән әни милиция бүлегенә шалтыратты.

Биккинин учы белән каты итеп өстәлгә сукты.

— Кыргансыз икән! Булдыргансыз!

— Ә нәрсә? Бүген мине, иртәгә сезне. Шуны телисезмени?

Биккинин урыныннан торып аның каршына ук килде.

— Ярар. Илһам Шаһзамановны утыртып куйдылар, ди. Шуннан колхозда...— Ул чак кына: «Хатының йөрүдән туктаячакмы?» — дип ычкындырмады.— Синең авторитетың артачакмы?

— Әйдәгез, күзгә төтен җибәрмичә генә сөйләшик әле.

Биккинин эченә китереп төрткәндәй туктап калды, әллә Яхъяның сүзләрен туры мәгънәдә аңлап, әллә болай, сигаретын көл савытына атты.

— Аңлашырга кирәк, аңлашырга! — дип дәвам итте ул урынына утырып.— Сез бит бер авылда туып-үскән, бер мәктәптә укыган егетләр. Кырыкка җиттегез, ә акыл ягы чамалы...

—Яхшы киңәшегез өчен рәхмәт, Дәүләт Хәсәнович.

Яхъя эре адымнар белән чыгып китте. Аның артыннан акрын гына Латыйпов та юк булды.

— Шулай да милиция начальнигына шылтыратып карыйк әле, бәлкем эшне зурга җибәрмәсләр.

Биккинин трубканы алып номер җыярга керешге.

— Дөрес эшләмисез, Дәүләт Хәсәнович,— диде Солтанов аягүрә басып.

— Дөрес эшләмим?!

Биккинин үзенә каршы әйтүне бик авыр кабул итә иде. Ул гаҗәпләнү катыш ачу тойгысын яшерә алмады, җыя башлаган номерын ташлап, телефон трубкасын шартлатып куйды һәм урыныннан сикереп торды.

— Ә дөресе ничек була?! Миңа, илле җидене тутырган кешегә, әйтеп бир әле дөресен?!

Солтанов тыныч иде.

— Көпә-көндез аракы эчеп, баш агрономны кыйнауны ансат кына йоммакчы буласыз. Сезнеңчә, моннан да зуррак кешелеклелек юк кебек.

— Алай икән! Шаһзаманов бит синең коммунистың! Шуны беләсеңме?

— Минем бернинди дә коммунистым юк. Сез дә, мин дә, ул да бер партия членнары — бары шул гына.

Биккинин кайтарып бер сүз дә әйтмәде. Секретарьның менә шушылай үйламаганда-көтмәгәндә, гел юктан гына председательне шартлатып тиешле урынына утыртып куюы беренче тапкыр гына түгел һәм мондый чакларда Биккинин дәшми калу ягын карый иде. Солтановның әнә шулай уңайлы форсат көтеп торуы, колхоздагы барлык җитәкчеләр нindидер кичектергесез эшкә дәррәү купкач та аның әле һаман кузгала алмыйча, ашыкмыйча утыруы Биккининнең җен ачуын чыгара. Наряд беткәч, бөтенесе үзләре билгеләнгән участокларына чәчелә, ә Солтанов һаман булмәсендә утыра, кемнедер чакырта, нәрсәдер сөйләшә дә сөйләшә. Берсендә, чәчү вакыты иде, Биккинин түзмәде, партком ишеген ачып җибәрде дә:

— Әле һаман басуга чыкмадыңмыни, Солтанов?! — дип кычкырды.

Ләкин секретарьның моңа исе дә китмәде:

— Менә планлаштырам әле, каян башларга, кемнәрне күрергә.

Хәтер йомгагын сүтә башлау Биккининнең ачуын кабартты, ул инде кискен-кискен сүзләр әйтергә дә әзерләнеп беткән иде. Әмма тәрәзәгә күз ташлау белән телен тешләде. Идарә каршына, сары мотоцикл белән ут өертеп, участок милиционеры килеп туктаган иде. Биккинин Солтановка ялт борылды.

— Хәзер Рәкыйпов безнең янга керә. Бер карарга килергә кирәк.

— Дәүләт Хәсәнович, сез нигә барысын да без генә хәл итәргә тиеш дип уйлыйсыз? Хуҗалык эшләрегез кырылып ята әнә.

Солтановның тавышы шул кадәр тыныч иде, әйтерсең лә сүз кеше язмышы турында түгел, ә бәлки ихатадагы чирле тавыкны чалып ату хакында бара. Колхоз тормышын читтән күзәтеп кенә белүче кешенең үз аршыны шул! Эшне зурга җибәрүнең нәрсәгә китерәсен ул уйлап та

карамый. Биккинин Урмәшнең бригадир ярдәмчесе Мөхәммәтшинне авыл Советы председательлегенә тәкъдим итәргә, ә аның урынына Илһамны куярга планлаштырып йөри иде. «Үзе менәсе баскычны үзе җимерде, мышыкый тәре»,— дип эченнән аны да сүкте. эшне милиция кулына тапшырып, үзе бер читтә калырга ниятләп торучы Солтановны да тиргәде. Ә бит тавыш-тын чыгармаганда, һәммәсе дә ул дигәнчә булачак.

— Соң, туганкаем,— диде Биккинин ялварулы сәер тавыш белән.— Шаһзамановның дүрт баласы, хатыны бар. Колхозда аның кебек эшләүчеләр бармак белән генә санарлык. Без аңа атказанган механизатор исемен алу өчен кәгазьләр дә тутырып җибәрдек бит.

— Казанга китмәгән булырга тиеш әле ул.— диде Солтанов.— Үзем шалтыратып, җибәрмәскә әйтермен.

Алар сүзне төгәлли алмадылар. Рәкыйпов җәһәт-җәһәт атлап килеп тә керде. Ул икесе белән дә кул биреп исәнләште. Биккинин, ярты минут элек кенә ташлаган булса да, авызына тагын сигарет капты. Рәкыйповка да сузды. Ул сирәк тарта иде, биргәч алды һәм саран гына елмаеп:

— Председатель сыйлаганда төтенен сула,— диде.

Биккинин сызган шырпыдан кабызгач, фуражкасын өстәлгә куеп, капитан тирләгән маңгаен кулъяулыгы белән сөртеп алды. Рәкыйпов озынча төз гәүдәле, илле биш яшьләрдәге кеше иде. Аның белән ачыктан-ачык сөйләшеп, бик авыр хәлләрдә дә уртак тел табып була.

— Йә, нәрсә булды сездә? — диде ул туп-туры Биккинингә мөрәҗәгать итеп.

— Хәбәр итәсе дә түгел иде инде.— диде Биккинин.— Әйдә, утырып сөйләшик әле, иптәш Рәкыйпов.

Рәкыйпов утыргач, аның фуражкасын илтеп элде, үз креслосына бармады, капитан янындагы урындыкның артына терсәге белән таянды.

— Күңелсезрәк хәл килеп чыкты бит әле...

— Мин ни булганын беләм. Сәбәп нәрсәдә?

— Менә шунысы сәер шул. Сәбәп юк. Әле яңа гына Хаков белән дә сөйләштек. Бернинди ачу-кычу юк, ди.

— Алай икән,— диде Рәкыйпов сузып.— Ә Шаһзаманов?

— Әле аны чакырырга өлгермәдек.

Капитан Илһам белән төнге сменада эшләүчеләрнең һәм идарә каршында күрүчеләрнең фамилияләрен язып алды.

— Ярый, тикшерербез,— диде ул аягүрә басып.

— Син инде, иптәш Рәкыйпов, эшне зурга җибәрергә тырышма,— диде Биккинин аның фуражкасын алып биреп.— Бу алар арасында бер аңлашылмау гына булырга тиеш. Безнең фикер шундый.

— Ә минем фикерем андый түгел,— диде кинәт Солтанов.— Җәмәгать тәртибен бозучыларга карата законның бөтен катылыгы белән чара күрергә кирәк.— Ул бераз көттереп торды да: — Иптәш капитан,— дип өстәде.

Сез шаяртмыйсызмы дигәндәй, Рәкыйпов аларның икесенә дә сынаулы караш ташлап алды һәм:

— Хәзергә хушыгыз,— дип ишекне япты.

Озак еллар халык белән эшләү тәҗрибәсе Биккининне дөртләп китүдән тыелырга өйрәткән иде. Шулай да эчендәге бик үк ишерә алмыйсың: алган сигаретын бармак арасында әвәли торгач, өзеп чыгарды, аны идәнгә төшереп җибәрде. Аннары графиннан агызып су эчте, калганын почмакта зур агач савытта үсеп утыручы фикус төлөнең төбенә салды. Шунда кулының шактый үк калтыравын тойды.

— Моны ничек аңларга инде, Фәһим Солтанович? — диде ул секретарь белән рәсми сөйләшүгә күчеп.

— Һәркемнең үзенчә фикер йөртергә хокукы бар, дип аңларга кирәк.

Солтанов урыныннан торды, аның калын күзлек пыялалары ялтырап куйды. «Күз алдымнан югал!» — дип кычкырасы килде Биккининнең. Ләкин тыелды, бик хәлсез, ишетелер-ишетелмәс тавыш белән:

— Мин сезне башка тоткарламыйм,— дип кенә әйтә алды.
— Сез мине бернечек тә тоткарлый алмыйсыз.

Солтанов бу сүзләрне дә тыныч әйтте һәм ашыкмыйча гына чыгып китте. Әле алда әллә ниләр ишетәсе, әллә ниләр күрәсе бар икән, дип уйлады Биккинин һәм ахмаклыгы, аңгыралыгы өчен үз-үзен сүкте. Ул бит Солтановны үзе сайлап алды. Райкомның оештыру бүлеге мөдире Фәттахов белән кадрлар резервын кырык мәртәбә актарып чыктылар, кемнәрне генә тәкъдим итмәде ул. Юк, берсе дә ошамады, аңа Солтановны бирегез! Чөнки Солтановның әтисе белән озак еллар бергә эшләделәр. Карусыз, эш өчен дәртләнеп-ашкынып йөри торган кеше иде. Тәкъдим ителгән өч кандидатурадан Солтановны яклап партия җыелышында Дәүләт ике мәртәбә чыгыш ясады, үзенең бөтен тел байлыгын, кайнарлыгын эшкә җикте. Әз генә акылы булса, малаеның әтисенә охшамаганын сизәргә тиеш иде бит ул!

Яңа секретарьның кемлеге эшләвенең беренче атнасында ук күренде. Март аенда азык кысанланды, сөт кими башлады. Һәр ферманы тимер йодрыкка кысып алырга кирәк иде. Биккинин иң кыен фермага үзен, икенчесенә — партком секретарен, өченчесенә авыл Советы председателен беркетте. Фермадан кайтмаска, азыкның ничек эшкәртелүен, улчәп бирелүен, көн тәртибенең үтәлешен, имчәк төпләренең савылып бетүен — кыскасы, бөтенесен контрольдә тотарга, сөтне арттыру өчен кулдан килгәнен дә, килмәгәнен дә эшләргә кирәк, диде ул аларга. Карый Биккинин, үзенә беркетелгән Үрмәш фермасына бер көн барып кайтты Солтанов. Икенче көнне, ни хәлләр бар микән дип Үрмәшкә сугылса, әзе дә юк тегенең. Идарәгә кайтса, күрә Биккинин: Солтанов үз бүлмәсенә стена газетасы редакторларын җыйган. Түзде Биккинин, аларның таралышуын көтте. Аннары секретарьны үзенә дәшеп кертте.

— Үрмәштә ни хәлләр бар? — диде ул берни белмәгәнгә салышып.
— Мин кичә өч фермада да булдым,— диде Солтанов.— Кешеләр белән эшләү җитми безгә.
— Сез Үрмәш өчен җавап бирәсез. Сөт артамы анда?
— Мин колхоздагы барлык участоклар өчен дә җаваплы, Дәүләт Хәсәнович. Ә Үрмәшкә килгәндә... анда сөт кимиячәк. Башкаларында да.
— Моны ничек аңларга?
— Өченче көн ачкан башняны күргәнсездер бит. Сенажыгызның сыйфаты шул кадәр начар...
— Сенажыгызның?!
— Аны мин түгел, сез әзерләгәнсез, Дәүләт Хәсәнович. Турысын әйтүем өчен гафу итегез. Әгәр ул тугыз йөз тонна азык сыйфатлы булса, хәзер безнең эшләр бөтенләй башкача тәгәрәр иде.

Ул чыгып киткәч, таш сын кебек катып утырды Дәүләт. Нәрсәдер булачак иде. Давыл яки яшенле яңгыр киләсе һавада алдан ук сизелгән сыман, ул аның билгеләрен бөтен барлыгы белән тойды.

Ике көннән Солтанов колхоз радиочелтәре аша фермаларда оештыру-тәрбия эшләренең йомшак куелышы хакында бәйнә-бәйнә сөйләде, моңа гаепле партком һәм идарә членнарын да, колхоз председателен дә тәнкыйть утына алды. Аның чыгышын тыңлаганда, Биккининнең пеләш башында адашып калган ак төкләре үрә торды, бөтен гәүдәсе шыбыр тиргә батты. Үзенең кече малае яшендәге кешедән, әле колхозга башы керсә — аягы, аягы керсә — башы кермәгән секретарьдан барлык халык алдында әр ишетү аның өчен үлем белән бер иде. Биккинин кызуланып райкомның икенче секретаре Апукаевка шалтыратты, ярты сәгать буе аңа һәммәсен тезде.

— Шушыларның барысын да колхоз кешеләре тыңладымы? — дип сорады Апукаев.
— Ничек кенә әле!

Апукаев көлеп куйды да:
— Сез иде моны, Дәүләт Хәсәнович, башка беркемгә дә чыгарма-

гыз.— диде.— Солтанов бик дөрес эшләгән. Молодец! Райком исеменнән аңа шулай дия аласыз.

— Сез минем райком бюросы члены икәнемне дә онытмагыз. Сәгыйть Мөбәракович! — дип кычкырды Биккинин.

— Политбюро члены булсагыз да. Солтанов хаклы.— Апукаев бераз тын торды да ачулы тавыш белән бастырып куйды: — Сөт кирәк. Дәүләт Хәсәнович. сөт! Беләсезме шуны?!

Биккинин трубканы куйды...

## 3

Ул тагын ындыр артлап кына кайтты. Аның баягы ярсуы юкка чыккан. гәүдәсе җиңеләеп калган иде. Үзенең кылган гамәленә Илһам һаман ышанып бетә алмый. бу бер минут эчендә күргән кыска төш кебек кенә булды. Шулай да Илһам канәгать иде. чөнки ул үз-үзен җиңде! Элекке кебек уйда. хыялда гына түгел. чын-чынлап җиңде! Ул үзен чиксез көчле итеп тойды бу минутларда.

Илһам юынып алырга булды. Әле кичә генә ягылган мунча җылы. суы да житешле иде. Ул озаклап юынды һәм тәнен өченче мәртәбәсенә мунчала белән ышкый башлагач. аптырап туктап калды. Ничек инде кичә генә мунча кереп. бүген өч мәртәбә уынырга мөмкин? Нишләп соң әле ул үзенең ни эшләгәнен сизми башлады? Нәрсә бу?

Мунчадан соң бакчадагы беседкада утырганда тагын шул сорау туды. Ул бит өйгә керергә. ашарга тиеш иде. Ә менә беседкада утыра. Ниһаять. Илһам соравына җавап тапты кебек: Халисә белән очрашырга теләмәүдәндер бу! Әйе. әйе. хәзер ул тагын зарлана башлаячак. безнең нәселне якын күрмисең. дип үпкә сүзләрен тезәчәк. аларны кичтән үк ишеткәнлектән. Илһамның кабат тыңларга һич тә теләге юк иде.

Кичә әбисе Төрекмәнстаннан кунакка кайткан кызы белән кияве хөрмәтенә мәҗлес җыярга ниятләгән. кичкә ашка әйткән булып чыкты. Иң элек Илһамның әбисенә ачуы килде. Бер авылда яшәп. үзен күреп әйтергә ярамаганмы? Ул бит әле яхшымы. яманмы. кияү кеше. йорт хуҗасы. Хатыны әйдә дигәнгә ияру. ул тегеләй ит. болай ит дигәнгә буйсынып эшләү — Илһам өчен ят эш. Шуңа күрә кичә төшлектә Халисә: «Әни ашка чакырды».— дигәч. ул ләм-мим әйтмәде. Гомумән. кем генә. кайда гына. нинди генә эш кушса да. Илһам каршы да дәшми. «ярар» дип әйткән чагы да сирәк. Ул болай әйбәт түгеллеген дә аңлый. әмма үзен «ярар»ны әйтергә мәҗбүр кыла алмый. Аның бу гадәтен беләләр. Биккинин дә. башкасы да эш кушасы булса. киңәшләшкән кебегрәк итеп әйтергә тырышалар. ул чакта инде Илһам эшкә дәртләнеп. тәмләп тотына. Үзенең берәр җитешсезлеген әйтсәләр. Илһамның ачуы килә. Шуңа күрә эшкә тотынса. ул аны беркем тел-теш тигермәслек итеп үти. Ә шулай да өч кешенең теләгенә ул берсүзсез буйсына. бу өч кешегә ул мең мәртәбә «ярар» дия ала. Беренчесе — әнисе. Ул әйткән сүзне. ул кушкан эшне кечкенәдән үк Илһам изге. мәҗбүри үтәлергә тиешле нәрсә дип санады. Чөнки әнисе тормышның үзе кебек зирәк иде. Икенчесе — Айнур. Малаен Илһам аңлатып бирә алмаслык көчле ярату белән ярата иде. Ата кеше улының бер генә теләгенә дә каршы килә алмый. Әйтик. Илһамның кызып-кызып юнышкан. нәрсәдер ясаган чагы. ә Айнур шахмат уйнарга тели. Ата кеше эһ тә итмичә эшен ташлап шахматка утыра. Айнур ниндидер йомыш белән район үзәгенә барасы бар дисә. Халисәне авырыксынып кына тыңлаган Илһам. малаена дигәндә шатланып риза булыр. Айнур да әтисенең яратуына шундый ук ярату белән җавап бирә. аның һәр сүзен. һәр теләген үтәргә биеп кенә тора. Өченче кеше — Яхъя хатыны Гөлзада иде. Егерме ел элек ул Илһамны шундый итеп үз янында биетте. шундый итеп бөтереп җибәрде. әле бүген дә башының әйләнүдән туктап җиткәне юк...

Шушы өч кешедән башка беркемнең дә әйдәкләвен, кушуын Илһам кабул итми, кай, чакларда киресен дә эшләп куя.

Төрекмәнстаннан кайткан баҗасы Шәһит булмаса, кем белә, бәлкем Илһам әбиләренә барган да булыр иде әле. Баҗасын бер дә өнәми шул. Теге атнада үзләренә ашка алып килгәч тә, Илһам аңардан туеп бетте. Шәһит, өченче класслы шофер булса да, айга мең сум акча күрәве, теләсә эшкә баруы, теләмәсә бармавы, җитәкчеләр белән әшнәлеге, өстәлендә күгәрчен сөтенә кадәр торуы хакында төнге икегә кадәр сөйләде. Әгәр ул Илһамны ничек яшәргә өйрәтмәсә, анысына гына түзеп тә булыр иде.

— Яши белмисең, баҗай,— ди ул елтыр-елтыр килеп торучы симез битен Илһамныкына тери язып.— Син йөзне җәлләп мең таңкәне ычкындырасың. Сез монда бөтенесе алдаганга риза булып яшисез. Ә син үзең алдаш — в… булырсың кеше!

Инде шушы сүзләрне тагын төне буе тыңлап утырыргамы? Юк инде, болай да гарык. Шуңа күрә Халисәне кисәтеп куйды:

— Бүген төнге сменага әйттеләр, ашка үзең генә барырсың.

— Сорарсың,— диде Халисә.— Елга бер мәртәбә сораган кешене эштән калдырмаска әллә...

Иренең дәшмәвен ул ризалык билгесе дип аңлады. Сорады ди! Төнге смена туры килмәгән булса, үзе ялынып басуга чыгар иде әле. Илһам кичке алтыда культиватор такмакчы булды. Ләкин тракторын кузгата алмады: ул кабынды да пырхылдап сүнде, кабынды да сүнде. Илһам моның сәбәпчесе ягулык фильтры икәнен шундук аңлады. Теләсәң дә, теләмәсәң дә фильтрны сүтәргә, насос белән өрдерә-өрдерә чистартырга, юарга кирәк иде. Моны бүген башламавың хәерле, чөнки караңгы төшкәнче барыбер бетереп булмас. Халисәнең кәефен җибәрмәс өчен әбиләргә барырга туры килер, дип уйлады ул. Шул чак Халисә үзе килеп җитте. Аның күзләре яшьле иде.

— Өч елга бер мәртәбә кайткан сеңелемне яратмаган сыман йөри бармыйсың син,— дип мышык-мышык еларга кереште ул.

— Күз яшеңне юкка әрәм итмә,— диде Илһам тыныч кына.

Ләкин Халисә ярсый гына барды:

— Җитәкчеләргә ярыйм дип үләсең инде. Син бит аларга бер сүз дә әйтә алмыйсың, ни кушсалар, шуңа буйсынасың...

Китте, китте!.. Илһамга шушы сүзләр дә бик җиткән иде инде. Ә Халисә тезде дә тезде:

— Сиңа колхоз өстенрәк, безгә караганда колхоз кирәгрәк. Язып-таеп бер нәрсә үтенсәм, шуңа теш-тырнагың белән карышасың.

Илһам башта тракторның әле бер, әле икенче ягына чыгып йөрде. Әмма Халисә аңардан бер тотам да калмагач, җиңнәрен яхшылап сызганды да, моторга менеп, ягулык фильтрын сүтәргә кереште. Болай булгач, төне буе фильтр чистартса чистартачак, әмма ашка бармаячак инде ул. Бервакыт, нишләп тынды бу дип артына борылып караса, хатынынннан җилләр искән. Ул да булмады, Биккинин килеп, колак төбендә бер үк сүзләрне тукыларга кереште:

— Илһам, апай, ничек тә бүген бетереп, төнгә чык инде син...

Бер әйтте, ике әйтте, өч әйтте. Ахырда Илһам түзмәде:

— Дәүләт Хәсәнович, мин тракторны кабызырга да тиеш түгел,— диде.

— Ничек инде ул алай?

— Мотор кызганыч — килеп чыгачак бит. Техник карау срогы үткәнгә күпме вакыт хәзер.

— Чәчү бетсен инде, чәчү бету белән керерсең.

— Мин ул сүзне ишетеп арыдым инде.

— Түз инде, түз.

Биккинин аның аркаларыннан кага-кага юмалады. Аннары Яхъя килеп ашыктыра башлады. Ул китүгә, күзе-башы тонып, баш инженер килеп җитте, бригадир да ахшам күләгәсе кебек каршына басты. «Дөнья-

ның кендеге әллә миңа гына терәлеп калганмы соң, ни булган боларга? — дип ачуланып куйды Илһам. Ләкин ул аларның табаны пешкән мәчедәй чабулауларының, тракторны рәтләп бетереп, басуга юнәлгәнче беркая китмичә сагалап торуларының сәбәбен аңламады, әле моңа төшенгәнче шактый тынгысыз көннәр үтәсе бар иде.

Әйе, бүген Илһамның хатыны белән очрашасы, кичәге үпкә сүзләрен кабат ишетәсе килми иде. Алай дисәң, Халисә фермадан да кайтмагандыр әле. Ник өйгә керми соң ул, нишләп беседкада утыра? Тукта, тукта, ул бит әнисе белән дә очрашырга теләми. Әнә бит инде ничә мәртәбә әнисе чыга күрмәсен дип ишеккә күз ташлап алды. Илһам гаеплеменни? Һәм шунда ниндидер бер нечкә хис аның йөрәген өттереп алды. Илһам аны яхшы аңлады: бу — үкенү иде. Әгәр ул бу эшне эшләмәгән булса, һәммәсе дә искечә калыр, әнисе белән хатыны каршында да, бүтәннәр каршында да җавап тотасы булмас иде. Җавап тотасы?! Нинди җавап? Тагын үзенең җебегәнлеген акларга азаплана түгелме соң ул? Юк, бу адым кирәк иде. Ул ничә мәртәбәләр омтылып карады, көче җитмичә чигенде, шау-шудан курыкты, тыныч яшәү ягын каерды. Һәм шуның өчен үз-үзен тагын йөзенче, меңенче мәртәбәсенә тиргәде...

Капка шапылдавы аны сискәндереп җибәрде. Илһам башын шул якка борды. Биккинин хатыны Мөшәрәфә йөгерә-йөгерә өйгә кереп китте. «Газета-журналларны коймадагы калай тартмада калдыра торган иде, әнинең пенсиясен китергәндер».— дип уйлады ул. Өч минут үтмәгәндер, Мөшәрәфә килеп тә чыкты. Хәзер инде ул Илһамны күрде, иреннәрен матур итеп бөреп, кабат-кабат исәнләште:

— Исәнме, Илһам, исәнме, ару гына ятасызмы, имиилекме?

Башын ия-ия, елмая-көлә, йөгерә-атлый юк та булды. Мөшәрәфә артыннан ук ишектә әнисе күренде. Аның йөзе борчулы иде.

— Улым, син ни эшләдең?! — диде ул, өзгәләнеп.

Илһам шунда гына почтальонның газета-журналлар, хатлар-телеграммалар урынына авылдагы иң соңгы яңалыкларны таратып йөргәнлеген аңлады. Ул әнисенең күз карашы астында башын түбән иде, үзе тагын баягыча гаҗәпсенеп: «Мин гаеплеменни? Ни өчен туры карый алмыйм?» — дип уйлады.

— Борчылырлык нәрсә юк, әни.

— Яхъяга сугуың хакмы? — диде әнисе кисәтүле тавыш белән.

— Ул үзенә тиешлесен генә алды.

Әнисе чал чәчләрен сыпырып куйды, авыр итеп сулады да башын чайкады.

— Безнең нәселдә кешегә кул күтәрүче юк иде әле.

Илһам, зиһенен күпме генә эшләтеп караса да, бер сүз әйтә алмады. Әнисенең йөзе кырысланды, иреннәре җыерылды.

— Әйбәт түгел, улым,— диде ул кисәткәндәй һәм, сынаулы карашын шактый озак төбәп торгач, шул ук сүзләрне кабатлады: — Әйбәт түгел, улым!..

Шулай диде дә өйгә кереп китте. Баягы җиңеллекнең эзе дә калмаган иде инде. Күңелдә бер-бер артлы авыр дулкыннар кубарылды, ул аңлаешсыз бер халәт эчендә калды. Шул чак Халисә эштән кайтып керде. Бакчада басып торучы Илһамга борылып караса да, бер сүз дә дәшмәде, өйгә кереп китте. «Кичә бармаганга үпкәләгән»,— дип уйлады Илһам. Хәзер әнисе Мөшәрәфә китергән яңалыкны сөйләячәк, аннары хатыны күз яшьләре түгәргә керешәчәк... Иң яхшысы — өйгә керергә. Әнисе Илһам барында берни дә сөйләмәячәк. Ул, шулай уйлап, хатыны артыннан өйгә керде. Илһам юынгычка барып кулын сабынлады һәм күз чите белән генә Халисәнең стаканны иснәп куюын күрде.

— Әни, әллә берәрсе булдымы?

— Юк, килен,— диде әнисе, таба белән итле бәрәңгене өстәлгә куеп.— Ник алай дидең?

— Болай гына,— диде Халисә.

— Ашагыз, балалар. Чәй кайнаган.

— Безнең белән утырмыйсыңмыни, әни? — диде Халисә.

— Мин ашадым инде...

Әнисенең тавышы түшенке иде.

— Әни, авырмыйсыңдыр бит?

— Юк, кызым, бераз ятып кына торам.

Әнисе түр якка чыгып киткәч, икесе дә сүзсез генә өстәл янына килеп утырдылар. Әгәр башка чак булса, Халисә иреннән: «Кем белән салдыгыз?» — дип туп-туры сорар иде. Стаканның берәү генә булуы да, Илһамның иртүк салган булуы да аның өчен табышмак иде. Ләкин ул тешен кысып булса да эндәшмичә түзде, Илһамның кичә төнге сменага эшкә баруын кичерә алмады. Халисә ире белән урамнан култыклашып узарга, машинада аның белән янәшә утырып барырга ярата, бергәләп клубка чыгасы, мәҗлестә утырасы килә. Ә мондый бәхетле көннәр сирәк эләгә. Фермадан кичке савымнан кайтканда сигезенче ярты яисә сигез тулган була, язып-таеп эләккән ял көнендә тагын ниндидер көтелмәгән мәшәкатьләр туа. Шуңа күрә кичә Илһамның әниләренә барырга җене белән карышуына Халисә бик нык рәнҗеде. Җитмәсә табын янында Шәһит мыскыллап көлде:

— Үз гомеремдә беренче мәртәбә шундый юләрне күрәм. Әйдәгез, дөньяда юләрләр күбрәк булсын өчен эчик әле! — диде ул, алтынчы рюмкасын кара мыек астына түнтәреп.

Аның сүзләрен барысы да игътибарсыз үткәрергә тырыштылар, ә Халисәнең күкрәгенә ниндидер авыр нәрсә килеп утырды. Һәм менә хәзер, Илһамны күргәч, ул нәрсә тагын үзен сиздерде, Халисәнең күзләре дымланды. Хатынының нинди хәлдә икәнен Илһам, каш астыннан гына караса да, аңлап утырды, аның күңелен йомшарту әмәлен эзләде. Ничек кенә булса да сүз башларга кирәк иде. Ләкин ничек? Таш кыяны җилкә белән күпме генә этсәң дә аудара алмаган кебек, ниндидер күзгә күренмәүче, әмма икесен бер-берсеннән аерып торучы калын стена аша һич үтеп булмый иде.

Шул чак кечкенә капка ачылды һәм авыл Советында җыештыручы булып эшләүче Сәрия күренде. Ул исәнләшеп тә тормады:

— Илһам абый, сине участковый Рәкыйпов чакыра,— диде.

Илһам җавап биргәнче, Сәрия юк та булды. Халисә авызын учы белән каплады, әмма күзләреннән яшь бәреп чыккач, тыелып кала алмады, кычкырып елап җибәрде. Олы шом, хафалану кичәге үпкә-рәнҗешләрне оныттырган иде инде...

Илһам өс-башын алыштырмакчы булган иде дә, бу уеннан кире кайтты. Капка янына килеп җиткәч, ул нишләптер туктап калды. Кояш инде төшлеккә җитә язган, көн матур, күк йөзе зәп-зәңгәр. Колга башына беркетелгән ояның түбәсендә очына-очына сыерчык сайрый. Үз көенә, ашыкмыйча гына җир йөзенә җәй килә. Илһам урамга чыкты һәм, башын аска иеп, ниндидер акрын, сак адымнар белән авыл Советына атлады...

## 4

Рәкыйпов эшне бик тиз тотты. Төнлә Шаһзаманов белән басуда эшләүчеләрне дә, иртән идарә каршында булган кешеләрне дә ярты көн эчендә күреп, сораштырып өлгерде. Ләкин йомгакның очы табылмады. Күпләр, әлеге бәрелешнең сәбәпчесе Гөлзада дип уйласалар да, ул хакта капитанга әйтергә базмадылар. Шулай диярсең, алай булмас. Кулда дәлилләр юк, ә дәлилсез сөйләү — яла ягуга тиң, үзеңне шуның өчен җавапка тартып куюлары да бар. Авылдагы имеш-мимешләрнең барысы да расланмый лабаса. Бәлкем, Гөлзаданың бер гаебе юктыр? Һәм, гомумән, кеше тормышында ни булмас?

Яхъя да хатыны турында ялгышып бер сүз дә ычкындырмады. Югый-

сә ничекләр генә сурәтләп күрсәтмәс иде ул аны! Эчтә кайнаган утның барысын да чыгарырга ярамый шул! Ул чакта Илһамның сугуы шәхси төс кенә алачак, ул аларның арасына инде ачыктан-ачык, тагын да оятсызрак төстә керә башлаячак иде.

Сүз берләшкәндәй, Илһам да башкаларның күрсәтмәсенә бер яңалык та өстәмәде. Рәкыйпов каршында ул үзен тыныч тотты, кыска, төгәл җаваплар бирде. «Салган баштан сукканмын, ул миннән көлгән кебек тоелды»,— диде. Капитан, төп сәбәпне ачыкламакчы булып, бер сәгать буе аңа төрлечә ачкыч эзләде, барлык осталыгын, тәҗрибәсен эшкә җикте, куркытып та карады, әмма шуннан башка берни дә ишетә алмады...

Илһам кайтты да, өйгә узып тормастан, веранда идәненә мендәр салып ятты. Бередә тыныч, салкынча, рәхәт иде. Бераз йоклап алмакчы булып күзләрен йомды. Ләкин күпме генә ятса да, йокы килмәде, күңеле тынычлыгын тәмам югалтты. Эшне бу кадәр зурга китәр дип ул һич тә фәһемләмәгән иде, төгәлрәк әйткәндә, иртән идарә каршына барганда ни эшләячәген үзе дә белми иде. Яхъя шаркылдап көлмәсә, бәлки сукмаган да булыр иде. Рәкыйпов биргән һәр сорау саен ул үзенең кылган гамәленең эченәрәк керә барды һәм тирәнрәк кергән саен аны яшерергә тырышты. Ул барысын да энәсеннән җебенә кадәр сөйләп бирсә, бәлкем үзен тулаем яки өлешчә аклый да алыр иде. Ләкин бу аклану бүген өчен, хәзерге өчен генә булачак. Яхъя бик күп еллар элек Гөлзада белән Илһам арасына керде, Илһамны кәкре каенга терәтеп, Гөлзаданы үзенеке итте. Яхъя Илһамны эштә дә оятсызларча алдап килгән һәм алдаячак. Ә Илһамның һич тә алданасы, алданган булып каласы килми иде. Шушыларның һәммәсен чыгарып селкесә, Илһам халык алдында кем булып кала? Яхъя тарафыннан гомер буе алданган мескенчәк, ачык авыз булып кала. Бу исем үзеңә генә түгел, балаларыңа, бөтен нәселеңә тагылачак. Ул моңа беркайчан да бармаячак. Гомере буе Илһам үзе хакында кимсетүче, түбәнсетүче сүз әйтергә урын калдырмаслык итеп яшәде, киләчәктә дә шулай яшәячәк! Дөрес, тирәнгәрәк кереп тикшерә башласаң, Илһамны теге яки бу нәрсәдә гаепләп тә буладыр, һәм ул моны аңлый, шуңа күрә үзен еш кына иң мәрхәмәтсез сүзләр белән орыша иде. Әмма ләкин андый олы таләпләр белән бәяли-үлчи башласаң, күпләр кеше буларак җирдән бөтенләй юкка чыгар иде. Шуңа да карамастан, аларга рәхәт: беркайчан да андый үлчәүләр белән эш итмиләр, җаннары да тыныч, исемнәре дә чиста. Ни өчен соң Илһамның исеме аларныкыннан түбән торырга тиеш? Шуңа күрә ул капчык төбен селкемәскә булды.

Бакчадан Халисәнең керүе күренде. Ул башта веранда ишегеннән башын сузып карады, аннары эчкә үтте. Илһам аны күрү белән йоклаганга салышты. Бәлкем чыгып китәр дип уйлады ул.

— Йокламаганлыгың күренеп тора, Илһам.

Илһам күзләрен акрын гына ачты, хәрәкәтләнмичә чалкан ята бирде. Төрле уйлардан чигә тамырлары сулык-сулык типсә дә, тыныч күренергә тырышты:

— Нәрсә бар?

Әйтерсең, берни дә юк, берни дә булмаган. Аның тавышы үзенә дә ят булып яңгырады. Гаепле кеше тавышы иде бу. Халисә иренең янына тезләнде, күз яшьләрен сөртте, иреннәрен еларга җаелүдән көч-хәл белән тыеп:

— Ни булды соң? Ник бездән яшерәсең? — диде.

Илһам аны чын күңелдән кызганып куйды, яткан килеш кенә хатынын беленнән какты.

— Борчылырлык берни дә юк. Яхъя белән икебезнең арада килеп чыккан аңлашылмаучылык кына...

— Рәкыйпов ни ди соң?

— Берни дә әйтми, сораштырды...

— Юу-ук...— шушы урында Халисәнең түземе бетте, ул тагын елап җибәрде һәм өйгә кереп китте. Димәк, халык сөйләгәннәр дөрес, Яхъя

белән тарткалашның килеп чыгуы юкка түгел. Тыштан бу нәрсә аны гомер буе борчып торса да, Халисә иренең хыянәтенә эчтән һаман ышана алмый, шуңа күрә көнләшүен Илһамга, күпме яшәп, сыңар сүз белән дә сиздергәне юк. Түзде, дәшмәде, һәм менә тагын... Әгәр Гөлзада янына барып, үзе белән генә сөйләшсәң? Безнең дүрт балабыз бар, гаиләбезне җимермә, дисәң? Юк, алар арасында ниндидер элемтә барлыгы кире кагылмаслык расланса да, Халисә бу түбәнлеккә төшмәячәк. Әгәр әйткәч кенә туктала торган булса, җир йөзендә хыянәтләр дә, ятимнәр дә, башка фаҗигаләр дә артмас иде.

Кемдер шапылдатып капканы ачты. Илһамның башыннан «Айнур!» дигән шатлыклы уй йөгереп үтте. Әмма керүче ул түгел, Габделхәй иде. Алар ирләрчә каты итеп кул кысыштылар.

— Нинди җилләр ташлады? — диде Илһам аны күрүенә чиксез шатланып.

— Сагындым,— диде Габделхәй елмаеп.

Ул арада Халисә чыгып, аларны өйгә керергә кыстый башлады. Ләкин Габделхәй өйгә керүдән баш тартты. «Үтеп барышым гына, хәзер китәм»,— диде.

— Тегене ишетеп килгәнсеңдер,— диде Илһам, икесе дә баскычка утыргач.

— Ишеттем...

— Соң? — Илһам дустының күзләрен күрергә теләп аңа елыша төште.

Габделхәй кулына ниндидер чыбык алган, шуның белән баскыч буендагы аяк кыргычка үрелеп чарт-чорт суга иде.

— Менә бу кыргыч нәрсәгә? — диде Габделхәй уйчан гына. Һәм үзе үк җавап та бирде: — Яңактагы төкләрне кырырга түгел, пычракны өйгә кертмәү өчен, билгеле.

Шулай дип каты гына селтәнгән иде, чыбык кыргычның үткен йөзенә тигән урыныннан сынып чыкты.

— Хатынның ничә мәртәбәләр сыер сыртына сугып та сындыра алмаган салкын коралын харап иттең,— диде Илһам көлеп.

— Ә менә син нәрсә белән кайда сугарга кирәген генә беләсеңдер,— диде Габделхәй ярым шаярган кебек. Бераз дәшми торгач, җитди итеп өстәде: — Мин сиңа ышанам. Башың урынында...

Габделхәй бүтән берни дә әйтмәде, ә күңелгә шул кадәр рәхәт, җиңел булып китте. Моңа нәрсә сәбәпче? Бәлкем, янәшәңдә аның барлыгын тоюдан йөрәк башкача тибә башлагандыр? Бәлкем, тәртипсез төстә җанны телгәләгән уйлар дустыңның сине аңлавын, сиңа берсүзсез ышануын тоюдан тынып, үз эзләренә төшәләрдер? Ничек кенә булмасын, Илһамның Габделхәйне күкрәгенә кысасы, әллә нинди ягымлы сүзләр әйтәсе килде. Тик каян аласың ул сүзләрне?

— Рәхмәт, Габделхәй,— диде ул һәм шушы ике сүзгә һәммәсе дә сыйган иде.

Бу рәхмәт Габделхәйгә аны түбәнсетмәве, югарыдан киңәш биреп, акыл атып җәфаламавы өчен дә әйтелде.

Их, нинди аерылмас вакытлары бар иде аларның! Яшь чакларны хәзер сагынып искә алырга гына калды. Илһам белән Габделхәйнең дуслашып китүләре очраклы рәвештә генә башланды. Мәктәптә укыганда алар аралашмадылар. Ник дисәң, Габделхәй Илһамнан ике яшькә зуррак, берсе югары очта, икенчесе түбән очта яшиләр, шуның өстенә Габделхәй ут борчасы кебек җитез, ә Илһам акрын, аз аралашучан иде. Габделхәй армиягә ике ел соңарып китте, кайтканда алар Илһам белән Бөгелмә вокзалында очраштылар, бертуганнар кебек кочаклашып күрештеләр. Район үзәгеннән Үрмәшкә йөк машинасы тартмасында кайттылар, Габделхәй юл буе сузып-сузып җырлады. Тау башыннан Үрмәш күренү белән Габделхәй, кабина түбәсен төеп, машинаны тукатты.

— Ни булды? — дип сорады Илһам гаҗәпләнеп.

— Авылны тау башыннан бер рәхәтләнеп карыйк әле,— диде Габделхәй.

Шофер көлемсерәп баш чайкады да кузгалып китте. Алар узган елгы кылганнар, әби чәчләре җилфердәп торган тау түбәсенә янәшә утырдылар. Май ахырлары иде, туган җир күздән яшьләр китерерлек булып сагындырган иде. Әнә авыл, әнә Сәрдәле әрәмәләре, вак күлләр белән нәкышьләнгән Чәчмәле болыны. Әнә уралып-уралып агучы зәңгәр Ык, аңа килеп кушылучы Казлы. Үрнәк белән Үрмәш арасындагы шомыртлык ап-ак чәчәккә күмелгән, әйтерсең лә, яшел болын өстенә ак кар китереп өйгәннәр...Шомыртлыктан ерак түгел, Акчарлак күле. Болар һәммәсе дә зур бер тәлинкәгә төшерелгән бизәкләр кебек, уч төбендәгедәй җәйрәп яталар һәм акрын гына синең тирәңдә әйләнәләр кебек. Баш өстендә иң биеге — кояш, аннары тау түбәсендә утыручы Габделхәй белән Илһам, аларның ике чемоданы. Габделхәй шушы биеклектән һәммәсенә дә барып ирешсен, бер генә куак та, бер генә үлән дә ишетми калмасын дигәндәй, аягүрә басып җырлап җибәрде. Аннары Илһамга:

— Минем шушы тау битендә алма бакчасы үстерәсем килә,— диде.— Көч житәрме икән?

— Ник җитмәсен! — диде Илһам чын күңеленнән.— Сугышка кадәр ат белән су ташып та бакча үстергәннәр бит әле.

Әйе, Үрмәш кешеләре бу тау битләрендә күкрәп утырган алма бакчасы турында хәзер дә сокланып сөйлиләр иде. Юкка гына тауны Бакча тавы дип йөртмиләр бит.

Габделхәй күзләрен еракка төбәп тын калды, аннары тирән итеп сулады да:

— Илһам, әйдә мәтәлчек атабыз! — диде.

Үзе, Илһамның җавабын да көтмичә, мәтәлчек ата-ата түбән тәгәрәде. Илһам да аңа иярде. Рәхәтләнеп көлештеләр, нәкъ малай чактагы кебек булып китте. Киемнәрен каккалап, чемоданнарын алырга менгәндә Габделхәй туктады да:

— Минем бакча турындагы уем икебезнең сер булып калсын,— диде.— Беркемгә дә әйтмәскә сүз бирәсеңме?

Җавап урынына Илһам аның кулын кысты. Шул көннән алар дуслашып киттеләр. Тик Габделхәйгә Бакча тавында алмагачлар үстерергә генә насыйп булмады...

Алар икесе дә шофер иделәр. Колхозда автомашина булмаганлыктан, «Сельхозтехника»да эшләп йөрделәр, яңадан авылга кайттылар, механизаторлар мәктәбендә укып, тракторчы булдылар. Ә бераздан Габделхәй читтән торып бакчачылык техникумына укырга керде. Аның ни уйлаганын Илһамнан башка беркем дә белмәде. Укуын бетергәч, ул алма бакчасы үстерү теләге турында колхозның отчет җыелышында сөйләде. Аны яклап чыктылар, бакча ясарга дигән карар кабул ителде. Ул карардан соң тагын ике ел вакыт үтте. Габделхәйнең районда кермәгән оешмасы, язмаган җире калмады, ахырда аны, трактордан алып, бакчачы итеп билгеләделәр. Ул үзенә бирелгән үшән генә карт алаша белән кыш буе тау битенә имән баганалар, киртәлекләр ташыды. Озын җәй буе берүзе чокыр казып баганалар утыртты, шикмәлекләр әзерләде. Кайдадыр Башкортстандагы бер питомникка барып, күз утырту өчен алмагач үсентеләренә заявка биреп кайтты. Ләкин күз күне бер төп үсенте дә бирмәделәр. Чөнки Габделхәй артыннан ук кемдер, колхоздан килеп, ул заявканы кире алган булып чыкты. Габделхәй бу хакта партҗыелышта ярсып сөйләде. Аңардан соң трибунага чыккан Яхъя Хаков бакча оештыру эшенең баштан ук уйланып җитмәгәнлеген дәлилләргә кереште. Туфрак составының ярлылыгы, уңыш алыйм дисәң, коточкыч күп ашлама кертергә кирәк булачагы, шунлыктан бакчаның үзенә тотылган чыгымнарны берничек тә капламаячагы, колхозга зыян гына китерәчәге хакында сөйләде. Сыер саварга да кеше җитмәгәндә, бакчага каян эшче көч табарбыз дигән мәсьәлә дә кузгатылды. Җыелышта фикерләр аерылды, мәсьәләне идарә утырышына

кертергә тәкъдим иттеләр. Идарә утырышында Биккинин туп-туры болай диде:

— Кемнәр икәнен әйтеп тормыйм, район башлыкларының шактый зурлары шушы бакча өчен соңгы чәч бөртегемне агарттылар. Итең белән сөтеңне, икмәк белән чөгендер планнарыңны үтәсәң, кем синнән алма сорый, ник кирәк ул, тау битендә көтү йөртсәң дә файда, диләр.

Утырыштагылар Биккининнең бу сүзләренә барыбер егылып төшмәделәр. Ахырда ул болай диде:

— «Колхозыңның дәүләткә бер миллион чамасы бурычы булган килеш тагын капчык-капчык акчаңны тау башына алып менеп җилгә очырасыңмыни?» — дип орышалар...

Моңа каршы утырыштагылар:

— Башка колхозларның бурычы дүрт-биш миллион әле, бакчаны туктатмаска кирәк,— диделәр.

Ләкин карга теләге белән кар явамыни? Алар әйтте, эшче көч тә, акча да, кирәк-яраклар да бирелмәде. Габделхәй тагын райком, район Советы башкарма комитеты юлын таптарга керешә һәм хәйран калды: элек аңа хәер-фатиха биргән кешеләр хәзер шул ук итагатьлелек белән ашыкмаска куштылар, мәсьәләнең бар ягын да үлчәп, тагын бер мәртәбә уйларга, киләчәккә карап фикер йөртергә өндәделәр. Габделхәй үзенең бернигә дә ирешә алмаячагын аңлагач, хатынының күз яшьләре белән ялваруына карамастан, колхоздан чыгып китте. Ул чыгып китү белән бакча баганаларын трактор белән суыртып колхоз ихатасына ташыттылар. Габделхәй бик ерактагы ниндидер бакчачылык хуҗалыгына эшкә урнашты.

Илһам дустының эчке халәтен бик яхшы аңлый, аның күзләреннән элекке тиле дәрт белән янучы утны күпме генә эзләсә дә таба алмый. Ул ут бит Габделхәйнең үзен генә түгел, аның янында чакта сине дә җылыта иде. Хәзер ул ут юк инде, беркайчан да кабынмаска сүнгән, урынында кайнар көл кебек моң гына калган.

Алар май төненең язгы дымнан, җир парыннан, яшел үлән, яфрак исләреннән куерган һавасын сулап, күктә җемелдәшкән йолдызларга карап шактый утырдылар. Язның килеше, игеннәрнең бердәм тишелүе, чәчмәле болынында да, Ык аръягында да биел печәннең мул булачагы һәм башка шундый нәрсәләр турында бер-берсен бүлмичә, ашыкмыйча гына гәпләштеләр. Халисә верандага чыгып-кереп йөргәндә аларның быдырдавына колак салгаласа да, үзен кызыксындырган бер генә сүз дә ишетә алмады. Габделхәй киткәндә Илһам берни булмагандай тынычланып калган, күңеле урынына утырган иде һәм ул яту белән үлгәндәй йоклап китте.

## 5

Илһам гадәттәгечә эшләп йөрде. Яхъя белән очрашсалар, бер-берсен күрмәмешкә салышып үттеләр. Ул хәзер кешеләрдән мөмкин кадәр читләшергә тырышты, өеннән чыкты да тракторына ашыкты, эшен бетерү белән өенә юл тотты.

Рәкыйпов аларның әле берсен, әле икенчесен чакыртып туйганнан соң, шундый нәтиҗәгә килде: боларның беркем дә белми торган шәхси ачулары бар, әмма ни берсе, ни икенчесе моны әйтергә теләми. Шаһзаманов — колхозның үрнәк кешесе, үз гомеренә эчеп, тәртип бозып йөргәне юк. Шуңа күрә капитан аларны соңгы мәртәбә күзгә-күз очраштырырга булды. Әгәр конфликтның төп сәбәбен әйтсәләр, Шаһзаманов Хаковтан гафу үтенсә, тегесе кичерсә, бәлки эшне иптәшләр судына гына бирермен, дип уйлады ул.

Иң элек Илһам килде. Рәкыйпов тагын барысын да башыннан ахырына кадәр сөйләтте, аңлатма язып бирде һәм кул куйдырды.

Бераздан Яхъя да килеп керде. Алар бер-берсенә туры карамадылар. Рәкыйпов бик гади, үз кеше булып аларның икесенә дә мөрәҗәгать итте:

— Егетләр, соңгы мәртәбә сорыйм: нәрсә бар сезнең арада? Дөресен генә әйтегез әле.

— Берни дә юк,— диде Яхъя.

— Син ни әйтерсең, Шаһзаманов?

— Юк...

— Ул чакта син, Шаһзаманов, Хаковтан гафу үтенергә тиеш буласың.

— Аның гафу үтенүе миңа нигә кирәк?

Әмма шул чак Илһам сикереп торды.

— Гафу?! Анысы булмас инде!

Шулай дип әйтүе кая, шарт борылып чыгып китүе дә булды.

— Шаһзаманов, тукта, ялгышасың! — дип кычкырды Рәкыйпов.

Ләкин Илһам борылып та карамады.

Икенче көнне Рәкыйпов Шаһзамановны чакыртмады, соңгы мәртәбә ачыктан-ачык сөйләшү нияте белән үзе аның янына керде, әмма Илһамнан өч сүз дә ала алмады.

Сорашасы, сөйләшәсе кешеләр беткән иде инде.

Берничә көннән Илһам Шаһзаманов өстеннән җинаять эше кузгатылды, бу хакта партия райкомына хәбәр ителде. Райком каршындагы партия комиссиясе председателе Гарипов коммунист Илһам Шаһзамановның аерым эшен тикшерүне Солтановка йөкләде.

Фәһим Солтанов җитәкчелегендә уздырылган партия тикшерүе югарыда әйтелгәннәргә берни дә өстәмәде. Шаһзаманов эше аның төн йокыларын качырды, тик ул бернинди анык фикергә килә алмады. Нидер бар, аны кемдер белә, ләкин беркем дә әйтми иде.

Бүген ул Шаһзамановны тагын үз бүлмәсенә чакырды. Илһам тыныч кына кереп утырды. Фәһим аның белән бөтен рәсмилекне читкә куеп сөйләшергә теләде. Елмаеп кул бирде, хәл-әхвәлләрен сорашты, шуннан соң гына:

— Илһам абый, әйдә мин партком секретаре, син коммунист булуыбызны читкә куеп, ирләрчә генә сөйләшик әле. Син каршы түгелме? — диде.

— Юк,— диде Илһам, сизелер-сизелмәс елмаеп.

— Алайса бик әйбәт. Эчеңдә таш йөртмә — сөйлә барысын да. Ир сүзе бирәм: әгәр теләмәсәң, икебез белербез дә, шуның белән бетәр, беркемгә дә чыгармам.

Аларның карашлары очрашты. Икесе дә җитди иде.

— Сөйләдем бит инде, сезгә тагын ни кирәк? — диде Илһам.

— Мин язмышыңны җиңеләйтергә телим.

— Әгәр ирләрчә икән, бер сүз әйтсәм, ачуланмассызмы? — дип сорады Илһам, карашын һаман аңардан алмыйча.

— Юк, билгеле.

— Язмыш-язмыш инде ул, Фәһим үскәнем. Син берни дә үзгәртә алмыйсың.

— Нигә үзгәртмәскә? — Фәһим, мин бит әле партком секретаре димәкче иде дә, башта сүз берләшүләрен хәтерләп, тыелып калды.

Илһамның ирен читләрендә ниндидер ачы елмаю чагылып үтте.

— Юк,— диде ул тамак төбеннән чыгучы карлыккан тавыш белән.— Күзлек кигерелгән атның дилбегәсе кемдә — барыр юлы шунда...

Кинәт ул Фәһимнең күзлеген абайлап алды, кыенсынудан бөтен битенең кызышуын тойды һәм сүзен төзәтергә ашыкты.

— Юк, юк, мин сине әйтмим. Күзлекле йөгән турында әйтүем.

— Минем турыда әйтсәң, җиңелрәк булган булыр иде,— диде Фәһим, ничектер сагаеп.— Синеңчә, кемнәргә кигертелә соң ул йөгән?

— Минемчә, барыбызга да. Ә синеңчә?

Фәһим дәшмәде, башын аска иеп утыра бирде. Ул мондый сөйләшү көтмәгән иде. Илһам торып басты.

— Минем эшкә барасым бар иде.

— Барыгыз, Шаһзаманов,— диде Фәһим, үзе дә сизмәстән рәсми эндәшүгә күчеп.

Илһам чыгып киту белән, Фәһим күзлеген салып өстәлгә ташлады, бүлмәсендә кызу-кызу әрле-бирле йөрергә керешә. Көчсезлеге, мәнсезлеге өчен — үзен, тискәрелеге, баш бирергә теләмәве өчен Илһамны сүкте. Бирелә барысы да ансат кына, шома гына котылырга өйрәнгәннәр. Барысы да алдына килеп тезләнгәнне көтә. Юк инде, иске тәртипләр, иске гадәтләрдән бизәргә туры килер, диде Фәһим эчтән ярсып. Бөтенесен гафу итә торган чорлар үтте. Песиемләү булмас! Эшнең кая таба барганын аңлагач, әле син табаны пешкән мәче кебек бөтерелерсең, тик ул чакта соң булыр, дип янады ул Шаһзамановка. Ләкин янаса да, аңа биреләчәк җәзаларны берәм-берәм хәтереннән үткәрсә дә, Шаһзамановның бер мәсьәләдә үзеннән көчле икәнен тою аны айнытып җибәрә иде. Ул көч — Илһам әйтмәгән яшерен сәбәптә...

6

Илһам бөтенләй беркем белән дә сөйләшмәс булды, иреннәре кысылды, йөзенә моңа кадәр күренмәгән кара күләгә иңде. Ул Халисәгә, әнисенә генә түгел, бөтен дөньясына үпкәләде, рәнҗеде. Аннары йокысыз төннәренең берсендә, сызылып ал таң атканда, үзе өчен бик зур ачыш ясады: бу күңелсез хәлләргә, чыннан да, ул үзе сәбәпче икән бит! Аның үпкәләп йөрүләре беркемгә түгел, үзенә икән ләбаса! Гөлзаданы бәхетсез итүче Илһам түгелмени? Әйбәт кенә йөргәндә, араларына Яхъя килеп кергәч, ул нишләп чигенергә, читкә китәргә тиеш иде? Яхъя бит мәҗбүр итмәде, аны Гөлзада белән бергә калдырып читкә китүче Илһам үзе булды. Ә Халисә? Әллә ул иренең йөрәгендә Гөлзада урынын били алмаганын белмиме, гомер буе шуны тоеп яшәмиме? Моңа кем сәбәпче? Илһам. Ә Яхъяга сугуы? Ул гаепле, ләкин бит Илһамның да олы гаебе бар. Ул гаепнең нигезендә әнә шул гомер буе дәвам иткән чигенү, килешү ята. Әгәр Илһам аны таныса, халык алдында үзенең Яхъядан гына түгел, Бәчә Фәргатьләреннән дә түбәнрәк баскычка төшеп китәчәген белә. Юк, ул моны күтәрә алмаячак! Шуңа күрә гаебен танырга көче дә җитми. Әмма эшнең судка, партия җәзасына барып җитүе ихтималы да бар. Бу хакта аны Рәкыйпов та, Солтанов та кисәтте. Илһам яхшы аңлый: ин яхшысы — бөтенесен ачып салып түбән тәгәрәү, аннары, бөтен әшәкелекләрдән, гаепләреңнән котылып, кабат югары күтәрелү, саф исемеңне кайтару. Моны эшләү өчен күп вакыт кирәк, кешеләрнең йөзенә бик озак астан өскә таба, гаепле күз белән карап йөрергә туры киләчәк. Бу хурлыкка озакка түгел, бик азга да түзә алмый ул. Ә суд, җәза? Алары хурлык түгелмени? Илһам уйларының очына чыга алмады, тәмам буталды. Көчсезлеге, җебегәнлеге өчен ул үзен күптән иң түбән баскычка куйган иде инде. Шушыны яшерүе, кычкырып әйтмәве өчен әнисеннән, Халисәдән, Гөлзададан, бөтен авыл халкыннан оят иде. Ул кешеләрнең күзләренә карамаска тырышты, көн саен тагын да тирәнгәрәк, түбәнгәрәк тәгәрәвен тойды. Нишләтсәләр дә эшләтсеннәр — иң гаделе шул булыр, дигән карарга килде Илһам. Аңа хәзер тегеләй дә, болай да барыбер иде.

7

Парткомиссия рәисе Гарипов аерым эшләрнең соңарып каралуы өчен каты кисәтелгән иде. Шуңа күрә ул Солтановка шалтыратып торды. Шаһзамановның эшен киләсе бюро утырышына өлгертергә кушты. Яшь секретарь карыша алмады, чөнки, кемнәр белән генә әңгәмә үткәрсә дә, өстәмә нәрсәләр ачыкланмады, төп сәбәп аракыга кайтып калды. Хәер, бу мөһим сәбәп түгелмени? Авылларда аракы сату инде күптән тукталган

булса да, колхозда эчүчелек белән шөгыльләнүчеләр әле күп иде. Кемнәрдер кайлардандыр юллап аракы таба, ачы бал коя, көмешкә куа... Штрафлар да салына, иптәшләр судларында да тикшереп торалар, башка чаралар да кулланыла, әмма эчүчелекнең беткәне юк. Ул коммунистлар арасында да сизелгәли. Төп бәла шушында иде, әлбәттә. Су башыннан болгана, ди. Әгәр партоешма эчүчелекне бетерим дисә, аның үзендә бер генә эчүче дә булырга тиеш түгел. Шуңа күрә бригада коммунистлары Шаһзамановның персональ эшен карыйсы көнне Солтанов партбюро секретаре Мөхәммәтшинга бу хакта аерып кисәтте.

— Иң югары партия җәзасы — бары шул гына,— диде ул.— Җыелышыгыз башкалар өчен дә зур сабак булырга тиеш.

— Аңладым,— диде Мөхәммәтшин.

Иртәнге нарядка килгәч, ул партком бүлмәсенә керде. Кул биреп күрештеләр.

— Йә, җыелыш ничек үтте? — дип сорады Солтанов.

— Барысы да Шаһзамановны кискен гаепләделәр.

— Нинди җәза бирдегез?

— Җәзасы... каты шелтә... исәп карточкасына язмыйча.

— Шаяртасызмы?!

— Нишләп шаяртыйм ди.— Мөхәммәтшин тикшерү кәгазьләре, җыелыш беркетмәләре һәм карары салынган «эш»не, миңа ышанмасагыз, үз күзләрегез белән күрегез, дигәндәй, аңа сузды.

Солтанов аны карап та тормыйча, ачу белән өстәленә ташлады.

— Сез моның нәрсә икәнен беләсезме?

— Барысы да бер үк сүзне сөйли. Моңа кадәр эчеп йөргәне, тәртип бозганы юк, диләр. Халык контроле төркеме члены.

— Шаһзаманов рәхмәт тә әйткәндер әле, шулаймы?

— Җыелышта ул үзе катнашмады.

— Ничек катнашмады?!

— Үзеннән башка карауны сорады. Кыенсынам, ди. Гаризасын шунда салдым.

Солтанов үзен куяр урын тапмады. Мөхәммәтшин ичмасам уфтансын, көяләнсен иде. Юк бит! Техника буенча бригадир ярдәмчесе булып эшләүче өлкән яшьтәге бу кеше ашыкмый да, акрын да йөрми, күтәрелеп тә бәрелми, таләп тә итә белә һәм шулай булуы белән Солтановка ошый да иде. Әллә гомер буе кыяфәтенә китереп, җайлап-майлап яшәгәнме?

— Ә сез, партоешма секретаре буларак, җыелышка нинди юнәлеш бирдегез?

— Сөйләшкәнчә инде. Тик барлык коммунистлар да: ялгышкан-төзәлер, диделәр. Бертавыштан каты шелтә...

— Ә сез?

— Нәрсә мин?

— Каршы тавыш бирдегезме соң?

— Юк.

— Кичә минем фикер белән килешкән идегез кебек.

— Җыелышта бит фикерләр үзгәрү мөмкин. Шуның өчен дә җыелыш ул. Аннары мин Илһамны бик яхшы беләм.

Солтанов аңа кабат бер сүз дә әйтмәде, чыгарып җибәрде. Хәзер сөйләшүдән ни файда? Кичке алтыга партком утырышы билгеләнгән иде. Солтанов үз-үзен ашады. Парткомиссия председателенә шалтыратып, бригада коммунистларының либераллык күрсәтүләре хакында әйтергәме? Ахырда аны бу адымыннан нидер тыеп калды, әгәр Гарипов үзе шалтыратмаса, аңа әйтмәскә булды. Партком утырышының җыелыш карарын үзгәртәчәгенә ул аз гына да шикләнмәде.

Кичке бишләрдә аның бүлмәсенә Шаһзаманов килеп керде. Аны кырынмаган, юынмаган, тузанлы эш киемнәрендә күргәч, Солтанов ни әйтергә дә белмәде.

— Сез нәрсә, Шаһзаманов, партком утырышына мондый кыяфәттә

килдегез? — диде ул, ачуын яшерә алмыйча.— Үзегезне хөрмәт итмәсәгез, партком членнарын санга сугар идегез.

— Мин... гариза китергән идем.

— Нинди гариза ул тагын?

— Үземнән башка гына карагыз.

Илһам костюм кесәсеннән алып аның өстәленә дүрткә бөкләнгән кәгазь куйды. Солтанов, аны укып тормастан, кул кыры белән читкә этте.

— Персональ эшегезне тикшергәндә читтән генә карап йөреп, җәзадан котылырга исәпләвегез белән бик нык ялгышасыз, Шаһзаманов,— диде секретарь кырыс рәсмилек белән.

— Мин котылырга теләмим.

— Кичә партия җыелышыннан качкансыз. Бүген партком утырышыннан.— Солтанов, өстәл артыннан чыгып, аның каршына ук килде.— Гаебегез ачылудан куркасыз. Шулаймы?

Секретарьның сүзләрендә хаклык бар иде, әлбәттә.

— Оят миңа,— диде Илһам.

— Утырышта катнашырга кирәк,— диде Солтанов бераз йомшап.— Бүген сезнең партиядә калу-калмавыгыз хәл ителәчәк. Сезгә барыбер түгелдер ич?

Илһам дәшмәде.

— Барыгыз, өс-башларыгызны алыштырып килегез.

— Үзегез генә...— диде Илһам һәм ишеккә атлады.

— Шаһзаманов, бу гаризагыз сезгә кыйммәткә төшәргә мөмкин,— диде Солтанов аның артыннан.

Илһам борылып карамады, сүзсез генә чыгып китте.

Солтанов, хәтере калса да, аның өчен борчылды, килер дип көтте. Алты тулды — Шаһзаманов килмәде. Тагын биш минут көткәннән соң, Солтанов утырышны ачык дип белдерде. Көн тәртибен әйтүгә, Биккинин:

— Шаһзаманов кайда соң? — дип сорап куйды.

— Аның гаризасы бар. Эшне үзенең катнашыннан башка карауны үтенә. Кичә,— дип дәвам итте Солтанов,— бригада партоешмасында Шаһзамановның персональ эше каралды.

Ул җыелышның Шаһзамановка теркәү карточкасына язмыйча каты шелтә белдерелүе хакындагы карарын укыды. Бүлмәдә авыр тынлык урнашты. Солтановның сүзе бетмәгән иде әле:

— Мин, бүгенге утырышны алып баручы буларак, алдан ук әйтеп куям: бригада коммунистлары эшне тикшергәндә либераллык, принципсызлык күрсәткәннәр. Шаһзаманов иртүк аракы эчә, идарә каршында бернинди сәбәпсез колхозның баш агрономын кыйный башлый. Кайда күрелгән хәл бу? Узган ел шул ук Үрмәштә дүрт ай буе взнос түләмәгән Галимовның персональ эше карала. Аңа да шелтә бирү белән чикләнгәнсез. Әгәр без бу юл белән барсак, партия дисциплинасыннан ни калыр? Массаларга нинди үрнәк күрсәтербез? Нинди тирән үзгәрешләр чорында яшәвебезне дә онытмыйк. Шуңа күрә мин, партком членнары бүген бу шәхси эшне устав куйган иң югары таләпләрдән чыгып тикшерерләр, дип уйлыйм.

Солтанов урынына утырды. Кемдер авыр сулап куйды, кайсыдыр, идәнгә кыршып, урындыгын күчерде. Аннары тып-тын калдылар. Биккининнең сулыш алуы гына ишетелеп тора иде.

— Йөгез, иптәшләр, озынга сузмыйча, конкрет фикерләрегезне, тәкъдимнәрегезне әйтегез. Кем беренче?

Солтанов күзлек аша барысына да карап чыкты. Ә күбесенең карашы Биккинində иде. Мондый кыен чакларда аның беренче булып чыгыш ясавына күнеккәннәр, арбаның алды каян китсә, арты да шуннан тәгәри. Ул салган юлның ышанычлы икәнен, үзгәрмәгәнлеген беләләр.

— Мин берничә сүз әйтим әле...

— Рәхим итегез, Дәүләт Хәсәнович.

— Миңа Шаһзаманов эше буенча чыгыш ясау икеләтә кыен,— диде Биккинин авыр сулап.— Чөнки партиягә кергәндә аңа рекомендация бирүчеләрнең берсе идем. Аның ышанычны аклавына һәрвакыт инанып йөрдем. Ләкин кешеләр без уйлаганнан катлаулырак, күрәсең. Шаһзамановның да безгә беленмәгән яклары бар икән. Хулиган коммунист кем инде ул? Бу бәрелешнең иң хәтәр ягы — партоешмабызга тап төшерүдә. Аның җыелышта да, партком утырышында да катнашырга теләмәве бик сәер.— Ул бөтен гәүдәсе белән Солтановка таба борылды.— Бу турыда үземә алданрак әйткән булсагыз, ничек тә күндергән булыр идем. Беребезгә дә сер түгел, моңа кадәр партия тормышы нормалары белән сыешмый торган күп кенә нәрсәләр гафу ителеп килende. Ә хәзер — юк. Үрмәш коммунистларының бу шәхси эшне тикшерүенә секретарь биргән бәя белән тулысынча килешәм. Алар чыгарган карарны үзгәртергә һәм Шаһзамановка исәп карточкасына язып каты шелтә белдерергә кирәк. Тәкъдимем шул.

Солтанов Биккининнән моны көтмәде. Нәкъ менә ул бернинди ташлама ясамыйча чыгыш ясарга һәм иң югары җәза бирүне сорарга тиеш иде. Нишләп алай булып чыкмады соң? Әллә бу либераллыкның башы аңардан киләме? Баш зоотехник Насыйбуллинның тамак кыруы аның уйларын бүлде.

— Миндә, Фәһим Солтанович, сезгә бер сорау бар иде,— диде ул.— Шаһзаманов белән Хаков арасында булган бу күңелсез хәлнең төп сәбәбе ачылып беттеме?

— Игътибар белән тыңласагыз, һәммәсен җентекләп аңлаттым. Алар икесе дә араларында берни дә юк диләр. Исереклектән башка нинди сәбәп булырга мөмкин?

Насыйбуллин авыз эченнән генә:

— Аракының сырты калын,— дип мыгырданды.

— Ике генә авыз сүз әйтергә булырмы?

Бу — Үрмәш фермасы сыер савучысы Фәхринурова иде.

— Әйдәгез.

— Мәсьәлә монда аңлаешлы бит,— диде ул тавышына гадәттәгечә күңелендәге барлык кичерешләрен салып.— Мин синең фикерең белән гел килешмим, Биккинин абый. Авылда кем якалашмаган да, кем сугышмаган инде ул? Шундый шәхси аңлашылмаучылык өчен коммунистларның партия билетын пычрата башласак, ни булыр? Әле кайчан гына шул ук хөрмәтле баш агрономның хатыны кара янган күз белән йөрмәдемени?

— Сез, Зәнфирә сеңлем, керергә хакыгыз булмаган һәм үзегез белмәгән җиргә тыкшынмасагыз, яхшырак булыр.

Кисәтүле, әмма тыныч тонда әйтелгән бу сүзләр мәктәп директоры Әнисә Нәҗиповна Хакова тарафыннан әйтелде.

— Мин белеп сөйлим, Әнисә апа.

— Белмисез,— диде Хакова тавышын күтәрә төшеп.— Үкенергә, хәтта барлык коммунистлар алдында Яхъядан гафу үтенергә туры килүе бар.

Утырышның болай кара-каршы әйткәләшүгә китүе Солтановның ачуын кабартты. Бу очракта Хаковага сабыр итәргә кирәк булгандыр да бит. Чал чәчле, йөзен вак җыерчыклар каплаган мөлаем йөзле бу ханымны Солтанов күптән белә, директорлар киңәшмәсендә аның, кемнең кем булуына карамастан, йөзенә бәреп тәнкыйтьләгән чыгышларын тыңлаганы бар. Ул аңардан әллә курка, әллә кыенсына, әллә артык хөрмәт итә, ничек кенә булмасын, Әнисә Нәҗиповна янәшәсендә чакта каушап кала иде. Секретарь, кисәтсәң дә, туктатсаң да, килешеп бетмәс, үзләре туктарга тиеш, дип утырган арада әйткәләшү дәвам итте:

— Курыкмагыз, Әнисә апа. Яхъяның ни өчен сукканы да билгеле. Без авылда яшибез.

— Анысы хак. Бу сезнең кешенең шәхси тормышына бернинди рөхсәтсез кереп баруыгызда үк күренә.

Биккинин Солтановка, утырышны алып бар, дигәндәй ым кагып куйды.

—Иптәшләр, әйдәгез, кем сүз алган шул кеше генә сөйләсен әле.

Әмма секретарьның кисәтүе һавада нәтиҗәсез асылынып калды.

— Без, укучыларыгыз булсак та, культуралы халык түгел инде, Әнисә апа.

— Элекке укучыларыгыз диегез.

— Ярар, элекке булыйк. Улыгыз Яхъя хәзерге бит,— диде Фәхринурова аның йөзенә туп-туры карап.— Аңа да исәп карточкасына язып каты шелтә тиеш. Хатынына кул күтәргән өчен.

Бу сүзләр Әнисә Нәҗиповнаның йөрәгенә барып кадалды һәм ул тыела алмады, сикереп үк торды:

— Фәһим Солтанович! Биредә кемнең шәхси эше тикшерелә: Шаһзамановныкымы, әллә аның тарафыннан кыйналган Хаковныкымы?

Түземе тәмам беткән Солтанов та аягүрә басты. Хәзер алар өчәүләп басып торалар иде.

— Бәлкем барыбызга да басаргадыр? — диде ул һәммәсенә караш ташлап.

Кемдер пырхылдап куйды. Әнисә Нәҗиповна әрнүен кичек яшерергә белмичә урынына утырды һәм башын түбән иде.

— Сезнең конкрет тәкъдимегез нинди, иптәш Фәхринурова?

— Мин тәкъдимемне кичәге җыелышта да әйттем, бүген дә кабатлыйм: шелтә белдерү белән чикләнергә. Әэчүенә килгәндә... Ник инде күпертергә? Эчкәндә генә кыюлыгы арта, теле ныклап чишелә бит аның. Сөйләшәсе килгәндер дә, артыграк киткән инде.

Берничә кеше җиңелчә генә көлешеп алды. Фәхринурова утыруга Әнисә Нәҗиповна сүз сорады, торып басты һәм:

— Киләчәктә гел сөйләшеп кенә торасы килмәсә ярый ла,— дип куйды.

Бу юлы бүлмәдә бердәм көлү яңгырады. Тик Солтановның гына йөзе үтә җитди иде.

— Гафу итегез, Әнисә Нәҗиповна, бер генә минутка,— диде ул Хаковага урынына утырырга ишарәләп.— Мин, күрәсең, сезгә аңлатып җиткерә алмаганмын. Беренчедән, партиянең эчүчелеккә каршы үткәрә торган сәясәтен, бу юнәлештә күрелә торган чараларны санап чыгу кирәкме? — Ул пауза ясады, беркем дә дәшмәде.— Сез аларны беләсез. Белгәч, шушы факт үзе генә дә Шаһзамановны партия политикасына каршы куя. Икенчедән, ул үзе кебек үк КПСС членына кул күтәрә, аннардан гафу үтенүдән баш тарта. Өченчедән, персональ эшен тикшергәндә катнашуны кирәксенми. Һәм соңгысы: аның өстеннән җинаять эше кузгатылды.

Солтановның чыгышы күпләрне сагайтты. Биккининнең маңгаена тир бәреп чыкты. Әйе, зур хата китте. Ул бит әле райком бюросы члены да. Әгәр хәзер партком утырышы Шаһзамановны партиядән чыгарса, Биккинингә йә үз тәкъдимен ахыргача яклап каршы тавыш бирергә туры киләчәк, йә булмаса тизрәк аңардан баш тартырга кирәк. Ике очрак та хурлыклы һәм ул ике начарның берсен сайларга мәҗбүр иде. Биредә Шаһзамановны партиядә калдырган очракта райком бюросы членнары Биккинингә ни әйтер? Яхшы диярләрме, әллә шул ук либераллыкта, бүгенге көн бурычларын аңламауда гаепләрләрме? Үз фикереңне беркемнән бәйсез рәвештә якларлык көч бирүче булса икән тормышта!

Ниһаять, Әнисә Нәҗиповна сөйли башлады:

— Минемчә, мәсьәлә ачык. Рекомендация биргәндә, Дәүләт Хәсәнович, сез дә ялгышкансыз, Шаһзамановны партиягә алганда без дә ялгышканбыз. Әгәр хәтерегездә булса, мин аны кабул иткәндә пассивлыгы өчен тәнкыйтьләгән идем. Шул чакта аның үз-үзенә бикләнүе, астыртынлыгы турында да әйтмәкче булдым, ләкин әдәп саклап, тыелып калдым. Ә тыелырга кирәк булмаган. Мин ике генә дәлил китерәм. Мәктәптә укыганда, җиденчедәме, сигезенчедәме икән, ачык хәтерләмим, дәрес вакы-

тында ул класс тәрәзәсеннән чыгып качты. Дәрескә юньләп әзерләнмәгәне өчен иптәшләре алдында кызартмакчы булып ике сүз әйтү ярамады. Армиядән кайткан елны клубта Фәргатьнең кулын кем чәрдәкләде? Шаhзаманов. Хәзер менә бусы. Сез ничек уйлыйсыздыр, аның эчендә без күрмәгән, яшерен, бөтенләй ят кеше утыруына шигем юк. Иң хәтәре — Шаhзаманов бит ачыктан-ачык түгел, ә бәлки сездермичә партия политикасына каршы эш итә, коммунистның әхлак кысаларыннан чыга. Мондый кешене мин партия сафларында калдыру мөмкин түгел, дип саныйм.

Әнисә Нәҗиповна утыргач, крахмалланган кулъяулыгын битенә тигереп-тигереп алды, авыз тирәләрен сөртте. Беркем дә сүз сорарга батырчылык итмәде, шактый вакыт узды. Аннары ул басмыйча гына hәм беркемгә дә карамыйча болай диде:

— Киленнең күзе нишләп күгәрүе белән кызыксынучылар булса, өйгә килсеннәр. Кайда, ничек бәрелгәнен аңлатырбыз.

Чәчрәп чыгып сөйләргә ашыгучылар юк иде. Солтанов: «Ягез инде, кыюрак»,— дигән ялварулы караш белән партком членнарына карады. Шунда Биккинин торып басты.

— Әгәр мөмкин булса, мин тәкъдимемне кире алыр идем...

Ул авыр сулады, кулындагы авторучкасын шыкылдатып өстәлгә ташлады, аны полировка өстендә тыз-быз әйләндерергә кереште. Нидән, ничек алып китәргә белми иде ул. Бөтенесенең игътибары үзенең ручка әйләндерүенә юнәлгәнен абайлап, аны тиз генә кесәсенә салды.

— Беләсезме... Шундый кешеләр була, аларга hич тә каты бәреләсе килми. Шәхси симпатия димме... Мин, күрәсең, әнә шул тойгыга биреләдем. Әнисә Нәҗиповна чыгышын тыңлагач, иптәш Солтанов та әйткәч, партком членнарыннан оялып куйдым. Юк, без Шаhзамановны партиядә калдыра алмыйбыз икән, иптәшләр.

Биккининнән моны көтмәгәннәр иде, кемнәрдер быдырдап сөйләшә башлады, Фәхринурованың: «Кешене харап итәбез, шул гына»,— дигән сүзләре ишетелде, кемдер ютәлләде, кемдер тамак кырды. Аннары Габделхәй торып басты.

— Барыгызга да мәгълүм булганча, Илhам минем иң якын дустым,— дип башлады Габделхәй hәм фикерен туплый алмыйча берничә генә секундка туктап калды.

Аның туктавыннан баш зоотехник Насыйбуллин бик оста файдаланды:

— Шулай булгач, синең аны яклаячагың сөйләмәсәң дә билгеле бит,— диде ул кәефле кеткелдәп.

Габделхәйне бу сүзләр каушатмады, киресенчә, аның күзләрендә усал очкыннар кабынып китте.

— Әйе, дустыңны яклый алмасаң, дус булып йөрергә дә кирәкми,— диде ул Насыйбуллинга таба кулын селтәп.— Дәүләт Хәсәнович кебек, рекомендация биргән кешең турындагы чын фикереңнән баш тарту да егетлек түгел...

Биккинин аңа: «Син, Низамов, башта үз фикереңне әйт әле»,— димәкче иде дә, авызы ачылмады, башын иеп утыра бирде.

— Мин бер генә нәрсә әйтәм: әгәр Илhам кебек кешеләрне партиядән куа башласак, ни булыр?

Бу сүзләргә Солтанов үзе дә түзеп кала алмады, чыгыш ясаучыны бүлдерде:

— Сез партиянең эчкечеләргә, хулиганнарга каршы килешмәүчән көрәш алып барырга тиешлеген онытмагансыздыр бит?

— Онытмадым, иптәш Солтанов,— диде Габделхәй.— Хикмәт шунда, Илhам эчкече дә, хулиган да түгел. Моның шулай икәнлеген монда утыручылар барысы да әйбәт белә. Намус-вөҗданга кагылсак та, күпләребезгә аңардан үрнәк алырга кирәк әле.

— Сез дисталәгән кеше алдында булган фактны кире кагарга җыенмыйсыздыр, шәт? — диде Хакова.

— Җыенам,— диде Габделхәй.
— Кызык! Ничек итеп?
— Белмим,— диде Габделхәй кулларын җәеп.— Кайчакта дәлилләрне читкә куеп торырга кирәктер. Әйе, Илһам ялгышкан. Тик, ни генә әйтсәгез дә, ул тормышның иң алдында бара торган кеше. Аңа теләсә кайчан таянып та, ышанып та була. Кыскасы, мин бригада җыелышы карары яклы.
Габделхәй утыруга Насыйбуллин сүз сорады. Баш зоотехник Биккининнең беренче чыгышыннан ук сүз алмавына сөенеп туймады. Ул күп еллар бергә эшләү дәверендә һәр нәрсәнең председатель әйткәнчә булачагына күнегеп беткән. Партком секретаренең Биккинин тәкъдимен тәнкыйтьләве аны өркетеп куйган иде. Димәк, аларның фикере аерыла. Насыйбуллин мондый очракларда икеле-микеле хәлдә калмаска тырыша, алдан ук барысын да ачыклый, барлый иде. Бүгенге утырыш алдыннан аның моңа вакыты булмады. Аннары бу эшне ул кечкенә, телдән шелтә белән үтә торган мәсьәлә дип уйлады. Баксаң, ул әнә нинди кискен, принципиаль төс алды.
— Шаһзамановның бу адымын, Габделхәй әйткәнчә, очраклы факт дип кенә карамаска кирәк,— дип башлады ул.
Председатель аңа нәфрәт белән карап утырды. Кыен чакларда Биккинин ярган утынны ул ягучы булды. Эшен эшли, ә җаваплылык алырга кирәк булса, Насыйбуллин куян кебек калтырап төшә, мең төрле сәбәп табып, читкә тайпыла иде. Биккинин аны яртылаш кына тыңлады, чөнки сүзенең нәрсә белән бетәсе билгеле иде. Ул үз уйларына чумып утырды. Хәвеф-хәтәрсез генә котылуына сөенергә тиеш булса да, Хаковага да, үзенең тәкъдимен хуплаган Насыйбуллинга да яратмыйча карап утырды. Шул ук вакытта үз фикерен уздыру өчен кабат ике-өч мәртәбә чыгыш ясарга да әзер иде. Әченнән генә ул Илһамга каты шелтә бирсеннәр, үзенең икенче тәкъдиме үтмәсен, дип теләде. Ул чакта аның райком бюросында, мин кулдан килгәнчә тырыштым, дип акланырлык дәлиле булыр иде...
Насыйбуллинның, Шаһзамановны партиядән чыгарырга кирәк, дигән тәкъдименнән соң беркем дә чыгыш ясамады.
— Ул чакта тәкъдимнәрне, устав таләп иткәнчә, җәзаның катылыгы буенча тавышка куям,— диде Солтанов.— Партия уставының уникенче параграфын бозган өчен коммунист Шаһзамановны КПСС сафларыннан чыгарырга, дигән иптәшләрнең тавыш бирүен сорыйм.
Ике кешедән кала, барлык партком члennары да берәм-берәм кул күтәрделәр.
— Төшерегез. Каршылар?
Фәхринурова белән Низамов каршы тавыш бирде.
— Төшерегез. Димәк, күпчелек тавыш белән Шаһзаманов партиядән чыгарылды,— дип нәтиҗә ясады Солтанов.
Шулчак Габделхәй Низамов сикереп торды.
— Ни әйтсәгез дә, дөрес түгел! — дип кычкырды ул бөтенесенең каршына чыгып. Аннары өзгәләнә-өзгәләнә: — Партия бөтенесен кеше өчен ди, ә сезнең бүгенге карарыгыз кешелекле түгел! — диде һәм кызу-кызу атлап чыгып та китте.
Бераз бүлмә тып-тын калды. Аннары Солтанов торып басты да:
— Партком утырышы ябык,— диде.
Берничә секунд һәммәсе дә, җилкәләренә авыр йөк баскандай, урыннарыннан кузгала алмыйча утырдылар. Биккинин шартлатып шырпы сызды һәм инде әллә кайчаннан бирле бармаклары белән йомшартып бетергән сигаретын кабызды. Иң элек керт-керт басып Әнисә Нәҗиповна чыгып китте. Аның артыннан Фәхринурова, башкалар кузгалды, беркем беркемгә бер сүз әйтмәде. Иң ахырдан Биккинин чыкты. Солтанов урындыклар теләсә ничек күчерелгән, тәмәке исе таралган бүлмәдә берүзе басып калды. Сәер хәл: утырышка кергәндә ул партоешма тормышында

зур вакыйга булырлык, барлык коммунистларга сабак бирерлек эш башкару нияте белән керде һәм үз дигәненә иреште. Тик хәзер ни канәгатьләнү тойгысы, ни шатлык кичермәде.

Өч көннән райком бюросы иде.

Икенче көнне кич кәгазь эшләре белән утырып, ул бик соңарды. Идарәдә беркем дә юк, инде сәгать унберенче киткән иде. Кинәт беренче каттагы тышкы ишекнең шапылдап ябылганы, икенче катка күтәрелеп килүче аяк тавышлары ишетелде. «Шаһзаманов килгәндер»,— дип уйлады ул. Солтанов бүген көне буе, ул очрамаса ярар иде, дип йөрде, очраса, үпкә белдерер, зарланыр, дип уйлады. Ләкин аяк тавышлары бик җиңел, йомшак булып ишетелде. Ул арада ишек ачылып китте һәм Хаковның хатыны килеп керде.

— Мөмкинме?

— Узыгыз, утырыгыз,— диде Солтанов нәрсәдәндер каушап.

Гөлзада аның каршына ук килеп утырды һәм керфекләрен аска төшерде. Аның күкрәкләре еш-еш күтәрелә иде. Юк, колхозның баш экономисты буларак килмәгән иде ул бу бүлмәгә. Кинәт ул башын күтәрде һәм туп-туры карап:

— Фәһим Солтанович, аның гаебе юк,— диде.

— Ирегезнең гаепсез икәнлегенә шикләнмибез.

— Мин аны әйтмим...

— Ә кемне әйтәсез соң?

— Илһамны...

Ул косынкасының очын бөтерде дә бөтерде. Гөлзаданың әз генә алга чыгып торган ияге, дугай кашлары, текә шома маңгае, түгәрәк бит очлары өстәл лампасы яктысында серле ялтырыйлар, аңа тәвәккәллек төсмерләре бирәләр иде.

— Сез аның гаепсезлеген раслардай берәр нәрсә әйтә аласызмы?

— Юк.

Солтанов баядан бирле күңелен тырнап торган сорауны кыенсынып кына булса да чыгарырга мәҗбүр булды:

— Сезнең... кемегез соң ул?

— Беркемем дә түгел,— диде Гөлзада керфекләрен күтәрмичә.— Яшьлек дустым иде... Ышаныгыз: Илһам гаепле була алмый!

— Ләкин ул чакта... сезнең ирегез гаепле булып чыга...

Гөлзада дәшмәде. Солтанов аптырашта иде.

— Мин колхозның игенчелек цехын җитәкләүче югары белемле агрономга күбрәк ышанам.

— Сукыр сез, Фәһим Солтанович! — дип кычкырып җибәрде Гөлзада.— Дәүләт Хәсәнович та шуңа мөкиббән. Карышмагач яхшы. Игенчелектә ни эшләде ул, йә әйтегез әле? Инде аның белән укып чыккан агрономнар бөтен республикага танылды. Ә аның сыңар мактау кәгазе дә юк.

Гөлзада сүзен бетерә алмады, кинәт ишек ачылып китте. Анда Яхъя Хаков басып тора иде. Ничек алар ишек тавышын, аның икенче катка күтәрелүен ишетмәделәр? Бәлкем, ул тыңлап та торгандыр?

Өчесе дә аптырап бер-берсенә караштылар.

— Гафу итегез,— диде Яхъя бер адым артка чигенеп.— Мин белмәдем...

Гөлзада аңа өттереп карады.

— Турысын әйт, Яхъя, көнләшеп артымнан килгәнеңне әйт. Мине Фәһим Солтановичтан көнләгәнеңне дә әйт...

Яхъяның беркайчан да мондый кыен хәлдә калганы юк иде. Гөлзада ниндидер бер эчке тою белән Яхъяның күңелендәген әйтә дә бирә. Бу юлы ул аны партком секретаре каршында ачып салды. Әйе, көнләшеп килде, хак! Әмма Яхъя үзе генә газапланган җитмәгән, инде кеше алдында хур итеп, аның ул газапларын тагын да көчәйтү ник кирәк?! Кечкенә сигезләрдә ул Дөмбер авылына әнисенең бертуган энеләренә ит илтергә китте. Кайтканда болын аша чыкмакчы булып кергән иде, батты. Мең

газап белән трактор табып, «Москвич»ын сөйрәп чыгарганчы һәм кайтып кергәнче ун тулган иде. Әнисе Гөлзаданың күптән түгел генә идарәгә китүен әйткәч, аның болай да беткән нервлары шартлап өзелгәндәй булды. Күз аллары караңгыланган килеш ул урамга чыгып йөгерде. «Солтанов янында, тагын Солтанов янында!» — дип сулкылдады аның күңеле. Күптән түгел ул аларны икәүдән икәү Солтанов машинасында очратты. Гөлзададан сорамады, ишетеп белде: фермада терлекчеләр белән җыелыш үткәргәннәр икән. Ләкин алар ни өчен икесе утырып кайталар? Кичтән әнисе педсовет утырышында иде, Гөлзада ашарга пешерергә соңарган булып чыкты. Алар әйткәләшеп киттеләр һәм ул хатынының күз төбенә сугып җибәрде. Гөлзада кулындагы чүмеч белән аның түбә чәркәсенә кундырды... Шулай итеп, Солтанов аркасында берсенең күз төбе күгәреп йөрде, икенчесенең баш түбәсе тавык күкәе кадәр шешеп чыкты. Икесе дә төп сәбәп ашның соңаруында түгеллеген белсәләр дә, бу хакта бер-берсенә әйтмәделәр.

Инде бүген ашыга-кабалана идарәгә барганда, Солтанов бүлмәсендә генә ут януын күргәч, Яхъя үз-үзен шул утка ыргытыр дәрәҗәгә җитте. Димәк, барысы да дөрес, дөрес, юкка булмаган аның шикләнүләре! Ул шушы мизгелдә үзен ничә еллар буе утка салган нәрсәнең раслануын теләде, аларның өсләренә килеп кереп, хатынының гомер буе аны алдавын күзенә карап фаш итү ләззәтен кичерде. Шул ук вакытта бу минутлык ләззәт аңа коточкыч бәхетсезлек китерәчәк. Гөлзаданы тормышыннан бөтенләйгә сызып атачак, ә Яхъя аңардан башка яшәүне күз алдына да китерми иде. Юк, чын-чынлап, тулаем караганда, ул үз шигенең раслан-мавын тели ләбаса. Әгәр шулай булмаса, ул аның һәр адымын сагалар идемени? Ул бит инде аны әнә шул ялгыш юлга кермәсен өчен сагалый. Оят булса да, Яхъя идарәнең тышкы ишеген шапылдатмыйча ачып япты, икенче катка аяк очларына гына басып күтәрелде, йөрәге дөп-дөп типкән хәлдә ишеккә колагын куеп тыңлады, сүзләрен аера алмагач, түземе бетеп, тотканы кискен рәвештә үзенә тартты. Аларның сөйләшеп утыруын күргәч, аның башыннан: «Әле берни дә булырга өлгермәгәндер»,— дигән шатлыклы уй йөгереп үтте. Шуңа күрә ул гафу үтенде. Әмма Гөлзаданың теге сүзләре кеше алдында әйтмәслек дәрәҗәдә дөрес булуы белән аның ачуын китерде. Шулай да Яхъя үзен кулга алды.

— Хатын-кызларга ни уйласа шуны әйтергә ярый — алар һәрвакыт хаклы. Менә шулай яшибез, Фәһим Солтанович,— диде ул елмаерга тырышып, тик иреннәре аңа буйсынмадылар, елмаю белән елау арасында калтырандылар...

Иренең бу кыяфәте Гөлзадага күп нәрсә сөйли. Үзенең төнлә өйдән чыгып китүен, биредә чит ир белән утыруын Яхъяның ни дип кабул итәчәген ул яхшы аңлый. Гөлзадага ире кызганыч булып китте. Яхъя да тамаша эзләп йөрми ләбаса! Болай итәсе түгел иде. Шуңа күрә ул:

— Кем хаклы икәнне киләчәк күрсәтер,— диде дә чыгып китте.

Алар икәүдән икәү торып калдылар. Солтанов Яхъя каршында үзен гаепле кебек хис итте, шунлыктан теле бәйләнде, берни дә әйтә алмады. Әгәр каршысында партком секретаре басып тормаса, һәм аның Гөлзада белән йөрүенә ишарәләрлек бер кечкенә дәлиле булса да, Яхъя хәзер үзен башкача тотар иде, әлбәттә. Ләкин юк бит ул, юк!

— Хушыгыз,— диде Яхъя ачыну белән һәм бүлмәдән чыгып китте.

## 8

Алар өйгә бер-бер артлы кайтып керделәр. Әнисә ханым яшькелт абажурлы өстәл лампасы яктысында иртәгәге дәресләренә план төзеп утыра иде. Киленен дә, малаен да ул күзлек өстеннән карап, сүзсез генә каршылады.

— Менә, әни, эзләп алып кайттым киленеңне,— диде Яхъя әнисен

гаепләгән төсле.

— Алай димә, улым,— диде Әнисә ханым.— Эзләп алып кайтырга ул бит көтүдән качкан мал түгел. Әше беткәч, үзе дә кайтыр иде әле...

— Әйдәгез өйдә рөхсәт язуы булдырыйк,— диде Гөлзада аларның икесенә дә туп-туры карап.— Һәркөн сез аны миңа тутырып бирегез. Язуда кем белән сөйләшергә, кемгә елмаерга, кая барырга, кая бармаска икәне күрсәтелсен.

— Килен, әле бит мин берни дә әйтмәдем.

— Мин дивана түгел, әни, барысын да аңлыйм!

— Безнең өйдә берәр нәрсә «шылт» итсә, ул көнендә үк мәктәп эченә килеп керә. Без бөтен авылның күз алдында. Син, килен, моны яхшы аңлыйсың.

— Әйе, аңлыйм.

— Минем дә, Яхъяның да авылда билгеле абруебыз бар. Ә син...— Әнисә ханым тиешле сүзләр таба алмыйча туктап калды, аннары дәвам итте: — Төнлә берүзең болай йөрү бер дә килешми бит.

Әнисә ханым тыштан бик тыныч сөйләргә тырышты. Әмма бианасының күзендәге таныш чаткылар аның күңелендә ниләр кайнаганын бик ачык сөйлиләр иде. Еш кына Гөлзада, Әнисә ханымга үч итеп, юри Яхъя тирәсендә бөтерелә, аңа иркәләнә, үзенә калса, бианасы көнләшүенең мәгънәсезлеген шушылай үртәп аңлатмакчы була иде. Үзенең болай кылануларының ире тарафыннан да, бианасы тарафыннан да бөтенләй киресенчә кабул ителгәнен, дәртенә чыдый алмау дип бәяләнгәнен, димәк, икесенең дә көнләшүен тагын да арттырганын ул башына да китерми иде. Гөлзада менә хәзер дә Әнисә ханымны өттереп алырдай сүзләр эзләде, тик таба алмады. Әллә шуннлыктан, әллә башка сәбәпле аның күңеле тулды.

— Минем бернинди дә гаебем юк,— диде ул акрын гына.— Юк гаебем...

Яхъя юл буе хатынын иң әшәке, моңа кадәр әйтмәгән мыскыллаулы сүзләр белән сүгәргә дип ярсып кайткан иде. Гөлзаданың болай йомшап калуы аңа да тәэсир итте.

— Гөлзада, әйт әле, ник барган идең аның янына? — диде ул тыныч күренергә тырышып.

— Йомышым бар иде. Шәхси түгел.

— Бик сәер, килен,— диде Әнисә ханым иңбашларын җыерып.— Сез көне буе бер бинада утырдыгыз. Төнлә нинди йомыш төшүдер ул — аңламыйм.

— Төште шул.

Яхъя аның каршына ук килде.

— Шәхси булмагач, әйтергә дә ярыйдыр бит аны, Гөлзада?

— Әйтермен, тик бүген түгел,— диде Гөлзада, аңа ялварулы караш ташлап.

Хатынының әлеге карашын яхшы аңлый иде Яхъя. Бу — әле аның белән ачуланышмыйча уртак тел табып, аңлашып була дигән сүз. Бу — әле аны иркәләргә, назларга, кайнар иреннәрен татырга мөмкин дигән сүз.

— Ярый, бүген түгел икән — бүген түгел,— диде Яхъя һәм беренче булып йокы бүлмәсенә юнәлде. Гөлзада кереп ишекне япты да аңа аркасы белән сөялде. Яхъя торшерны кабызды да чишенергә әзерләнде.

— Яхъя!

Гөлзаданың ниндидер бер эчке дулкынлану белән үз исемен әйтүе аны катып калырга мәҗбүр итте.

— Нәрсә? — ул хатынына борылды. Гөлзада, бианасы кермәсен дигәндәй, һаман ишеккә аркасы белән сөялеп тора иде.

— Син гафу итә беләсеңме?

Башта Яхъя бу сүзләрнең мәгънәсен аңламады. Бераздан аның миен: «Хыянәт иткән!» — дигән уй көйдереп үтте. Гөлзада аның каршына килде. Алар бер-берсенең күзләренә туп-туры карап тордылар. «Шу-

шындый саф, якты күзләр белән дә хыянәт итеп була микәнни?!» — дип Яхъя эченнән өзгәләнде. «Гафу итә беләсеңме?» Әгәр белмим дисә? Ул чакта Гөлзада барысын да яшерәчәк һәм аны Яхъя мәңге белә алмаячак.

— Гафу итә... беләм,— диде ул калтыранган тавыш белән.

Гөлзада аның янына утырды һәм кочаклап алды.

— Ул чакта гафу ит син аны...

— Кемне?

Гөлзада иренең колагына пышылдады:

— Илһамны.

Яхъя корт чаккандай сикереп торды. Ул сүз әйтерлек дәрәҗәдә түгел иде. Башында бер уй бөтерелде: «Нәрсә өчен?! Нәрсә өчен?! Ул Гөлзада белән бергә булганмы, шуның өченме?! Әллә сукканы өченме?!» Хатынының мондый нәрсә әйтүе оятсызлык кына түгел,ерткычлыкка тиң нәрсә иде, бу башка сыймый иде. Яхъя хәзер үзенең аңа ташланачагын, үтергәнче кыйнаячагын, изәчәген сизде, шуннан үз-үзен тыярга теләде, әмма ачу алдында торган саен көчсезләнә баруын тойды: кинәт Гөлзада аны кочаклап алды, кайнар иреннәре белән битләрен, күзләрен, муеннарын, кулларын шашып үбәргә тотынды һәм өзлексез бер үк сүзләрне кабатлады:

— Син аны гафу итәргә тиеш! Син бит чын ир кеше. Партиядән чыгару җитмәгәнмени?!

Аның туктаусыз кайнар үбүләре Яхъяның ачуын басты, хатынының иркәләүләре аның бөтен ихтыярын биләп ала иде.

— Син кичер, Яхъя. Кирәк булса, үзем гаепле диген. Юкса аны төрмәгә утыртачаклар! Аның балаларының, хатынының күз яшьләре безгә ник кирәк?!

Гөлзада иренең гафу итүе бернине дә үзгәртмәячәген, хәзер инде соң икәнен белми, ул Илһамны коткара алачагына әле һаман ышана иде.

— Гомер буе сүзеңнән чыкмам, буйсынып кына яшәрмен, бары гафу гына ит! — дип өзгәләнде ул.

Шушы берничә минут эчендә Яхъя Гөлзада өчен Илһамның кем, үзенең кем булуын бик ачык аңлады. Менә бу шашынып үбүләр, иркәләүләр, ялварулар — һәммәсе Илһам хакына, аны исән-имин саклау хакына иде. Яхъя үзенең хатыны өчен Илһамның дөньядагы барлык нәрсәләрдән дә кадерлерәк икәнлеген күрде. Моны кире кага торган түгел иде. Ләкин бу ялкын Гөлзаданың шушы матур күкрәкләре эчендә генә дөрлиме, әллә инде алар Илһам белән очрашып, ул ялкын аңа да бүләк ителәме — Яхъяның йөрәген шушы кайнар сорау телгәләде. Бу сорауга җавап хәзер аны шашып үбүче менә шушы чибәр һәм серле зат эченә яшерелгән иде.

— Гафу итәсең бит, шулаймы? Гафу итәсеңме?! — дип, Гөлзада аның битеннән йомшак куллары белән сыпырды.

Юк, Илһамны ул мәңге гафу итмәячәк иде. Ләкин моны хатынына әйтергә теләмәде. Ичмасам бүген генә булса да аның ачуланышмыйча: иркәләнеп, сөешеп бергә ятасы килде, ә иртәгә киләчәк көннәр хакында уйларга да куркыныч иде.

— Идарәгә ник барганыңны әйтерсеңме? — диде Яхъя хатынының йомшавына өметләнеп.

Ул ялгышмаган булып чыкты.

— Әйтермен,— диде Гөлзада.

— Ул чакта мин дә аны гафу итәм,— дип алдады Яхъя.

Гөлзада үзе дә сизмәстән кулларын чәбәкләп куйды.

— Рәхмәт, җаным, рәхмәт!

Ул тагын Яхъяны кайнар үбүләр белән бүләкләде.

— Я, хәзер әйт инде?

Гөлзада кинәт кенә җитдиләнеп китте һәм:

— Синең өчен хәзер яңалык түгел инде ул,— диде.— Мин анда Илһамның гаепсез икәнлеген әйтергә бардым.

Яхъя аны этеп җибәрде. Гөлзада идәндәге келәмгә барып төште.

— Аның өчен! Барысы да аның өчен! — диде Яхъя тавышын күтәреп.— Юк, көтмә дә, өметләнмә дә! Беркайчан да кичермәячәкмен мин аны!

— Син мәрхәмәтсез! — диде Гөлзада сикереп торып.— Мин сине күрә алмыйм! Син вак җанлы кеше!

Ул үкси-үкси еларга кереште. Яхъя ачуына буылып бүлмәдән чыгып китте.

Әнисә ханым аларның сүзләрен аңларга тырышып ишек янында тора иде, малае атылып килеп чыккач, ул сервантка таба китеп, аннан әйбер алган булып маташты. Яхъя аңа күтәрелеп карамыйча гына сыңар мендәрне атты да диванга ятты. Әнисә ханым, утны сүндереп, үз бүлмәсенә керде. Уйларына баткан хәлдә озаклап урын җәйде, чишенеп ятты. Йокы качкан иде инде. Башта ул килененең ике кешелек софада ялгызы аунавына, аның да йоклый алмыйча газапланып ятуына шатланып бетә алмады. Шул кирәк сиңа, дип уйлады ул. Ләкин газиз баласының бөгәрләнеп диванда ятуын күз алдына китергәч, котырып ачуы чыкты. Шуның аркасында интекмимени аның йөрәк парәсе?! Ни өчен ул җәелеп йомшак урында ятарга тиеш?! Ах, бу дөньяның гаделсезлеге! Гөлзада мәктәптә укыганда югыйсә бер дигән кыз иде. Аны үзенең килене итү өчен әнисе эшләгәннәрнең Яхъя йөздән берен генә белде. Ә белмәгәннәре? Сихердән башка һәммәсен дә кулланды Әнисә ханым. Ә нәрсә килеп чыкты? Бер сүз әйтсәң, ун сүз булып кире кайта. Баш бирү, буйсыну дигәнне белми. Гомер буе Яхъяны бәхетле итим дип тырышты. Ә хәзер бер түшәм астында, өчесе өч урында газапланып яталар... Әнисә ханым Яхъяны артык иркәләп үстермәде, аңарда фәнгә кызыксыну уятырга тырышты. Улы «биш»ләргә генә укыды. Син сәләтле, син галим булачаксың, дигән нәрсә малайның бөтен барлыгына кереп урнашты. Ул үз-үзенә, кешеләргә бәя куя башлагач, Әнисә ханым аңа фән дөньясы кешеләренең нинди зур, иркен тормыш белән яшәүләре хакында тәэсирле итеп сөйли торган булды. Яхъя биология, зоология белән мавыкты. Аның урыны инде университетта, барысы да уртага салып сөйләшенгән, хәл ителгән иде. Әмма ул елларда аттестат белән авылда калу, комсомол путевкасы белән фермага эшкә килү модага кереп китте. Мәктәпнең уку-укыту бүлеге мөдире буларак, Әнисә ханым да бу эшнең уртасында кайнады. Колхозның алдынгы кешеләре, авыл хуҗалыгы белгечләре, җитәкчеләр белән очраштылар, авылда эшкә калган яшьләр катнашында комсомол җыелышлары уздырдылар, лекцияләр укылды, башка чаралар үткәрелде. Урта мәктәпне тәмамлагач, Яхъялар классы да авылда калырга булды. Әнә шул чакта Әнисә ханымга олы уй төште, ул аның йөрәген туктаусыз яндырып тора башлады. Аттестатында нибары ике «дүрт»лесе булган алтын башлы Яхъяның колхозда эшкә калуыннан җәмгыять отамы соң? Юк, әлбәттә. «Өчле»гә, «өчле»-«дүрт»ләргә укыганнар әнә никадәр! Алар бит фән өчен барыбер берни дә бирә алмаячак. Тик моны кемгә исбатлый аласың? Дөрес, малаен ул беркем белән дә исәпләшмәстән укырга җибәрә ала, бу рөхсәт ителә иде. Ләкин Әнисә ханым абруе төшүдән курыкты. Әгәр син халык укытучысы, тәрбияче икәнсең, әхлак йөзеңә бер бөртек тузан да кундырмаска тиешсең. Һәм ул гомере буе шул принципка тугры калды. Ирен кугач, әгәр шул абруен сакламаса, кем беләндер йөрер, яңа гаилә корып җибәрер иде. Тирәсендә чуалучылар булмады түгел бит. Кайсылары үзеннән түбән иде — андыйларга бер сүз белән нокта куйды. Тиң санаганнары да бар иде. Әмма халык, балалар ни әйтер, дигән нәрсә Әнисә ханымны шулкадәр салкын, сак кыланырга мәҗбүр итте ки, ул андыйларны капка төбенә, мәктәп тирәсенә түгел, авылга да (алар я район үзәгеннән, я башка авылдан иде) якын китермәде. Әлеге ирләр аның берничек тә якын китермәвен үзләренчә гөманлап, аңардан ераграк качарга мәҗбүр булдылар. Ел саен бара торган санаторий-курортларда, командировкаларда гына Әнисә ханым ирләрдән читләшмәде, алар сүзенә буйсынды. Авылда

мәҗлесләрдә, туйларда катнашырга туры килсә, аның бер генә мәртәбә дә кулына рюмка алганын, бер генә йотым шампан шәрабе капканын да күрүче булмады. Дөрес, нервысы беткән, эш белән башы каткан чакларда өендә ул йөз-йөз илле грамм ак аракы эчеп куйгалый, тик моны Яхъяга да, беркемгә дә сиздерми иде.

Абруен әнә шулай саклаган педагог өчен малаен башкалардан аерып университетка җибәрү мөмкин түгел иде. Шуннан соң ата-аналар алдына чыгып: «Балаларыгызны авылда калдырыгыз»,— дип ни йөзең белән әйтәсең? Күп баш вата торгач, ул бердәнбер дөрес юл сайлады: Яхъяны колхоз стипендиаты итеп авыл хуҗалыгы институтына җибәрергә. Укып кайтсын, эшләп бераз тәҗрибә алсын да аспирантурага керер. Яхъя күнде, аңа тегеләй дә, болай да барыбер, әнисе сүзе аның өчен закон иде. Ул начар укымады, диплом алып ректорга үзенең аспирантурага керү теләген белдергәч, рәхим итегез, фәнгә яшь көчләр кирәк, булышырбыз, дигән өметле җавап ишетте.

Колхозга кайтып эшли башлаган көненнән үк Яхъя үзен вакытлы кеше итеп тойды. Ул фән юлына чыгасы яшь галим, әмма биш ел буе колхоз акчасын ашагач, аяк-кулы бәйләүле иде. Авылда кыл-бырдак килеп чабуларны, эш өчен үзара тарткалашуларны, якага-яка килүләрне ул аңлый алмады. Җыелышларда, слетларда, киңәшмәләрдә бернинди кәгазьсез чыгыш ясавы белән ул киң эрудициясен, агрономияне, биологияне яхшы белүен күрсәтте, хәл итәсе җитди проблемаларны күтәрде. Аның аспирантурага керергә җыенуы колхозда гына түгел, районга да мәгълүм булды.

Әнисә ханым аның фән кешесе булырга тиешлеген килененә дә нык-лап төшендерде. Яхъя барлык йорт эшләреннән азат ителде, аңа нәкъ вакытында аш-су әзерләнде, газета-журналлар, китаплар уку өчен барлык шартлар тудырылды. Башта ул шактый вакыт бик тырышып укып маташты. Аннары, барыбер кирәкмәгән дигән уй белән, ул шөгылен киметте. Ә инде соңрак мәҗбүри алсалар да, аспирантурага бармаячагын аңлады. Моның сәбәпчесе Гөлзада иде. Аны биредә калдырып, үзең Казанга китәргәме?! Ул бит бер сәгатькә, бер көнгә, бер атнага, бер айга гына түгел. Ике елга! Әле укып бетергәч, диссертация яклыйсы бар, кайчан квартира бирәләр дә, кайчан ул аны Казанга алып килә?! Юк, болай да китәргә генә торган Гөлзада аныкы булмаячак иде. Гел аныкы булган сурәттә дә, Яхъя бит аңардан башка ике көн дә тора алмый, шашар дәрәҗәгә җитә. Гөлзаданы югалту аның өчен үлем белән бер иде. Шуңа күрә ул аспирантурада читтән торып укырга булды. Ләкин вакыт аккан су кебек үтте дә китте, институт белемнәре дә аз-азлап онытылдылар, искерделәр, аларны яңартырга вакыт тимәде. Инде кырыгынчы яшь белән барганда яңадан бөтенесен кабатлау, чит тел өйрәнү һәм имтиханнар тапшыру мөмкин түгел иде. Яхъя моның шулай килеп чыгуына колхозны гаепләде. Әгәр аның институт бетергәч тә аспирантурада калырга хакы булса, мәҗбүри рәвештә аны авылга җибәрмәсәләр, тормыш бөтенләй башка эздән китәсе, Гөлзада белән алар әллә кайчан фән һәм Казан кешеләре иде. Барысыннан өстен хәлдә бөтенесе белән бер дәрәҗәдә эшләп йөрүдән дә кыен, рәнҗешле нәрсә бар микән бәндә өчен?! Колхоз кешеләреннән башлап район җитәкчеләренә кадәр аны аспирантурага керәчәк кеше дип санаганда, аңардан шул турыда сораштырып торганда, Яхъя инде әлеге рольдән баш тарта алмый, аны һаман уйнарга мәҗбүр иде. Ни генә әйтсәң дә, бу уен әле аны башкалардан бер баш өстен куя, белемлерәк итеп күрсәтә... Әнисә ханым боларның һәммәсен дә аңлый, улының бәхетсезлегендә әле үзен, әле киленен гаепли иде...

Ләкин Яхъяны бәяләүдә иң алданган кеше Гөлзада булды. Менә хәзер дә ул йомшак софада утлы күмер өстендә яткандай ята. Ах, бәхетсез башларым, бу миңа Илһамга хыянәтем өчен җәза дип, ул үзен меңенче мәртәбә генә битәрләмидер. Аларның дуслашып китүләре дә, йөрүләре дә, аерылулары да кешечә булмады. Беркөн кинодан соң Гөлзада каршына

адашкан эт килеп чыкты. Тугызынчы класс кызы өчен эт бик куркыныч тоелгандыр, күрәсең, ул чәрелдәп кычкырып җибәрде. Тавышка Илһам абыйсы йөгереп килде һәм аны өенә озатып куйды. Икенче көнне кичәдән кайтышлый,— инде укулар беткән, каникуллар башланган иде,— Гөлзада аңа:

— Илһам абый, теге эт очрамас микән? — дип дәште.

Илһам сүзсез генә елмайды да аны тагын озатып куйды. Өченче көнне Гөлзада аны үзе култыклап алып китте. Яшькә өлкәнрәк, ә гәүдәсе белән кимендә ике мәртәбә зуррак кешене янәшәсендә тою Гөлзадага кыз-кыркын, егет-җилән каршында рәхәтлек бирә иде. Алар көн саен бергә йөри башладылар. Атналар, айлар үтте. Илһам кочакламады, үпмәде, яратам димәде, матур сүзләр сөйләмәде. Гөлзада исә туктаусыз чытлыкланды, аны төрлечә шаяртты, үртәде, чеметте, муенына көнбагыш, борчак, чуерташ салды, пычрак булса сазга этеп кертте, кыш көне кар белән коендырды, үзе чырык-чырык көлде дә көлде. Илһам шуышыларның һәммәсенә түзде: «эһ» дигән тавыш та чыгармады, рәхәтләнеп елмайды гына. Шулар өстенә, Гөлзада бар көченә аның бармакларын тарткалый, төрлечә каермакчы була, тик чәнти бармагын бөгәргә дә көче җитми иде. Кайчакта Гөлзаданың әле ныгып та бетмәгән кечкенә йомшак куллары аның сөялле кайнар учына кереп юк була. Илһам аларны бик озак җибәрмичә тора...

Аннары Гөлзада — Казанга укырга, Илһам армиягә китте. Алар Яхъя белән бергә укыдылар. Гөлзада Илһамга үчекләүләр, үртәүләр белән тулы хатлар язды, ә аңардан ун-унбиш җөмләдән торган җитди җаваплар килде. Иптәш кызлары, аларны укыгач, кычкырып көлә: «Бу бит егет түгел, утын түмәре»,— дип Гөлзаданың эчен яндыра иде. Илһам армиядән кайткач, алар авылда очрашты. Гөлзада институт шау-шуына, очынып-канатланып танцевать итүләргә, телләр алҗыганчы сүз көрәштерүләргә, адым саен чыр-чу, уен-көлке чыгаруларга күнегеп беткән иде. Илһам танцыга кермәде, чөнки белми иде. Гөлзада аны иң аулак урынга — Акчарлак күле буена алып барып, җәйге таңнар атканчы танцыга өйрәтеп карады. Ул исә елмая-елмая аю табаннары белән аның аякларын таптады, барыбер өйрәнә алмады. Хәзер элекке кебек шаярулар кызык түгел, Гөлзаданың күңеле ниндидер зуррак, яңарак нәрсәләр тели иде. Ә Илһам тамчы да үзгәрмәгән, элеккечә үк сүзсез, басынкы, юаш килеш калган булып чыкты. Аларның ике ел күрешмичә торганнан соң уздырган ул көннәре Гөлзадага шатлык китермәде. Иртәгә китәм дигән көнне ул:

— Илһам, без дуслар булып калыйк, тик хат язышмыйк, яме? — диде.

— Ник?

Гөлзада аның бармаклары белән уйнап:

— Синең хатларың бигрәк кыска була. Кызлар укыйлар да көләләр, мине үртиләр,— диде.

Илһам елмаеп:

— Нишлим соң инде? Әнидән яздыра алмыйм бит,— диде.

Тагын шау-шулы институт тормышы башланды. Яхъяга әнисе әледән-әле күчтәнәчләр җибәрә, алар килгән саен Яхъя Гөлзаданы да чакыра иде. Әнисә ханым махсус Гөлзадага атап та әйберләр салды. Яхъя Гөлзаданы танцыларга, кино-театрларга да чакыра башлады. Шул рәвешле алар дуслашып киттеләр. Яхъя яхшы укый, чибәр, терекөмештәй җитеш, концертларда, мәҗлесләрдә өздереп җырлый, ут өертеп бии иде. Авылга җәйге каникулга кайткач, алар Яхъя белән икесе танцевать иттеләр, Илһамны да алып урамда йөрделәр. Ләкин Илһам, үзен артык дип уйлап, аларга комачауламау ягын карады. Шул рәвешле алар икәүдән-икәү калдылар, бәхет диңгезендә йөзделәр. Бөтен кешенең күзе аларда булды, күрше-күлән, әти-әнисе Яхъяны мактады, аларның пар килүенә шатланды, ә ул Гөлзаданы өрмәгән урынга утыртмады, бер генә секундка да күздән ычкындырмады. Дүртенче курс ахырында алар ир белән хатын булдылар. Көнләшү галәмәтләренең торган саен арта баруын исәпләмәгәндә,

Гөлзада иреннән канәгать иде. «Шулкадәр көчле яраткач, нишләсен инде ул?» — дип юаттылар аны дус кызлары һәм ул тора-бара үзе дә бу фикер белән килеште.

Институт бетергәч, алар авылга яшь бала белән кайтып төштеләр. Илһамны Гөлзада берничә мәртәбә урамда очратты, ул, күрәсең, үпкә сакламаган, аларның хәл-әхвәлләрен сораштырды, тик зәңгәр күзләре генә сагыштан мөлдерәмә иде. Гөлзаданың йөрәгендә ниндидер юшкын калды, ул аны мәңгегә рәнҗеткәндер кебек иде.

Гөлзаданың күңелен тетрәтерлек бер хәл булмаса, бәлкем ул юшкын юылыр, үткәннәр онытылыр да иде. Аның өйдә бала карап яткан чагы, тышта коеп көзге яңгыр ява. Әнисә ханым да, Яхъя да эштә, ул ялгызы гына иде. Гөлзада баласын йоклатып, кичке аш салырга йөргәндә тәрәзә турыннан яшькелт кожан кигән кеше үтте һәм ишек шакыды.

— Керегез,— диде Гөлзада.

Ишектән Илһам килеп керде.

— Ни хәлләрдә ятасыз? — диде ул тупса турыннан узмыйча.

— Әйбәт кенә,— диде Гөлзада, битләренең кызышуын тоеп.— Әйдә, Илһам, түрдән уз...

— Юк, узып тормыйм...

Илһам кожанының башлыгын төшерде, битен, юеш кулларын кульяулыгы белән сөртте, үзе берни дә әйтмәде. Бианасы йә ире кайтып, Илһамны монда туры китерсә, коточкыч зур тавыш чыгачагын белгәнгә күрә, Гөлзада аны ашыктырырга теләде:

— Әллә йомышың бар идеме, Илһам?

— Бар иде шул...

Илһам бер урында таптанды, сөрмәле күзләре белән аңа карады. «Нинди матур, элеккечә яшь аның күзләре»,— дип уйлады Гөлзада.

— Мин өйләнермен дигән идем, Гөлзада...

Илһам туктап калды, башын читкә борды һәм ике кулын да кесәсенә тыгып нидер эзләгәндәй итте. Аның бу сүзләрен ишеткәч, Гөлзадага нидер булды, әйтерсең, дулкын өстендә аны моңа кадәр батырмыйча тоткан ышанычлы әйберне тартып алдылар. Күзләре, суга батып барган кешенеке кебек, зур булып ачылды. «Миңа бит хәзер барыбер, минем аңарда бернинди катнашым да юк!» — дип әлеге сәер тойгыны читкә куарга тырышты. Ләкин ул тойгы көчәя генә төште һәм Гөлзада аның беркайчан да кайтарып булмаслык югалту тойгысы икәнлеген аңлады. Ул, барлык ихтыяр көчен җыеп, үзен кулга алды һәм калтыранган иреннәреннән бер генә сүз кысып чыгара алды:

—Кот-лыйм...

Гөлзада, үзе дә сизмәстән, нишләптер,— күрәсең, чыннан да котларга теләп,— аңа кулын сузды. Илһам үзенең бармакларына күп мәртәбәләр сарылган, хәзер дә күңеле белән көн саен учында итеп тойган шушы кечкенә йомшак кулга изге әйбергә карагандай карап торды, аннары, нәни сандугач баласын имгәтүдән курыккандай, сак кына ике кулына алды. Гөлзаданың керфекләре йомылды, кулы калтыранып китте. Илһам аның бөтен җылысын, калтыравын соңгы мәртәбә үз йөрәгенә озату өчен Гөлзаданың кулын ныгытып кысты.

— Илһам, зинһар, җибәр,— диде Гөлзада ишетелер-ишетелмәс пышылдап. Аның тавышы Илһамга йомырка эчендәге бәпкә пипелдәве кебек кенә ишетелде.

— Гөлзада... миңа... өйләнергә рөхсәт итәсеңме?

Әгәр кулы бу кайнар учлар эчендә кысылмаган булса, ихтимал, ул чайкалып кына калмас, егылып та киткән булыр иде. «Рөхсәт итәсеңме?» Йә аллам! Димәк, бер генә мәртәбә кочакларга, үбәргә үрелмәсә дә, ул хакта бер генә сүз әйтмәсә дә, Илһам аны өзелеп яраткан, мәңгелеккә, бернинди хыянәтсез, теләсә нинди үпкәләүләрдән өстен калып яраткан! Димәк, ничә еллар буе ул аны бер генә секундка да йөрәгеннән чыгарма-

ган, өметләнгән, бу хакта беркемгә сиздермәгән, әйтмәгән, бары тик ялгызы бәргәләнгән, бөтенесен күтәргән һәм кичергән, шушыларның бөтенесен дә күңелендә сакларлык, бер генә кайнар тамчысын да читкә чыгармаслык көч тапкан! Һәм менә хәзер әгәр ул «өйләнмә» дисә, Илһам өйләнмәячәк, әгәр «мине көт» дисә, гомеренең ахырынача көтәчәк... Гөлзада бу кайнар учларны мәңгегә югалтуын аңлады, бу бармакларны бөгеп, каерып ул инде беркайчан да уйный алмаячак. Нишләп моны йөрәк кабул итми, ачыргаланып кире кага соң?! Димәк, аның да йөрәге Илһамны мәңгегә үз иткән, ә акыл икенче якка борган, алдаган... Менә хәзер коточкыч югалту тойгысы уянгач, Гөлзада үзенең моңа кадәр кичергән барлык куаныч-юанычларының, рәхәтлекләренең Илһамны янәшәсендә тойганлыктан гына булганын аңлады. Аның тормышта, бөтен гамәлдә бердәнбер таянычы Илһам гына булган икән! Шул ук вакытта Гөлзада аның барлык кайнар хисләрен, балаларча садә кичерешләрен оятсызларча пычракка салып таптаганлыгын, әмма аларның барыбер элеккечә саф, чиста калуларын күрде. Соңгы мәртәбә шушылай якыннан Илһамның сөрмәле күзләренә бер тутырып карыйсы килсә дә, ул оялды, керфекләрен күтәрә алмады... Тагын әз генә шушы хәлдә торсалар, Гөлзада кычкырып елап җибәрәчәк иде. Шуңа күрә күз яшьләренә буыла-буыла:

— Рөхсәт, Илһам, рөхсәт! — диде дә кулларын тартып алып, түр өйгә йөгереп кереп китте һәм мендәргә капланды. Ул Илһамның ничек чыгып киткәнен дә ишетмәде...

Илһамның бу керүе Гөлзаданың бөтен күңелен айкап, актарып ташлады. Корыда озак вакытлар тишелә алмый яткан бөртек, дым булу белән шытып-үсеп киткән кебек, Гөлзаданың күңеле аңа карата кайнар хисләр белән тулды. Илһам әлеге сөйләшүдән соң ярты ел узгач өйләнде, гөрләшеп яшиләр, диделәр. Сөйләшмәс, басынкы Илһамның хатыны белән шаяруы, ишегалдында су яисә кар сибешеп уйнаулары турында хәбәрләр Гөлзадага ишетелә торды. Шулай итеп, кешегә тормышында бер генә мәртәбә бирелә торган иң кадерле нәрсә мәңгегә югалтылган иде. Моңа үзе сәбәпче булганлыктан, Гөлзада язмышы белән килеште.

...Өйләнешеп күп тә үтмәстән, Яхъя беренче мәртәбә көнләшүен күрсәтте. Аннары, өянәге ешая барган авыру кебек, шул нигездә чыккан тавыш-гаугаларның саны арта барды. Гөлзада дөньяга елмаеп караучан, шат табигатьле хатын-кыз иде. Иренең көнләшүләрен күп вакытта ул елмаеп кабул итте, үзен үлеп яратучы кеше барын тоюдан рәхәтлек кичерде. Ачуын артык китерә башласа, ирен юри көнләштерде, тавыш-гауга чыкса, туйганчы тузынды, бер генә сүзне дә җавапсыз калдырмады. Яхъя кул күтәрсә, ул да кул күтәрде һәм боларның берсен дә фаҗига төсендә кабул итмәде, тормыш юлында очрый торган бәрелешләр, чәкәлешләр дип кенә карады. Яхъя эчми, тартмый, акчаны күп ала, ярамаслык ир түгел иде. Малай булу гаиләдәге мондый күңелсезлекләрне тиз оныттыра, өчесен дә татулаштыра, килештерә килде. Әмма ләкин җанын талкыган, изгән бер нәрсәне Гөлзада иренә дә, бианасына да кичерә алмады. Ул нәрсә Яхъяны һаман да югары баскычта торучы фән кешесе итеп куярга тырышудан, Гөлзадага аңа барлык төр хезмәтләрне күрсәтергә тиешле зат итеп караудан гыйбарәт иде. Гөлзада бусын күтәрә алмады, аны челпәрәмә китерү өчен һәммәсен дә эшләде. Ул Яхъяның беркайчан да аспирант та, фән кешесе дә була алмаячагын аның үзенә дә, бианасына да йөзләренә бәреп әйтте. Ләкин Әнисә ханымның Яхъяны, Яхъяның Әнисә ханымны алдавы дәвам итте, алар бер-берсен алдаганнарын эчтән белсәләр дә, тыштан хуплашып сөйләшүләре белән Гөлзаданы үтерәләр иде. Ник кирәк бу? Әллә алар аны ышандырырга телиләрме? Алай дияр идең, алар икәүдән-икәү чакта да Яхъяның фән юлына чыгуы турында сөйләшәләр — моны Гөззаданың йокы аралаш та, алгы бүлмәдә аш-су әзерләп йөргәндә дә ишеткәне бар. Күрәсең, бу ялган алар өчен аеруча кадерле, алар аны, саран кеше үзенең байлыгын барлаган кебек, кузгаткалап, яңартып торалар. Тормыштан аерылган әлеге буш сүзләр олы ялган бу-

лып өйне генә тотырып калмый, авылга, районга да тарала һәм аларның кайтавазы кеше теле аша әледән-әле Гөлзадага да килеп орыла һәм ул андый чакларда үзен кая куярга белмичә бәргәләнә, иренең дә, бианасының да ачуын чыгару өчен пырдымсызлана, әшәкеләнә иде. «Әле ирең аспирантурасын бетерәме?» — дип юри үртәүчеләр дә, белмичә сораучылар да шактый табылып тора. Бу ялганны инде юкка чыгарырлык түгел, ул тамыр җибәреп кенә калмаган, котырып үскән солыча кебек гаять зур мәйданнарга җәелгән... Иң әшәкесе, иң аянычы шунда, Гөлзада бу ялганның эчендә яши һәм аны юкка чыгару өчен берни дә эшли алмый иде.

...Гөлзада төне буе авыр сулый-сулый аунады. Таң алдыннан гына тәрәзә турында яшькелт-зәңгәр эз калдырып йолдыз атылды. «Илһам» дип уйлады ул. Аның тормышында Илһам шул йолдыз шикелле балкыды да сүнде һәм аны сүндерүче Гөлзада үзе иде.

Таң атып яктыра башлаганда гына ул авыр, саташулы йокыга талды.



## 9

Габделхәй партком утырышыннан туп-туры Илһамнарга кайтты. Ничек әйтергә? Ничек юатырга? Үз гаебеңне ничек юарга? Алдан Илһамга сугылса, бәлкем ул аны утырышка барырга да күндерер, персональ эшне тикшерү дә бүтәнчәрәк төс алыр иде...

Илһам, капкада Габделхәйне күргәч, яшелчәләргә су сибеп йөргән җиреннән туктап, аның каршына чыкты, дустының йөзенә күз ташлау белән эшнең әйбәт түгеллеген аңлады.

— Без уеннан уймак чыгардык бугай,— диде Габделхәй, бер кулы белән койма башына тотынып.

— Нигә?

— Сине бит партиядән ук...— ул «чыгардылар» дигән сүзне әйтә алмады, башын аска иде.— Зәнфирә белән мин яклап карадык та...

Илһам аның иңбашына шапылдатып кулын салды.

— Кайгырма, Габделхәй,— диде ул күтәренке тавыш белән, иреннәре генә сәер дерелдәп куйдылар.— Җирдән аерылмыйк... башкасы җайланыр.

Габделхәй Илһамга шаккатты. Ул аны бу көтелмәгән хәбәрдән өнсез калыр дип уйлаган иде. Ә Илһам берни булмагандай сөйләшә.

— Мин иртәгә сине яклап райкомга барам! — диде Габделхәй кызып.— Бюро бит бөтенесен үзгәртә ала.

Утырыштан чыкканда ук ул шундый фикергә килгән иде. Илһам башын чайкады:

— Вакытыңны әрәм итеп йөрмә,— диде.

— Нигә?

— Кирәкми. Мин гаепле... Караны ак дип ышандыра алмассың.

Алар беседкага керделәр. Габделхәй партком утырышының ничек үткәнен сөйләп бирде. Ул сүзсез генә тыңлады, йөз чалымнарыннан, кыяфәтеннән бернинди борчылу сизелерлек түгел иде. Әмма эчтән ул йөрәгенең кысылганнан-кысыла баруын, тамырларының кайнарлануын тойды.

Илһам кич ашап тормады, тамагым тук, диде. Бүтән көннәрне бакчада үзе ясаган душ астында юына, өс-башын алыша иде. Бүген керде дә веранда идәненә сузылып ятты. Халисә аның партиядән чыгарылуын Габделхәй белән ничек сөйләшеп торуыннан ук аңлады. Иренә ни әйтергә дә белмәде. Юатыр идең — хәленә керә торган түгел. Мондый чакта кеше үз вөҗданы белән үлчи, үз йөрәге белән ничек кичерсә, шулай кичерергә тиешлеген Халисә аңлый иде. Шуңа күрә ул йомышы булса да верандага кермәде, тавыш-тынсыз гына йорт эшләрен эшләде, әмма йөрәге сулык-сулык килде, туктаусыз күз яшьләрен сөртте.

Илһам уйларының очына чыга алмады. Иң әүвәл ул партком утырышына бармаганлыгына сызланды. Ә барып ни кырыр иде? Ярамаган эш

эшләнде — ул гөнаһлы. Ләкин күңеленең иң ерак, иң тирән, иң кайнар почмагындагы нindидер бер нечкә тойгы ул гөнаһны барыбер ярлыкап тора, аны аклый икән, моны ничек аңлатырга? Партком члennары бит ул тойгы турында сорамаячаклар, алар ташка басылган, һәркемгә билгеле кануннар буенча фикер йөртәчәкләр. Әгәр утырышта катнашса, кайсын тыңларга тиеш булыр иде Илһам: күңеленме, аларнымы? Аларның ни әйтәсен ул якынча белә иде. Аларныкы белән үзенеке капма-каршы килә. Димәк, үзеңнекен әйтергә, аларга җиткерергә кирәк. Ә мөмкинме соң ул? Һәммәсен дә без үлчәми, без белми торган бизмәннәр белән колачлап алган, әйтеп бирә алмаслык ул тойгыны ничек аңлатырга? Юк, моңа Илһамның көче җитми иде. Димәк, парткомга барган очракта, ул аларны тыңлап, «әйе, мин гаепле», дип утырырга, хәтта гафу үтенергә, ә эченнән шуның капма-каршысын уйларга тиеш булып чыгар иде. Иң сәере шунда, әгәр ул шулай эшләсә, аның партиядә калу ихтималы бермә-бер артачак иде. Бу хакта Биккинин аңа баштук сиздереп куйды. Әгәр үз гомерендә бер генә мәртәбә шулай кыланса да, Илһам кешеләрнең күзенә туры карый алмас иде. Йә үзеңнеке, йә аларныкы! Әгәр икесе дә бергә булса, яшәп тә торасы юк, бусы инде Илһам өчен партиядән чыгарылудан да хәтәррәк иде.

Юк, ул ялгышкан, аңа барыбер булмаган икән! Тыштан барысына кул селтәсә дә, эчтән, бик тирәндә ятучы нindидер бер көч аны партиядән чыгарылу ихтималы турындагы уйлардан читкә алып киткән иде. Ул бит теге чакта да Гөлзада Яхъя белән йөреп китәр, аңа кияүгә чыгар дип уйламады. Күңелнең ниш ләве бу? Үзен-үзе алдавымы? Әллә һәр чигенүен, куркаклыгын аклавымы?

Илһам төне буе керфек тә какмады. Ул үзенең шыксыз, кирәксез, шыр-шыр буш булып калуын тойды. Әйтерсең, эчендәге бөтен әгъзаларын, йөрәк-бавырларын алып ташлаганнар, бернинди теләк, бернинди омтылыш юк. Эчтәге бушлык, бер карасаң, кургаш кебек авыр, икенче карасаң, боз кебек салкын, йә булмаса дөрләп янган уттай кайнар иде...

Иртән аны урманга агач сөйрәтергә җибәрделәр. Ул әллә урманда, әллә диңгез төбендә йөрде — белмәде. Аны чолгап алган барлык дөнья, кешеләр, машиналар, агачлар, җәнлекләр, кошлар — һәммәсе дә төссез, җансыз, тавышсыз иде. Ул нәрсәләрдер сөйләште, сорады, җавап бирде, елмайды, ашады, эчте, әмма болар һәммәсе шәүләләр генә, син дә үзең түгел, әйтерсең, үткәндә дә берни дә булмаган, хәзер дә юк, киләчәктә дә булмаячак — бөтенесе буш, мәгънәсез, кирәксез, әһәмиятсез.

Илһам, эштән кайтып, шушыларның һәммәсен күз алдыннан уздыргач кына, бер әйберне аңлады: менә хәзер, чыннан да, аңа барыбер иде! Хәзер ни эшләтсәләр дә, ул берсүзсез риза иде! Аңа гомере дә, исеме дә, берние дә кызганыч түгел иде!

Нишләп болай булды соң? Сәбәп нәрсәдә? Тукта, боларның һәммәсе дә нindидер авыр йөкнең күңелне басып, сытып торуыннан ич! Ул һаман ныграк баса, ул баскан саен бүтән нәрсәләр турындагы уйлар киселә, барлык тойгылар, уй-фикерләр әнә шул авыр йөккә килеп чапырыша, башка дөнья күләгә төсле читтә кала... Кайларга барып, ничекләр котылырга бу йөктән?!

Әле караңгы төшәргә шактый вакыт бар иде. Илһам машинасына утырып чыгып китте. Үрнәк белән Үрмәш арасын үткәндә аның йөрәге бик нык чәнчешеп куйды. Менә хәзер шушында Акчарлак күле исән булсын иде! Үлде шул инде ул, мәңгегә юкка чыкты. Әтисе вафат булгач, Илһам үзенең кайгысын шул күл янына утырып таратты. Чөнки бирегә тып-тын, беркем юк, йөрәгеңнең сызлавы басылганчы җирдә ауный-ауный еларга да, башыңдагы авыр уйларны бер-бер артлы сүтәргә дә була иде. Гөлзаданың кияүгә чыгуын ишеткәч тә, Илһамны Акчарлак күле генә үзенең таң алсулыгына манылган сулары, җикән камышлары белән юатты... Үлде шул Акчарлак күле, мәңгегә юкка чыкты...

Илһам үткән көз үзе сөргән арыш басуына юл тотты. Борыла-сарыла

барган юл каен полосасына килеп чыкты. Илһам машинасын туктатты. Арыш полосаның теге ягында иде. Ул, каеннарны учы белән сөя-сөя, арыш басуына чыкты, эчкәрәк кереп сабакларның куелыгын, биеклеген карады. Арыш тездән булып кила, буынга сикерә иде.

Илһам полосага чыкты да, каенга аркасын терәп, үләнгә утырды. Яшел басу өстеннән талгын гына җил йөгерә. Башак кысарга, серкә очырырга да күп калмый. Сабан туйлары, печән өсләре генә үтсен, биредә чын бәйрәм башлана. Илһамның балачактан ук өзелеп ярата, көтеп ала торган бер вакыты бар: ул — арыш өлгергән чак. Илһам ихатадагы олы мәшәкатьләрне бетереп тора, каядыр барасы булса, алдан ук барып куя. Ул, арыш өлгергәндә, ажаган уйнаган кичне тәкатьсез булып көтә. Менә бер кичне ажаган уйный башлый. Илһам, бәйрәмдә генә кия торган киемнәрен киеп, арыш басуына китә. Басу ерак булмаса, җәяүләп, ерак булса, «жигули»е белән бара. Бара да, басуның әле эченә кереп, әле читенә утырып дөньяны күзәтә. Җирен дә, күген дә, офыкларын да күзәтә.

Арыш басуы аксыл диңгез булып җәйрәп ята. Җирдән көч алган саллы башаклар, бер-берсенә бәрелеп, акрын гына кыштырдыйлар. Ашыгаашыга төрле якта чикерткәләр сайрый, аларның тавышы, бер карасаң, җилгәргеч машинаның калай иләгендә икмәк җилпегән шикелле яңгырыйлар, икенче карыйсың, бик еракта ашыга-ашыга чалгы чүкегән һәм янаган кебек тоела, өченче карыйсың, сандугачның чут-чут итеп тел чатылдатканын хәтерләтәләр. Шушылардан башка шылт иткән тавыш та юк. Күк белән басу тоташкан җирне әле бер, әле икенче урыннан гөлт итеп алсу яктылык камчылап ала. Бу серле яктылык туктаусыз уйный да уйный. Ул балкыганда алсу нур белән читләнгән болытлар, ерактагы офыклар, күк гөмбәзе сиңа таба якынаеп-якынаеп куя. Акчарлак күленең өсте дә шәфәкъ баткан, таң аткан чакларда нәкъ шундый төстә була... Ажаганның һәр балкышы арыш сабаклары арасына, камыл төпләренә кереп сүнә, югала. Әйтерсең, табигать үсемлекләрнең тамырларына ут өрә, яктылык бөрки, аларны чыныктыра. Күпме сер, күпме хәрәкәт, күпме нур һәм нинди тынлык! Илһам шушы арыш камчылау күренешен хәйран калып күзәтә. Мондый күренеш тылсымлы әкиятләрдә генә була. Ажаган җир белән, арышлар белән элемтәдә, ул нидер күзәтә, өзлексез яктыртып басуның төрле почмакларыннан нидер эзли кебек. Димәк, барысы да бергә, бу һавалар, җир-сулар, кояш-йолдызлар, җил-яңгырлар бөтенесе бергә яшиләр, хәрәкәтләнәләр, бергә кушылалар, аерылалар, безнең тамырларыбызга җылылык, яктылык, сүл булып керәләр, тереклек иярәренең җанын ажаган кебек уйнаталар. Хәер, ажаган камчылаганнан соң, арыш басуына да нидер була бит.

Илһам тагын бер нәрсәгә хәйран кала: яшәүнең бөеклеге, тормышның матурлыгы хакында табигать белән шушылай бер аваз чыгармыйча рәхәтләнеп аңлашып утырганда, арыш басуыннан ниндидер нечкә сагыш дулкыны килә башлый. Ул ныклап сизелерлек тә түгел, әмма ул бар, күңел аны тоя һәм аның нәрсәдән туганын әйтеп тә булмый... Ул сагыш шундый татлы, бәлкем әле генә сине тулаем биләгән тойгылардан татлырактыр да, һәм, ахры, шуңа күрәдер, сабый чактагы күз яше кебек ул бик тиз үтеп тә китә. Син аны яңадан көтмә, өметләнмә, ул инде булды, күңелеңдә үзенең татлы эзен калдырды, башка булмаячак, юк, көтмә дә, өметләнмә дә, башка ул килмәячәк, килсә дә, андый ләззәтле булмаячак.

Арыш басуында ажаган уйнаган чак булса, Илһам үзен борчыган сорауларга җавапны җиңелрәк табар иде. Чөнки ул чакта аның зиһене кылны кырыкка ярырлык булып сизгерләнә, хисләре нечкәрә, дәрт-дәрманы ургылып чыга. Хәзер исә Илһам авыр тойгылар басымыннан сытылган кебек булып калды. Уйларын кайсы баштан ничек итеп сүтмәсен, ул бер үк сорауларга килде дә төртелде: Ник яшәдең? Нәрсәгә ирештең? Бәлки, ул дөрес яшәмәгәндер? Бәлкем бу күңелсез хәлләрнең килеп чыгуы очраклы түгелдер? Әллә бөтен гомере мәгънәсезгә, кирәксезгә үтте микән?

Механизаторлар курсын бетергәч, Илһамга бер иске ДТ-54 тракторы эләкте. Ике көн дә эшләмәде, аның моторы шакылдап чыкты. Илһам икенче көнне таң белән моторны сүтеп атты. Моны күргәч, ул чакта трактор бригадиры булып эшләүче Биккининнең күзе бәрәңге булды:

—Син нишлисең, малай актыгы!? — дип кычкырды ул килә-килешкә.

— Мотор төзәтәм.

— Мин бит аны Хуҗәмәткә җибәрә идем. Сүтәргә кем кушты сиңа?!

Биккинин әшәке итеп сүгенде дә китеп барды. Аның тагын бер иске моторы бар иде, ремонтка шуны җибәрде.

— Моторыңны ташла, әнә чәчкечләрне кардан көрәп чыгарырга кирәк,— диде Биккинин.

— Миңа чәчкеч нәрсәгә? — диде Илһам аңа каш астыннан карап.— Тракторымны төзәтәм.

— Төзәтәсең... Нәрсәкәеңне! — диде Биккинин чыгырыннан чыгып.— Шәйбене гайкедән аера алмаган башың белән мотор җыярсың кая таба! Аңа гомер буе эшләгән абыеңнар да куркып кына тотына әле!

— Төзәтәм,— диде Илһам авыз эченнән мөгрәп.

Биккининнең аңа шул кадәр ачуы килде, ул аны акылга утыртырга уйлады.

— Төзәт! — диде ул җикереп.— Һәр көнеңә шымытыр язып барачакмын!


Илһам дәшмәде. Ул иң элек «Сельхозтехника»дан кемнәндер вкладышлар тапты, аларны үз акчасына сатып алып кайтты. Моторны бик яхшылап җыйды, күтәрделәр, куйдылар, ләкин аны кабызу түгел, ярты-лаш та әйләндереп булмый иде. Аңа өлкәннәр мыек астыннан, көлеп карап тордылар. Моторны тагын салдырды Илһам. Тагын җыйды, тагын барып чыкмады. Аптырагач, «Сельхозтехника»ның мотор җыю цехына китте, анда өч көн эшләде, өйрәнде. Терсәкле валны кырдырырга кирәклеген аңлады. Ул да булды, ниһаять, мотор кабынды, әмма май басымы бөтенләй юк иде. Тагын сүтте. Поршень боҗраларын алыштырды. Тагын барып чыкмады. Егерме көн эчендә ул моторны җиде мәртәбә алды, җиде мәртәбә сүтте, җиде мәртәбә җыйды, җиде мәртәбә куйды һәм мотор эшләп китмәсенме! Парктагы механизаторлар авызларын ачтылар да каттылар. Тракторларны язгы чәчүгә вакытында хәзерләмәгән өчен алдагы көнне генә идарәдә ярты сәгать буе Биккининнең «аягына сыер бастырганнар» иде. Гөрләп эшләп киткән моторны күргәч, аның авызы колагына җитте, тракторны үзе кузгатып, бераз йөреп килде.

— Рәхмәт, Илһам апай! Синә әйткән сүзләрем өчен сүксәң дә, суксаң да риза,— диде һәм язгы ташу тавышлары чыгарып сулый-сулый идарәгә йөгерде. Ул Илһамга күңеле йомшап кына егерме сум акча язган иде. Бухгалтериядәгеләр белән талаша-талаша кәгазьләрен кабат алды һәм аңа иң күп эшләгән механизаторлардан да артыграк итеп наряд язды. Шуннан соң Илһамга механизаторларның да, җитәкчеләрнең дә карашы үзгәрде. Ул, беренче урынга чыгам, дип беркайчан да кабаланмады. Җир сөрә икән — төрәнне күпме батырырга тиеш, шулай сөрде. Уракка чыкса, сыңар башакны да, бер грамм бөртекне дә югалтмаска тырышып эшләде. Башкаларның норманы икешәр-өчәр йөз процентка үтәвенә ул хәйран калды. Күпләр күзләре-башлары тонып гектарлар, центнерлар артыннан куды, җирне кадерсезләде, бик күп ашлык югалтты. Шуның өчен аларны газеталарда мактадылар, алар хөрмәтенә дан йолдызлары яндырдылар, аларга уч тутырып акча, кыйммәтле бүләкләр бирделәр. Бу хакта өлкән игенчеләр җыелышларда ачынып сөйләделәр, ләкин хәл үзгәрмәде, Илһамның шуңа эче янды.

— Чәчүне иртә срокларда бетерәбез!

— Уракны фәлән көндә тәгәллибез!

— Туңга сөрү буенча рапорт бирәбез! — дип һаман ашыктырдылар. Колхоз җитәкчеләре генә түгел, районнан, өлкәдән килеп тә ашыктырдылар. Илһам дәшмәде, алар ашыктырган саен үҗәтләнеп акрынрак эшләде,



*Алсу Тимергалина рәсеме*

һәр эшне вәземләп, җиренә җиткереп башкаруы белән аларның ачуын кабартты. Аның белән янәшә кишәрлектә эшләгәндә хурлыкка калучылар да аз булмады. Илһам тракторы, Илһам комбайны кергән җир ул инде әллә каян күлеп тора, аңа беркем дә, берничек тә бәйләнә алмый иде. Ничә еллар иген игү дәверендә аңа бер генә мәртәбә дә: «Нишләп ялгызым гына тырышам. Мин дә башкалар кебек акча куа башлыйм әле»,— дигән уй килмәде. Ул җиргә хыянәт итәргә теләмәде, әз генә ашыга-кабалана башласа да, җирдән ояла иде. Бу нинди тойгыдыр, ул ничек тәрбияләнгәндер — анысын Илһам әйтә алмый. Бәлкем иң ябык, бер тиен акчасыз елларда шушы җир үзенең ипекәе, бәрәңгесе, какылары, кәҗә сакаллары, балтырганнары, кычыткannары белән барысын да туендыргандыр? Бәлкем шушы басуда ялан аяк сабан сөреп, тырма тырмалап, чәчү чәчеп, урак урып, шуларның кайнар туфрагында йоклап, бер кан, бер тән булып беткәндер? Илһам өчен иң ямьле нәрсә — иген кырлары. Язын чәчү чәчкәндә дә, игеннәр яшел чакта да, өлгергәч тә, аларны урганда да, ургач та, сөргәндә дә, кыш көне дә матур басулар. Җир матур, су матур, күк матур, кояш матур, игеннәр матур. Бу җирне ул дөньяның бернинди байлыгына, матурлыгына да мәңге алыштырмаячак. Бу җирләр өчен ул җанын бирергә дә әзер. Шушы бәгыренә кереп утырган газиз нәрсәләрне һәм җирдән оялу тойгысын Илһам кемгә дә булса әйтергә кыенсынды, аны күңеленә бикләп йөртте. Чөнки җирдән генә түгел, бер-берсеннән дә ояла белми торган кешеләр барлыкка килде... Хәер, бәлкем аларның гаебе ул кадәр үк зур да түгелдер? Күбрәк! — дип сорагач, кеше дигәнең барешә шул. Җир белән игенчене бутый, бер-берсен суыта торган иң нечкә урын, Илһам уйлавынча, менә шушында иде.

## 10

Теге кичне Гөлзада белән Яхъяның бер-бер артлы парткомга килүе Солтановны сискәндереп җибәрде. Биредә бит әле мәхәббәт тә бар икән! Мәхәббәт кенә түгел, көнчелек тә бар икән! Кешеләр белән сөйләшкәч, Гөлзаданың теге чакта күз төбенең күгәрүен дә Яхъяның көнләшүе аркасында булырга тиеш, диделәр. Кистереп кенә беркем дә әйтә алмады, ә Гөлзаданың үзеннән мондый әйбер хакында сорау әдәпсезлеккә керер иде. Ничек кенә булмасын, Солтанов бер нәрсәгә төшенде: ул Илһам белән Яхъяның, аларның икесенә дә якын Гөлзаданың ни үткәндәге, ни хәзерге мөнәсәбәтләрен белмәгән һәм белми. Гөлзаданың Яхъя турында әйткәннәре аны бигрәк тә сагайтты. Ул сүзләр үзенең күңелендә өлгереп килә торган сизенүгә килделәр дә кушылдылар. Ә хаклыгын ничек тикшерергә? Тотты да РАПОның игенчелек һәм терлек азыгы хәзерләү бүлеге начальнигы, үзләренә туган тиешле Нәгыйм абыйсына шылтыратты. Хәл-әхвәл сорашкач, сүзне Яхъяга борды:

— Агрономнар арасында безнең Хаков ниндирәк урында йөри ул?

Нәгыйм абыйсының көлгәне ишетелде.

— Син бит Дәүләт Хәсәновичның аны ничек яратканын беләсең.

— Мине синең фикер кызыксындыра. Ләкин дөресен генә әйт. Бу бик мөһим.

— Беләсеңме, нәрсә...— ул туктап торды.— Бу бит телефоннан сөйләшә торган сүз түгел.

— Син аның турында телефоннан әйтергә ярамаган әйберләр дә өсти аласың, шулаймы?

— Шулай, билгеле.

— Рәхмәт, мин барысын да аңладым.

— Басуларыгызны нишләп солыча басканлыгы хакында да уйлап кара.

— Безнеке генә түгел...

— Бөтен бәла дә шунда шул — сезнеке генә түгел...

Сүз шуның белән бетте. Калганы күзгә-күз карап сөйләшкәндә ачыкланачак. Ә бәлкем кабат Мансур Рафиковның кылын тартып караргадыр? Илһам суккач, Яхъя тәгәрәп ятканда аның канәгатьләнгән шикелле карап торуы Солтановның күз алдыннан һич тә китмәде. Моңа кадәр сөйләшкәндә ул Яхъя белән Илһам турында бер яңа нәрсә дә әйтмәде.

Яхъя турында аның фикерен Солтанов тагын сорап карарга булды. Рафиков агрономнар бүлмәсендә иде, чакыру белән кереп тә җитте.

— Утыр әле, Мансур,— диде Солтанов аңа фамилиясе белән дәшмичә.— Безнең бу сөйләшү икебезнең арада гына калсын. Мин сине ипташләрчә киңәшкә чакырдым.

Мансурның гаҗәпләнүдән күзләре түгәрәкләнде.

— Әйт әле, Яхъя абый ошыймы сиңа?

— Ул барлык кешегә дә ошый,— диде Мансур сак кына.

— Анысы шулай. Агроном буларак син аның эшен ничек бәяләр идең?

Мансур аптырап, бүлмәдә башка кеше юкмы дигәндәй, як-ягына карап куйды, урындыгының бер почмагыннан икенче почмагына күчеп утырды. «Шулкадәр җайсыз утыра, әллә тагы урындыкка эләкмәгән дә инде».— дип уйлап куйды Солтанов.

— Синең үз фикерең кирәк. Бу хакта сине сер сыярлык егеткә санаганга гына соравым.

Мансурга беркемнең дә мондый сүзләр белән мөрәҗәгать иткәне юк иде әле. Әти-әнисе дә, мәктәптә дә, техникумда да, эшли башлагач та беркем дә аның фикерен сорап тормады. Һәм менә хәзер бу сүзләрне ишетү үтә сәер иде.

— Тыңлыйм сине, Мансур.

— Әгәр миңа... чыннан да ышансагыз...

— Ышанам, билгеле.

Мансур уйланып торды да:

—Яхъя абыйга икмәк тә, бәрәңге дә, терлек азыгы да кирәкми,— диде.

— Моны ничек аңларга?

— Баш агроном түгел, җир корыткыч ул! Чәчүлек орлыкны бухгалтерия кызларыннан чүпләтеп чистарта да лабораториягә төшерә. Аннары безнең орлыкны мактыйлар...

— Ә син?

— Якага яка киләбез дә, мин Дәүләт Хәсәновичка керәм. Ул әйтә, районнан ашыктыралар, ди, яңадан тиешле кондициягә китербез әле, ди. Аннары шул килеш кала.

— Син аларның Илһам белән мөнәсәбәтләре хакында ни булса әйтә аласыңмы?

— Анысын белмим,— диде Мансур.

— Ярый, рәхмәт сиңа. Минем янга кергәләп йөр.

Аны озату белән Солтанов Биккинин янына керде. Ул телефоннан сөйләшә иде, трубканың авыз турындагы башын учы белән каплап:

— Апукаев шалтырата,— диде.

— Болында көтәбез, болында,— дип сөйләшүен дәвам итте Биккинин.— Яшел масса атна-ун көнсез өлгерми әле. Борчак әйбәт буласы иде дә...

Телефонда Апукаевның бик каты кычкырган тавышы хәтта Солтановка да ишетелде. Биккинин чытырдап торган трубканы колагыннан читкәрәк алды һәм йөзен җыерып теләмичә генә тыңлады.

— Аңладым, Сәгыйть Мөбәрәкович, аңладым...

Биккинин трубканы куйды.

— Иртәгә бюрога килгәндә сыер башына йөз грамм сөт арттырып киләсез, ди. Соңыннан сөт буенча бик кискен сөйләшү булачак икән.

— Азыктан башка сөтне арттырып булмаганын, минемчә, райкомның икенче секретаре белергә тиештер,— диде Солтанов.

— Ул бит идеология секретаре, белеп тә бетермәскә мөмкин,— диде Биккинин, астыртын елмаеп.— Син бюро члены, мин колхозыгызны күз уңында тотучы секретарь буларак, без дә арттырмасак, ни йөзебез белән хуҗалык җитәкчеләре каршына чыгарбыз, ди. Каршы килеп кара аңа...

Солтанов аның кая таба бөккәнен бик яхшы аңлады.

— Ялган сводкага исәп тотмагыз, Дәүләт Хәсәнович,— диде ул.— Элеккесе үтте, бусы үтмәячәк.

— Җитмеш килограмм сөт — диңгездән тамчы бит ул, Фәһим Солтанович.— Биккинин кул селтәп куйды.— Ә менә районның башка хуҗалыкларын кузгатырга кирәк. Иртәгә бит сезгә дә эләгәчәк. Ә шул йөз грамм коткарачак... барыбызны да.

— Ун граммга арттырып күрсәтергә уйласагыз да, бюрода басып әйтәчәкмен.

Секретарьның бу сүзләре Биккининнең кулына урак белән китереп чапкандай итте. Аңа әйтүенә эчтән үкенеп бетә алмады ул. Белмичә калыр иде әле. Дөрес, май бәйрәме тирәсендә күпертелгән сан биргәнне Солтанов сизде. Ләкин бит ул центнер ярым иде. Арттырып бирелгән сөт элегрәк икешәр-өчәр тоннага җитте, аңа беркем дә сүз әйтмәде. Райкомнан, авыл хуҗалыгы идарәсеннән шулкадәр сөтнең артуы мөмкин түгеллеген белә торып кысалар иде. Район җитәкчеләре Казанга пленумга, сессиягә, киңәшмәгә чакырылса, якты йөз белән барырга тиеш дип кысалар: күбрәк чәчелсен, күбрәк урылсын, күбрәк тапшырылсын, сөтне әйтеп тә торасы юк. Алар Казанда ике көн торсалар, ике көн буе, өч көн торсалар — өч көн буе саннар гел артып, үсеп торсын, аларны анда тиргәрлек булмасын — бусы мәҗбүри таләп иде.

Хәзер мондый нәрсәләр белән шаяру ут белән уйнау кебек хәтәр. Саннарны әз-мәз арттырырга тәвәккәлләсә дә, бик сирәк, чиктән тыш авыр хәлләрдә генә, үтә нык саклык белән генә тәвәккәлли Дәүләт Хәсәнович. Апукаев белән дә шаярырга ярамый, бу парторг малайдан да барысын да күтәргә була. Аңа гомер буе берничә ут арасында яшәргә язгандыр, ахрысы. Яңадан башлап булса, нишләргә кирәген белер иде дә ул, юк шул, соң инде. Председатель булып эшләвенең бишенче елында Дәүләт колхозга тимер торбалар сатып алды. Законлысы юк иде, законсыз юл белән таптылар. Шул торбалар белән ындыр табагына түбә ясадылар, техника өчен өсте ябулы урын төзеделәр. Үрнәк урамнарына су үткәрделәр. Ә аннары җинаять эше кузгатылды, бер ел буе ОБХССка, прокурорга чакырдылар. Ул ашаудан-эчүдән калды, чәче агарды, ике баласыннан, Мөшәрәфәсеннән аерыласын уйлап, төннәр буе сызды. Әгәр район җитәкчеләре, бигрәк тә Апукаев якламаса, ул әле хәзер дә ирекә чыкмаган булыр иде. Шул чакта ул хөкем юлында йөрүнең нинди хәтәр нәрсә икәнен аңлады, үз гомеренә куркып калды, югарыдан әйтелгән бер генә сүзгә дә карышмас булды. Карышса, торбаны искә төшерделәр. «Кесәңә генә салма, эш эшләнсен»,— дип юл күрсәткән кешеләр үзләре үк, җинаять эшең кабат кузгалырга да мөмкин, дип котны алдылар. Карышудан файда юк, артка юл киселгән, абынып муеныңны сындырсаң да, алга атларга кирәк иде. Колхозда финанс законнарын әйләнеп үтеп салынган тораклар, башкарылган бүтән эшләр дә аз булмады. Казысыннар гына — аягың бүген дә җиргә тимәячәк. Ә кем башлап җибәрәсен белгән юк. Шуңа күрә Дәүләт Хәсәнович мондый хәтәр мәсьәләдә Солтанов белән дә каршылыкка керергә теләмәде.

— Сез хаклы, Фәһим Солтанович,— диде ул.— Мин үзем дә өнәмим аны. Иртәгә ни ишетсәк тә ишетербез.

Биккининнең үзен тыңлавына Солтановның күңеле булды. Ләкин аның керүе моның өчен түгел иде.

— Без Шаһзамановның персональ эшен тикшергәндә бер мөһим якны искә алмаганбыз.

— Нәрсә ул? — диде Биккинин башын артка ташлап һәм күзләрен йомып. Бик нык арыганда аның кешене шулай тыңлый торган гадәте

бар иде.

— Яхъя Илһамнан көнләшә икән бит. Аның хатыны белән Илһам яшь чакта...

Биккинин аның сүзен бүлде:

— Моны кем белми?— Күзләрен акрын гына ачты да өстәп куйды:— Хатыны чибәр. Яхъя көнләшә. Илһам белән Гөлзаданың бернинди гөнаһы булмаса да, көнләшә.

— Миңа беркем дә бу хакта әйтмәде,— диде Солтанов үпкә белдергәндәй.

— Бу бит берни дә үзгәртми.

— Ничек кенә булмасын, аны бюрода әйтмичә ярамый.

Моңа кадәр тыныч кына утырган Биккинин дөртләп китте:

— Кирәкми, кирәкми! Нәрсәгә ул? Нигә мәсьәләне катлауландырырга?!

— Киресенчә... Һәммәсе дә билгеле булырга тиеш.

Солтанов хаклы иде. Персональ эш материалларында бу нәрсәнең эзе дә булмаган килеш. Солтанов бюрода чокып чыгарса, Биккинингә хаклы рәвештә: «Сез нишләп партком утырышында ул турыда дәшмәдегез?» — дигән сорауны бирәчәкләр иде. Шуңа күрә ул:

— Без болай килешик, Фәһим Солтанович,— диде.— Җае чыкса, ул хакта мин үзем әйтермен.

— Җае чыкмаса да, әйтергә кирәк,— диде Солтанов.

Сөйләшү шуның белән тәмам булды. Аннары Солтанов техника паркына юл тотты. Шаһзамановка иртәгә бюро икәнлеген әйтергә кирәк иде. Ул бүген дә урман тарттырырга киткән булып чыкты. Солтанов кичкырын аның өенә килде. Илһам эштән кайткан, абзар-кура арасында йөри иде. Кул бирешүсез генә күрештеләр.

— Әйдәгез, өйгә керегез,— диде Халисә болдырга чыгып.

— Рәхмәт, Халисә апа, мин бер генә минутка.

— Алайса бакчага керик,— диде Илһам.

Алар беседкага кереп утырдылар.

— Кем эшләде? — диде Солтанов, беседканың оста итеп бизәкләнгән һәр җиренә сокланып.

— Буш чакта үзем маташтырган идем.

Алар тынып калдылар. Казлы буеннан берөзлексез бакалар чырылдаганы гына яңгырап торды.

— Беләсезме... иртәгә бюро. Сезнең шәхси эшегез каралачак.

Солтановка бу сүзләрне әйтү гаять авыр булды. Чөнки Шаһзаманов үзенең зәңгәр күзләре белән аның күзләренә сынап, бернинди каушаусыз карый иде. Бу караш шулкадәр тыныч, гөнаһсыз, ышанычлы иде ки, Солтанов ирексездән: «Гаепле кеше болай карый алмый»,— дип уйлады.

Халисә аларга ике йомры чәй, конфет, варенье, ипи һәм сөт өстеп китереп куйды.

— Төштән соң сәгать икедә башлана... Сезне эштән азат итәрләр.

— Нигә эш калдырырга? — диде Илһам, Солтановның күзләреннән карашын алмыйча.

— Анда сезнең язмышыгыз хәл ителәчәк.

— Минем язмышым сезне борчыймы?

— Сез бит мин җитәкләгән партоешманың коммунисты.

— Мин хәзер коммунист түгел инде,— диде Илһам тимер тавыш белән.

Әйтерсең, аның өчен барыбер иде.

— Әле бюро бар бит.

— Анда нәрсә? Мин эш көче буларак кирәк.

— Ялгышасыз,— диде Солтанов ашыгып. Илһамның бу сүзләре аның йөрәгенә барып кадалды.— Минем теге чакта ук сезнең белән ачыктан-ачык сөйләшәсем килгән иде, теләмәдегез.

— Ә мин сез теләмәдегез дип уйлап йөрим тагын,— Илһам ничек-

тер балаларча беркатлы итеп елмайды.

— Ничек мин?! Ничек мин?!

— Сез бит һаман шул бер нәрсәне төпчендерез,— диде Илһам. Анна-ры житдиләнеп калды.— Райкомда кәгазьләр тәртиптә булмаса, ай-яй, каты эләгә диләр. Мин бюрога бармыйм. Бирегез бер бит кәгазь, язам.

— Бәлки уйлап карарсыз? — диде Солтанов.

Илһам дәшмәде. Солтанов аңа ручка һәм папкасыннан алып кәгазь сузды.

— Кем исеменә? — диде Шаһзаманов, җайлап утыргач.

— Партия райкомы бюросы исеменә.

Ул һәр хәрефен зур авырлык белән куя-куя, юлларның тигезлеген бик үк саклый алмыйча гариза язды. «Шәхси эшемне үземнән башка каравыгызны сорыйм».— диде дә имзасын куйды.

— Числосын бүгенгенеме?

— Әйе.

Гаризаны папкасына тыгып, чәй өчен рәхмәт әйткәч, ул аңа соңгы мәртәбә мөрәҗәгать итте:

— Шулай да уйлагыз әле. Мин сезгә барырга киңәш итәр идем.

— Юк.

— Хушыгыз.

Солтанов зур гаепле кеше кебек башын иеп, әллә нинди авыр тойгы-лар белән чыгып китте.

## 11

Алар Халисә белән ихатадагы эшләрне тәгәлләп, мал-туарны карап кергәндә, караңгы төшкән иде инде. Солтановның ник килгәнлеген, үзенең гариза язуын Илһам Халисәгә йокларга яткач кына әйтте.

— Ник бармыйсың соң? — диде хатыны.

— Бер кискән ипи кире ябышмый.

Иренең ике сөйләшергә яратмаганын белгәнгә күрә, Халисә башка сүз катмады.

Илһам иртә белән су буена төште. Өстән бик күе тоелса да, аста томан аша сукмак та, елга ярының кызыл балчыгы да, өянке ботаклары да күренә иде. Аяк астына карап барган җирдән нәрсәдер сизенеп ул ба-шын күтәрде һәм туктап калды. Берничә адым ераклыкта, аның нәкъ кар-шысында Гөлзада басып тора иде.

— Илһам! — диде ул ялварулы тавыш белән.

— Гөлзада?!

«Бирегә нишләп йөрисең?» — димәкче булды Илһам, ләкин бу сүз-ләрнең урынсыз икәнен сизеп, әйтмәде. Аның биредә басып торуына, дөресен әйткәндә, ул шатланды. Гөлзаданы кайда гына очратса да,— идарәдәме, урамдамы, башка урындамы — аның бөтен барлыгын әйтеп аңлатмаслык җылылык били. Үзенең шул халәтен сиздермәс өчен андый чакларда ул йөзенә таштай битарафлык чыгара, салкын кыяфәт кертә. Илһам хәзер дә тыштан караганда тып-тыныч иде. Гөлзада белән очрашу шатлык китерсә дә, җиңел түгел, ай-һай, җиңел түгел аңа!

— Илһам! — диде Гөлзада өзгәләнеп.— Сиңа бюрога бармыйча яра-мый! Мин сине шушыны әйтү өчен сагалап тордым.

Илһам аптырап калды. Иртүк, елга ярында Гөлзада килеп чыгар да шушы сүзләрне әйтер дип кем уйлаган? Бу бит башка да китерерлек түгел. Аның барырга теләмәвен каян белеп өлгергән ул? Башында мең сорау, күңелендә әллә ничә төрле тойгы бөтерелсә дә, Илһам бары тик:

— Юкка сагалагансың, Гөлзада,— дип кенә куйды.

— Синең читтә калырга хакың юк! — Гөлзада дулкынланудан кул-ларын селкеп куйды.— Син үзеңне үзең якларга тиеш!

Илһам аңа гаҗәпләнеп карап торды. Гөлзада башын аска иде дә

пышылдап акрын өстәп куйды:

— Инде бирсен югалттык бит.

— Нәрсәнең бирсен? — диде Илһам аңламыйча.

— Бәхетнең. Мин сине мәңге онытмаячакмын...

Гөлзаданың ике бите кып-кызыл булды. Илһамга бу сүзләрне ишетү рәхәт тә, кыен да иде. Ник ул моны бик күп еллар элек, икәүдән-икәү шаярышып йөргәндә әйтмәде икән?!

Гөлзада серле итеп елмаеп җибәрде дә, күзләрен шуклык белән уйнатып:

— Ә син минем ни өчен гел ал төстән киенгәнемне беләсеңме? — диде.

— Ю-ук,— диде Илһам һәм сизмәстән аңа ияреп елмайды.

— Ә син уйлап кара.

Гөлзаданың йөзе тагын җитдиләнде, хәтта ул менә-менә елап җибәрер төсле иде. Нечкә сагыш, әрнү белән ул болай диде:

— Без бит... бергә була идек...

— Мин гаепле,— диде Илһам аның сагышын җиңеләйтергә теләп.

— Юк, мин гаепле, мин! — диде Гөлзада.

Кинәт ул ике кулы белән Илһамның уң кулын электереп иркәләргә, учларын, бармакларын үбәргә тотынды. Илһам бөтенләй коелып төште, ни кулын тартып ала алмады, ни бер сүз әйтергә теле әйләнмәде. Гөлзаданың кайнар иреннәренең һәр кагылуы аның кулын гына түгел, бөтен тәнен пешерде. Үзенең шушылай берни эшли алмыйча тору әйтеп бетергесез кыен һәм оят иде.

Гөлзада аның кулын чытырдатып кыскан килеш ялварулы карашын төбәп:

— Әйт, бюрога барасыңмы? — дип пышылдады.

— Барам,— диде Илһам әлеге сүзнең мәгънәсенә ныклап төшенүдән битәр бу кыен хәлдән котылу өчен.

— Рәхмәт.

Гөлзада аның кулына соңгы мәртәбә иреннәрен тигерде дә йөгерә-йөгерә яр өстенә менеп китте. Илһам әле бик озак айный алмыйча томан эчендә басып торды. Хәтта ул: «Төш күрәмме әллә?» — дип тә уйлап куйды.

Ләкин бу өн иде. Бюрога бармаска дигән карарны ул үзе өчен инде күптән кабул иткән иде. Гөлзаданың бүгенге сүзләре, җитмәсә үзенең «барам» дип әйтеп ташлавы аны төрле уйларга салды. Бәлки, чыннан да, нидер эшләп булыр? Барысын да аңлата алмаса да, нәрсәдер әйтә ала бит ул. Гөлзада иртүк торып, аны сагалап, аның өчен нидер эшләргә тырыша, бәргәләнә, ә ул үзе гамьсез йөри бирә. Илһам тагын бер нәрсәгә хәйран калды: ничә еллар буе Гөлзада аның ал төс яратуын онытмаган. Гөлзаданың ал күлмәк, ал кофта киюен, ал яулык, ал шәл бәйләвен ул күреп йөрде, ә үзе өчендер дип башына да китермәде. Гөлзада аның турында уйлый, аның өчен куанып, аның өчен борчылып яши, үзен һаман да Илһам белән бергә итеп тоя. Моны белү чиксез рәхәт иде. Бүген Илһамның иң бәхетле көне түгел микән?

Паркка кергәндә ул Габделхәй белән очрашты.

— Бүген бюро дип ишеттем,— диде иптәше.

— Анда баруның файдасы шуның кадәр генә инде,— диде Илһам кулын селтәп.

Габделхәй кинәт ярсып китте:

— Юләр сүз сөйләмә!

Аның ярсуына Илһам уң як ирен чите белән генә елмайды.

— Барырга кирәк дисеңме?

— Бармыйча калалармы соң?! — диде Габделхәй тагын да кайнарлана төшеп.— Күзгә-күз карап, ачыктан-ачык сөйләшергә кирәк.

— Ярый алайса, барырга икән, барырга,— диде Илһам, ныклы карарга килеп.

Төш турында Илһам машинасын гараждан чыгарып куйды, аннары душта коенды, ап-ак күлмәк, вак шакмаклы өр-яңа костюм-чалбарын киде. Партия билетын беренче мәртәбә күргәндәй озаклап, битләрен ак-тара-актара карады. Фоторәсеме бик яшь, бала-чага кебек тоелды. Әллә аз гына елмайган да инде? Туйганчы караганнан соң гына билетын күкрәк кесәсенә салды. Халисә өйдә юк иде, моңа Илһам шатланды гына. Ичмасам аңлатып торасы булмады. Борчылып, ут йотып йөрмәс. Әнисенә дә: «Район үзәгенә барып кайтам!» — диюдән артык берни дә әйтмәде, ә үзе авыл башына җиткәч, район үзәгенә баручы шоссега менмәде, аны аркылы чыгып, басу юлына төште. Теге төндә үзен гөнаһлы иткән борчак җирен күрми торып, ул бюрога бара алмый иде. Илһам матур гына булып тишелгән бодай, арпа басуларына сөенеп карап барды. Ниһаять, «Жигули» балтырган чокыры буеннан барды да туктап калды. Илһам машинасыннан чыкты һәм бер адым да атламыйча борчак басуына карап торды. Ул культивацияләнгән килеш кап-кара булып ята, анда берни дә чәчелмәгән иде. Каяндыр бер сары күбәләк очып килеп чыкты. Ул, әле югары күтәрелеп, әле түбән төшеп, кара җир өстенә кереп китте, нидер эзләгәндәй, әле бер якка, әле икенче якка очып бөтерелде, ял итмәкче булып туфрак өстенә якынайды, ләкин, кунарга сыңар үсемлек тә тапмагач, тагын очып китте, айкалды, чайкалды, үрелде, бөтерелде дә юл буена чыгып былтыргы кәрешкә үләненә кунды.

Аны бүгенге бюрога китергән нәрсә шушы басудан башланды. Ягулык фильтрын куйгач, караңгы төшкәндә культиватор тагып, ул бирегә килде. Аны яшел «Москвич»ы белән Яхъя куып җитте. Ул чакта Бәчә Фәргате белән Рашат, борчакны ике кишәрлеккә бүлеп, шактый культивациялә-гәннәр иде инде. Басу буена туктап, тракторыннан төшкәч, Илһам шаккатты. Борчак шырпы кабы биеклеге үскән, аны мүк кебек солыча каплап киткән иде. Илһам белән Яхъяны күреп, Бәчә Фәргате дә килеп җитте.

— Бүген төнлә бозып бетерергә кирәк,— диде Яхъя, туфля үкчәсе белән борчакны изеп.— Иртәгә тары чәчәбез. Синең кишәрлек теге таяктан башлана.

— Ярый торган эш түгел бу! — диде Илһам ямь-яшел басу өстенә Фәргать белән Рашат киң итеп сызган ике кара тасмадан күзен алмыйча.— Һич югы малга ашатырга кирәк моны.

— Аны мин дә уйлаган идем дә,— диде Фәргать сүзгә кушылып.— Бөтен җиргә иген чәчелгән — көтү кертерлек түгел.

Илһам Фәргатьне ишетмәгәндәй Яхъяга карап сүзен дәвам итте:

— Дүрт-биш көн көтәргә кирәк, бераз баш калкытсын, аннары чабып ташырга була.

— Бөтен кеше юләр, син генә акыллы инде,— диде Яхъя үпкәләүле тавыш белән.— Тары соңара! Аңлыйсыңмы? Соңара!

— Ә шушы кадәр байлыкны туфрак белән күмдерү оят түгелме?

Бәчә Фәргате көлеп җибәрде.

— Син турысын гына әйт инде, Илһам: бүген ашка барасы бар иде диген...

Фәргатьнең бу сүзләре Илһамның җенен чыгарды. Яхъя кабызу ачкычы белән машинасының канатына чык-чык суккалап астыртын гына елмая иде. Яхъяга әче генә бер-ике сүз әйтәсе килсә дә, Илһам тыелып калды. Аның Яхъя белән беркайчан да телгә килгәне юк, әчтән бик кыҗраган, рәнҗегән чаклары булса да, халык башкача аңлар дип, дәшми кала. Үз-үзен «мин җебегән, мин чүпрәк», дип битәрләп яшәү бик кыен, тәмам туйдырган иде.

Ул ачу белән басу эченә кереп китте, артта сузылып кара җир калды. Аның уң ягының бер урыны дерт-дерт тартышты, куллары трактор рычагын чытырдатып кысты. Яхъя «Москвич»ы белән борчакны ярып эчкә үк кереп китте, төшеп бер көпчәгенә типкәләп алды, аннары басуны

ярып чыккач, күздән югалды. «Әгәр кайтып китсәң?» — дигән уй килде Илһамның башына. Ләкин нәрсә үзгәртә ала соң ул? Биккинин дөньяга сыймас. Бүген төнлә булмаса, иртәгә көндез боздырачаклар. Ә Фәргать: «Эчәргә барырга була, төнге сменадан әбиләренә качты»,— дип сөйләп йөриячәк. Сәбәп кенә булсын. Илһам хакында Бәчә берне ун итеп сөйләргә генә тора. Җай чыккан саен аның үзенә бәйләнеп, төрттереп торуның сәбәбен Илһам бик яхшы белә. Кул ачуын онытмый ул.

Фәргать малай чактан ук кешегә бәйләнде. «Берне бәчәм бит!» — дип кул күтәрде. Шуннан ябышты да инде аңа Бәчә кушаматы. Юньләп исеме белән әйтмәделәр. «Әнә, Бәчә килә, берне бәчмәсен»,— диләр иде көлеп. Зурраклар, көчлерәкләр аның үзенә дә: «Нихәл, Бәчә!» — дип җибәрәләр иде. Фәргатьнең йә авызы җимерелгән, йә күз төбе күгәргән була. Егет булып җиткәч, кесәсенә пәке тыгып, эчеп, бәйләнеп йөрүеннән авыл халкы гарык иде. Ә теге хәл клубта ниндидер бәйрәм алдыннан булды. Фәргать әле берәүгә, әле икенче кешегә бәйләнеп йөри иде. Илһам клубка керде дә ишек янына басты. Бервакыт Фәргатьнең кулында пәке ялтырап китте, кыз-кыркын пырхылдашып ишеккә ташланды. Фәргать Илһам каршына килде дә:

— Юлдан кит! — дип кычкырды.

— Ташла пәкеңне,— диде Илһам күзен дә йоммыйча.

Фәргать пәкесе белән аңа кизәнде. Илһам аның кулына яннан сугып җибәрде. Фәргатьнең кулы чартлап стенага бәрелде, пәке очты, ул авыртуга түзә алмыйча:

— А-а-а! — дип кычкырды.

Аның кулы бик нык чәрдәкләнгән булып чыкты. Фәргать әллә ничә ай буе больница юлын таптады, врачлар аның кулын өч мәртәбә сындырып, өч мәртәбә ялгадылар. Шуннан Фәргать ник бер тәртип бозсын ла! Күп тә тормастан өйләнде. Тик барыбер бер гадәте бетмәде: кеше белән исәпләшү, хәл-әхвәл сорашу дигән нәрсәләр аның өчен кирәкмәгән, юк нәрсә булып калды.

Бәчә нәрсә ул! Илһамның җанын башка нәрсә борчый. Әйтерсең лә, янәшәңнән икенче тормыш — син белмәгән, син эченә керергә тиеш түгел тормыш ага. Анда барысы да дөрес хәл ителгән була, каршы бер сүз дә әйтә алмыйсың — моңа хакың да, акылың да юк... Бу басуга борчак чәчәр алдыннан Сәләхетдин абый Яхъяга әйткән, солычасы тишелгәнне көтик, аннары кабат эшкәртеп чәчәрбез дигән. Ләкин аны тыңламаганнар. Элеккерәк заманнар булса, бер басу борчакны харап иткән өчен агрономлыктан кудырырлар, судка бирерләр иде...

Ул бер мәртәбә дә туктамыйча эшләде, күңелсез, авыр уйлардан башы тубал булды, чигә тамырлары сулык-сулык типте. Төне буе баш очында кургашындай авыр болытлар асылынып торды. Иртәнге күк йөзе ачылып китте, таңның беренче ал нурлары сузылганда һавада өем-өем каурый болытлар гына калган иде. Озакламас, урман артыннан кояшның кызыл түбәтәе дә күренер. Шулчак Илһам җиргә игътибар беләнрәк карады да, нидер сизенеп тоpакторын сүндерде. Ул сикереп җиргә төште һәм, ялан аяк үткен әйбергә баскандай, шаккатып калды: борчак рәхәтләнеп чабып алырлык иде! «Бәлкем бу урында гына шулайдыр?» — дип уйлады ул һәм йөгерә-йөгерә басуның уртасына кереп китте. Ул әле бер якка, әле икенче якка ташланды. Фәргать белән Рашат бозган урынны да карап килде. Борчак барлык җирдә дә биек иде. Басуның алар кереп киткән ягында гына сабак тәбәнәк булган икән. Илһам әле генә үзе ергычлап киткән җирдәге һәм культиватор табаннарындагы озын-озын сабакларга карап хәрәкәтсез катып торды. Инде басу көл-күмер китерелгән, тагын берничә әйләнүгә өч урындагы тар яшел юл да бетәчәк иде... Яхъя бит борчакның чабып алырлык икәнен алдан ук белгән, басу уртасында ул юкка гына туктап алмады. Димәк, юри алдаган. Фәргать белән Рашатка арба ватылса утын, үгез үлсә ит, аларга кушсалар, башагы саргайган игенеңне сөреп атудан да тайчанмаслар...

Илһам җиргә тезләнде, бармакларын туфракка батырып, борчак сабакларын көрәп алды. Туфрак эчендә бүртеп, дым алып шыткан, тамыр җибәргән, кояшка урелә-урелә үсә башлаган, талгын май җилләрендә иркәләнеп утырган шушы тере үсемлекләрне алар туракладылар, издeләр, юк иттеләр... Илһам ергычланган җиргә капланды, беләкләре белән туфракны үзенә таба сыдырып китерде һәм иякләрен, яңакларын шул туфракка ышкый-ышкый елап җибәрде. Ул тавышсыз гына, ыңгырашып елады, күз яшьләре кара җиргә, борчак сабакларына тамды. Җирдән оят иде, җирдән гафу үтенеп тә булмый иде. Ә аның баш очында, алсу болытлар астында очына-очына сабан тургае җыр сузды. Тургай җиргә бер якынаеп, бер ерагаеп иртәнге сәгатьләрдә генә була торган иң моңлы, иң дәртле авазлар чыгарып, җирдәге кешегә мөрәҗәгать итте, ләкин ул аны ишетмәде. Илһам, башын күтәргәч, һавада тирбәлүче кара ноктаны күрде, әмма аны ишетмәде, сыкрап йөрәге типкәнне ишетте — тургайны ишетмәде. Башының шаулавын ишетте — тургайны ишетмәде, үзенең өзек-өзек хырылдап сулыш алуын ишетте — тургайны ишетмәде, баш очына килгән алсу болытларны күз яшьләре аша күрде, тургайны күрде, әмма ишетмәде.

Ул акрын гына җирдән күтәрелде, кагынмады, җиңе белән битен сыпырды. Бу җирдән тизрәк качарга теләгәндәй, тракторына менеп утырды. Тукта, Яхъя, тары соңара, диде. Аны чәчү вакыты кайчан әле? Карабодай белән бер чамада — июнь башларында да чәчкән бар тарыны. Бүген майның егерме сигезе генә. Әле бит атна-ун көн бар! Димәк, борчакны малларга бүген үк чабып ашата башларга мөмкин булган. Ничек соң моңа Илһам хәзер, эш узгач кына төшенде. Яхъя әйткәч, уйлап та карамады?! Бу бит гап-гади нәрсә. Ярый, җир уйламасын, туфракка күмдерелгән бөртек уйламасын — алар барыбер үзләренең мәңгелек зирәк эшләрен башкаралар. Ә син? Син бит уйларга тиеш идең, диде Илһам үз-үзенә. Нәкъ шуңа исәп тоткан да инде Яхъя. Ул уйламасыңны белеп алдаган, шуңа күрә астыртын елмайган да. Ул теләсә нинди боерыкны сүзсез кабул итәчәгеңне белеп торган, үзенең гөнаһларын яшерер өчен басуны харап иттергән. Илһам гомере буе бер эшенә дә хыянәт кертмәде, җир каршында намусым пакь дип яшәде. Бәлкем, ул үзенең күпчелек гомерен шушылай кемнәрнеңдер гөнаһларын каплау өчен тырышып үткәргәндер, җиргә кадер-хөрмәт күрсәтәм дип, үзе дә белмичә, уйламыйча, аңа зарар гына салгандыр?

Илһам, тракторын җен урынына кузгатып, авылга ашыкты. «Өрлектәй гәүдәң белән, тау кадәр трактор йөртеп, орчык буе Яхъядан көлдергәч, чын ахмак, ачык авыз мин!» — дип битәрләде ул үз-үзен. Аның ничә еллар буе җыелып килгән иң әрнүле сүзләрен Яхъяның йөзенә бәреп әйтәсе килде.

Бая кәрешкә үләненә кунган сары күбәләкнең нәкъ аның йөзе турына килеп бөтерелүе Илһамны уйларыннан айнытып җибәрде. «Яз көне сары күбәләк күргән кеше сагыштан саргаеп үлә»,— ди торганнар иде алар бәләкәй чакларда. Ул бу сүзгә ышанмады, ләкин барыбер сары күбәләк күргән саен күңелендә гомер буе нииндидер эчпошыргыч тойгы уянып куя. Илһам ашыгып сәгатенә күз төшерде: ике тулып биш минут киткән иде. Машинасын борып, бар көченә район үзәгенә куды.

## 13

Тормышта без белмәгән, галимнәр әле ачмаган закончалыклар күптер. Шуларның берсе — кешегә иң кыен чакта кырынлык китерүче яшерен көч. Иблис кебек рәхимсез бу көчнең барлыгы Биккинин өчен бәхәссез иде. Апукаевның, йөз грамм сөт арттыр, дип шалтыратуыннан соң әлеге көч үзенең астыртын эшен эшләде. Иртәгә бюро дигән көнне кичтән трансформатор янып, ике ферма да электрсыз калды. Сыерларны кулдан

саварга туры килде, шунныктан сөт кимеде. Ярый әле Биккинин подстанция башлыгының өенә барды, ялынып-ялварып, бөтенесен аякка бастырды, төнлә булса да яңа трансформатор куйдылар. Кичтән нервы туздырып, чабулап йөреп, соң гына кайтып ауды. Бюро көнне болай да иртә торучан булса да, бүген ул сәгать өчтә үк күзен ачты. Әле керфегеннән керфек аерылганчы ук башына килгән беренче уе сөт булды. Ул йокысын бөтенләй качырды һәм Биккинин, юынып та тормастан, машинасы белән фермаларга юл тотты.

Ул идарәгә кайтып кергәндә алты тулмаган иде әле. Урындыгына килеп утырырга өлгермәде — телефон шылтырады. «Апукаев» дип уйлады ул һәм дөрес тә булып чыкты.

— Сәлам, Дәүләт Хәсәнович,— диде ул.— Я, шатландыр мине.

— Шатландырырлык хәбәр юк шул, Сәгыйть Мөбәрәкович,— диде Биккинин авыр сулап.

— Башка хәбәр кабул ителми. Син шуны беләсеңме? — Апукаевның көр тавышы кисәтүле төс алды.

— Кичтән ике фермада электр булмады,— диде ул аңлатырга теләп.— Сиксән өч килограмм сөт кимеде...

— Мин моны ишетергә дә теләмим, белергә дә теләмим. Аңладыңмы? Биккининнең түземе бетте.

— Син миңа нишләргә кушасың соң, Сәгыйть Мөбәрәкович?! — диде ул тавышын шактый күтәреп.— Әгәр булса, савып бирер идем дә бит — юк!

Апукаевка шәһәрара телефон станциясеннән кемнедер тоташдырдылар һәм аларның сөйләшүе өзелде. Биккинин моңа сөенде генә. Тик унбиш минут үттеме-юкмы, Апукаев кабат шылтыратты. Бүлмәдә бу вакытта нарядка җыелган белгечләр, бригадирлар, башка актив утыра иде.

— Я, нәрсә? — диде Апукаев.

Биккинин аның нәрсә теләгәнен бик яхшы сизде. «Ялган сводка бирмим!» — дип ярып саласы килде аның. Ләкин бу кадәр халык алдында ничек әйтәсең?

— Әйттем бит инде...

— Мин аңламыйм, син нәрсәгә исәп тотасыңдыр, Дәүләт Хәсәнович. Башлар очканны күреп торасың, ә үзгәрмисең.

— Куркытма әле, Сәгыйть Мөбәрәкович.

— Мин куркытмыйм, кисәтәм генә,— диде Апукаев һәм салкын гына көлеп куйды.— Син ат белән крестьян турындагы мәсәлне беләсеңме? Крестьянның җиргә солы чәчүен күреп, ат аны эттән-эткә салып тиргәгән, наданлыкта гаепләгән. Бүген, бөтен кеше бер олы эш белән мәшгуль чакта, син шул атны хәтерләтәсең. Ләкин син, Биккинин, ул аттан мең мәртәбә наданрак һәм ахмаграк! Син — үткән гасыр кешесе. Хуш!

Апукаев трубкасын куйды. Биккинин бер сүз әйтергә дә өлгермәде. Аңа бүлмәдәгеләр елмаешып куйдылар кебек тоелды. Әллә ишеттеләрме? Ул нарядны юньләп бирә алмады, күрәсең, кан басымы күтәрелде: ике чигәсе кысты, башы әйләнде. Нарядны эштер-өштер бетерде дә, кырынып-юынып та тормастан, рульгә үзе утырып, район үзәгенә элдерде. Апукаев бүлмәсенә барып кергәндә анда пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире Минсалихов һәм ике инструктор утыра иде. Биккинин рөхсәт-мазар да сорамады, исәнләшеп тә тормады, туп-туры түргә узды.

— Бераз сабыр итегез, Дәүләт Хәсәнович,— диде Апукаев.

Ул сабыр итә алмаганга, йөрәгенә чыдый алмаганга килгән иде шул.

— Син кешене ничек мыскыллаган да ярый дип уйлыйсың! — Бик каты кычкырудан аның колакларына кадәр кызарды.— Син ничә еллар буе идеология секретаре булып утырган буласың, ә үзеңдә идеологиянең «и» хәрефе дә юк!

Тыныч кына сөйләшеп утырган Минсалихов белән инструкторларга бу аяз көнне яшен суккан кебек тәэсир итте. Алар берни аңламыйча аптырашып, әле Апукаевка, әле Биккининга карап тордылар.

— Син үзеңнең кайда икәнеңне онытып җибәрәсең, ахрысы, Дәүләт Хәсәнович,— диде Апукаев тыныч кына.

Әмма Биккинин аның ни әйткәнен дә ишетмәде. Ул, Апукаевның нәкъ каршына килеп, полировкаланган өстәл өстенә башта сейф ачкычларын, аннары колхоз печатен ыргытты. Печать каядыр почмакка чәчрәп очты.

— Әнә печать, әнә ачкычлар, бар да утыр, үзең җитәклә колхозны!

Кинәт Апукаевның моңа кадәр тыныч йөзе ачулы кыяфәт алды.

— Хәзер үк бүлмәне бушатыгыз! — диде ул боерып.

— Әйтәсе сүзләремне әйтеп бетергәч, мин үзем үк чыгармын!

Апукаев бер сүз дәшми телефоннан номер җыйды.

— Дежурныймы? Апукаев бу. Хәзер үк наряд җибәрегез әле. Минем бүлмәдә бер хулиган бар.

Ул трубкасын атып бәрде. Биккинин өнсез булып калды.

— Син мине... мине милиция белән озатмакчы буласыңмы?! — диде ул бер агарып, бер күгәреп.

— Ә нәрсә эшләргә кушасың? Син безгә эшләргә комачаулыйсың.— Апукаев кулы белән Минсалиховка һәм инструкторларга күрсәтеп алды.— Комачаулаучыларга карата көч кулланырга туры килә.

— Ярар! — диде ул сулышына буылып.— Син дә фәрештә түгел!

Биккинин ишекне тибеп кенә ачты да чыгып китте. Ул райкомның беренче секретаре Мөхәммәтовка керергә булды. Ләкин кабул итү бүлмәсендә СМУ начальнигы белән райплан председателе көтеп утыра, тагын кемдер бар иде. Ул, коридорга чыгып, әрле-бирле йөри башлады.

Өч минут үтмәгәндер, астагы пыяла ишекнең ачылып ябылганы ишетелде. Аннары таш баскычтан шык-шык атлап ике милиционер күтәрелде һәм Апукаев бүлмәсенә кереп китте. Алар шундук чыктылар, тагын шык-шык басып түбәнгә төшеп киттеләр. Биккинин вестибюль тәрәзәсеннән урамга карады. Милиционерлар зәңгәр билле машиналарына утырдылар да кузгалдылар. Ул гаҗәпләнүдән башын чайкап куйды.

Кабул итү бүлмәсендәге кешеләрнең әле берсе дә кермәгән иде. Торабара Биккининнең башында икенче уй туды. Нигә керергә кирәк соң әле беренчегә? Ярар, кердең ди, сөйләп бирдең ди, мыскыл итте: милиция чакыртты, дип зарландың ди. Мөхәммәтов Апукаевны шелтәләде, тиргәде ди. Шуннан ни үзгәрә? Апукаев ачкыч белән печатьне беренче өстәленә кертеп салырга да күп сорамас, ә төптәнрәк уйлаганда, ул шулай эшләргә дә тиеш. Юк, һич тә керергә ярамый инде бу бүлмәгә. Сөт кимегән килеш бигрәк тә.

Әле апрель башында гына аларны сөт җитештерү мәсьәләсе буенча бюрода тикшерделәр. Шул чакта ук ярты еллык планның үтәлеше кыл өстендә икәнлеге ачык күренә иде.

— Хәлне төзәтербез, планны үтәрбез,— дип вәгъдә бирде Биккинин.

Бюродан соң Мөхәммәтов Биккининне дә, Апукаевны да бүлмәсендә калдырды һәм болай диде:

— Мин сезгә, Дәүләт Хәсәнович, нәсел эшен үз кулыгызга алыгыз, шунсыз сөт җитештерүдә борылыш булмаячак дип, моннан өч ел элек әйткән идем. Моны эшләмәдегез. Сез дә, Сәгыйть Мөбәрәкович, үзегезнең җаваплылыктагы колхозга тиешле ярдәм күрсәтмәдегез, ахрысы.

Телефон шылтырады һәм Мөхәммәтов кем беләндер сөйләшә башлады. Биккинин белән Апукаев башларын игән килеш бер-берсенә каш астыннан гына карап утырдылар. Беренченең сүзләре хак иде. Сөйләшеп бетергәч, ул болай диде:

— Искечә эшләп булмый, Дәүләт Хәсәнович. Яки эш стилегезне үзгәртергә, яки...— ул уйланырга вакыт калдыргандай дәшми торды.— Башка юл юк. Мине аңлагансыздыр дип уйлыйм.

— Аңладым, Ярулла Ильясович.

— Алайса хушыгыз. Уңыш телим. Сезгә дә чыгарга мөмкин, Сәгыйть Мөбәрәкович.

Беренченең сүзләре: «Кызым, сиңа әйтәм, киленем, син тыңла»,— дигән кебегрәк яңгырады. Шуннан соң Апукаевның килсә килеп, килмәсә телефоннан сөт турында сөйләшмәгән бер генә көне дә булмады.

Юк, беренчегә керергә ярамый иде!

Урамга чыгып, машинасын акрын гына кузгаткач та уйларыннан арына алмады ул. Апукаевка каршы сикереп берни дә кыра алмаячагын яхшы аңлый Дәүләт. Әмма ачу чыкканда ул истә торамы соң! Пенсиягә китәр вакытың якынлашканда, әллә ни тырпылдар чама юк шул. Хәзер соң инде председательлекне ташларга. Үзе ничә еллар буе тәпәләп эшләткән егетләрнең кулы астында калса, ни буласын яхшы аңлый ул. Картайган арсланга куян да тибеп китә. Күпне күргән Дәүләт моны тәнендәге һәр күзәнәге белән тоя. Эшли башлаган заманнарда ул көне-төне чаба, һәммәсенә өлгерә, бөтенесен хәл итә иде. Тора-бара бер хакыйкатьне аңлады: планны үтәсәң — син кеше, планны үтәмәсең — кеше түгел. Беренче очракта сиңа кадер-хөрмәт, дан, мактау, икенче очракта — тукмалу, тиргәлү, хурлану. Планны үтәсәң — һәммәсе дә гафу ителә, үтәмәсәң — бөтен тырышкан-тырмашканың тәгәрмәчкә таяк тыгу санала. Шуннан чыгып караганда, нишләргә кирәге ап-ачык. Игенчелек ничектер җиңелрәк барды. Бәлкем, Дәүләтнең үзенең техниканы белүе дә, читтән торып авыл хуҗалыгы институтының агрономия бүлеген тәмамлавы да моңа азмы-күпме ярдәм иткәндер. Иллә мәгәр терлекчелек, бигрәк тә сөтчелек тармагы, аның өчен карурман кебек аңлаешсыз тармак булып калды. Сөт планын, күрше республикадан ак май сатып алып, шуны район сөт заводына тапшырып үтәгән чаклар да булмады түгел. Бер елны хәтта кайсыдыр колхоз председателе кулдан түләп сатып алып кайткан бер тонна май алты хуҗалыкның сөт планын үтәргә җиткән, дип сөйләделәр. Беренче колхоздан шул бер тонна майны завод кабул итеп ала да икенче хуҗалыкка бирә, тегесе акча түли. Ә май завод буфетыннан халыкка сатылган итеп документлаштырыла. Сатып алган колхоз майны тагын үзенең сөт планы хисабына заводка китерә. Аннары чират өченче колхозга җитә. Кәгазьдә барысының да планы үтәлә, тик сөт кенә артмый. Йон эзләп тә күршеләргә чыккан чаклар булды. Ләкин ул чорлар артта калды. Хәзер инде тау башына менеп, бүре булып уласаң да юк алар.

Идарә турына кайтып җиткәч, ул хәйран калды: кайчан, кайсы юлдан, ничек кайтылган? Хәтерен күпме генә эшләтеп караса да, Дәүләт моны исенә төшерә алмады һәм аңа куркыныч булып китте: берәр җирдә бәрелеп яисә авып хәзергесе минутта кан эчендә үлеп ятсаң? Ул бүлмәсенә кергәч тә тынычлана алмады. Җитмәсә, баш бухгалтер акча күчерү өчен порučениегә мөһер басарга дип керде.

— Сейф ачкычын таба алмыйм,— дип алдашты Дәүләт.

«Печать Апукаевта, районга баргач, шуның янына кереп чыгарсың»,— дип булмый бит инде. Үч иткән кебек, шуны гына көткәндәй, иртәдән төшлеккә кадәр аның бүлмәсенә туктаусыз халык агылды — кайсы районнан, кайсы Казаннан — һәм барысына да сейфтагы документлар кирәк тә мөһер кирәк. Күбесе белән кычкырышып бетте, әйтеп аңламаганнарын бүлмәсеннән сөреп чыгарды. Ярты көн буе эченнән Апукаевны каргады, барысына да шуны гаепләде, аннары әлеге кешеләрне сүкте, шуларның бөтенесе арасына кыстырып үзенең тетмәсен тетте. Сәгать икедә бюрога килеп кергәндә аңарда кеше кыяфәте калмаган иде инде...

## 14

Илһам эченнән никадәр ашыкса да, йөрәге ничек кенә еш-еш типсә дә, райком ишеген кыюсыз гына үзенә таба тартты, шапылдатмыйча гына япты, икенче катка аяк очларына гына басып күтәрелде. Шул чак аны кулына берничә бит кәгазь тоткан Апукаев куып җитте.

— Ашыгам,— диде ул үтеп барышлый аның җилкәсенә кагылып.—

Ышаныгыз: мин бары тик гаделлекне генә яклаячакмын!

Ул елмаеп үтеп китте, ә Илһам туктап калды. «Минем хакта әйтә,— дип уйлады ул.— Танышың булсам да, берни эшли алмам»,— диюеме әллә?

Апукаев көн саен булмаса да ике көннең берендә Илһамнарның колхозына килми калмый. Төп-төз озын гәүдәле бу кеше халыкка үзенең таләпчән булуы белән билгеле. Аның Биккининне дә, башка җитәкчеләрне дә колхозчылар күз алдында шыбыр тиргә батырганчы тиргәгәне бар. Сәгыйть Мөбәрәковичның чал чәчләре дә, чарлап утыртылгандай төз борыны да, туктаусыз хәрәкәтләнүче соры күзләре дә бик килешеп тора. Аның юка иреннәреннән барысын да аңлап була: нәрсәнедер ошатмаса, иреннәре кысыла, нindидер мәсхәрә билгеләре чыга; хупласалар — калынаеп, тынычланып кала. Илһамны сокландырганы тагы шул — Апукаев яңгырдамы, тузандамы — һәрвакыт ап-ак күлмәктән, кара галстуктан һәм чем-кара костюм-чалбардан, ялтырап торучы туфлялардан булыр. Илһам аны үз гомерендә бер генә мәртәбә таушалган, пычранган киемнән күрде. Узган көз яңгырлы салкын бер төндә ул тунга сөрә иде. Бервакыт трактор каршына Апукаев килеп чыкты. Машинасы Чәмчәле әрәмәсе буенда баткан, бензины беткән икән. Яшәәсендә ак плащлы бер хатын-кыз да бар иде. Бик нык туңганлыктан, аны К-700 кабинасына меңгерделәр. Апукаев рульгә утырды. Хатын юл буе авызын ачып бер сүз катмады, йөзен яшерергә теләгәндәй, башын гел читкә борып барды, район үзәгенә кергәнче үк саубуллашмый-нитми төшеп калды. Сәгыйть Мөбәрәкович Илһамны мәҗбүриләп квартирасына алып керде. Ишек төбеннән үк аларны бик чибәр, яшь хатын каршылады. Ул кай арададыр Илһамның сырмасын, фуражкасын салдырып элеп тә куйды. «Кызы» дип уйлаган иде Илһам, ялгышкан булып чыкты.

— Карчык, өстәл әзерлә әле,— диде Сәгыйть Мөбәрәкович.

Аларның өйләре алты почмаклы зур гына агач йорт иде. Ике як стена түшәмнән идәнгә кадәр китап белән шыплап тулган. Бу кадәр китап Үрмәш китапханәсендә дә юк иде.

— Шаккатмагыз,— диде Апукаев аңа.— Мин башкалар кебек затлы келәмнәр, чүпрәк-чапрак, ялтыравыклы җиһазлар җыймадым. Сез китаплар карый торыгыз, мин хәзер...

Илһам бер калын гына китапны алып актара башлады. Ул гаҗәеп төсле матур рәсемнәр белән бизәлгән иде.

— Яңарыш чорында әнә нинди гүзәл әсәрләр иҗат ителгән! — диде Сәгыйть Мөбәрәкович «Посольский» шешәсеннән ике рюмкага эчемлек салып.

Өстәлгә кыздырылган тавык ите, ак май, сыр, кызыл балык һәм башка ризыклар куелган иде инде. Аның хатынының җитезлегенә Илһам хәйран калды. Апукаев рюмкаларга балчык шешәдән бальзам тамызгач, Илһамны өстәл янына утыртты.

— Әйдәгез, тотыйк әле.

Алар рюмкаларын чәкештерделәр. Сәгыйть Мөбәрәкович тиз генә эчеп куйды, Илһам иренен дә тигермәде.

— Сез нәрсә, Шаһзаманов, мине хөрмәт итмисезмени? — диде ул юка иреннәрен кысып.

— Рәхмәт, Сәгыйть Мөбәрәкович...

— Борчылма, кирәк булса, милиция үзеңне озатып куяр.

Илһамга шушындый зур кешедән кыстатып утыру ничектер кыен иде. Ләкин барыбер бирешмәде:

— Рульдә эчкәнем юк,— диде.

Апукаев төрлечә кыстап карады да, файдасы юклыгын белгәч, үзе тагын бер рюмка салып куйды.

— Сез мине гафу итегез, мин бик туңдым, арыдым,— диде ул аклангандай итеп.

Аннары бая Илһам караган китапны алып, бөтен битләрен берьюлы

бөкте дә баш бармагы астыннан берәм-берәм чыгарырга кереште.

— Биредә хатын-кыз, ир-ат образларының камиллеген күрегез әле сез! — диде ул тирән дулкынлану белән.— Аларга табынмый, баш ими мөмкин түгел. Шаhзаманов, сезнең уйлап караганыгыз бармы: ни өчен элек шушындый шедеврлар туган да, хәзер юк, ә?

Илhам бер сүз дә әйтә алмады, наданлыгы өчен оялды. Аның белән Сәгыйть Мөбәрәковичның уйлары арасындагы ераклык җир белән күк аермасы иде — бусын ул яхшы тойды. Апукаев сүзен дәвам итте:

— Беләсезме, хикмәт нәрсәдә: ул заманда кеше үзен куәт иясе итеп сизгән, дөньяда үзенең бөеклеген аңлаган. Ә хәзер тормышның кан тамырларында машиналар, автоматлар, электроника йөри. Бөтенесе коточкыч тизлек белән хәрәкәтләнә, кайдыр ашыга, ә кеше шуның арасында ни эшләргә дә белми.— Сәгыйть Мөбәрәковичның соры күз алмалары нәрсәдер эзләгәндәй әле уңга, әле сулга хәрәкәтләнделәр.— Әлеге хәрәкәтнең дөньяны кая алып барганын югарыдан гына күреп була.

Илhам рәхмәт әйтеп урыныннан торды. Озата чыккач, Апукаев аңа кул бирде. Аның кулы бик кечкенә, бармаклары озын һәм үлгән кешенеке кебек салкын иде. Илhам хәйран калды: ул бит колхозга килгәч, аларның барысы белән дә кул биреп күрешә, әмма аның кулы мондый түгел иде! Әйтерсең, мәетнекенә алыштырганнар! Яңадан аны күргән саен Илhамның беренче уе нишләптер гел аның куллары турында булды.

Кабул итү бүлмәсенә шактый кеше җыелган, аларның берсе дә Илhамга таныш түгел иде. Ул аякларын шудырып кына диярлек секретарь кызга таба атлады, гүя аркасыннан кемдер этkәнгә генә килә иде. Кыз, Илhамның хәлен аңлап булса кирәк, аңардан нинди эш белән килүен сорады. Фамилиясен әйтүгә үк, аны бүлдерде һәм:

— Сез парткомиссиягә өлгермәдегез,— диде.— Хәзер бюрога керерсез.— Аннары коридорга таба борылды да: — Фәһим Солтанович! — дип дәште.

Шундук кулына дело тоткан Солтанов күренде һәм бөтенесенең игътибарын җәлеп итеп:

— Шаhзаманов?! — дип кычкырды.— Сез кайчан килдегез?

Үзенә төбәлгән күз карашларыннан Илhам кыенсынып куйды.

— Әле генә.

— Алайса... бюрога керергә булдыгыз?

— Әйе.

Бу яңалык Солтановны хафага гына салды. Парткомиссия членнары Шаhзамановның килмәвен зур гаепкә санадылар, аңа бирергә теләгән сораулар бирелмичә калды. Кичә баш тартып, бүген киресен уйлаган икән, Шаhзаманов бюрога ниндидер яңа нәрсә хәбәр итәргә җыенадыр. Солтанов аның йөзеннән шуңа җавап эзләде, әмма берни дә тапмады. «Нинди тыныч, салкын кеше бу?» — дип уйлады Солтанов. Илhамның уң кул тырнакларының канатырлык булып уч төбенә батып кергәнлеген ул күрмәде, әлбәттә...

Беренче секретарь бүлмәсеннән ике кеше чыгуга, секретарь кыз Солтановка мөрәҗәгать итеп:

— Керегез,— диде.

Илhамның тыны кысылып куйды, ул аркасына салкын тир бәрүен тойды. Солтанов дермантин белән тышланган ишекне ачты да аңа пышылдады:

— Әйдә, уз.

Илhам эчкә атлады, каршында тагын бер ишек бар иде, анысын үзе этеп ачты һәм алар яп-якты бүлмәгә килеп керделәр. Иң түрдә, сул як почмактарак, берничә кызыл байрак тора. Стенада төсле итеп эшләнгән Ленин портреты. «Т» хәрефе рәвешендә урнаштырылган өстәлнең иң түрендә райкомның беренче секретаре Ярулла Ильясович Мөхәмматов утыра. Аның алдынгылар слетларында Илhамга кулын кысып бүләк тапшырганы бар, төрле җыелышларда да, басуда да очраштыргаладылар.

Илhамга партия билетын да Мөхәммәтов бирде. Ул чакта аның чәчләре шомырттай кара, куе, күз төпләре дә хәзерге кебек күкшелләнеп тормый иде. Хәзер инде чәченә көмеш бәсләр кунган.

Аның каршысыннан ишеккә таба сузылган озын өстәлнең ике ягына кара-каршы бюро членнары утырган. Һәрберсенең алдында кызыл папка, ниндидер кәгазьләр. Аларның күпчелеген Илhам таный иде.

Солтанов, терсәгенә җиңелчә генә кагылып, Илhамны бюро членнары утырган өстәл каршына алып килде. Анда арка терәгеченә һәм утыргычына шакмаклы көрән күн куеп ясалган ике урындык тора иде. Алар икесе дә шул урындыкларга утырдылар. Илhам кабул ителү бүлмәсендә чакта, «кергәч исәнләшергә кирәктер», дип уйлаган иде, ул онытылган булып чыкты.

— Солтанов, эшне аңлатып бирегез,— диде Мөхәммәтов.

Солтанов, аягүрә басып делоны ачуга, дело тышы усак яфрагы шикелле калтырарга керешге. Фәһимнең бюрога үз гомерендә өченче мәртәбә, ә партком секретаре булгач, беренче тапкыр керүе иде — авызы кипте, теле әйләнмәс булды. Мөхәммәтов яшь секретарьның хәленә керде.

— Солтанов, каушамагыз,— диде ул сизелер-сизелмәс кенә елмаеп.— Монда иптәшләрегез утыра, беркем дә сезгә гаеп ташларга җыенмый.

Бу сүзләр үзенә әйтелмәсә дә, Илhам да тирән сулап куйды, йөрәге бераз урынына утырды. Солтанов та үзен кулга алды, эшне җентекләп аңлата башлады. Аның сүзләрен Илhам юньләп тыңламады, чөнки ул инде әле Солтановка, әле тикшерүчегә сөйли-сөйли бу нәрсәләрдән тәмам гарык иде.

Солтанов сөйләп бетерде, «Эш»не аның кулыннан алып Мөхәммәтовка бирделәр. Ул аны ачып, озак итеп актарды да башын күтәреп:

— Шаhзаманов! — диде.

Илhам ни эшләргә дә белмәде.

— Басыгыз,— диде кемдер акрын гына.

Ул урыныннан күтәрелде. Берүзенә шул кадәр кеше карап торганда басып тору коточкыч кыен иде. Илhам башын әле аска иеп, әле сулга — тәрәзәгә таба борып, күзләрен яшермәкче булды, тик үзенә төбәлгән кешеләрнең йөзләрен, гәүдәләрен кай төше беләндер барыбер күрде, алардан кача алмады.

— Сезнең өстәп нәрсә дә булса әйтәсегез бармы? — дип сорады Мөхәммәтов аңа туп-туры карап.

— Юк.

— Сезнең аңарда үчегез бар идеме? — диде Биктаhиров.

— Юк.

— Алайса ник суктыгыз?

Илhам дәшмәде.

Шулчак Апукаев тамак кырып куйды һәм әрләгән кебегрәк итеп:

— Син, Шаhзаманов, менә хәзер үзеңнең партиядә калу-калмавың хәл ителгәнне аңлыйсыңмы соң? — диде.— Сугуыңның сәбәбен яшерүең белән бюро членнары алдында эчкерлелек күрсәтәсең.

Илhам ничек аңлатырга, кайдан, нәрсәдән башларга да белмәде, бөтенесе бергә буталды. Ул инде әллә ничә мәртәбә кабатлаган, барлык сорауларны да канәгатьләндерүче әзер җавабын әйтте:

— Кызып кителгән...

— Ни өчен кыздыгыз? — диде Биктаhиров.

— Аракы эчкәнгә...

Шушы сүзләрне генә көткәндәй, Мирхәйдәров әләктереп алды:

— Димәк, сез партия карарлары белән килешмисез?

— Килешәм.

— Килешкәч?

Илhам үзенең ник килгәненә, ник бирегә кергәненә үкенеп куйды. Бу сораулар аңа мәңге бетмәс кебек тоелды.

— Эчәсе булмаган,— диде ул туры җаваптан качып.

Шулчак Солтанов сүз сорады.
— Шаһзамановның да, Хаковның да әйтәселәре килми. Аларның бәрелешүе Хаковның хатыны аркасында да булырга мөмкин,— дип башлады Солтанов караңгыда абына-сөртенә барган кеше сыман.— Ул кыз чакта Шаһзаманов белән йөргән, хәзер Хаков аны көнли, диләр.
Биккинин Солтановка күзенең агы белән карап куйды. Илһамның да ачуы килде. Әллә кайчан булган, онытылган нәрсәләрне шушы кадәр халык алдына ник чыгарырга иде?
— Дәлилләрегез бармы?— диде райком секретаре Имамиев.
— Юк, ләкин шулай сизелә.
— Без тойгыларны, сиземләүләрне шагыйрьләргә калдырыйк,— диде Апукаев.— Бюрога кергәндә алар ныклы аргументларга, дәлилләргә әверелергә тиешләр иде. Сезне хисләрегез Шаһзамановтан да ныграк адаштырырга мөмкин. Биредә утыручылар һәр мәсьәләне сиземләүләргә генә таянып хәл итә башласа, ни булыр иде? Мин моны сезгә — яшь секретарьга киләчәк өчен әйтәм.
— Утырыгыз,— диде Мәхәммәтов Солтановка. Аннары Илһамга мөрәҗәгать итте: — Шаһзаманов, секретарегыз әйткәннәргә ачыклык кертергә теләмисезме?
Илһам ни әйтергә дә белмәде.
— Дөрес түгел,— диде ул, уйларының ахырына чыгып җитмәстән.
— Солтанов алдашамыни? — диде Апукаев.
— Алдашмый,— диде Илһам, тәмам буталып.
Бу кадәр кеше аңа төбәлеп һәр сүзен көтеп торганда, ул ни генә әйтсә дә эләктереп алырлар, гаеп итәрләр кебек тоелды. Аның уйларын сизенгәндәй, Апукаев йомшак кына итеп:
— Оялмагыз, Шаһзаманов, монда бернине дә яшермиләр,— диде.
Сәгыйть Мөбәрәковичның сүзләре аңа көч бирде, ул дәвам итте:
— Яшь чакта Гөлзада белән дуслар идек. Яхъя белән ачуланышканыбыз юк. Гөлзада белән ике тапкыр очраштык.
Аның соңгы сүзләреннән соң бүлмәдә ниндидер тынычсызлану дулкыны үтеп китте, ул ирексездән чыккан күкрәк авазы кебек кыска, ләкин һәркемгә сизелерлек булды. Аны Илһам да тойды, эченнән: «Их, аңлата алмадым!» — дип үкенде. Сәгыйть Мөбәрәкович, тигез ак тешләрен күрсәтеп, авызының уң як чите белән генә елмайды. Бу елмаюда кыенсыну да, нәрсәдәндер тыелу да бар кебек иде.
— Сез әле бабник та мыни? — диде ул әллә шаяртып, әллә чын.
Мөхәммәтов кашын җыерып кисәк кенә Апукаевка карап куйды.
— Түгел,— диде Илһам.
Ул Сәгыйть Мөбәрәковичның үзеннән ни теләвен аңламакчы булып туп-туры аңа төбәлде һәм шундук җавап алды.
— Сез ник үз-үзегезне интектерәсез? — Аның тавышы шул кадәр дустанә, йомшак иде.— Барысын да әйтеп бетерегез. Ышаныгыз, Шаһзаманов: бу сезгә яхшыга гына булачак.
Илһам тирән итеп сулыш алды да:
— Без болай гына очраштык,— диде.— Беренче мәртәбә алар өйләнешеп кайткач. Гөлзаданың баласы бар иде инде.
Илһам туктап калды. Үзенең Гөлзада янына ник керүен ничегрәк әйтү турында баш ватты ул. Инде хәзер, болайга киткәч, яшереп калу, әйтмәү аның өчен мең мәртәбә авыррак булачак. Гөлзада белән аның намусын кешеләр алдында таплаячак иде.
— Мин аңардан... өйләнергә рөхсәт сорадым,— диде ул, ниһаять.
Бүлмәдән тагын ниндидер дулкын үтеп китте һәм баягыча ук авырттырып Илһамга килеп бәрелде.
— Ирле, балалы хатыннан ничек рөхсәт сорарга мөмкин?! — диде комсомол райкомының беренче секретаре Газизуллин кызып. Ул кулларын як-якка җәеп җибәрде: — Сез ни сөйләгәнегезне беләсезме?
— Ничек инде ярамасын,— диде Илһам. Аннары Газизуллинга карап,

бик җитди төстә сорау бирде: — Ә син сорамас идеңмени?

Газизуллин нишләптер кызарды, ык-мык итте. Илһам нәрсәдән икәнен аңлап та бетермәстән, бүлмәдәгеләр берьюлы пырхылдап көлеп җибәрделәр. Хәтта Мөхәммәтов та әллә елмаеп, әллә көлеп алды, күзләрен, төтен кергәндәй, еш-еш йомгалап кулъяулыгы белән сөртте... Биккининнең йөзендә генә бер генә якты нур да күренмәде, ул таш сын кебек дөм орынып утыра бирде. Көлү тынгач, кемнәрдер колактан колакка пышылдашып алды, кемнәрдер гаҗәпләнү белдереп баш чайкады.

— Икенче мәртәбәсендә бүген иртән очраштык,— диде Илһам.

— Аңлашылды, булды, Шаһзаманов,— диде Мөхәммәтов, аны кыен хәлдән коткармакчы булып.

Бу бүлмәдә ул сүз бирсә сөйлиләр, бирмәсә сөйләмиләр, ул җитте дип бер ишарә ясаса, шундук туктыйлар — беркем дә боза алмый торган тәртип шундый иде. Ләкин Илһам, беренче секретарьны да, башкаларны да гаҗәпләндереп дәвам итте:

— Мин әйтеп бетерәм,— диде ул.— Гөлзада бүген иртән мине эшкә барганда очратты. Бюрога бар дип ялынды. Шул менә...

Бүлмәдәгеләр тагын тынычсызланып алдылар.

— Сез ул ялынганга гына килдегезмени? — дип сорады орденлы хатын-кыз.

— Аңа гына түгел.

Берничә секундка тынлык урнашты, ләкин ул Илһамга иркенләп тын алырга да җитмәде. Халык контроле комитеты председателе Мирхәйдәров алтын кысалы күзлеген елтыратып сорау бирде:

— Шаһзаманов, әйтегез әле: быелгы социалистик йөкләмәгез нинди?

— 4500 эталон-гектар эш башкарырга,— диде Илһам моның ни өчен кирәген аңламыйча.

— Шуны күпмегә үтәдегез инде?

— Хәзер генә әйтә алмыйм.

Солтанов тагын кып-кызыл булды.

— Механизаторлар каршында быел лекция укыганнары бармы? — диде Мирхәйдәров.

— Юк...

Мирхәйдәровның мәсьәләне читкә алып китәргә маташуы пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире Минсалиховның эчен пошырды. Апукаевның чәнчеп карап куюы аны телгә китерде.

— Ярулла Ильясович, бер сорау бирергә мөмкинме? — диде ул беренчегә карап.

Мөхәммәтов баш кагып ризалыгын белдерде.

— Менә әйтегез әле: Хаков белән арагызда ачу булмагач, ни өчен сез аңардан гафу үтенергә теләмәдегез?

— Теләмәдем,— диде Илһам акрын гына.

Моңарчы тыңлап кына утырган РАПО башлыгы Әсраров та сорау бирде:

— Бу эшеңне ничек бәялисең?

— Әйбәт булмады инде,— диде Илһам башын аска иеп.

— Бөтен бәяң шулмы?

— Әйе.

— Үкенәсездер бит? — диде Минсалихов.

Илһам дәшмәде. Кайсы өлешенә үкенгәнен, кайсына үкенмәгәнен аңлатуы бик катлаулы, ерып чыгышлы түгел иде, шуңа күрә алдашырга теләмәде. Соравы һавада асылынып калган Минсалихов аптырап җилкәсен җыерды. Аның бөтен кыяфәте, «акланырга теләмисең икән, үзеңә кара», дигәнне аңлата иде.

— Клубыгызда әдәби кичәләр, тематик конференцияләр, диспутлар узамы? — дип сорады Мирхәйдәров.

Бу сорауга Илһам тагын аптырады, әмма бүлмәдәгеләрдән беркем дә гаҗәпләнү белдермәгәч, шулай кирәктер дигән карарга килде.

— Ишеткәнем юк.

Шулчак Апукаев бик хәтәр сорау ташлады:

— Әгәр сезне партиядә калдырсак, Хаковтан гафу үтенер идегезме?

Бөтенесе, Шаһзаманов ни дип җавап бирер икән дип, аңа төбәлделәр. Һәм бөтенесенең гаҗәпләнүенә каршы, Илһам көттереп-нитеп тормыйча:

— Юк,— диде.

Бүлмәдә чебен очкан тавыш ишетелерлек тынлык урнашты. Апукаев, аны юри бозарга теләгәндәй, ручкасы белән өстәлне һәр сүзе саен шакылдатты:

— Димәк, гафу үтенү сезнең өчен партиядә калудан югарырак? — диде ул.

— Юк.

Илһамның тавышы пышылдаган кебек кенә чыкты. Апукаевның бу сүзләреннән соң аңа нидер булды. Әйтерсең лә, шушы минутка кадәр үзе ышанган, таяныч санаган ниндидер зур нәрсә җимерелеп төште. Илһам үзе өчен коточкыч яңалыкны сиземли башлады. Ул яңалык Апукаев белән бәйле иде. Илһамның уң яңагы дерт-дерт тартышты. Кулы белән ул әлеге урынны ышкып алды, ләкин тартышу көчәйде генә. Илһамга бөтен кеше аның яңагына карап торадыр төсле тоелды.

— Гафу үтенсәм...— диде ул каушавыннан уйларын тәртипкә сала алмыйча.—...әгәр үтенсәм... партия билетымны...— Илһам күкрәк кесәсеннән нишләптер партия билетын алды, сул кулының учына алды.— Аны пычракка салып таптаган булыр идем...

Ул билетын кабат кесәсенә тыгып куйды, тыңлаусызга әверелгән бармаклары белән кесә авызындагы сәдәфен озаклап эләктереп маташты.

— Партия билеты сезнең горурлыгыгызны дәлилләү өчен бирелгән документ түгел, Шаһзаманов!

Бу сүзләрне кем әйткәнен Илһам абайламый калды, шуңадырмы, алар аңа әллә ни тәэсир итмәде. Күңелне иң борчыганы, йөрәкне иң сыкратканы әле генә үзенең телен яндырып тамган сүзләрдә иде...

— Мин берничә генә сүз әйтим әле, Ярулла Ильясович? — диде Мирхәйдәров.

Мөхәмматов «әйе» дигән мәгънәдә баш кагуга, ул торып басты. Илһам бу кешенең ике сөйләшмәгәнен, токкан җиреннән шартлатып сындырганын белә һәм аны күргән саен ниндидер хәвефләнү кичерә иде. Чөнки аның белән берничә мәртәбә бәрелешкәне, телгә килгәне бар. Соңгысы ике ел элек уттай урак өстендә булды. Мирхәйдәров килеп төште дә унөч комбайнны бер бодай басуына җыйнады.

— Сезгә, иптәшләр, партия райкомы бюросы исеменнән сугышчан задание алып килдем,— дип сүзгә керешге ул.— Шушы бодайны бүген иртән суктыра башларга һәм бетермичә туктамаска! Төнлә дә, кирәк булса — егерме дүрт сәгать буе эшләргә! Көч җитәрме шушыңа?

— Көч җитүен җитәр,— диде кемдер.

— Рәхмәт, егетләр, мин сездән бүтән җавап көтмәгән идем,— диде Мирхәйдәров.— Ә сәбәбе бик җитди. Колхозыгыз ике көн икмәк сату графигын өзде. Урак маневр сорый. Бу басуның бодае коры да, чиста да. Димәк, без аны турыдан-туры ашлык кабул итү пунктына озата алабыз. Басуда сезнең белән бергә төнлә барлык шоферлар, барлык җитәкчеләр эшләячәк.

Мирхәйдәров дәртләндерерлек итеп сөйләде, пленум карарларын да, бишьеллык планнарны да онытмады, икенче көнне редакциядән фотохәбәрче һәм журналист киләсен дә әйтте. Биккинин гына шатлана алмады, чөнки бу бодай — чәчүлек орлык өчен дип саклаган иң яхшы участок иде.

Бөтенесе дәррәү теземнәрне суктыра башладылар. Илһам гына комбайнын кабызмады.

— Сез нишләп кузгалмыйсыз, Шаһзаманов? — диде Мирхәйдәров аның янына килеп.

— Мин моңа каршы,— диде Илһам, шприцына салидол тутыра-тутыра.
— Ничек каршы?!
— Шулай. Ашлыкның яртысы җирдә калачак.
— Ә сез калдырмагыз!
Илһам дәшмәде. Мирхәйдәров шуны белмимени? Өер белән бер басуга килеп кергәч, нәрсә булганын Илһамның күргәне бар инде. Анда ата — улны, ана кызны белми.
— Мин сезне көтәм,— диде Мирхәйдәров.
— Кыстамагыз, иптәш Мирхәйдәров, мин кермим бу басуга,— диде Илһам.
— Ул чакта башка кеше керер.
— Керсен...
Илһамны Биккинин да кыстап карады, ул үз сүзендә катты, басуга кермәде. Икенче көнне аны комбайннан алдылар. Шул хәлдән соң Мирхәйдәров, механизаторлар белән кул кысып күрешсә, Илһамны йә күрмәмешкә салышты, йә читкә карап бармагының очын гына суза торган булды.
Юк, аңардан рәхим-шәфкать көтми Илһам. Мирхәйдәров алтын кысалы күзлеген салып, пыялаларын кулъяулыгы белән сөртергә кереште һәм сүз башлады:
— Сезгә ничектер, ә минә минем үземнең күңелдә бу бюро утырышы бик тә авыр тойгылар кузгатты,— диде ул.— Карагыз әле, нинди коммунистны партиядән чыгарабыз. Без бит Шаһзамановны беләбез. Мине бирегә кереп утырганнан бирле бер сорау борчый: ничек шушындый тайгак юлга баскан ул? Минемчә, иптәшләр, бөтен сәбәп эчүчелеккә каршы һөҗүмчән көрәш алып бармауда. Зинһар, дөрес аңлагыз, мин көн саен кешенең колак төбендә эчүчелекнең зарары турында тәкрарлап торуны әйтмим. Юк! Көрәш — ул культура учакларының төрле чаралардан гөрләп торуы. Безнең районда рахит бала хәлендәге физкультура-спортны әйтеп тә тормыйм. Лекторлар, агитаторлар халык арасына онытканда бер генә чыгалар. Ярышның ничек оештырылуын күреп торасыз: Шаһзаманов йөкләмәсенең үтәлешен дә белми. Самогон куган өчен апрель аенда бер коммунистны партиядән чыгардык... Әлбәттә, без бүген Шаһзамановны партия сафларында калдыра алмыйбыз. Әмма ләкин торгынлык дәвам иткәнне онытмыйк! Ул тәрбия эшендә, кешеләр җанында. Ул сазлык хәтта коммунистларны да үзенә суыра...
Мирхәйдәров утыруга, кайнарланып, Имамиев сүз сорады.
— Әйтегез әле, иптәшләр, без кая бармакчы булабыз болай итеп?! — диде ул торып басу белән.— Без бу иптәшне тикшерүгә шушы кадәр вакыт әрәм итәргә дә тиеш түгел идек. Шаһзамановның партиядә берничек тә кала алмавын эчүчелеккә каршы көрәш логикасы үзе үк әйтеп тора һәм шуның сезгә һаман барып җитмәве миңа һич тә аңлашылмый. Әгәр коммунист иртүк аракы эчә, хулиганлык кыла икән, партоешма халык арасында нинди тәрбия эше алып барырга мөмкин?!
Имамиев районда эшләнгән җинаятьләрнең, аварияләрнең, прогулларның ничә проценты эчүчелек аркасында булуы хакында сөйләде.
— Әлек йомшаклык, килешүчәнлек күрсәтүнең әче җимешләрен без әле һаман җыябыз,— диде ул чыгышны йомгаклап.— Моның тамырына балта чабарга кирәк. Партиядә эчкечеләргә урын юк!
Район Советы башкарма комитеты председателе Биктаһиров сүз сорады. Ул башын алга сузган хәлдә торып басты. Илһам аның бик кыска сөйли торган кеше икәнен белә иде. Нәрсә әйтер ул?
— Мин сезнең тәкъдим белән килешмим,— диде Биктаһиров.— Шаһзамановны барыбыз да беләбез. Аның кебек гадел эшләүчеләр күп түгел.
— Галимҗан Фазылович, партиягә эшләүчеләр генә кирәкми ләбаса! — диде Имамиев.
Биктаһиров сүзен дәвам итте:

— Анысын гына беләбез. Ләкин бер ялгышы өчен кешенең бөтен тормышын сызып атарга да ярамый.

— Аның тормышын берәү дә сызып атарга җыенмый,— диде Апукаев, карашын алдындагы кәгазьләреннән күтәрмичә генә.

— Партиядән чыгару, кем ничек уйлыйдыр, минемчә, сызып ату инде ул. Әгәр дә кеше партиягә нинди дер шәхси максатларын гына күздә тотып кергән булмаса, әлбәттә. Безнең алда кеше язмышы. Ун-унбиш елга якын безнең белән бер сафта тора. Монда минем үземә аңлашылып җитмәгән нидер бар. Шуңа күрә аны партиядән чыгаруга бөтен йөрәгем белән каршы.

— Сез нәрсә тәкъдим итәр идегез соң? — диде Имамиев.

— Минем әлегә конкрет тәкъдимем юк.

Шулай диде дә Биктаһиров урынына утырды. Шунда Биккинин белән Апукаев берьюлы сүз сорадылар. Ләкин соңгысы баскан иде инде. Ул, бер генә мизгелгә башын аска иеп, кара кашларын югары күтәрде, киң маңгае вак җыерчыклар белән капланды. Башын кискен генә селкеп, чал чәчләрен артка ташлагач, галстук төенен турылады, аны турылаганда уң як ирен почмагы, кулына ярдәм итәргә теләгәндәй, иягенә таба тартылып-тартылып алды.

— Партия матбугатында,— дип башлады Апукаев,— бүгенге үзгәртеп коруга консерватив караштагы торучылар хакында күп языла. Ләкин кайда соң алар? Кемнәр? Иң авыры — әнә шул кешеләрне ачыклау, күрү. Чөнки аларның күзгә бәрелеп торган негатив социаль йөзе юк, алар безнең белән янәшә торып эшлиләр, янәшә утыралар.— Ул бюро члennары-ның әле берсенә, әле икенчесенә күз төшереп алды.— Шаһзамановның персональ эше нәкъ менә шушы күзлектән чыгып, хәзерге чор таләп иткән югары сәяси сизгерлек яктылыгында каралырга тиеш. Син дә әйбәт, мин дә әйбәт, барыбыз да әйбәт, дип утырган чаклар үтте. Күреп торуымча, арабызда әле һаман либералланучылар, психологиясен үзгәртә алмаучылар яисә үзгәртергә теләмәүчеләр юк түгел.— Апукаев, нәрсәнедер читкә тибәргәндәй, кулын салмак кына селтәп куйды һәм сүзен дәвам итте: — Кыскасы, революцион үзгәрешләргә лаек кыю, батыр адымнар ясарга сәләтлеме без?! Кемнәрнеңдер моңа көче җитмәсә, алар тормыш арбасыннан төшеп калачак! Мине кайберәүләр, бәлкем, төп мәсьәләдән читкә китүдә гаепләрләр. Ләкин, миңа калса, бу шәхси эш аңлый белгән кеше өчен зуррак нәрсәләр турында чаң суга. Игътибарыгызны бик мөһим тагын бер якка юнәлтәсем килә: консерватив караштагы торучылар күп, ул гына да түгел, алар бердәм, берсе икенчесен теш-тырнаклары белән яклый, чөнки алар башкача яши алмый. Хәзер бәяләгез: Үрмәш коммунистлары ни өчен Шаһзамановны яклау позициясен ала? Утыз өч КПСС члены устав таләпләреннән читендерә алгач, Шаһзаманов ялгыз түгел! Аны яклаучыларның колхоз парткомында да, бирелдә дә булуы очраклымы икән? Бу да ниндидер хәвефле симптом турында чаң сукмыймы?

— Сез, Сәгыйть Мөбәрәкович, үз өстегезгә артык күбрәк алмыйсызмы? — диде Биктаһиров аны бүлдереп.

— Әйе, бернигә дә җавап бирмичә, читтән боерып йөрү заманнары үтте,— диде Апукаев бернинди каушаусыз.— Мин үз өстемә бик күп нәрсәләрне алырга телим һәм барысы өчен дә курыкмыйча җавап бирәчәкмен.

Илһамның йөрәге туктаган кебек булды, аның бөтен гәүдәсенең хәле китте, колагы томаланды, тешләре кысылды. Әйтерсең лә, дөньяның асты өскә әйләнде һәм моңа сәбәпче ул иде. «Ник килдем мин, ник килдем?!» — дип уйлады ул. Тик хәзер берни дә эшләп булмый, ул чарасызлыктан гаҗиз иде.

— Мине тагын бер нәрсә борчый,— диде Апукаев тынычрак тавыш белән.— Бу персональ эш «Маяк» колхозында партия эшенең начар куелуын, коллективта сәламәт атмосфера булмавын да күрсәтүче җитди сигнал. Хуҗалыкта әчүчелек фактларының һаман беткәне юк, хезмәт

дисциплинасы түбән. Бу нәрсә үзенең аяныч нәтиҗәләрен сөтчелек тармагында инде күптән күрсәтә. Тыштан карап торуга костюм өр-яңа, ә эче череп, сүтелеп беткән. Колхоз миңа шуны хәтерләтә.

— Эчлекне алыштыру вазифасын сез үзегезгә алмыйсызмы соң? — диде Биккинин, аңа күзенең агы белән астан өскә карап.

— Ә сезгә тәнкыйтьне күтәрергә кирәк, Дәүләт Хәсәнович,— диде Апукаев кисәтеп.

Мондый урынсыз тәнкыйтьне түгел, гадел сүзне дә күтәрерлек хәле юк иде Биккининнең. Ул бюро башланганнан бирле өстәлнең каршы ягындагы Апукаевның чыраен күрмәс өчен ишек ягына карап утырды. Аның йөрәге ярылырлык дәрәҗәдә талкынган, нервлары пружина кебек киеренке иде. Ул үзен яклап Мөхәммәтов берәр сүз әйтер дип көтте, ул дәшмәгәч, чын-чынлап рәнҗеде.

— Сүземне йомгаклап шуны әйтәм: без Шаһзамановны берничек тә гафу итә алмыйбыз,— диде Апукаев шатлангандай дәртле тавыш белән.— Партком секретаре аның яхшы эшләвен әйтте. Ә эш башкаручының социаль-сәяси йөзе нинди? Ул үзен бүгенге бюро утырышында әчкерле, икейөзле кеше итеп күрсәтте. Бәрелешнең төп сәбәбен яшерде, яшьлек мәхәббәте белән очрашуларын сөйләп, үзен балаларча саф итеп күрсәтергә маташты. Болар һәммәсе дә пәрдә, чын йөзен яшерү чарасы гына. Асылда, әлбәттә, баш агрономның эш таләп итүе Шаһзамановка ошамаган, күптәннән аның эчен пошырган һәм ул аңа кул күтәрүгә кадәр барып җиткән. Менә аның социаль йөзе! — диде Апукаев тирән хис белән һәм озын кулын Илһамга таба сузды.— Без тизләнеш стратегиясенә каршы килә торган һәр очракны төбе-тамыры белән йолкып атарга тиешбез. Шаһзамановка партия сафларында урын юк! Чөнки тизләнеш эшенә, күргәнебезчә, ул бернинди өлеш кертә алачак кеше түгел.

Шулчак Илһам сикереп торды һәм тамагына килеп утырган ачуын йотып:

— Ә Хаков кертәме?! Хаков тизләнеш кешесеме?! — диде.

Моны беркем дә, хәтта Илһам үзе дә көтмәгән иде. Ләкин ул шуннан соң бер сүз дә әйтә алмады. Авыз-борыны калтыранды, ияге ачылмады, тамагыннан тавыш чыкмады. Тирләгән бармаклары белән полировкалы өстәл читенә ябышкан хәлдә ул шашынган кыяфәттә басып калды.

Мөхәммәтов кул ишарәсе белән Апукаевка утырырга кушты.

— Әллә сүзегез бармы, Шаһзаманов? — диде ул.

Илһам «әйе» дип тә әйтә алмады. Күңелендәге уй-кичерешләр бөтенесе берьюлы бәреп чыгарга теләп ашыга, тәртипсез рәвештә бөтереләбәргәләнә иде. Нәрсәдәндер һава җитмәде. Илһам ничек итеп башларга белмәде, теленнән өзек-өзек сүзләр генә чыкты:

— Яхъя Хаков... агроном түгел... ул җирдән көлә!

— Без бит Хаковның персональ эшен тикшермибез.

Бу сүзләрне Апукаев әйтте. Илһам, ярдәм сорагандай, барысына да карап чыкты.

— Миңа партиядә калырга ярамый, ә аңа...— ул тотлыгып калды да сүзен дәвам итте.— Ул бит... үскән игенне җиргә күмдерде...

— Шаһзаманов, әйдәгез читкә китмик әле! — диде Апукаев.

Хәзер аның карашы ачулы иде. Мөхәммәтов өстәл шакылдатып куйды:

— Сәгыйть Мөбәрәкович, бүлдермәгез. Дәвам итегез, Шаһзаманов. Игенне ничек итеп җиргә күмдерде агрономыгыз?

— Егерме сигезенче майда ул безне төнге сменага кертте. Борчак басуын бозарга. Өч трактор. Басуны солыча каплаган иде...

Биккинин урынында кыбырсып куйды. Үзенең башына Илһам җитәр дип һич тә уйламаган иде ул. Хәзер аның авызын ничек томалыйсың?

— Борчак биек идеме? — дип сорады Әсраров.

— Без кергән башта тәбәнәк булган... Төне буе боздык, борчак бетте... Иртән төшеп карасам... Басуны әйләнеп чыктым... Борчак бөтен

җирдә дә чабып алырлык булган.

Апукаевның йөзе каралып китте. Әлеге борчак басуы аңа яхшы таныш. Ул Биккинингә тамак кырды, ләкин теге бөтенләй читкә караган иде. Әллә язу җибәрергәме, дип уйлады ул. Юк, ярамый. Биккинин элеккечә түгел, иртән маңгайга-маңгай бәрелешкәч, аңардан һәммәсен дә көтеп була иде.

— Ул басу ничә гектар? — дип сорады Мирхәйдәров.

— Йөз илле...

— Бу хакта берәр кешегә әйттегезме?

— Кемгә әйтәсең? Дәүләт Хәсәнович үзе ашыктырды, Хаков, «тары чәчәргә соңарабыз», диде.

— Мин әле кичә генә сезнең ул басу янынннан үттем,— диде Биктаһиров.— Анда берни дә чәчелмәгән. Шулаймы, Дәүләт Хәсәнович?

— Шулай,— диде Биккинин карлыккан тавыш белән.— Чәчәргә орлык таба алмыйбыз...

Бүлмәдә уңайсыз тынлык урнашты. Солтанов башын аска иде. Ул менә хәзер генә нидер аңлый башлады. Ләкин бит ул аңа күптән төшенгән булырга тиеш иде! Формаль яктан бөтенесе дә дөрес кебек. Тик җанлы тормышның төп агымы гына читтә калган булып чыга... Аңа парткомиссия председателе Гариповтан да, бюро членнарыннан да, бигрәк тә Мөхәммәтовтан оят иде. Беренче мәртәбә бюрога кереп, шушы кадәр хурлыкка калырмын дип уйламаган иде ул. Җәйге лагерьларны җиһазлыйбыз, масса-политик эшне җәйләүләргә күчерәбез дип йөреп, басуданиләр булганын белми калган.

— Сүзегез беттеме, Шаһзаманов? — диде Мөхәммәтов.

— Басуны шушылай харап иткәнебезне күргәч, миңа әллә ни булды... Ничек кайтканымны да белмим...

Илһам урынына утырды. Аның өстеннән, әйтерсең, тау төште. Ничә көннәр буе, юк, алай гына да түгел, ничәмә-ничә еллар буе басып килгән, төннәрендә уятып борчуга салган бу коточкыч йөк дәшмәү аркасында өелгән дә өелгән иде.

Апукаев эченнән бәргәләнде, Биккинин эшне бозып куйганчы, инициативаны кулга алырга кирәк иде.

— Дәүләт Хәсәнович, нишләп сез шушындый башбаштаклыкка юл куйдыгыз? — диде ул Биккинингә.

— Нәрсә?! — Биккинин үзенең ничек кычкырып җибәргәнен дә сизми калды.

Бу сүзләрне әйтү өчен оятсыз гына түгел, иблис булырга кирәк иде! Ничек ул Биккининнең күзенә шушылый туп-туры карап тора ала?! Ничек оялмый?! Шулчак Апукаевның кулында сейф ачкычлары күренде. Биккининнең күзенә астыртын елмаюлы караш ташлап, ул ачкычларны шалтыратып өстәлгә төшерде. «Син мине аңла, мин болай гына әйтәм, мине буйый күрмә»,— ди иде аның күзләре. «Үзе куркытмакчы, үзе ялагайланмакчы»,— дип уйлады Биккинин җирәнеп һәм чыгырыннан чыгып. Ул рөхсәт тә сорамастан сикереп торды, урындыгын кискен хәрәкәт белән артка этеп җибәрде. Урындык йомшак келәмдә булганлыктан шумады, шартлап идәнгә ауды. Биккинин аны торгызу түгел, сизмәде дә. Аның йөзе кәфендәй агарган, иреннәре күп-күмгәк, гыжлап сулыш алганы бүлмәдәге һәркемгә ишетелеп тора иде.

— Шушы сүзләрне әйтергә син ничек оялмыйсың?! — Биккинин бөтен гәүдәсе белән өстәл аркылы Апукаевка омтылды һәм йодрыгын аның чырае каршында кызу-кызу селкеде.— Солычасы да, боздыруы да синең эшең бит!

Апукáев аның кайнар башын суытмакчы, һәлакәтле юлга керүдән туктатмакчы булды:

— Дәүләт Хәсәнович, син бит акыллы кеше,— диде ул, сейф ачкычларын кулында шылтырата-шылтырата көлемсерәп.— Давай, агрономының да гаепләрен миңа тагарга маташма әле син!

— Син демагог! — дип җикерде Биккинин.

Шунда Мөхәммәтов терсәген өстәлгә куйган килеш кенә, уч төбен алга каратып кулын күтәрде. «Туктагыз» дигән сүз иде бу. «Димәк, үтте»,— дип уйлады Апукаев шатлык белән. Биккинин Газизуллин торгызган урындыгына утырды, калтыранган кулларын бер өстәлгә куйды, бер аска яшерде, ахырда, галстугын бушатырга теләп, күлмәк якасын тартты. Шартлап сәдәфе өзелде һәм ул полировка өстеннән тәгәрәп китте. Аның тәгәрәвен һәм идәнгә төшеп китүен барысы да бик әһәмиятле нәрсә күзәткәндәй карап тордылар. Сәдәфнең өзелүен дә, идәнгә төшүен дә Биккинин генә сизмәде, чөнки ул ярым борылган хәлдә урындык артына култыгы белән таянып, хәрәкәтсез калган иде. Йөрәге шундый итеп чәнчеп алды, ул хәтта кесәсендәге нитроглицеринга үрелергә дә курыкты.

— Минем сезгә, Шаһзаманов, бер соравым бар,— диде Мөхәммәтов.— Ни өчен сез партия җыелышында да, партком утырышында да катнашырга теләмәдегез?

— Курыктым,— диде Илһам башын аска иеп.

— Нәрсәдән?! — Мөхәммәтовның тавышына гаҗәпләнү билгеләре чыкты.

Илһам бераз уйланып торды да:

— Ул чакта... Мин аларның күзләренә карасам, барысын да сөйләргә тиеш була идем,— диде.

— Ә хәзер нишләп сөйләдегез? Башта яшердегез, ә хәзер сөйләдегез. Нишләп алай? — Мөхәммәтов ничектер астан карагандай Илһамга башын ярым кыйшайтып карады.

— Белмим...

— Беләсез, әйтмисез генә,— диде беренче.— Әгәр баштук сөйләп биргән булсагыз, үз-үзегезне күпмедер аклаган булыр идегез. Шулай бит?

— Интектермәгез мине,— диде Илһам бу хәтәр сораудан качарга теләп. Мөхәмметов аның күңеленең моңа кадәр яшереп килгән иң авырта торган урынын эләктереп алды.

— Җавап бирегез. Ник яшердегез?

Күрәсең, әйтмичә котылып булмый иде. Илһам үзенә тиешле олы җәзаны алырга әзерләнде.

— Мин... мин... җинаятьче! — диде ул ничә көннәр буе күпме кешедән яшереп саклаган гаебен танып.

— Җинаятьче?!

— Мин борчакка кагылмаска тиеш идем... Бозарга хакым юк иде.

— Сезгә кушканнар,— диде Мөхәммәтов аны яклагандай.

— Юк! Кем кушса да... Борчакны көл-күмер китерүче мин бит, мин!— диде ул үзенең калтыранган кулларын учы белән өскә караткан хәлдә алга сузып.— Менә шушы кулларым белән... Мин гомер буе җинаятьче... Минем гомер буе үзем теләгәнне әйтергә, үзем теләгәнне эшләргә көчем җитмәде... Мин үтәүче генә.

Илһам хәлсезләнеп урынына утырды, башын аска иде. Кабинет бик озак тып-тын торды.

Ниһаять, беренченең тавышы ишетелде:

— Шаһзаманов эше буенча тагын нинди тәкъдимнәр бар? — дип сорады ул.

Беркем дә дәшмәде.

— Әйе,— дип дәвам итте Мөхәммәтов,— мәсьәлә без уйлаганча гади булып чыкмады. Тойгыларны, сиземләүләрне дә шагыйрьләргә генә калдырсак, ялгыш булыр иде. Алар көндәлек эшебез теземенә керә. Монда Сәгыйть Мөбәрәкович безне кыюлыкка һәм батырлыкка өндәсә дә, мин әлегә Шаһзамановны партиядән чыгарырлык дәлилләр күрмим. Аның язмышын гадиләштермичә, әзер кысаларга куып кертмичә, бөтен катлаулылыгы белән, бүген бюрода ачылган якларны да искә алып, тикшерергә һәм шул хәлендә колхоз коммунистлары хөкеменә кабат чыгарырга кирәк. Кем дә кем шушы фикергә кушыла, кул күтәрүегезне сорыйм.

Апукаевтан кала барысы да кул күтәрде.

— Каршылар?

Ул каршы якка да кул күтәрмәде.

— Сезгә, Шаһзаманов, кайтып китәргә мөмкин,— диде Мөхәммәтов.— Тынычланыгыз, яхшы гына эшләгез.

Илһамның тамак төбен нәрсәдер яндырып үтте. Ул нибары бер сүз әйтә алды:

— Рәхмәт...

Алар Солтанов белән ишеккә юнәлделәр.

— Ә сез, Солтанов, калып торыгыз әле.

Илһам ниндидер эчке җиңеләю белән чыгып китте, Солтанов кабат урынына утырды.

Кабинетта тып-тын иде. Шулчак ишек ачылды һәм секретарь кыз күренде:

— Ярулла Ильясович, юл бүлеген кертимме?

— Бераз сабыр итсеннәр.

Секретарь чыгып китте.

— Сез әйтеп бетермәдегез бугай, Дәүләт Хәсәнович,— диде Мөхәммәтов, аңа сораулы караш ташлап.

Биккинин бу юлы баягы кебек җилләнеп тормады, ә акрын гына күтәрелде.

— Мин гаепле.— Аның тавышы баягыдан да ныграк карлыккан иде. Ул берничә мәртәбә тамагын кырды, әмма тавышы барыбер ачылмады.— Борчакның чабарлык икәнен күрдем. Хәзер дә, шуны уйласам, йөрәгем ярылырдай була: кимендә утыз мең сумлык продукция алырлык яшел массаны җиргә күмдек! — Биккинин башын аска иеп берничә мәртәбә тирән сулады да кычкырып: — Апукаев боздырды! Мәҗбүри боздырды! — диде.

Апукаев аңа күзен нәфрәт белән кыскан килеш карап утырды. Юк, кешедә булмаса булмый икән. Тумыштан ахмак — кабергә кергәнче ахмак, дип уйлады ул. Әллә аның савымны йөз граммга күтәрим дисә, өстәп бирерлек фуражы юк идеме? Бар иде, моны Апукаев яхшы белә. Теләмәде, ә ахмак икәнен әйткәч, тагын ярамады. Иртән кабинетта кылануы гына җитмәгән, инде монда бөтенләй кирәксез нәрсәләрне сөйрәп чыгарып ята. Аны бер генә сынамады Апукаев: куркак булса да, ялгыш адым ясаганыңны күтәп кенә тора һәм гел искәрмәстән шул ялгышыңны шундый итеп чыгарып селки — үл дә кит. Шуның бер мисалы күз алдында. Бусы инде гафу итә торган түгел, бусы аның башына күсәк белән оруга тиң. Бу очракта тыныч кына утырса, Сәгыйть Мөбәрәкович үзен беркайчан да гафу итмәс иде. Ул бу юлы сүз сорап тормады, басты да сөйли башлады:

— Безнең җитәкчеләр арасында үтә сәер кешеләр бар. Алар белән эш өчен бәрелешкә керсәң, шундук үч ала башлыйлар. Кайбер колхоз председательләре, совхоз директорлары шундый азынды, байрак белән герб алып, үзләре аерым дәүләт төзерләр иде. Хәзер эш кушарга ярамый — демократия диләр, аны барысы да белә. Ә ничек эшләргә? Кеше факторын хәрәкәткә китерү, партия өйрәткәнчә, ныклы таләпчәнлек белән җитәкчеләрдән башланырга тиеш югыйсә. Җавапсызлыкны җитәрлек тәрбияләдәк. Бүген «Маяк» колхозы сиксән өч килограмм сөт киметтe. Шуны әйткәч, хөрмәтле Дәүләт Хәсәнович беләсезме нишләде? Райкомга махсус килеп, колхозның мөһерен, сейф ачкычларын йөземә ыргытып чыгып китте. Менә алар.— Апукаев мөһер белән ачкычны Мөхәммәтов алдына куйды.— Ул гына җитмәде, хәзер борчак басуын күтәреп чыкты. Алай бик кадерле булгач, бозмаска идегез! Мин тәкъдим иттем, сез хуҗа, үзегез хәл итегез иде.

— Ялган! — дип кычкырды Биккинин һәм сикереп торды.— Ялган! Син тәкъдим итмәдең, син мәҗбүр иттең. Мин сиңа ничекләр генә аңлатып карамадым?! Юк, «иртәгә обком секретаре киләчәк, төнлә бу солыча

юкка чыгарга тиеш!» Я, шулай булмады диген әле!

— Ярулла Ильясович! — диде Апукаев Мөхәммәтовка ялварып.— Үтенеп сорыйм: туктатыгыз бу базарны! Әгәр кирәк табасыз икән, бу хакта без өчәү генә сөйләшә алабыз.

— Сезне нәрсә куркыта соң? — диде Мөхәммәтов.

— Мине берни дә куркытмый. Мәсьәләнең бит биредә әйтеп бетерми торган яклары да бар...

— Нинди яклары?

Апукаев җавап бирмәде. Шушындый хәлдә барысын да әйтеп бетереп булмаганын Мөхәммәтов ник аңларга теләми?! Әйе, ул Биккининнең бугазыннан алып сөрдерде, үзләренең гөнаһын өлкә комитеты секретареннан яшерү өчен сөрдерде. Әйе, үзенең урыны өчен куркып сөрдерде. Шәхси шөһрәте өчен түгел, урыны өчен курыкты. Шәхси шөһрәт эзләгән булса, ул әллә кайчан бөтен республикага таныла ала иде. Аны элегрәк Казанга олы абруйлы, масштаблы эшләргә тәкъдим иттеләр — риза булмады. Аны, элеккеге район газетасы редакторын, ничә еллык тәҗрибәсе булган партия работнигын, республиканың татарча да, русча да яза белүче иң яхшы журналистлары рәтендә саналып йөрүче кешене, әлбәттә, бүген дә Казан биш куллап кабул итә. Тик урын белән урынның аермасы бар. Берсе — эш эшләү, икенчесе — сүз белән эшләү. Беренчесе белән халыкка аның күбрәк файда китерәчәге бәхәссез.

Ничә еллар буе аңардан да теләбрәк көткән кеше бар иде микән бу үзгәрешләрне?! Буш лыгырдаулар, урынсыз мактанышулар, юкны бар итеп күрсәтүләр аны тәмам туйдырган иде. Һәм менә конкрет эш, конкрет нәтиҗәләр, революцион үзгәрешләр заманы килде. Сусап, зарыгып көткән көннәр килде. Инде шушы сәгать суккач кына урынны ташлау аның бөтен тормышының мәгънәсен югалтыр иде. Апукаевның эштән курыкмаганын район халкы гына түгел, республика җитәкчеләре дә белә. Өч йөз алтмыш биш көннең һәр тумыш иртәсендә сәгать биштә ул инде бүлмәсендә. Яңа ел да, Беренче Май да, сабантуй да, туган көн дә юк. Ә хәзер ул рәхәтләнеп, колачын җәеп эшли башлады, чөнки ышаныч туды. Эшлеклелек чоры килде. Хәзер ул үзен теләсә нинди очракта да яклаячакларын сизә, чөнки конкрет эш белән шөгыльләнә. Кайберәүләр кебек, ул ялагайлануның ни икәнен белмәде, андый кешеләргә нәфрәт белән карады. Бәлкем, аның югарырак баскычка үрли алмавына шул сәбәпче булгандыр да. Әле күптән түгел генә өлкә комитеты инструкторы аны районда идеология эшенең артта калуы өчен гаепләмәкче булды. Ә ул аңа: «Ярар, төзәтербез, рәхмәт, тиешле ярдәмегез өчен»,— дип кәнфитләнеп тормады. Уйлаганын туп-туры әйтте дә бирде:

— Безнең идеология чаралары нәтиҗә бирәме соң? — диде Сәгыйть Мөбәрәкович.— Халыкны стена газетасы белән тәрбияли торган заманалар үтте. Ул лектор белән агитаторны да тыңламый, чөнки алар телевидение каршында нуль. Башка чаралар да искерде. Хәзерге этапта иң үтемле идеология — экономика. Кешеләрне кадерсезләнгән акчаның кадерен белергә өйрәтергә — менә бөтен идеология.

Инструктор, әлбәттә, кабул итмәде аның бу сүзләрен. Чөнки алар шомартылмаган, һәркемне табигый хәленнән чыгара торган сүзләр иде...

Әсраровның тавышы аның уйларын бүлде.

— Минем Дәүләт Хәсәновичка бер соравым бар,— диде ул.— Сез алайса баш агрономыгызны да Сәгыйть Мөбәрәкович авторитеты белән бөктегез?

Биккинин аңа гаҗәпләнеп карап куйды.

— Ник аның авторитеты? Минем үз авторитетым да җитешле,— диде ул.

— Аңа шундый-шундыйрак хәл дип аңлаттыгызмыни?

— Аңлатмадым. Аның беркайчан да кушканга каршы килгәне юк.

Бу сүзләр Апукаевның рәнҗегән күңелен тагын да ярсытып җибәрде. Бюро утырышы түгел, колхозда наряд вакыты диярсең, валлаһи!

— Ярулла Ильясович, без нәрсә тикшерәбез соң монда? — диде ул үзенең барлык кичерешләрен тавышына чыгарып.— Шаһзамановның персональ эшеме бу, минекеме, Хаковныкымы?

— Барыбызныкы да бу, Сәгыйть Мөбәрәкович,— диде Мөхәммәтов.— Барыбызныкы да.

Апукаев дәшмәде. Тыштан үтә торган мәгънәле булып күренүче мондый купшы сүзләрне яратмый ул.

Мирхәйдәров бөтенесенә ишетелерлек итеп тамак кырды да:

— Бирегә Шаһзамановка кадәр куеласы персональ эшләр бар икән әле,— дип куйды.

— Ә сез ялагайланмагыз, барыбер файдасы тимәс,— диде Апукаев, аның бюрога кергәннән бирле тырнак астыннан кер эзләп утыруына ачуы килеп.

Аларның арба күчәрләре җай килгән саен орылышып тора. Апукаевның ничә еллар буе сводкага карап: «Сөтне арттырыгыз», «ит җитештерегез», «ашлык бирегез»,— дип утыруын, үзләре өстеннән командалык итүен күтәрә алмый Мирхәйдәров. «Сизәсезме, егетләр, районда идеология эше үлеп бетте ләбаса!» — дип өзгәләнә ул үзенең сер сыярдай кешеләренә. Әйе, аның фикеренчә, тәрбия эше онытылды, бетте. Шуны яшерү өчен урамнар, биналар ялтыравыклы плакатлар, паннолар, стендлар белән чуарлана, каяндыр килгән шабашник-рәссамнарга, финанс законнарын бозып, ел саен әллә ничәшәр мең сум акчалар түгелә. Мирхәйдәров эшли башлаган вакытларында бу нәрсәне фаш итәргә тырышты, финанс законнарын бозган өчен кайбер җитәкчеләрнең кесәсенә дә сукты. Тик Апукаевны җиңү мөмкин түгел иде. Әгәр Мирхәйдәров кулына бирсәләр, ул шушы үлеп беткән тармакка җан өрер иде...

Бикташиров башын Биккинингә таба борып сорау бирде:

— Дәүләт Хәсәнович, ул басуны нишләп шул дәрәҗәдә солычага батырдыгыз соң сез?

— Мин әле әйтеп бетермәдем,— диде Биккинин, урыныннан тормыйча гына.— Ул сорауны һәркайсыгыз да бирергә хаклы. Безнең исәп борчакны бер атна соң чәчү иде. Солыча тишелгәнне көтеп, башта аны юк итәргә уйладык. Тик әнә ул (Биккинин кулы белән Апукаевка күрсәтте) моны тыңларга да теләмәде. Чәчәсез — югарыдан шулай кушалар, беттекитте! Нәтиҗәсен үзегез беләсез.

— Әйе, чәчтердем! — диде Апукаев та урыныннан тормыйча гына.— Шулай тиеш түгел идемени, Ярулла Ильясович? Обком — сезгә, сез — безгә, без — аларга. Чәчүне тизрәк бетерү бурычы куелмаса, моны эшләүнең миңа ник кирәге бар иде?

Мөхәммәтов сәер итеп көлемсерәп куйды. Бу ничектер көлемсерәүдән бигрәк ачынуга охшаган иде.

— Кызганыч ки, сез эшләгән нәрсә без куйган бурычларны җимерә шул, Сәгыйть Мөбәрәкович,— диде беренче.

«Менә рәхмәт ишетер көнең дә җитте, Сәгыйть! — дип уйлады Апукаев эченнән.— Менә синең ничә еллар алны-ялны белмичә тырышуыңа бәя! Ә кем гаепле?» Әгәр ул беренче урынында утырса, районның бүгенге хәле бөтенләй башкача булыр иде. Барысын гафу итү, принципсызлык чоры үтте, ә аның тарафдарлары урыннарында калды. Алар таләпчәнлек, реаль нәтиҗәләр заманы килгәнне сүздә таныйлар, гамәлдә юк. Принципиальлек, таләпчәнлек аларга куркыту, кеше иреген кысу булып күренә. Ә сындырмыйча үзгәртеп буламы соң?! Хәзерге этапта аннан башка мөмкин түгел. Бу вакытлы чара, ләкин котылгысыз. Аның күпме дәвам итәре билгесез. Аннары икенче этап — хәзер бик күпләр теләгән йомшаклык этабы башланачак. Тормыш диалектикасы шундый. Соңгы ике елда күпме эш башкарылды! Былтыр районның шикәр чөгендере сату планы өзелү куркынычы туды. Ә тугыз колхоз карлы яңгыр астында чөгендерләрен ала алмыйча изалана. Мөхәммәтов Казанда больницада чак. Апукаев әлеге хуҗалыкларның чөгендерен район үзәгендәге хезмәткәрләргә бүлдереп

бирде. Мәктәпләрнең өлкән класс укучылары да читтә калмады. Бөтенесе хәрәкәткә килде, ун көннән, инде кар яугач, чөгендер алынып, киселеп, дәүләткә тапшырылып бетте, өч ел буе үтәлмәгән план үтәлде. Ә моны оештыру өчен кемнәрне генә сындырырга туры килмәде?! Сындырмасаң, чөгендер кар астында кала иде. РОНО мөдире Мәгариф министрлыгына шалтыратты, банк управляющие «Труд» газетасына жалоба язды, җитәкчеләрдән әллә ничәсе эштән азат итүне сорап гариза кертте. Барысының да авызында бер үк сүз: «Җәй буе басудан кайтмадык, терлек азыгы әзерләдек, уракта эшләдек, бәрәңге-чөгендер алдык...» Моны Апукаев белмимени? Чөгендерне кар астында калдырырга идемени? Сындырмыйча гына бөгеп кара син! Юк, Мөхәммәтовның либераллыгы, йомшаклыгы белән хәзерге бурычларны хәл итеп булмый. Иң аянычы шунда, ул шушыны аңламый, кеше факторын песиемләп хәрәкәткә китереп була дип уйлый, һаман Апукаевны гаепли. Ул барлык кешегә дә — халыкка да, җитәкчеләргә дә яхшы булмакчы. Ә консерватизмның оясы — җитәкчеләрдә. Шуларны туздырмый торып, алга барып буламы?

Апукаев авыр сулап куйды да, ачуын һәм рәнҗешен яшерергә тырышып:

— Әгәр беренчеләрне тәнкыйтьләргә яраса, сезнең адреска да үпкә сүзләре аз әйтелмәс иде,— диде.

— Ә кем тыя?

— Беркем дә тыймый.

Шул вакыт Мирхәйдәров:

— Ә икенчеләрне тәнкыйтьләп буламы соң? — диде.

Кабинетта коры яшен шартлагандай бердәм көлү яңгырады. Әмма ул шундук тынды, чөнки барысы да Мөхәммәтовның йөзенә көлү түгел, елмаю әсәре дә чыкмаганын аермачык күреп тордылар. Аның йөзен дә, күзләрен дә моңа кадәр беркайчан да күрелмәгән уйчанлык пәрдәсе каплаган иде.

— Сәгыйть Мөбәрәкович, минем бер шигем бар,— диде Мөхәммәтов сагышлы тавыш белән.— Сез көчегезне тиешле өлкәгә саласыз микән?

Кинәт Апукаевның күзләре зураеп китте, кашлары өскә күтәрелде.

— Урыныгыз райкомда түгел, дияргә теләмисездер ич?

— Юк, аңламадыгыз,— диде Мөхәммәтов.— Беләсезме, мин нәрсә уйладым: Шаһзаманов сезнең яңагыгызга чапса, бәлкем, аңлаган булыр идегез.

Эченнән болай да кайнап утырган Апукаев сикереп торды:

— Бусы инде мыскыл итүгә керә, Ярулла Ильясович! Бу болай гына калмаячак!

— Әлбәттә, калмаячак,— диде Мөхәммәтов.— Тик миңа алай нәфрәт белән карамагыз әле. Безнең шатлыгыбыз да, кайгыбыз да бер нәрсәне аңлавыбызга бәйле.— Мөхәммәтов бераз уйланып торгач, сүзен тәгәлләде: — Кеше — тормышның кушымтасы түгел. Аңа яшәүнең кызыгын калдырырга кирәк. Шушы хакта уйланып карагыз әле сез.

Апукаевның бер-берсенә кысылган юка ирennәре калтыранды, берничә мәртәбә мәсхәрәле җыерылып куйды, ләкин ул бер сүз дә әйтмәде, кабинеттан кызу-кызу чыгып китте. Барысы да аны күз карашы белән озатып калдылар һәм Мөхәммәтовка төбәлделәр. Әле район тарихында беренче секретарьдан рөхсәт сорамыйча бюроны ташлап чыгып китүченең булганы юк һәм моны бары бер генә төрле — эштән китү дип кенә бәяләп була иде. Мөхәммәтов ике-өч минутлап башын иеп утырды, алдында яткан ак кәгазьгә кызыл карандаш белән тәртипсез рәвештә кызу-кызу сызгалады. Аның йөзендәге җыерчыклары арткан, күз төпләре тагын да ныграк күләгәләнгән иде.

Биккинин үзен үтә кыен хәлдә сизде. Чөнки бу күңелсез хәлнең төп сәбәпчесе ул иде. Ул ни Мөхәммәтовка, ни башкаларга күтәрелеп караргы кыймады.

Менә Мөхәммәтов башын күтәрде һәм:

— Дәүләт Хәсәнович! — дип дәште.

Биккинин ялт итеп аңа карады.

— Минем соңгы соравым бар. Менә сез авылда туып үскән, гомер буе җир белән бәйле кеше. Апукаев кушкан, сез шул кадәр яшел массаны харап иттергәнсез. Ничек риза булдыгыз? Ни өчен тавыш-гауга күтәрмәдегез?

Биккинин авырлык белән торып басты.

— Утырган килеш кенә дә җавап бирергә мөмкин.

— Юк, басып җавап бирер чак җитте,— диде Биккинин.— Сез дә, монда утыручы башкалар да әйтегез әле: кайсыгызның күрсәтмәсенә каршы килгәнем бар? — Ул җавап көтеп бераз торгач, дәвам итте:— Юк, шулай ич? Ни өчен дисәгез, мин барыгызга да бәйле, барыгыздан да көчсез. Аннары...

— Ник соң башыгызны шул кадәр идегез? — диде Биктаһиров аның сүзен бүлеп.

— Беренчедән, белемем юк,— диде Биккинин бармак очы белән маңгаена төрткәләп.— Шулай булгач, кушканны тыңламыйча кая барасың?

— Без сезгә читтән торып авыл хуҗалыгы институты бетерергә мөмкинлек бирдек,— диде Мөхәммәтов.

— И Ярулла Ильясович! Иртәнге дүрттә торып, кичке тугызда кайтыпауган кешенең укырга вакыты каламы соң?! Читтән торып укыган колхоз председателен сез аны «укыды» дип әйтеп тә тормагыз! — диде Биккинин шактый кызып.

— Җиде класс белем белән дә бер дигән итеп эшләүче председательләр бар бит,— диде Әсраров, аның белән килешмичә.

— Бардыр,— диде Биккинин һәм тагын галстугын бушайтып куйды.— Әгәр ул эшкә күңеле ятса, җаны тартса. Мин, ел ярым үткәч тә, председательлекнең үз эшем түгел икәнен аңладым. Гомер буе техника тирәсендә кайнашкан кеше мин, тимернең рәтен, җанын беләм. Ә халык белән эшләү... үлем белән бер! Әйтерсең, көн саен эшкә түгел, суд залына барам. Бюрога, колхозчылар җыелышына ничә мәртәбә гариза керттем. Тик ул гаризаларны кире алырга мәҗбүр иттегез. Имеш, беркемгә дә җиңел түгел, өйрәтербез, һәрвакыт булышырбыз. Шушы ук Апукаев: «Оештыру талантыгыз бар, сезгә укырга гына кирәк»,— дип бюрода очына-очына сөйләде. Чөнки аңа минем кебек сүзсез буйсынучылар күбрәк булган саен уңайлырак. Ә сез? Күбегез шушыларны күрдегез, ялваруларымны ишеттегез! — Биккинин күкрәгән тотып туктап калды.

Аңа графиннан агызып су бирделәр. Ул суны өч йотуда эчеп бетерде дә тирән итеп, шаулатып сулыш алды һәм бөтенләй ят тавыш белән сүзен дәвам итте:

— Башка эш сорадым, тик берегез дә минем хакта, тере җаны булган кеше хакында уйламадыгыз! Сезгә кеше кирәкми, ә колхозга председатель кирәк иде. Төгәлрәк әйткәндә, сезгә план үтәүче кирәк иде. Һәм мин аны үтәдем. Кем отты,— минме? Юк. Колхозмы? Юк. Ә кемгә файда? Белмим.

— Сез хаклы,— диде Мөхәммәтов. Ул инде күптән, карашын печать белән ачкычларга төбәп, хәрәкәтсез утыра иде.— Үткәннәр өчен без гаепле. Тик соңгы елларда сезнең бу мәсьәләне күтәргәнегезне хәтерләмим.

— Хәзер соң инде,— диде Биккинин һәм урынына утырды.

Аннары кисәк кенә бөтен гәүдәсе белән Мөхәммәтовка таба борылды да пышылдап:

— Ә хәзер, пенсиягә өч ел калгач, гариза бирүем кирәкмидер бит? — диде.

Бүлмә тып-тын иде, пышылдап әйтелсә дә, аның сүзләрен барысы да бик ачык ишеттеләр. Мөхәммәтов дәшмәде. Аның йөзе нindидер үкенүле сызлану белән җыерылды. Әйтерсең лә, эчтә нәрсәдер өзелеп, аны тынсыз итеп катырды... Һава җитмәүдән ачылган авызын көч-хәл белән ябып, ул тешләрен кысты. Иреннәре сулъяк яңагына таба тартылды һәм

бөтен йөзе агарып китте. Мөхәммәтов мөһер белән ачкычларны Бикта-һировка сузды, ул алып Биккининнең алдына куйды.

Барысын да сискәндереп кинәт ишек ачылды һәм Апукаев килеп керде. Аның йөзе тынычланган иде. Сәгыйть Мөбәрәкович салмак адымнар белән түргә узды һәм урынына кереп утырды. Кемнәрнеңдер йөзендә гаҗәпләнү, сорау билгеләре чыкты. Мөхәммәтов кенә керфеген дә селкетмәде, башын күтәрмичә, иреннәрен генә сизелер-сизелмәс кыймылдатып:

— Сез... нишләп кердегез? — диде.

Апукаев тигез матур тешләрен күрсәтеп авызының уң як чите белән елмайды.

— Устав куша, Ярулла Ильясович,— диде ул.— Мин бит бюро члены.

## 15

Илһам бюродан чыгуга, коридорда Габделхәйнең басып торуын күрде.

— Йә, ничек? — диде ул.

Габделхәйнең йөзе борчулы, гәүдәсе сугудан сакланган кешенеке кебек алга иелгән иде.

— Син нишләп йөрисең? — диде Илһам дустының соравына җавап бирмичә.

— Синең янга килүем. Ничек түзеп ятмак кирәк.

# Эльмира Шәрифуллина

## Эзләдек, исем эзләдек...

Тудырдым,
Исем эзләдек
Йолдызлар арасыннан.
Күзләре җете булсын дип
Зәңгәр күк карашыннан,
Раушан диеп исем куштык
Баш балам — багалмама.
Әй, күгем! Минем баламны
Биеккә дәш — алдама!

Тудырдым,
Исем эзләдек
Кызыма — уртанчыма.
Фирүзә дип исем куштык
Аңа — бәгырь тамчыма:
Фирүзә диңгезләр кебек
Киң булсын барыр юлы,
Фирүзә җилләрдә генә
Дулкынлансын толымы...

Тудырдым,
Исем эзләдек
Чәчәкләр арасыннан.
Төпчек кызым төпле булсын,
Бер назлы карашыннан
Нур агылсын йолдызларга,
Нур агылсын диңгезгә.
Туган якта чәчәк аткан
Резидәдәй, тиң гөлгә...

Тудырдым,
Исем эзләдек
Күктән, Судан һәм Җирдән.
Каян табылса да исеме,
Бәхете — Туган илдә!

❁

Бәби кайтты бүген өйгә,
Җыру туды яңа көйгә:
— Ризыккае мул булсын, мул булсын,
Килер җире киң булсын, киң булсын,—
Дип теләде әбисе дә,
Дип теләде әнисе дә.
Кардәш-күрше котлады,
Изрәп бәби йоклады.

Бәхет кайтты бүген өйгә,
Сихәтле сүз сеңде көйгә:
— Бул йөзебез аклыгы, аклыгы,
Син бар дөнья шатлыгы, шатлыгы,
Татлы балам баласы,— дип,
Кызым аның анасы,— дип,
Такмаклады бабасы,
Кабатлады атасы!

---

Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА — *шагыйрә, өч шигырь китабы авторы. Проза әсәрләре дә яза. Казанда яши.*

## Бишек җыры

Туган өемдә тирбәтәм,
Туган телемдә җыр әйтәм:
— Багалмам син, бергенәм, былбылым,
Җанда җыр уятучы бер кылым,
Энҗе-мәрҗән, асыл ташым,
Серле күзем, сәйлән кашым,
Әлли ит син, бәлли ит син, нарасый,
Игелекле булып үс, ярабби!

Туган илемдә тирбәтәм,
Туган телемдә җыр әйтәм:
— Газиз балам, җимешем, сандугач,
Өем нурга күмелде син тугач...
Йөрәк парәм, асыл кошым,
Назлы гөлем, матур кешем,
Әлли ит син, бәлли ит син, нарасый,
Игелекле булып үс, ярабби!

## Ятим

Таң нурларын ягып йөзләремә,
Кояш назын салып күзләремә,
Туган идем дөнья йөзләренә...
Сәер исем керде сүзләремә:
Син — ятим...

Туган идем бәхет табар өчен,
Мин тудым дип, ишек кагар өчен,
Җирдә йолдыз булып янар өчен,
Бәгыремә төште сәер исем:
Син — ятим.

Җилләр безне кай тарафка ташлар,
Кая тартыр ризык булган ашлар,
Ник кадерсез булды безнең башлар?
Кендегем күк өзек өметем:
Син — ятим.

Язмыш шулай салып таптадымы?
Җинаятьне кеше акладымы?
Бар дөньяны болыт капладымы? —
Нигә һаман яши шул исем:
Син — ятим!..

## Кемгә сыенырмын?

Вакыт җиткән,
Яучылары белән
Юлга чыккан инде юртаклар.
Кызларымны туйлап биргән чакта
Шатлыгымны кемнәр уртаклар?

Егет куенына кергән мәлдә
Алтын алма кебек кыз балам,
Мин тартынып кемгә сыенырмын,
Кемгә серем сыяр, йә аллам.

«Ир шәүләсе — гарше күләгәсе»,
Саклап торыр яман күзләрдән.
Сөелеп кенә яшәсәгез иде,
Өстен булып бәгъзе сүзләрдән.

Без күрмәгән бәхет сезгә булсын,—
Эшләп тапсын аны кулыгыз.
Бер-берегезгә дөнья бәяседәй
Олы бәя биреп торыгыз!

❁

Тыныч кына атлый идем. Уйны
Кузгаттымы, белмим, ак көртләр.
Су ташкыны кебек агып чыкты,
Бәреп чыкты бүген пакь хисләр.

...Тау битенә инде урман үскән
Без килмичә торган арада.
Чагылдырып күзне, кәүсәләрдән
Истәлекләр ахры тарала...

## Ап-ак дөнья уртасында

Әйләнәмдә сихри аклык,
Чорнап алган якты пакьлек
Бетмәс кебек тоела.
Әллә минем карашымнан,
Ылыслары арасыннан
Энҗе карлар коела.
Коелалар энҗе карлар,
Сагындыра иске ярлар,
Җанны салкын кар сыра...
Ак патшалык уртасында,
Күз күреме ноктасында
Кеше — кара тап тора...

## Бу мәхәббәт

Тылсымлыдыр бу мәхәббәт —
Бер караштан ярала.
Ярты сүздән коелып төшә,
Шашып яна-яна да.

И, кызык соң бу мәхәббәт —
Канга ялкын йөгертә.
Елларга сузылыр эшне
Секундында өлгертә.

Кыен да соң бу мәхәббәт —
Кайчак ашны таш итә.
Утлы табага бастыра,
Үрле-кырлы сикертә,
Хисе артык булганнарны
Йокысыз, төнсез итә.

Якты гамәл бу мәхәббәт,
Кайтмас мизгел — һәр караш...
Бәхетсез түгел — кайчандыр
Сөелгән, сөенгән баш...

## Кышка соклану

Мамык кебек карга басып,
Атлыйм ап-ак дөньядан.
Күперәп тула баскан эзем,
Күперәп тула яңадан.

Барам да барам — аклыктан
Сихерләнгәнмен бугай.
Ул гүзәлдер бу агачлар,
Ул гүзәлдер бу тугай.

Тирә-юньгә соклнудан
Шашып китмәсәм кана.
Хисләремнең ялкыныннан
Битләрем дөрләп яна.

Салкын аклык күңелләрне
Шулай алдый алганын
Аңладым да... салмакладым
Үтәр юлның калганын.

## Горур идем...

Горур идем,
Түгел үземә күрә...
Башкаемны иеп, килдем сиңа, түрә.
Инәлепләр сорыйм: ярдәм әйлә.
Балакаем үлә, балам үлә...

Үзем түгел, сабый хакларына
Гозеремне тыңла, тәкәллефле түрә!
Иренеп әйткән бер әмерең җитә:
Синең кулда бүген тылсым-сүрә.

Йөз суымны түгеп басып торам,
Ярдәмеңне боер, и, вәкарьле түрә.
Горур башым — аяк асларыңда:
Балам тернәкләнә...
җаным үлә.

## Сурәтең ясыйм да...

*Нурихан Фәттахка*

Зәңгәр күк фонына бастырып,
Кояшны элеп бер почмакка,
Мәңгелек сурәтең ясыйм, дип,
Ут яктым — нур сорап учактан.

Зәңгәр күк — чисталык билгесе,
Гаделлек, гадилек символы,
Син Кеше исемен йөрттең дә
Калдың шул йолага гел тугры.

Ә кояш — иң изге, гали көч,
Кодрәте киң дә киң... ай-һай, киң!
Син минем хыялым түрендә
Шул кояш, зәңгәр күк, нурга тиң.

Ясыймын сыныңны чын итеп,
Ә аннан табынам, таң калып!
...Һай, мин дә балкысам, кемнеңдер
Уенда сурәтем ясалып...

## Зәңгәр дулкын

Сикергечле уйныйм әле:
— Берәү, икәү... тугызак.
Сикергечем — зәңгәр дулкын,
Берсе эре, берсе вак.

Дугай, дугай үзләре лә,
Өчәү, дүртәү... тугызак.
Йөгерешеп килә алар:
Берсе зәңгәр, берсе ак.

Сикергечем — зәңгәр дулкын,
Бишәү, алтау... тугызак.
Берсе ярда, берсе янда,
Калганнары бик ерак.

Саныйм, саныйм дулкыннарны:
Җидәү, сигез, тугызак...
Хисапсыз күп дулкыннар да
Берсе парлы, берсе так...

Берәү, икәү... тугызак,
Өчәү, дүртәү... тугызак,
Бишәү, алтау... тугызак,
Җидәү, сигез... тугызак...

# Ренат Харис

## Кәрван

Кояш бата.
Ай калка,
җемелдәшә йолдызлар...
Юллылар алга атлый.
Нишли икән юлсызлар?

Бик авырдыр аларга,
юлдан сапкач көндезен:
кай тарафка китәргә,
юл итәргә кем эзен?

Йолдыз сүнәр...
Ай батар...
Таң атар...
Кояш чыгар...
Ни әйтерләр кәрванга
адашкан юлбашчылар?..

## Ике гаскәр

Күңелемдә минем ак гаскәр бар...
һәм бар анда кара гаскәр дә.
Бер-берсенә алар гомер буе
торды төрле ызгыш хәстәрләп.

Көн дә алар ярсып сугыштылар.
Кара ота, йә ак мат куя.
Ә мин гадел, имеш: җиңүчегә
чын күңелдән җырлыйм мәдхия.

Җиңүчегә, имеш, хаклык юлдаш!
Җиңү китермәде җиңеллек...
Хәзер генә мин аңладым бугай:
«җиңә-җиңә» яшәп җиңелдек,

«җиңә-җиңә» яшәп сукырайдык,
һәм күрмәдек юлда хәтәрне,
вак-төяккә генә абындык та,
йөрәк ярыгына мәтәлдек...—

таш тоз булып, ачу ташы булып...
Әрни-әрни хәзер айныйбыз,
һәм күрәбез куык җиңүләрдән
туган мәдхияләр кайгысын.

Күңелемдә минем ике гаскәр...
Көн дә алар ярсып сугыша.
Орышлары ихласланган саен
иркенәер кебек сулышлар.

---

*Ренат ХАРИС (1941) — шагыйрь, татар һәм рус телләрендә дөнья күргән егермегә якын китап авторы. Казанда яши.*

## Уйланабыз

...Уйланабыз,
уйланабыз...
Төштә, өндә уйланабыз:
хөр яшәгән кебек идек —
уйнаганбыз, уйнаганбыз!

...Ләкин уйнап туймаганбыз,
нәфсебезне тыймаганбыз...
Хөрлек безгә капка ачкан,
без капкага сыймаганбыз,

этешкәнбез, төртешкәнбез...
Сизмәгәнбез-тоймаганбыз —
хөрлекнең капкасы ватык,
ә үзебез кыйналганбыз.

Уйнаганбыз,
уйнаганбыз...
Эштә, төштә уйнаганбыз.
Азарттан ничек чыгыйк дип,
уйланабыз, уйланабыз...

## Дилбегә

Туры юлга чыккач кына
җибәрәләр дилбегәне.
Җибәрдем дә уйга калдым:
мин белгәнне Ил беләме?

## Канәгатьсезлек

Тамыр очы якты җиргә чыкты килеп.
«Ә бу нәрсә?» — диде үз алмасын күреп.
«Яшәвеңнең мәгънәсе ул», — дигән идем,
тамыр тизрәк кара җиргә китте кереп...

## Миңнәр

*Миңле кеше бәхетле була.*
Халык юравы.

Аркам миңле булгангадыр —
авырны
күп күтәрдем. Белмим кайчан
авармын...

Беләк миңле — эшлим, эшлим
туктамый,
үзем табып киям җитмеш
нукта мин.

Авыз миңле — бусы да рас,
ач түгел;
бик тук булсам, бетәр иде
ачы тел.

Колагым миңле дә түгел.
Ни файда? —
Күпме нахак сүз ишетәм
шулай да...

Ике күзгә бер генә дә
миңем юк,
ә күз тулы утлы дым һәм
дымлы ут.

Килеп житте менә тагы сабантуйлар...
Көрәшәләр жанда төрле-төрле уйлар,

белеп булмый әле кайсы кайсын егар —
яңасымы, искесеме өстен чыгар...

Яңа — кыю! Иске — жайлы! Кайсысына
хәсрәт азрак, бәхет бераз күбрәк сыйган?

Һәм быел да, үҗәт марофончы кебек,
йөгерешкә чыкты житмеш яшьлек өмет,

сәерлеге артты аның елдан елга:
әллә кая китә иде ярты юлда,

беркайчан да житми иде финишына...
Бигрәкләр дә жан борчыла менә шуңа!

Ләкин хыял һаман матур булып кала,
баганага менеп ел да әтәч ала...

## Кәшә авылы

Кәшә белән Васильевка арасында
шундый күлләр иде!
Шундый таллык!
Шул таллыкта, шул күлләрдә
без Тарзан да, Робинзон да
була алдык.

Кәшә күленең суы шундый жылы иде,
шундый тоньк, шундый серле!
Шул суларда без капитан Грант булып,
йә капитан Немо булып йөрдек.

Кәшә сабантуе кебек зур сабантуй
Казанда да хәтта юктыр.
Егылганга беренче тапкыр шунда еладым мин,
беренче тапкыр шунда ектым...

Кәшә урамында
шәһәрдән кайткан кунак кызы
күргән идем ерак язда,
гомер буе шуңа, адресын, исемен белмичә,
хат кебек нәрсә язам;

язам, язам, язам, язам —
һаман бетми... Ә гомер үтә тора...
Язганымны, әрәм булмасын дип,
бер барып ирешер әле дип,
китап итә торам.

## Мәхәббәт авырлыгы

Кырык давыл аша узып,
сакланып кала алган
оялчан елмаю күрсәм,
хәтта югалып калам.

Маңгайдагы җыерчыклар,
күз төбендәге сырлар
сөю-сөелү серләрен
менә ачарлар сыман.

Ачылсалар, мин аларны
күтәрә алырмынмы? —
Хатын-кызның һәр серендә
мәхәббәт авырлыгы.

## Җиргә төшермә

Төшермәче мине җиргә син...
Аяк очымны да тидертмә —
сөюемнең биек очышы
аһ, тилертә мине, тилертә.

Төшеп килгән аккош мамыгын
сулышыңа салып этәр син,
күзләреңнән аккан җылылык
йолдызларга мине күтәрсен.

Йолдыз нурларыннан сүз эрләп,
Җир белмәгән җырлар чигәрмен...
«Бар, оч!»— дидең... Ачтың кочагың...
Ә кулларым синнән җибәрми.

Очырмачы мине күккә син...
Ирек биреп, мине тилмертмә...
Җырның җиргә тамыр җәюе
нирванәгә салып тилертә!

## Бәхетлеме син бүген?

— Хәтерлим:
бөтен дөньяны вәгъдә иткән идем кайчандыр...
Мин сиңа
үземне генә бирә алдым — алдадым...

— Һәм сүзеңдә тора алдың,
кадерлем!

*

Тәрәзәдән кулны сузып,
тартып алдым бер болыт.
Язу өстәлемдә болыт
тора ап-ак үр булып.
Кар тавы күк...
Юк, мәрмәр күк!
Үземне рәссам итеп
тойдым да, алмакчы булдым
мәрмәрнең читен китеп —
сыныңны синең ясарга
иде татлы исәбем,
онытканмын хәрәкәттән
җил чыгасын — исәсен...
Булачак сының таркалды,
таралды томан сыман...
Шул томанны гына хәзер
утырам инде сулап.

## Минутлык төшенкелек

Тартып алчы мине, йолдыз,
салчы якты ташыңа —
җирнең карасы аяктан
саркып менде башыма.
Телемә артык еш килә
керләнеп беткән сүзләр.
Якты дөньяны томалап,
томан куера күздә.
Берни дә аңлыйсы килми,
бернәрсә аңлатасы...
Бүгенге ыгы-зыгылар
ул бит ходай хатасы...
Тартып алчы мине, йолдыз,
коткарчы каралыктан.
Ялварыр идемме сиңа,
ялварам чара юктан...

Юк, тыңлама мине, йолдыз!
Минутлык төшенкелек
бөтен узган гомеремнән
алмакчы булды көлеп.
Мин бит үзем гомер буе
суздым коткару кулы
һәм күпләрне һич мәгънәсез
үлемнән калдым йолып,
аларның сүнгән күзенә
үз нурымны өстәдем...
Яшәвемнең, ни булса да,
үз яме һәм үз тәме.
Миңамы җебеп торырга?!
Тәнем, акылым исән!
Төшенкелектән үрелгән
кулын елмаеп кисәм.

## ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

### Зөфәр Фәтхетдинов

# ҮЛЕМ ЭЛМӘГЕ

РОМАН



а! Санька анархистны күрәсе килгән берәүнең... Ни йомышың төшкән иде, әйт әйдә!..— Тубалбаш, алтын тешләрен елтыратып, тагын ыржайды. Шамилнең дәшмәвен күреп, револьвер көпшәсен аның күкрәгенә үк терәде.— Дәшмисеңме? Котың ботыңа төштеме? Һа-һа! Эчәгеңне сауганчы сорап кал: сине абзаң лично үзе тыңлый. Йә, кыстатма!

Шамил күз кырые белән генә Миргазияновны ялмап алды. Ул урындыкта кадакланган төсле утыра иде. Өстәл уртасындагы авыр җиз шәмдәлне ике учлап тоткан да, өскә ыргылырга торган мәче кебек, йомарланып калган. «Әгәр бу анархистны аяктан егып, тегесенә — ишек төбендәгесенә сикерсәм, Миргазиянов арттан китереп бәрәчәк,— дип уйлады чекист.— Әгәр дә Санька артыннан ук Миргазияновны түндерсәң...— ишек янагына сөялгән адәмнең кулында немец маузеры: кесәсеннән яртылаш чыгарып ук өлгергән, ике дә уйлап тормый атачак. Нишләргә соң?.. Бердәнбер юл кала... Вакытны сузу. Вера Петровна җибәргән егетләр килеп җиткәнче. Уйнарга туры килә».

Измайлов, берни дә булмаган төс белән, анархистның күзенә карады:

— Сорау бер генә, Санька. Сез, нәрсә, чынлап та банк басарга уйлыйсызмыни?

— Басарга?.. Фу, нинди оятсыз сүз. Баш капкачыңа киртләп куй, дустым: анархист кесә карагы да, йорт басучы да түгел. Син әле яшь кеше, анархистны ниндидер бур яисә ат карагы дип беләсеңдер. Авызыңа майлы тәпәч: без угрылык белән кул буямыйбыз. Без, дустым, экспропри-ация-либез. Банктагы алтын-көмеш кемнеке? Патша хәзрәтләренеке. Ә патнашы кем дөмектерде? Большевиклар гынамы? Шалиш! Патшага каршы эш йөрткән меньшевиклар фиркасен кая куясың? Һәм дә эсерларны? Ә анархистлар?.. Без дә хакның бәндәсе! Тиешлесен яхшылык белән бирмиләр икән — өлешебезгә тигән көмешне үзебез каерып алырбыз. Җае чыккан саен гаделлекне торгызырга кирәк, дустым. Яшәсен анархия-анакай!

«Аңысы аңлашыла...— Шамил эчтән генә көлемсерәде.— Көя кискән киез итеккә аслык салган кебек, һәр тишеккә үз теориягезне китереп кыстыра беләсез инде».

---

Дәвамы. Башы 9 нчы санда.

— Син тагын үзләрен генә кайгырта болар дип уйлама...— Санька Шамилдән алган револьверны бер кулыннан икенчесенә сикертеп куйды.— Әнә Саматны күр: анархист та, чурт та түгел ул. Үзенә тиярен барыбер алачак. Экспроприация ясаганда безгә ярдәм итсә, әлбәттә... Банкта эшләүче кардәшен күндерсә — бер өлеш. Дары заводына да барса — ике өлеш.

Измайловның аркасына салкын тир бәреп чыкты. Барысын да ачыктан-ачык сөйләшә болар: каршыларында чит кеше басып тормаган да кебек. Димәк, аны инде дөньяда юк дип саныйлар. Эч серләрен үк ишеткәннән соң — бетте, исән килеш ычкындырмаячаклар.

— Әмма ләкин без чекисттан да җирәнмибез,— дип дәвам итте анархист.— Җитәр, бу куллар большевик канына да байтак буялды... Теләсәң, синә да эш табылыр. Тапкан мал уртак булыр, анысына да борчылма. Тик иң элек син миңа шуны әйт: чекада кайсыгызның борыны сизеп алды әле банк тирәсендәге хәлләрне? — Измайловның башына револьвер көпшәсе белән каты гына төртеп алды Санька. Җавап бирмәсәң — шунда ук атам, дигән ишарә иде бу.

Шамил ялт кына Миргазияновка борылып карады. Җиз шәмдәлне кулыннан ычкындырмаган теге, өстәлгә бер кыры белән бастырган да әйләндергәләп тора.

«Сәер генә хәл килеп чыга бит, ә. Һәрхәлдә, Санька-анархист чекага хәбәрне кем салганын белми. Юри хат язып, чекистны тозакка эләктерү нияте дә булмаган, димәк. Алай дисәң, нәкъ шул мәлне каян килеп чыкты соң бу ике бандит? Ә-ә!.. Алар, мөгаен, монда яшәп ятадыр. Шул, Саматның пычак батырылган дуңгыз шикелле шыр кычкыруын ишетеп килгәннәр. Дусларын ярдәмгә чакырган Самат!.. Безгә дә дөресен хәбәр иткән. Әмма, «Үзе чакыра — үзе кача» икән, максаты ни аның? Анархистларга тере чекист тотып бирүме? Әллә үзара бәрелештереп, бездән дә, тегеләрдән дә котылырга теләвеме?.. Миргазияновның чекага хат язуын әйтү белән, бөтен сорауларга җавап табылачак. Ул үзе дә йә теге якка, йә бу якка басарга тиеш. Әгәр инде провокатор икән... Шул чуалыш вакытында тәрәзәдән сикерергә була. Йөзне генә кул белән капларга кирәк — пыяла кыйпылчыклары күзгә кадалмасын өчен».

Бу уйлар яшен тизлеге белән узып китте.

— Йә, телеңне йоттыңмы әллә?! — дип ярсып акырды Санька.

— Вакланмыйк шул юеш борын белән...— икенче бандит, бусагадан эчкә атлап, ишекне япты, суда йөзеп барган кебек, маузерын өскә күтәрде.— Кая, үзем берне төкертим чигәсенә, ыһ та итми калыр.

Шамил шунда гына аңа төбәлеп карады һәм танып алды: соң бу бит — теге чакта, Чистай базарында якалашкан өчәүнең берсе! Аны, изүеннән умырып алып, чүлмәкләр өстенә очырган френчлы ир! Бөтен тәне буйлап электр тогы үткәндәй калтыранып куйды егет, йөзенә кайнар кан йөгерде.

— Ә-ә-әй... Танымый да торам, анавы, син икәнсең ләбаса! — Шулчак бандит та, аны танып, яңадан очратуына чын-чынлап куанды бугай.— Мин бит сине, җанкисәгем, бөтен Чистайны бетереп эзләдем. Тешләреңне берәм-берәм... берәм-берәм суырырга дип. Ха-ха-ха! Ул чакта менә шушы примус...— ул кулындагы пистолет белән кизәнеп алды. Аннары, шәраб тулы бокал күтәргән кебек, аны сак кына борып, көпшәсен янә өскә каратты.— Менә шушы примус очына утыртып, йоныңны өтәргә өлгерә алмый калдым, анавы. Хәзер инде пуля йотудан котыла алмассың. Юк!

Бандит, җилле генә килеп, пистолет көпшәсен Шамилнең тешенә төртте.

— Сабыр, сабыр!..— дип арага керде Санька-анархист.— Син кызып китмә, Азман. Яшь дустыбыз әле сүзен әйтеп бетермәде бит. Без әүвәл аның тел төбенә төшәргә тиешбез. Тел төбенә! Шунсыз бу дөньяда да, тегесендә дә тынычлык булмаячак. Аңа гына түгел, безгә дә...

Анархист, кыз кочаклаган кебек назлы гына итеп, Шамилнең җилкә-

сенә кулын салды:

— С-син... әгәр тагын бер минуттан мәеткә әйләнәсең килмәс-сә... Дустым, әйт... куркасың икән, колагыма гына пышылда: кем с-сүзе белән килдең? Кем с-сатты безне? Кем?!

Бу оятсыз танауга куш йодрыклап берне тондырасы килде Шамилнең. Әмма көчләр тигез түгел, ут белән уйнау бик хәтәр иде бу мәлдә. Ул, чак кына борылып, Миргазияновка күз төшерде. Тегесе шундук куырылып килде, каш астыннан усал итеп карады, җиз шәмдәлгә ябышып, аны үзенә табарак тартты...

— Ул...— диде Шамил, башы белән ишарә ясап.— Ул хат язып җибәрде...

— Яла якма, кабахәт! — Миргазиянов, урындыгыннан сикереп торып, өстәл аша шәмдәл белән кизәнде.

— Тукта, Самат!..— Санька-анархист револьверын аңа төбәде.— Кагыласы булма!.. Ул хәзер безнең кулда. Йомдырырга кайчан да соң түгел. Өстәвенә бик кызык сөйли бит, әй...— Янадан юха тавышка күчте.— Дәвам ит, егет, дәвам ит. Бәлки, ул «бөти»не безгә дә күрсәтерсең әле... Йә!

— Учына кыскан... Шәмдәл белән бергә...— диде Шамил. Үзе, зиһенен җыеп, хәзер нинди адым ясау бердәнбер дөрес юл булыр дип уйланды. Бөтен җаны-тәне белән сизеп тора: инде кечкенә генә ялгышу да гомер бәрабәренә торачак.

Миргазиянов, шәмдәлне үз урынына куеп, уч төбендә бөгәрләнеп яткан газета ертыгын бирергә мәҗбүр булды. Куркудан тибеп чыккан тир белән, ахрысы, кәгазь лычма юешләнгән иде. Санька-анархист, үзе сораган «бөти»не күргәч, аны ерткыч җитезлеге белән умырып алды. Елан бәбәгедәй керфексез күзләрен тигез, матур юллар өстеннән шудырды.

— Самат!.. Сабакы дустым минем!..— ул, сихерләнгән кебек, карашын язудан аера алмый иде.— Монда бит... монда без икәү генә аулакта сөйләшкән нәстәләр сырланган. Һай-һай-һай... Бигрәкләр дә үкенечле үлем белән бетәсең икән...— Санька, өстәлне тиз генә урап үтеп, револьверын Саматның чигәсенә терәде. Шамил бер мизгелгә әлеге Чистай бандиты белән генә калды. Шул иркенлекне сизеп, ярты гәүдәсе белән өстәлгә таба борылды.

— Саня!.. Чынлап та шуңа ышандыңмы, Саня? — Миргазияновның йөзе акшар кебек агарды, теле тотлыкты, тавышы калтырап чыкты.— Мин түгел, валлаһи, мин түгел!

Анархистның йөзеннән дәһшәт, сүзеннән гүр салкыны бәреп чыкты:

— Йәле, әфәндем, үзең сырлаган берәр «бөти»не китер әле, карыйк.

— Санюшка, кирәкмәгәнне эшлисең. Болай берни дә ачыклый алмассың. Санюшка, гөнаһтан курык...— Миргазияновның тез буыннары капчыктай салынкы зур гәүдәсен күтәреп тора алмады, ахрысы — хәле китеп, урындыкка ишелеп төште. Миргазияновның ишеткәне дә бар, күреп тә чамалый иде: ни хәтле генә салкын канлы булып кыланмасын, Санька-анархисттан да холыксыз, кызу канлы адәм дөньяда юктыр. Әйе, талканы коры бу ерткычның: ул дигәнчә булмаса, хәзер ботарлап атарга тора.

Саматның киреләнүе, тарткалашуы анархистка тәгаен ошамады, канын гына кыздырды:

— Сиңа әйтәләр!.. Тиз бул, күрсәт язуыңны!

Әмма Самат тораташка әйләнгән, ул инде суламый да, дәшми дә иде.

— Йә, Азман, тиз генә берәр «бөти» табып бир әле... Бу ахмак сырлаган берәр кәгазьне дим.

Чистай бандиты, күзен Измайловтан алмаган көе, Самат янына авышты, бер кулы белән маузерын кысып тоткан хәлдә аңа буш учын сузды: янәсе, китер, дускай, китер үзең язган кәгазьләрне.

Санька-анархист, андый-мондый хәл килеп чыкмасын өчен булса ки-

рәк. Измайловка урындыгы белән стена буена ук кучеп утырырга кушты. Юрамалый йомшак кыланып:

— Кулыңны артка куй, дустым. Шулай уңайрак булыр,— диде.

«Азман» дигәне исә ул арада өстәл тартмаларында казына башлаган иде инде. Каяндыр, иң аскы бүлемнән берничә бит кәгазь суырып алып Санькага сузды. Анархист газета кисәге белән әлеге кәгазь битләрен чагыштырып карады: шунда ук йөзе агарынды, яңак төерләре хәтәр уйный башлады:

— Ах, эт җан! Ах, кабих!

Аның һәр сүзе, мылтыктан аткан кебек чатнап-чатнап, коры яңгырый.

— Аяк астыңда туфрак булыйм, Санюшка. Акылыңа кил, зинһар. Гөнаһтан курык...— дип мышкылдады Миргазиянов.

Анархист, өзгәләп ташлардай булып, аның өстенә килде, күзләрен акайтып, тешләрен шыгырдатты:

— Гөнаһтан син куркыр идең, дустым. Син куркыр идең!

Самат кычкырып елап җибәрде. Куллары белән башын кочаклады.

— Мин язмадым бит аны, Санюшка. Валлаһи, мин түгел,— дип такмаклый иде ул.— Кайсыдыр мәлгуне... Нәкъ минем кулга охшатып... Безне бәрелештерәсе килә ул явызның. Маңгайга-маңгай!

— Аһ, син, сөйрәлчек! Икебез генә белгәнне... Кемгә диген әле. Чекистларга! «Чәки», «антихрист», имеш... Һәр сүзенә синең селәгәең ябышкан. Әле дә мин түгел дип торасың, кабахәт.

Санькaның ярсуы һаман ташый иде әле. Шулай да бөтен булмышында кинәт кенә икеләнү сизелде. Саматның үкси-үкси елавы шиккә калдырды, ахрысы.

«Чынлап та, әллә ул хәбәрне Миргазиянов салмады микән? — дип уйланды Шамил дә.— Аның кулына охшатып, бүтән берәү язган булса? Ә бит язганнары дөреслеккә туры килә. Кем кулы уйнаган соң алайса? Анархистларның юлын кисү кемгә хаҗәт? Ихтимал, кайчан да булса ул адәмнең юлына анархистлар каршы төшкәндер. Шуңа үч алуы — чека кулы белән бугазлап ташларга тели үзләрен. Шулаймы бу, түгелме?..»

Санька-анархист ботларын аерып басты. Көр тавыш белән:

— Азман, пычагың бармы? — дип кычкырды: әйтерсең лә хәзер тавык суярга җыена иде.

— Саня... Ходайдан курык! — дип буылды Миргазиянов. Аның тәмам өне киткән, тавышына үлем ачысы чыккан иде. Ул кинәт буш балак кебек ләпшердәп калган аякларына басты, ава-түнә тәрәзәгә таба юнәлде.

Азман, атаманның боерыгын гына көтеп торган кебек, маузерын Саматның аркасына төбәде.

— Тавыш-тынсыз гына...— диде Санька салкын кан белән.

Бандитның икенче кулында фин пычагы ялтырап китте. Әмма Миргазияновның да җиңел генә бирелəсе килмәде. Ул хәзер атылудан калган эт кебек иде. Тәрәзә төбендәге гөл чүлмәген эләктереп алып, гаҗәеп бер оста хәрәкәт ясады да, артыннан килүче Азман аңышып өлгергәнче, аның шешенгән чыраена тондырды. Тегесе, чынлап та, абайламыйчарак калды,— чүлмәк аның уң җилкәсенә килеп капланды. Пистолет «чырк» итеп идәнгә очып төште. Миргазиянов, «ә» дигәнче өстәлгә үрелеп, җиз шәмдәлгә ябышты.

Санька-анархист бу мәлдә револьверын Измайловка төбәп торса да, мөгаен, түзеп кала алмас, иң әүвәл Саматка берне төкертер иде. Әмма ике арада Азман буталып калды, үзе дә сизмәстән, гәүдәсе белән Миргазияновны ышыклады.

Бу хәлне күреп торган Шамил нишли ала иде соң?! Комиссар Соловьев биргән алтатарны үзеннән калдырмаган булсачы... Терсәкне тешлисеңме! «Исән калсам — киләчәктә ике пистолетсыз йөрмәм,— дип ант итте ул эченнән генә.— Хәзер менә икенче коралыңны суырып ал идең дә...»

Ә бүлмә эчендә чын-чынлап пәри түе кузгалды! Азман, алдында гына торган урындыкны күз ачып йомганчы һавада болгап, Миргазиянов өстенә җибәрде. Тегесенең ничектер иелеп калырга башы җитте. Чылтырап пыяла коелды. Астан, урамнан кычкырышкан тавышлар ишетелде. Урындык үзе ялангач тәрәзә рамына атланып калган иде.

Кызык кына хәл туды: Санька белән Шамил, ихтыярсыздан, берберсенә «күз-колак» булу аркасында, тегеләрнең бәргәләшүенә катнаша алмый торалар. Өстәвенә, бу һич тә Санька-анархист көткән, ул теләгән борылыш түгел. Каршысындагы юеш борынлы егетне атып кына егар иде,— бик мөһим ике сорау чекист мәете астында күмелеп калачак. Аларның берсе: Самат дигән мүкләк сыердан чека тагын ниләр савып алган? Икенчесе: банк кадәре банк басарга уйлаган анархистларга каршы Совет власте хәзер нинди тозак кора?

Ул арада Азман, кулындагы фин пычагын айкап, Миргазияновны кысрыклый башлады. Әмма Самат, җәһәт кенә борылып, шәмдәл белән тегенең беләгенә орырга өлгерде. Икенче мизгелдә инде ул, коралсыз калган бандитка нык кына сугып, тәрәзәгә таба ыргылган иде. Мәче җитезлеге белән тәрәзә төбенә атылып менде, җан ачуы белән тибеп, рамны ике якка аерып төшерде. Инде сикерәм дигәндә... аны баядан бирле сагалап торган Санька-анархист, ниһаять, револьвер чакмасына басты. Миргазиянов бер мәлгә тәрәзә уемында катып калды. Аннары аның капчыктай гәүдәсе, ничектер урталай сынып, тышка — урамга ишелеп төште. Азман, йөгереп килеп, тәрәзәгә капланды. Ул нәкъ шул мәлне яшь чекистның Санька-анархистка очып кунуын күрми калды.

Ә Измайлов бу сикерүгә пружинадай кысылып, йөрәгеннән уч төбенә йомарлап әзерләнде. Аңа хәзер иң-иң соңгы мөмкинлек — керфеккә керфек орынып алган арада гына булса да анархистның читкә каравы кирәк иде! Һәм менә ул мизгел — Саньканың үз ахириенә аткан чагы булды. Измайлов бөтен көче белән бандитның беләзек сөягенә китереп сукты — коралын бәреп төшерде. Тагын бер сугу белән аяктан ук егарга иде дә, әмма тегесе нык бәдәнле булып чыкты, каһәр, чайкалып кына алды да шунда ук егетнең бугазына ябышты.

— Эзләп киләләр! — дип акырды Азман: аның башы әле дә тәрәзә уемында, күзе урамда иде.— Санька, мильтоннар! Теркелдәргә кирәк, анавы!..

Бандит ашыгып артына борылды, идәндә бугазлашып ятучы икәүне күрде. Беренче талпынышы — Санькага ярдәм итү иде, ләкин шунда ук бүтән уй белән бүленеп, ярты юлда туктап калды. Ишек катында аунаган маузерын эләктереп алды да бәрелә-сугыла коридорга чыкты. Юл ябык иде инде: аргы баштан бирегә таба ике чекист йөгерә. Азман төзәп тормыйча бер генә атты да бүлмәгә кире атылып керде. Идәндә әүмәкләшкән анархист белән чекистка карап та тормастан, туп-туры тәрәзәгә ташланды. Әмма уйлап өлгерде: качуын кача да бит, бүлмәдә куркыныч шаһитлар кала. Бигрәк тә Санька гафу итәрме? Көн кебек ачык: йә — тотылса — аны да чекистларга сатачак, йә — алай-болай котыла калса да — якты дөньяда яшәтмәячәк.

Бандит инде тыштан, тәрәзә төбенә ябышкан килеш, үрелеп кенә ике тапкыр шарт-шорт атты.

Мурашкинцев белән Копко, бүлмә ишеген бәреп керү белән, идәндә сузылып яткан ике гәүдәгә абына яздылар.

— Тәрәзәне кара! — дип кычкырды Копко, үзе Шамилгә ярдәмгә ашыкты. «Соңардык микәнни?» — дип, ачынып уйлап алды. Әмма егет шунда ук башын күтәрде, аннары әкрен генә торып утырды.

— Исән, шайтан алгыры! Исән! — Копко, тезләнеп, аны кочып алды.

Измайлов монда булып узган хәлләрне кыскача гына аңлатты. Санька-анархистны карадылар: аның күлмәге ике төштән кан тибеп кызарган, тәнендә җан әсәре юк иде.

— Ну, малай, Шамил, син тәки җиде тишек белән калгансың,— дип

шаярткан булды Копко.— Ә менә бу адәмгә җан дусты тагын ике тишек өстәгән.

Яраланган Миргазияновның да хәле бик авыр иде. Шулай да, чыкмаган җанда әле өмет бар дип, больницага озаттылар. Шамил аның аңына килгәнен көтеп утырды. Кичкә таба Самат, чыннан да, күзен ачты. Чекага мин язмадым, диде. «Газыйм эше... Бүтән беркем дә түгел... Газыйм... Дардиев... Аның үче бар миндә...» — дип ыңгырашты.

— Кем соң ул, кайда яши? — дип сорады чекист. «Анархистларның банк басарга җыенганын, дары заводында шартлау булачагын кайдан белгән ул Газыйм?» — дип тә сорамакчы иде...

Әмма үлеп баручының күкрәгендә нәрсәдер бокырдап куйды, ап-ак иреннәренә күбекләнеп кан саркып чыкты.

«Франция» мөсафирханәсендә Дардиевны белүче табылмады. Бер карагаңда, бу адәм әллә ни игътибарга лаек түгелдер, аны эзләп маташуның кирәге дә юктыр кебек иде. Ләкин, төптәнрәк уйлаганда, ул үзе белән нииндидер бик мөһим табышмакның җавабын йөртә, аның табылуы һәм чишелүе зур җинаятьне ачуда хәлиткеч бер адым булуы бар. Чөнки әлеге исем тирәсендә сорау арты сорау калка. Әйтик, Дардиев бер максатны — Миргазияновны һәлак итү максатын гына күздә тотканмы? Ә бәлки ул тагын да мәкерлерәк тозак коргандыр? Банк басу һәм дары заводы шартлату хакында Санька-анархист белән Саматның сөйләшүен үзе тыңлап торганмы, әллә аны кемдер өченче берәү котырткангы? Анархистларга аның нинди катнашы бар? Гомумән, кем ул Дардиев, аның артында кемнәр тора?..

Миргазиянов Саматның бу сорауларга җавабы булгандырмы-юктырмы, әмма ул аларны — булган тәкъдирдә дә — үзе белән бергә теге дөньяга алып китте.

* * *

Санька үлеме генә анархистларны Совет властена каршы җинаять әзерләүдән туктатып калмас, әлбәттә. Моны Гирш Ольkenицкий яхшы аңлый иде. Әле генә ВЧКдан килгән шифрлы телеграмма да күңел тынычлыгын алды.

*Казан, Гоголь урамы, 28, Ольkenицкийга.*
*Мәскәүдә анархистларның Дәүләт хәзинәсенә һөҗүм оештырулары фаш ителде. Шундый ук акциянең Казанда да әзерләнүе хакында хәбәрләр бар. Тиешле чаралар күрегез.*

*Петерс.*

Бу телеграмманы Брауде белән Измайловка да укытты губчека башлыгы:

— Анархист халкыннан барысын да көтәргә була...— дип фикер йөртте ул.— Әйтик, хәзерге вакытта безнең Казан — Россиянең өченче башкаласы кебек мәртәбәле шәһәр. Бу җәһәттән ул, мөгаен, Мәскәү һәм Питердан гына калышадыр. Ә инде хәзинә ягыннан?.. Унбишенче елда ул Питердан китерелгән биш йөз капчык алтын тәңкәләрне генә искә төшерик. Җәмгысе ким дигәндә бер миллиард сумлык байлык саклана Казанда. Әйтерең бармы: пайтәхеттән кайсы ягы белән ким? Шулай булгач, мондагы анархистлар белән Мәскәүнең турыдан-туры эш йөртүе бик ихтимал...

Ольkenицкийны шул арада шәһәр милиция начальнигы белән тоташтырдылар. Ул, сүзне кыска гына тотып, Дардиев Газыйм һәм «Азман» кушаматлы анархист турында барысын да белешергә кушты.

— ...Без монда әлегә,— дип дәвам итте Гирш Шмулевич.— бик шәп-

ләп корылган ныгытманың судагы шәүләсен генә штурмлап ятабыз. Әмма шәүләсе бар икән, кайдадыр янәшәдә генә крепость үзе дә булырга тиеш бит, шайтан алгыры. Шулай түгелмени? Инде Санька-анархист күперен-нән кереп әллә ни уңышка ирешә алмаганбыз икән, һөҗүмне дары заводы ягыннан җәелдерергә мөмкин түгелме? Теге газета кисәгендә дә заводта диверсия әзерләнә дип хәбәр иткәннәр бит. Һич кичекмәстән, аның дөрес-ме-түгелме икәнен ачыклыйсы бар. Бигрәк тә хәзер — яман хәбәрнең, һәрвакыттагыча, дөреслеккә якын булуы беленгәч...

Губчека рәисе, нидидер уйга бирелеп, имән бармагы белән яңагын сыпыргалады; аннары, бик тырышып,ияген ышкып торды — бер тәүлек эчендә сакал-мыегының ничек җитүен тикшерә кебек иде ул.

— Димәк, Миргазиянов исеменнән хат язучыны да дары заводы тирәсеннән эзләргә кирәк.— Олькеницкий янында әлегәчә дәшми утырган Вера Брауде тынлыкны бозды.— Ничек әле, «развилка»га алу, диләрме артиллеристлар... Ике яклап, капыл гына һәм төп-төгәл китереп басу өчен...

— Шулайрак килеп чыга,— дип куәтләде Олькеницкий.— Берьюлы берничә юнәлешне күздә тоту зарар итмәс. Әле бит без Миргазиянов булып хат язучының да Дардиевмы, түгелме икәнен тәгаен генә белмибез.

— Хәтта нәкъ менә Дардиев кулы уйнаган булса да, ул ялгызы гына түгел... Аның янында тагын кемдер бар... Бөтен бер шайка булуы да ихтимал.

— Син шулай уйлыйсыңмы, Вера? Ә Миргазияновны авыр хәлдә калдыру? Ул да уч алу нияте белән генә булмагандыр дисеңме?

— Әйе, ныграк уйланган саен, мин шул фараз ягынарак авыша барам.

— Ачыграк итеп әйт...

— Беләсеңме, әгәр ул Дардиев — ярар, чекага хатны шул бәндә язган дип санык,— шәхси исәп-хисабын гына өзәргә уйласа, һич югы Миргазияновның эш урынын күрсәтер иде. Ә болай без бит Миргазияновны таба алмаска да мөмкин идек. Бигрәк тә шундый болгавыр заманда. Хат язучы моны гына чамалагандыр, дип уйлыйм. Бик чамалагандыр. Ул безнең озаклап, нечкәләп эзләргә вакытыбыз, җаебыз юклыгын да, гомумән эзләп-нитеп маташмавыбыз ихтималын да белгән, әлбәттә. Шулай түгелмени!?

— Хуш... Бусына кул куеп була! — Олькеницкий, хуплавын шулай расларга теләгәндәй, өстәл кырына учын бәреп алды.— Ә шуннан...

— Бәс шулай икән...— дип, канатлана төшеп дәвам итте Брауде.— хат язучының йә аны эшкә җиккән кампаниянең төп максаты бер: безне анархистларга каршы кузгату. Ягъни анархистларның оясына чека кулы белән ут салу. Кемгәдер бу бик кирәк. Әнә шул «кемсә», анархистларның ниятен белеп алгач та, җай чыгудан файдаланып калырга ашыга. Минемчә, ул хак-дөресен яза. Бер сукканда берәгәйле итеп сугасы килә...

— Ихтимал, синең сүзләрең дә чама-чамага туры киләдер,— дип килеште губчека башлыгы.— Бер нәрсә ачык: чиста куллы кеше эше түгел бу. Намуслы адәм, хәтта изге ният белән булса да, бүтән берәү артына посып шикаять язмас иде. Шулай булгач, Совет властеның дошманнарын фаш итү, безгә булышу теләге генә илһамландырмаган аны. Тыштан дөрес хәбәр астына нидидер яман ният салынган...

Бүлмәдә кинәт кенә сәер тынлык урнашуын абайлап алдылар. Сәгать туктап калган икән. Гирш Шмулевич, урыннан торып, авыр бронза гәрләрне берәм-берәм күтәреп куйды. Аннары кире өстәл янына килеп утырды.

— Миңа Вера Петровнаның икенче фикере кызыклырак тоела...— Тынлыктан файдаланып, Шамил дә сүзгә кушылды: — Хат артында бер генә кеше булмавын әйтәм... Бәлки, анархистларга аяк чалырга маташкан нидидер төркем яисә оешма эшедер бу?! Алтынга үзләре генә хуҗа булмасын әле дип...

— Менә хәзер шул хакта фараз итеп карыйк...— Ольконицкий күнегелгән хәрәкәт белән пенснесын иплэбрәк куйды.— Чеканың анархистлар белән ныклап торып шөгыльләнә башлавы нәкъ менә кемгә кирәк булыр? Кем моннан үзенә майлы калҗа өмет итә?

Вера Брауде затлы портсигардан бер папирос алды, әмма кабызырга ашыкмады, кулында әйләндергәләде.

— Орды-бәрде генә хәл итә торган мәсьәлә түгел бу. Төрле яклап, бик тирәннән уйлашасы бар.

— Анысы хәзер дә башны эшләтеп карауның зыяны юк. Ул кадәр үк тирәнтен булмаса да. Безнең максат — алга таба хәрәкәт итү һәм, димәк, шуңа таяныч булырдай моментларны билгеләү.— Ольконицкийның, кирәк чагында үз сүзен сүз итәргә, хезмәткәрләренә конкрет бурыч куярга омтылуы сизелә иде. Өстәл тартмасыннан бер бит кәгазь алып, тиз генә нидер сызгалап куйды.— Иртәгә Казан хәрби округының элеккеге контрразведка начальнигы белән сөйләшәм. Минем белүемчә, алар узган елны дары заводы белән шактый гына шөгыльләнеп алганнар. Анда ниндидер диверсия әзерләнүе ачылган. Әллә ни зур нәтиҗәгә өмет итеп булмый. Шулай да... Карап карыйк әле.

Телефон чылтырады. Шәһәр милициясе Дардиев хакында ниндидер мәгълүматлар тапкан, күрәсең. Ольконицкий, телефонны куйгач, кыскача гына сөйләп бирде. Андый кеше, чыннан да, бар икән. Казан гарнизонында прапорщик булган. Аннары Вакытлы хөкүмәт «милиция»сендә хезмәт иткән. Шуннан соң, унҗиденче елның декабрендә, җинаять җаваплылыгына тартылуы мәгълүм. Хөкем булганчы ук, сак астыннан качкан. Аңа тутырылган кәгазьләр дә югалган... Ә «Азман»ның кем икәнлеген әлегә ачыклый алмаганнар.

— Шундый-шундый хәлләр...— дип таркау гына сузып куйды губчека башлыгы. Бер мәлгә сүзнең очын югалтып алганы сизелде. Үзе дә моны яшермәде: — Кайда туктап калган идек әле без? Ә-ә...— дип исенә төшерде.— Анархистларга каршы... Әйе, ниндидер оешма, ниндидер кешеләр безнең кул белән утлы күмер чүпләргә чамалый... Шул хакта иде бит сүз, әйеме?

— Әйе,— дип әкрен генә җөпләде Измайлов.

— Инде мәсьәләгә якынрак килик. Хәзерге көндә шәһәрдә Совет властена каршы нинди көчләр бар? Зур, оешкан көчләрне генә алсак...— дип дәвам итте Гирш Шмулевич.— Эсерлар — бер. Монархистлар — ике. Төп менә шул ике астыртын оешма. Дөрес, хәзергә бик сизелмәсә дә, безнең муенга асылынган тагын бер авыр таш бар: элеккеге хуҗалардан мирас булып калган бәла — герман разведкасы. Барысын бергә кушып карасаң, өч башлы аждаһа килә дә чыга. Нәкъ әкияттәге кебек: мәкер, явызлык һәм үлем белән тулы өч баш.

Шамил, бу чагыштыруны күз алдына китереп, мыек астыннан гына елмаеп куйды.

— Аждаһаның өченче башын — герман разведкасын беренче селтәнүдә үк кисеп ташларга була. Дөресрәге, аны исәпкә дә алмаска кирәк,— диде Брауде.

— Чү, без аңлап җиткермәдек,— диде Ольконицкий.

Вера Петровна, баядан бирле кулында әвәләгән папиросны кире урынына салып, портсигарын шартлатып япты.

— Кайзер шымчылары гомер-гомергә Россиянең ике казыгын селкетәләр...— дип башлады ул.— Берсе — хәрби, экономик һәм сәяси серләрен урлау юлы белән булса, икенчесе — хәрби заводларда һәм транспортта диверсияләр оештырып. Сугыш хәлендә исә, ундүртенче елдан башлап, немецлар диверсия ягына күбрәк басым ясыйлар. Аларның стратегиясе хәзер дә үзгәрмәде дип уйлыйм. Шулай булгач, диверсия әзерләнүен алдан сиздереп кую... Германнар өчен бу һич тә файдалы эш түгел. Поездларны әйләндереп каплау, заводларны шартлату — чит ил разведкасының күзгә күренердәй эше шул бит хәзер. Безгә ни хәтле начар

булса — аларга шул хәтле әйбәтрәк... Бусы мәсьәләнең хәрби ягы, диик. Медальнең икенче ягы да бар, анысы сәяси як. Илдәге хәлнең тотрыксыз булуы, беркемгә дә буйсынмый торган төрле оешмаларның, мәзһәбләрнең күбәюе... Аждаһаның өченче башын болар кызыксындырмый дисезме. Ә инде анархистларны әйткән дә юк. Алар болгаткан мохит — дошман шымчыларына оҗмахтан да шәбрәк ич! Менә шуңа күрә ул «өченче баш» анархистлар оешмасын һич тә утлы сулышы белән көйдермәячәк. Киресенчә, әлеге шайтан таяклары Россия суыгында шиңә күрмәсен дип, йомшак кына итеп, җылы сулышын өрә торырга әзер ул.

— Алайса, сиңа бер сорау, Вера.— Ольксницкийның пенснесы ялтырап китте. Мәсьәләне кабыргасы белән куярга тели иде, ахрысы, ул.— Мондый хәл-халәтне күз алдына китерик: имеш, безгә хат язган адәм бер үк вакытта герман разведкасына да теш кайрый, анархистларга да үчле, ди. Булырга мөмкинме шундый хәл?

Бер мәлгә өчесе дә тынып калдылар.

— Ә ник булмасын,— диде кинәт Измайлов.— Ул, әйтик, немец шымчысы, ди: нинди дер сәбәпләр аркасында үзләренекеннән ычкынырга тели, яисә, киресенчә, тегеләргә хәзер аның кирәге беткән... Менә шуңа бәргәләнә... Икенче төрле дә булуы бар: шул ук Дардиев, мәсәлән, үз вакытында чит ил разведкасы белән бәйле булган, әмма немецлардан да, анархистлардан да игелек күрмәгән, ә хәзер йә эсерлар, йә монархистлар арасына барып эләккән...

Ольксницкий белән Брауде бер-берсенә карашып куйдылар.

— Ә безнең егет уенга кереп бара...— дип көлемсерәде губчека башлыгы.— Авызына бармагыңны тыксаң, тешләп өзәр. Ә?

— Шундый ул минем якташ,— Вера Петровна да матур итеп елмайды.— Миргазияновны көнә-сәгате белән эзләп тапты бит.

Шамил кызарды. Сүзне үзеннән читкә борасы килеп, авыз эченнән ботка пешерде. Әйткәннәреннән бер фикер оешты: хәрби контрразведканың соңгы ике-өч елдагы архивын өйрәнер идем, рөхсәт булса, диде. Каушап, буталыбрак сөйләсә дә, Ольксницкий аның теләген аңлады:

— Мөмкинлектән файдаланып, тирәнрәк казын. Герман агентурасының дары заводы тирәсендә кайнашуы турында мәгълүматлар кирәк. Күбрәк шуңа игътибар ит,— диде.

* * *

Герман контрразведкасына кагылышлы кәгазьләрнең архив дип зурлап әйтерлеге дә юк булып чыкты. Бармак калынлыгындагы бер «эш» һәм берничәшәр бит кәгазь генә тегелгән тагын ике катыргы.

Тышына «1915—1916» дип язылган, нинди дер күгәрек таплар төшкән бер папкада төрле гаризалар, түләүле шымчыларның хәбәрләре теркәлгән. Шунда ук һәр «сигнал»ны тикшерү, чарасын күрү турында белешмәләр дә бар. Хәер, аерым-аерым карый башласаң, һәр сигналны ук түгел икәне аңлашыла. Кайбер фактларга бөтенләй игътибар ителмәгән, ярым-йорты гына тикшерү эзләре дә ярылып ята. «Күрәсең, контрразведка кешеләренең бүтән мәшәкатьләре дә күп булгандыр»,— дип уйлап алды Шамил. Аларның кәеф-сафа кору, кызлар күңелен күрү җәһәтеннән төрле маҗаралары турында анекдотлар ишетергә туры килгәләде инде.

Унҗиденче ел папкасы да бик арык, таш астында калып сытылгандай мескен кыяфәтле иде. Әмма андагы кәгазьләрнең берсе Измайловны чынчынлап сискәндерде. Әле кайчан гына Чистай төрмәсендә күргән газаплары, үлем җәзасы көтеп яткан сәгатьләре ап-ачык булып күз алдына килде. Үз вакытында хәтта үлемгә хөкем ителүе дә бөтен тулылыгы, бөтен фаҗигасе белән аңына барып җитмәгән иде шикелле, ә менә хәзер, инде байтак сулар аккач, ул чаклар искә төшсә, бөтен тәне чымырдап, куркынычтөш күргәндәге кебек сулыш буыла. Әле исә авыр хатирәләрне куз-

гаткан кәгазь — контрразведка начальнигы полковник Кузьминга Чистай прапорщиклар мәктәбе башлыгы полковник Кузнецов җибәргән хат иде.

«Менә бит нәрсәдә булган хикмәт! — Яшь чекистның күз аллары карангыланып китте.— Теге чакта миңа кырлач кебек ябышкан «эш»нең тамыры менә кайда икән! Полковник Кузнецов кайзер агенты булырга теләмәгән, шуның өчен гомере белән түләргә туры килгән. Ә үтерүче бөтенләй гаепсез кеше аркасына ышыкланып калган. Һәрхәлдә, тикшерүче мине стенага китереп терәгән иде ич инде. Очратасы иде ул эт җанны хәзер».

Измайлов зәңгәр бизәк белән каймаланган почта кәгазен кулында әйләндерде. Аның читендә контрразведка башлыгы Кузьмин сырлап куйган кыска резолюция генә бар иде: «Тикшерүне капитан Т. Ә. Мулюковка тапшырырга». Бу эшкә мөнәсәбәтле бүтән бер кәгазь дә күренми..

«Мулюков... Мулюков...— дип кабатлады Шамил.— Мине үлем тырнагыннан коткарган «Хозер Ильяс» шул икән». Ул чакта фамилиясен сорап калырга да башка килмәде. Хәле бик авыр иде. Зиһене таралган иде... Исән микән әле ул кеше?..

Контрразведка капитаны Мулюков фамилиясенә Шамил инде беренче папканы актарганда ук игътибар иткән иде. Анда немец агентурасы һәм дары заводы җимләсеннән берничә бит очрады. Шул язулардан күренгәнчә, әлеге «эш» белән шөгыльләнү нәкъ менә Мулюковка тапшырылган була. Кыска гына вакыт эчендә капитан беренче нәтиҗәгә дә ирешә: заводка оялаган диверсантның эзенә төшә. Ләкин «эш» ни өчендер бүтән кеше кулына күчә. Резидент кына түгел, аның элемтәчесе дә болганчык суга чумган балык кебек юкка чыга...

Архив белән танышу, ниндидер ачыклык кертәсе урында, бер көтү сораулар гына тудырды. Шуңа күрә элеккеге контрразведка начальнигы полковник Кузьминның губчекага килүен Гирш Шмулевичтан да бигрәк Шамил Измайлов көтеп алды.

Әмма инде комы коела башлап, акылы корсагына төшеп беткән бу карт үзенә багланган өметләрне акламады. Боргаланды, ык-мык итте, буталып бетте. Бераздан аңлашылды: сорауларга җавап бирәсе килмәүдән генә түгел, ахрысы, бу. Күптәнме әле хәрби округ контрразведкасы башыда утырган адәм соңгы бер-ике елда үз тирәсендә нинди хәлләр булганын белми һәм төшенми иде. Немец диверсанты турындагы «эш»нең ни өчен бер тикшерүчедән алынып, икенчесенә (әле, мөгаен, көчсезрәгенә) бирелүен дә рәтләп аңлата алмады. Борын астыннан гына мыгырдап әйткәне шул булды: «Мулюков олыны олы итә белми иде. Әйткән сүзгә колак салмый. Һәрвакыт үз туксаны туксан булыр. Башына бер уй төшсә, фил кебек, җимереп-сындырып, юлсыз төштән юл салып барадыр иде».

— Начальникның хатасына да ләббәйкә дип тору — шул хатаны фаҗигалерәк итү генә бит. Сез аңа юкка үпкәләгәнсез,— дип төрттереп куйды Ольккеницкий.

Карт полковникка бу сүзләрнең мәгънәсе барып җитмәде бугай. Ул:

— Әйе шул, әйе шул,— дип баш кагып кына куйды.

Олькеницкий урыныннан торып баскан. Кузьмин да, бу ишарәне аңлап, китәргә кузгалган иде, Шамил иң соңгы соравын бирергә ашыкты:

— Александр Павлович... Мулюков хәзер Казанда микән? Аның кайдалыгын әйтә алмыйсызмы?

— Төгәл әйтергә кыенсынам, әфәндем, әмма ул монда булырга тиеш. Галим-голәмәгә кызыгып карый иде. Университетка шылтыратып белешегез. Шул тирәдә күп ышкынды ул минем белән эшләгәндә дә...

Чыннан да, Мулюков Талип Әкрәмовичның гыйнвар аеннан бирле юридик факультетта укытучы булып эшләве ачыкланды. Кузьмин белән сөйләшүнең бөтен файдасы шул иде.

Олькеницкийның да бу очрашудан канәгать калмавы сизелде:

— Туз, имеш. Полковник. Хәрби округта контрразведка башлыгы. Ә бөтен белгәне — әтәчтән күкәй салдырган кебек булды...

Шамил өчен дә Кузьминның кызыгы калмаган иде. Губчека рәисенә ул унҗиденче елның көзендә Чистайда булган мажаралар, капитан Мулюковның үзен ничек итеп үлемнән коткарып калуы турында сөйләде. «Шуңа күрә хәзер үк университетка йөгерер идем».— диде.

Гирш Шмулевич каршы килмәде.

— Немец агентының тышкы кыяфәтен, үз-үзе тотышын төгәлрәк итеп тасвирлый алмасмы... Нечкәләп сораш,— диде.

...Бәхеткә каршы, Мулюков университеттан кайтып китәргә өлгермәгән икән. Бары дәрес тәмамланганын гына көтеп торырга туры килде. Шамил соклану катыш кызыксыну белән як-ягына каранды. Ут алырга иртәрәк әле, ахрысы, беренче катның коридорында лампочкалар янмый; шуңадыр, җиңелчә эңгер-меңгердә мәшһүр дивар тагын да серлерәк, мәһабәтрәк булып күренә иде.

«Их, шушында укысаң...» — дип уйлады Шамил. Көчле тәэсирләрдән күкрәге кысылды. Ниндидер гаҗәеп җан иярәренә таба кулын сузган кебек, эңгер куләгәсе төшкән диварларга сак кына кагылып-кагылып алды: «Кемне генә, ни генә күрмәгән бу стеналар...»

Татлы хыялга чумып, дөньясын оныта язган ич. Дәрес беткән, аудитория ишеге шар ачык. Иң соңгы берничә студент чыгып килә. Шамил, этешә-төртешә булса да, вестибюльгә, аннары чыгу юлына йөгерде. Шунда гына колонналар арасындагы баскычтан төшеп баручы Мулюковны күреп алды.

Башына соры эшләпә батырган кыска буйлы агай, беләгенә җиңелчә генә кагылу белән, кисәк борылды. Мондый кискен хәрәкәт аның контрразведкада озак эшләвеннән килә торгандыр, дип уйлап алды Шамил.

— Талип Әкрәмович, сезнең белән сөйләшәсе бар иде...

Тавышы ничектер әкрен, оялчан чыкты, йөзенә дә кызыллык сирпелде. Шуңа күрәдер, ахрысы, мөгаллим Мулюков, бер күз төшереп алу белән, яшь чекистны зачетын тапшыра алмый йөргән студент дип уйлады. Туктап тормаска итте:

— Иртәгә килегез, агайне. Иртәгә. Нәкъ шушы вакытта,— дип кырт кисте. Тик, бер адым атлауга, нәрсәдер исенә төшкән кебек, капылт кына туктады.— Карагыз әле... Мин сезне элегрәк тә күргәнем бар шикелле... Ә? — диде.

— Хәтерегез яхшы икән, Талип Әкрәмович. Измайлов булам мин. Чистайдан. Теге чакта үлем җәзасыннан коткарып калдыгыз бит. Рәхмәт яусын.

Мулюковның чырае яктырды, иреннәрендә, күзләрендә канәгать елмаю чагылды.

Коры рәхмәттән тун тегеп булмый, диләр диюен; бигрәк тә мондый яшь-җилкенчәктән әллә ни игелек көтәсе юк. Әмма күренеп тора: үткән көннәрдән рәхмәт-ихтирам сүзе ишетү, онытып бетермәүләрен тою барыбер рәхәт.

— Сез хәзер кайда соң, агайне? Ничек көн күрәсез? — дип, хәлгә кергәндәй итеп сорады Мулюков. Чистай хәлләре шактый ачык булып исенә төште, күрәсең; йөзенә шушы яшьли төрмәгә эләккән егетне кызгану төсе чыкты.

Измайловның, нигәдер, турыдан гына җавап бирәсе килмәде.

— Беләсез бит, Талип Әкрәмович: революция бөтен баскычларны әйләндереп куярга ярата. Аскы басмалар күз ачып йомганчы өскә күтәрелә. Җырдагыча: «Кто был никем, тот станет всем».

— Һәм киресенчә,— дип кыстырды Мулюков.— «Кто был всем, тот стал никем». Шулай түгелме?

— Сезгә карап мин һич тә алай дип әйтмәс идем.

— Шаяртасызмы...— Талип Әкрәмович уңайсызланып елмайды, кулын селтәп куйды. Акланган сыман тезеп китте: — Мин бит коточкыч зур механизмда кечкенә бер тәгәрмәч кенә идем; ак сөягем белән дә мактана алмыйм: сабын заводы эшчесенең малае. Сәнәктән кирәк булган, диләр безнең хакта.

— Алай икән...— дип сузды Измайлов.— Сезне эзләп килүем — рәхмәт әйтергә дип кенә түгел. Фикерегезне ишетәсе килә. Ничек уйлыйсыз, Талип Әкрәмович: дары заводында әле дә булса герман агентурасы эш йөртергә мөмкинме? Бусы бер...

Шамил, үзенең сораулары белән мавыгып, әңгәмәдәшенә игътибар да итмәде. Ә тегесенең шундук иреннәре кысылып, йөзе агарынып китте, кашлары маңгаена менде.

— ...Һәм тагын бер мәсьәлә...— дип дәвам итте Шамил.

— Карагыз әле... иптәш кем...— Мулюков аны бүлдерергә мәҗбүр булды.— Сезне чекада эшлисез дип беликме соң?

— Гафу итегез... онытып җибәргәнмен.— Яшь чекист күкрәк кесәсеннән мандатын алып күрсәтте.

— Сүзегез бик җитди булырга охшаган. Әмма монда килешеп бетәрме соң...— Үтеп-сүтеп йөргән студентларга ымлап, мөгаллим-контрразведчик җилкәсен сикертте.

Сөйләшә-сөйләшә Державин бакчасына таба үттеләр. «Бакыр бабай» һәйкәле янындагы буш эскәмия әңгәмә өчен бигрәк тә кулай күренде. Эскәмиягә үк иелгән яшь яфраклы тупыл ботакларыннан гаҗәп хуш ис аңкый. Сулыш алганда һава түгел, шул яшь тупылның дымсу исен сулыйсың кебек. Өстәвенә, аз гына да җил исми, ул бөтенләй йокыга талган, ахрысы,— хәтта иң биек агачларның иң өске ботак очлары да селкенми. Агач башлары, биек морҗалар, урам булып тезелгән ике катлы йортларның түбәләре кичке якты нурга күмелгән булса да, моннан кояш эшләпәсе үзе күренми — ул монастырь гөмбәзенә ышыкланган.

Әйе, көн җилсез, кояшлы, җылы бүген. Әмма, эскәмиягә утыру белән, җирнең әле җылынып җитмәгәнен тоясың, аның дымсу-салкынча сулышы әкренләп сине дә өшетә башлый. Инде байтак дым эчүдән кара төскә кергән иске яфраклар корамасында үзара чыр-чу килүче чыпчык халкының гына моңа бер дә исе китми төсле.

Чыпчыкларга эскәмия каршыннан узып баручы пар да игътибар итте. Яшь чырайлы, текә күкрәкле ханымның җилле адымнарына көчкә-көчкә ияреп баручы карт, сүз юктан сүз булсын дип әйтте ахрысы:

— Чыпчык туйлары апрель башында ук уза торган иде. Ә сезнең Казан чыпчыклары бигрәк дәртле күренә. Ай бетеп бара — һаман да тынычлана алмыйлар әле, хи-хи...

Картның кинаясе мут ханым күңеленә дә бик хуш килде: рәхәтләнеп хихылдады.

Шамилнең сорауларына бәйнә-бәйнә җавап бирә башлаган Мулюков әлеге сәер пар үткән арада тынып торган иде. Ниһаять, яңадан телгә килде. Студентларга дәрес аңлаткан кебек, сүзләрен кул ишарәсе белән озата-озата, сабыр гына сөйли иде ул:

— ...Кабатлап әйтәм: мин контрразведкадан киткәнгә әле ярты ел гына узса да, бик күп нәрсә үзгәрергә өлгерде. Иң әүвәл — Идел буеның хәрби-сәяси тормышы хәзер бөтенләй бүтән. Ә бу хәл герман разведкасының үз-үзен тотышына йогынты ясамый каламы? Һәрхәлдә, алар эш алымнарын бик ашыгыч төстә үзгәртергә мәҗбүр булганнардыр. Сыйнфый сугышлар тынмаса да, күпләрнең яңа власть яклы булуы бик ачык. Үзен ил хуҗасы итеп тойган халык исә дошманны ишектән дә, тәрәзәдән дә куачак. Ахыр килеп, чит ил шымчыларына иң олы капка да ябыла: патша заманындагы, аннары Вакытлы хөкүмәт дәверендәге кебек, төрле түрәләрне сатып алу мөмкинлеге көннән-көн чикләнә.

Талип Әкрәмович тупыл ботагыннан ачылып ук җитмәгән бер яфрак өзеп алды, аны бармаклары белән бөтергәләде, шул яшел бөтерчекне иснисни, сүзен дәвам итте:

— Билгеле, разведка — дөньяда иң тиз үзгәрүчән контора ул. Шартлар алышына башлаганчы ук яңача эш йөртергә күчмәсәң — харап: бетте баш, калды муен утырып, диярсең. Бер хезмәтнең дә бәһасе шундый

кыйммәт тормый: ә монда — һәммәсе дә күбәләк кебек җаның бәрабәренә генә килә. Кечкенә генә хата киттеме — капут; картлар әйтмешли: «иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун»... Ягъни гел үзең утырган ботакка балта чабасың...

Хәзер мәгърифәтчелек белән шөгыльләнүче контрразведчикның төп мәсьәләгә шундый урау юллар белән килүен Шамил түзем генә тыңлап утырды. Нияте изге Талип Әкрәмовичның — егеткә герман разведкасының үзенә генә хас сыйфатларын аерым шартлар яссылыгында аерып-аерып күрсәтәсе килә.

Дары заводында «шпион тоту» белән бәйле вакыйгаларны да тезеп-тезеп сөйләде Мулюков.

— Кызганычка каршы, сез инде белгәнчә, барысы да пәрәвез җебе кебек тиз өзелде,— дип искә алды ул күңелсез генә.— Шул җеп буйлап барып, резидентка чыгарга иде исәп. Өстән күрсәтмә булды да, ашык-пошык тоттылар диверсантны. Аннары, диверсант сүзе буенча, Перинов Семен Семенович дигән берәүне кулга алдык. Ә ул бөтенләй бүтән кеше булып чыкты. Агентыбыз шул исем артына яшеренеп кенә йөргән... Адәм хурлыгы инде.

Мулюков, урелеп, тагын бер яфрак өзде.

— Дары заводына теге заманда шул ялгыз диверсант кына үтеп керә алган булса кирәк. Миңа шулай тоела. Дөресрәге — моңа минем иманым камил. Ни өчен дисәгез, немец инде әллә кайчан шартлаткан булыр иде заводны. Бигрәк тә илдә хуҗалар алышынган вакытта. Аларга ул чакта берни дә комачауламады бит. Шулай булгач, хәзер төп шик-күләгә яңа алынган кешеләргә төшә. Аларны нечкә иләктән үткәрергә туры киләчәк сезгә. Немецлар да, әгәр бүтән чара калмаса, сатып алудан җирәнмиләр... Ояты барыбер сатлык җаннарга төшә ич...

— Икенче сорауга да әлегә сез генә җавап бирә аласыз, Талип Әкрәмович. Архивтан полковник Кузнецов хаты килеп чыгу мине икеләтә тетрәндерде. Иң әүвәл — теге чакта үз язмышым белән бәйле булганга күрә. Аннары, хәзерге хәлләргә нинди дер бәйләнеше юк микән, дип уйлаганга да. Архивта ул эшнең сезгә тапшырылуы гына теркәлеп калган. Нинди дә булса нәтиҗәгә ирешә алдыгызмы? Полковникны үтерү белән герман разведкасы арасында бәйләнеш юкмы?

— Кара син аны, яшь бүре карт бүре эзеннән килә икән... Сорауны дөрес кую — үзе ярты җавап, диләр.— «Карт бүренең» йөзе канәгать-горур елмаю белән яктырды.— Сезне бу очракта, гомумән, немец агентурасы түгел, аның дары заводы белән бәйле эшчәнлеге кызыксындыра, әлбәттә. Дөрес әйтәсез: бу сорауга әлегә мин генә җавап бирә алам... Әгәр Казан хәрби округына бер генә түгел, унбер немец шпионы оялаган булса да (гәрчә бусы бик шикле), аларның дары заводы тирәсендә йөрүчеләре белән Кузнецов үлеме арасында турыдан-туры бәйләнеш бар дип уйлыйм. Бая сөйләгәнемне мыекка урап калдыгыз микән: агентның хәтта диверсант каршында да Перинов Семен Семенович булып йөргәнен әйткән идем... Ә Кузнецов хатында кем искә алына? Шул ук исем түгелме?

— Сез бит, андый фамилияле кеше тотылды, дидегез. Димәк, ул исем бер тапкыр фаш ителгән. Шуннан соң инде, ай-һай... Хәтта икенче юлы әлеге исемне бүтән бер шымчы файдалангандыр дисәң дә... Һич ышанасы килми.

— Баштарак мин дә шулай аптырашта калган идем.— Мулюков, башындагы фетр эшләпәсен салып, пеләшен сыпыргалап куйды.— Ул баш-ваткычка төгәл генә җавап таба алмадым. Әмма... ялган Периновның — аның әле Карачкы дигән кушаматы да бар — бөтен тасвирламасы, беләсезме, кемгә туры килә? Полковникны таптаткан вакытта дилбегә тотып утырган кешегә! Тарантас башына сезне кунаклатканда Кузнецовның эше беткән була бит инде. Ә полковникны таптатып үтерү — һич очраклы хәл түгел. Хатын да укыган булгач, беләсез: бу — аңа икенче тапкыр һөҗүм ясаулары...

— Шуннан соң бөтенесен миңа сылап калдырырга тырышкан инде тикшерүче агай... Карагыз, ул да бар бит әле. Алай-болай аның немец разведкасына яллануы расланмадымы? Әллә җинаятьне тиз ачу өчен теләсә нинди этлеккә бара торган бер туңбаш кына булганмы ул, Талип Әкрәмович, ә?

— Фамилиясе ничек иде әле аның? Сера... Сера... Ә-ә, Серадов бит? Аны, мөгаен, тикшерүгә керешү белән, куркытып та, акчага кызыктырып та сатып алганнардыр. Ләкин шпионнан ришвәт алу — үз муеныңа үзең элмәк салу белән бер. Шул үлем элмәгеннән тартып йөртәләр инде аннары: тегене эшлә, моны эшлә, дип... Серадов, минемчә, бик куркак кеше булган. Кыю адым ясарга тумыштан сәләтсез. Шуңа күрә безнең контрразведкадан гына түгел, кайзер агентларыннан да качкандыр дип уйлыйм. Аны, билгеле, эзләп табарга кирәк. Алай-болай булмасын өчен. Чөнки хезмәт урынындагы кеше чит ил разведкасыннан бер тапкыр ришвәт алган икән, аны инде, теләсәң-теләмәсәң дә, түләүле агент дип санарга туры килә. Ул, үзе дә аңлап бетермәстән, куркыныч җинаятьче — илгә хыянәт итүче булып әверелә. Минем уемча, Серадовны кулдан ычкындырмаска тырышачак герман агентурасы. Чөнки нәкъ шундый кешеләр җилкәсендә яши ул. Иң пычрак эшләргә шуларны кертеп җибәрә.

Резидентка чыктым дигәндә генә диверсант «эше нең бүтән берәүгә тапшырылуын Талип Әкрәмович үзенчә аңлатты. «Җеп очын чуалту өчен юри шулай эшләнмәдеме икән? Кузьминга немец агентурасының тәэсире булмаганмы?» — дигән сораулар аны бераз уйга салса да, җавабы катгый иде: «Юк, юк, алай булуы мөмкин түгел».

Элеккеге контрразведчик төп бәлане Кузьмин белән ике арадан кара мәче узуыннан күрә иде.

— Кеше арасына керү өчен зур акыл кирәкмени? Бигрәк тә шикчел, карт кешене саташтыру җиңел...— дип аңлатты ул һәм шулчак прапорщик Дардиев Газыйм исемен телгә алды.— Үчле кешеләр коткысы беләнме, әллә инде Александр Павлович үзе үк шулай оештырдымы — Дардиев минем кулга охшатып бер язу язган иде. Полковникны мин мыскыл иткәнмен кебек килеп чыкты. Шуннан соң, билгеле, аралар бөтенләй бозылды.

Шамилнең тамак төбе кипшенде, тавышы карлыгып чыкты:

— Дардиев?.. Сез ул кешене беләсезмени?! Хәзер кайда ул?

— Кайда ул хәзер?..— дип кабатлады Мулюков.— Мин төгәл генә әйтә алмыйм. Теге чакта әле беренче Казан запас полкында хезмәт итә иде, прапорщик булып. Аннары, февраль вакыйгаларыннан соң, милициягә күчкән дип тә әйттеләр. Болай соңгы араларда күргән-белгән кеше юк. Инде җаны җәһәннәм төбенә очкан булуы да бар...

— Юк, ул исән. Андыйлар үлемсез була... Аның ишеләрдән җир җирәнә, диләр бит. Безгә бик кирәк иде ул адәмне табу.

Мулюков, көлемсерәп, Шамилнең беләгеннән тотты:

— Сезгә дә мәшәкать тудырган икән алайса. Үзе кача да, эзе кала, димәк. Осталык җитми! — Ул, нәрсәдер күрергә теләгәндәй, башын күтәреп, күзләрен кыса төшеп, Театр мәйданы ягына карады. Кулы белән дә шул тарафка ишарәләп куйды.— Анда, Дворянское собрание йортында, төрле атаклы артистлар килгән чагында күргәли идем мин ул Дардиевны. Һәрвакыт полковник Кузьмин тирәсендә чуалып иде...

— Алайса, Кузьмин белергә мөмкин әле аның кайда торганын? — дип, түземсезләнеп бүлдерде Шамил.

— Ах, әйе шул... Ул, һич югы, элеккеге адресларын әйтә ала. Бәлки, хәзер дә элемтәләре бардыр. Җепнәре килешә иде аларның...

Күпмедер сүзсез тордылар: элеккеге контрразведчик, чираттагы сорау нинди булыр дип, сабыр гына көтте; ә яшь чекист, берәр мөһим нәрсә онытылып калмадымы икән дип, ашыга-ашыга хәтер сандыгын актарды.

— Талип Әкрәмович, ничек уйлыйсыз... Немец агенты инде ике тап-

кыр эләгә язган икән, хәзер аны үеннан вакытлыча чыгарып торулары, яисә бүтән шәһәргә күчерүләре, хәтта бөтенләй... юк итүләре мөмкин бит. Шулай түгелме?

— Шактый четерекле мәсьәлә. Мондый хәлләрдә, әлбәттә, еш кына сез әйткәнчә эш итәләр. Сыналган вариантлар. Ләкин тагын бер юл бар... Агентның ике мәртәбә ялгышуы резидентны сискәндереп куя. Сагайта гына түгел, куркыта да: ике аягы белән баткач, унга-сулга карамый йөгергән диверсант эзеннән килеп, «шеф»ның үзенә чыгарга мөмкиннәр бит! Кем белә, бәлки, контрразведка аны юри качыргандыр?! Убырлы карчык себеркесенә атланып очкан кебек, агент койрыгына утырып, выжт итеп кенә үз өенә килеп керсәләр!? Шулай дип уйлый резидент. Әгәр хуҗасы куркак, шикчел бәндә булса, шымчыга көн бетә моннан соң. Ул шуны сизеп, башын саклау чарасын күрә. Йә кача, йә алдан шартын килешеп, каршы якка күчә. Без күздә тоткан Карачкы-Периновка да үзенекеләрдән качу юлы гына калгандыр. Бик ихтимал. Ул, билгеле, безнең якка күчмәс инде. Әмма, әгәр милләте белән немец булмаса, монархистлар яисә анархистлар икмәгеннән баш тартмас дип уйлыйм.

Контрразведчик-мөгаллим пәлтәсенең өске төймәләрен каптырды, эшләпәсен батырыбрак киде. Ашыкмыйча гына урыныннан торды. Аяк буыннарының шыгырдап-шыртлап куюы ишетелде.

— Менә бит, әле кырык та тулмаган, ә буыннарга утырган тоз... ничә пот бар икән...— Мулюков тирән итеп көрсенде. Саубуллашырга дип сузган кулы белән тагын Шамилнең җиңеннән тотып алды.— Беләсезме, ул Карачкы-агент, яраланган балык төсле, яңадан өскә йөзеп чыгар дип уйлыйм мин... Россия инде йөклаган диңгез генә түгел хәзер, ул — коточкыч давылга тарган су өермәсеннән гыйбарәт. Берәү карый тамаша, берәү карый алаша дигәндәй, шундый мәхшәрдә ат каракларыннан алып немец шпионнарына кадәр һәр җинаятьче үзенә файда күреп калырга тырыша: юк, исән калу турында гына уйламый, череп баю яисә, берәр төркемгә сыланып, баш әйләнгеч карьера ясарга омтыла. Әлеге шул ат карагының да кукрәгендә йөгәне-ияре белән шәп айгыр кешнәп тора. Ә безнең Карачкы, кырган эшләренә караганда, күктән йолдыз чүпләргә җыенмый. Моны аның иске яисә яңа хуҗалары да беләдер, әлбәттә. Шуңа күрә аяктан егарлык зур эшләрне бүтәннәргә тапшырып, «безнең» агентны кечерәк, күрексезрәк, ярдәмче рольләргә тыгачаклар. Уртакул артистлар гомер буе массовый күренешләрдә селкенеп йөргән кебек...

«Алай ук күрексез артистка охшамаган ул Карачкы. Контрразведканы ике тапкыр кәкре каенга терәтеп калдырсын әле! — дип уйлады Шамил, урыныннан кузгалып.— Хәзер аның мин-минлеге, үзенең яхтулыгын[1] күрсәтү теләге үрә баскан булырга тиеш...»

Шулай, эчтән бәхәсләшеп, телдән рәхмәт әйтеп саубуллашты ул Талип Әкрәмович белән. Аерылып китү белән, туп-туры Гоголь урамына — үзенең чекасына юл тотты.

«Дардиев... Кузьмин...» дип торган яшь чекистны ярты сүздән аңлап, Ольженицкий тиз генә күрсәтмә бирде:

— Картны икенче тапкыр чакырудан бер файда да булмас. Йә бөтенләй качар. Болай да шөлләп калгандыр әле. Үзең белән ике гаскәрине ал да, чаптырыгыз, әйдә, полковник йортына!

* * *

Кояш инде күптән офык артына төшеп югалган, әмма күк гөмбәзенең өчтән бер өлеше карбыз телеме кебек җете төскә манчылып тора, шуннан

---

[1] Яхтулык — русча «Я кто?»дан үзгәртелгән: «Минем кемлегемне беләсезме?», яңәсе. (Тәрҗемәче искәрмәсе.)

таралган яктылык әле ким дигәндә йөз адымнан да бик ачык күрергә мөмкинлек бирә иде.

Шамил белән аны озата килгән ике егет Островский һәм Петропавловский урамнары чатында төшеп калдылар. Аларга кирәкле йорт каршы якта, почмактан икенчесе икән. Бу шактый тәкәббер кыяфәтле агач йортның күршесендә, нәкъ Олькеницкий өйрәтеп җибәргәнчә, арадашчы мебель конторасы булып чыкты. Кичке әңгер көчәйгәннән-көчәя барса да, контора тирәсендә кешеләр ыгы-зыгы килә. Буш арбаларга кием шкафы, комод, өстәл, урындык ише нәрсәләрне чыгарып төяп торалар, аласын алганнары китә бара. Ат пошкырган, тәгәрмәч шыгырдаган тавышлардан, олаучыларның: «На-а!», «Тр-р!» — дип әвәрә килүләреннән бөтен тирәюнь кайный.

«Итәк астыннан ут йөртүчеләр өчен бик кулай урын», — дип уйлап алды Измайлов.

Ул да түгел, контора ягыннан өстенә френч кигән, симез гәүдәле, ярты башын «сыер ялаган» бер агай килеп чыкты. Кузьмин йорты каршысында туктап калды. Шунда ук ян тәрәзә ачылып, эчтән хатын-кыз башы сузылды. Френчлы тиз генә ачык ишектән кереп югалды. «Әһә, хуҗа өйдә икән, димәк».

Измайлов һәм аның иптәшләре, урам аша чыгып, әлеге йортка якынлаштылар.

— Өчәүләп басып керү килешмәс,— диде Шамил.— Сез монда көтеп торыгыз.

Шыгыр-шагыр килгән агач баскычтан болдырга менеп, ишек шакыды, сак кына тартып карады: эчтән бикле иде. Катырак шакылдатты. Йомшак кына басып килүче аяк тавышлары ишетелде.

— Кем бар? — дип шыпыртлап сорады хатын-кыз җәмәгатеннән булган берәү.

— Хуҗа кирәк иде.

— Ә кем сорый аны?..

— Чекадан мин, ачыгыз.

Теге якта кинәт чыш-пыш, ыгы-зыгы килеп алдылар, тәлинкәме, чынаякмы төшеп ватылды. Аннары барысы да тынды. Әмма ишекне ачучы булмады; чекистны, әйтерсең, шунда ук оныттылар. Бераз көтеп торгач, Измайлов яңадан ишек шакыды.

Кинәт урамда атышу башланды. Якында гына аталар иде. Измайлов ни булганын аңыша алмый торды. Кесәсеннән револьверын суырып алып, болдырдан урам ягына йөгереп чыкты. Колак төбендә үк винтовка дөпелдәде. Чылтырап пыяла коелды. Гаскәри егетләрнең берсе, кулындагы винтовкасына йөзтүбән төшеп, баскыч төбенә үк сузылган. Ә урамның каршы ягында калган кызыл армияче, мылтыгының затворын каударланып тарта-тарта, төзәмичә дә диярлек, Кузьмин йортының тәрәзәләренә ата. Шамил сак кына үрелеп карады: кемнеңдер җансыз гәүдәсе тәрәзә төбеннән яртылаш салынган. Бая гына ишектән кереп киткән френчлы адәм бит бу! Ялтыр башыннан кан тамчылый, әмма шул көе дә йомарланган учыннан маузеры ычкынмаган.

Күз ачып йомганчы купкан бу атыш узып баручыларны, мебель конторасы тирәсендәгеләрне пошаманга салган — кырмыска оясы тузгыган кебек, кайсы кая йөгерергә белми. Олаучылар исә куркынган атларын сүгенә-сүгенә камчылыйлар. Кинәт кузгалган арбалардан дөбердәп ишелеп калган өстәл-урындыкка таба әйләнеп тә карaучы юк.

Измайлов, кире борылып, ишек бите турысына бер-ике пуля җибәрде. Йөгереп барып көч белән тарткан иде,— әллә инде шуннан чыгарга җыенган булганнар,— ишек бөтенләй дә бикләмәгән кебек, шар ачылып китте.

— Йорт камалган! Каршылык күрсәтү файдасыз! — дип кычкырды Шамил, ишекне каерып ачып. Җавап кайтаручы булмады. Тәвәккәлләп эчкә сикергән иде, шулчак каршы яктагы ачык тәрәзәне күреп, аһ итте. Инде кырык-илле адымнар чамасы булыр — ике ир качып бара: алардан

уңдарак, үрдәк кебек чайкала-чайкала, бер симез хатын йөгерә. «Тәрәзәләрне сакларга баш җитмәде, ике гаскәригә ике якка бастырасы гына иде бит».— дип уйлап алды Шамил.

— Тукта!! Тукта, диләр сиңа!

Качып баручыларның берсе, озыны, борылып — төзәп тә тормыйча диярлек — атып җибәрде.

— Тукта, атам! — дип яңадан кычкырды Шамил.

Тегеләрнең туктарга исәпләре юк иде. Хатын белән янәшәдәрәк йөгергән ир-ат кына, атарга чамалап, ахрысы, артына борылды. Измайлов барысыннан да алдарак йөгерүче иргә төзәп, чакмага басты. Юк, булмады, тидерә алмады. Ике качкын, үзара сөйләшкәндәй, берьюлы атып җибәрделәр. Бер пуля тәрәзә янагына тиде, аннан каты йомычка каерылып, Измайловның сул беләгенә килеп кадалды. Авыртудан «Ах!» дип кычкырып җибәрде егет, ярсудан күзләре томаланып, барабанында патрон беткәнче атты. Иң соңгы пулясыннан гына хатын белән янәшә йөгерүче ир егылды. Ә алдан йөгергән озын ир, инде каршыдагы йортка барып җитеп, аның артына яшеренде.

Шамил, револьверын пинжәк кесәсенә тыгып, биленә кыстырган бүләк пистолетны алды («Франция» номерларында булган мажарадан соң ул инде аны үзеннән калдырмый иде), шул пистолетны алды да качкынны куа китте. Әмма каршыдагы йортка кадәр барып җитә алмады...

Чекист корал алыштырып торган арада, качкыннар арасындагы хатын-кыз да шактый ерак китәргә өлгергән иде инде. Янәшәсендәге ир-ат егылганын күрмичә, берничә адым ялгызы гына йөгерде. Кинәт нәрсәдер сизенеп, шып туктап калды. Исерек кебек чайкала-чайкала кире борылып килде. Егылган ирнең аяк очына басты. Бер мизгелгә катып калган кебек торды. Аннары иелеп, нидер эндәште. Исәндер дигән соңгы өмете өзелмәсен өчен, ахрысы, тәненә кагылырга курыкты. Әмма, инде якынлашып килүче ят кешене, аның кулындагы пистолетны күрү белән, хатынның чыраена тәвәккәл төс чыкты: тиз генә тезләнеп, җирдәге ирнең күкрәгенә колагын куйды. Шул ук мизгелдә сикереп тә торды, имәнеч тавыш белән кычкырып та җибәрде.

Измайлов җиргә тезләнгән хатын яныннан йөгереп кенә узасы иде, ләкин пуля тигәннән соң чалкан авып төшкән ирнең чырае аңа бик тә таныш тоелды. Туктап, якынрак килде, күңеле алдан сизенсә дә, күзләренә ышанмыйчарак торды: Кузьмин бит бу... Кузьмин! Бандитлар һәм... кичәге контрразведка башлыгы... Бүгенге кара көчләрнең һәм кичәге көннең күләгәсе... Шуннан соң гына ул Кузьмин өстенә яткан шактый яшь хатынга дикъкать беләнрәк карады. Хатыны чибәр, үзеннән утыз яшькә кечерәк, дигән иделәр шул... Болар барысы да, куркыныч төш күргәндәге кебек, бер-берсенә бәйләнешсез булып күз алдыннан кичте. Ләкин йоклаганда бастырылсаң да, мөгаен, хәзергедән авыррак тойгы кичермәс идең. Шашынудан, куркудан йөзе чалышайган хатын кинәт, чекист белән йөзгә-йөз килеп, ике куллап аның бугазына ябышты. Шамил каршылык күрсәтмәде: куллары, олау башыннан салынган аркан төсле, дәрмансыз калды; күз алдында кызыл түгәрәкләр йөзә башлады.

Йөгереп килеп җиткән кызыл армияче егет, башта ни булганын аңышмыйча, авызын ачып торды. Йомры гына, юантык кына бер хатынның ямьсез тавыш белән үкерә-үкерә яшь чекистны буарга маташуы, ә тегесенең каккан казык кебек катып калуы бик тә сәер иде. Шулчак Шамилнең кулындагы пистолет шапылдап җиргә төште. Гаскәри егет тә, аңына килеп, хатынны ике җилкәсеннән тотып каерды. Ләкин тегесе әллә ничек кенә ычкынып китте дә чекистны уңлы-сулы яңаклый башлады:

— Минә сиңа!.. Менә!..— дип чинады ул.— Мине дә ат, әйдә. Минем дә яшисем килми хәзер. Син безнең икебезне бергә үтердең. Каһәр төшсен сиңа! Каһәр төшсен!

Кызыл армияче, инде ике арага кереп, хатынны ике кулыннан элак-

терел алырга чамалаган иде. Әмма ул тагын ничектер шома гына шуып чыкты. Тик бу юлы, ире өстенә барып капланып, иңри-иңри елый башлады.

Бу хәлгә түзеп торырлык түгел иде. Шамил инде полковник Кузьминга атып тидергәненә чын күңелдән үкенә башлады. Озын бандит барыбер качып ычкынды, картны үтерүнең исә бернинди мәгънәсе дә калмаган иде. Гәрчә шушындый шикле кешеләрне җыеп ятса да, үз өеннән үзе чыгып качса да...

Губчекадан ярдәм килеп җитте. Баскыч янында һәлак булган кызыл армияче егет белән тәрәзә төбендәге бандитны, аннары Кузьмин гәүдәсен машинага күчерделәр. Полковникны кузгата башлагач янә Измайловка ташланган хатынны конвойчы гына тотып калды. Ләкин аның шайтан төкергән теле пулемет урынына атудан туктамады, берсеннән-берсе әшәкерәк каһәрләү сүзләре яудырды.

Шамил аның соңгы сүзләрен ишетмәде, кинәт башының арт чүмеченә кемдер җылы чүпрәк куйган кебек булды да, күз аллары караңгыланып, машина басмасына утырды. Әле генә булып узган киеренке хәлләр һәм кичерешләр аның хәлен алган иде.

Яшь чекист машинаны инде Клячкин больницасына таба куганда гына аңына килде. Аңа әллә ни ярдәм күрсәтәсе булмады. Врачлар, беркике көн булса да, ял кирәк, диделәр.

Губчекага әйләнеп кайткач, Ольконицкий берни дә сорашмады.

— Иртәгә Беренче май бәйрәме. Шәһәрдә йөр, кызларга күз сал. Аларның иң кәттә вакыты хәзер. Кышкы кабыкларын салып, ачылып кына килә торган чаклары...— диде.— Ә берсекөнгә, һәрвакыттагыча, биредә очрашабыз.

* * *

Бәйрәм кояшлы, җылы көнгә туры килде. Идел ягыннан искән җиләс җил Воскресенскийдагы, Зур Проломныйдагы кызыл әләмнәрне җилфердәтте. Бу кадәр күп халыкның бәйрәмчә күтәренкелек белән шәһәр урамнарына чыгуын Шамил әле беренче тапкыр күрә иде. Халык дигәч тә, әлбәттә, монда кырык корама диярлек,— төрлесе бар. Пассаж каршына, элеккеге Офицерское собрание янына кызыл байраклар белән моряклар, эшчеләр җыелган. Шунда ук, «Даздравствует Анархия!» дип язылган кара әләмнәрен күтәреп, анархистлар таптанып тора. Арырак, аукционкибет артында — авылча киенгән, йөзләрен җил, кояш ашаган ир-атлар һәм хатын-кызлар төркеме.

Демонстрациядә катнашучылар тиздән, шау-гөр килеп, гармун күреге кебек бер сузыла, бер кысыла барып, Лобачевский урамы буйлап китте. Аннары Грузинский урамына савылып керделәр дә театр янында туктап калдылар. Шунда митинг башланды.

Казанның бөтен урамнары да бәйрәм тантанасы белән әсәренгән иде. Кремль тарафына таба, төркем-төркем булып, эшчеләр һәм крестьяннар агыла. Алар белән бергә үк солдатлар һәм хәрби әсирләр колонналары — немецлар дисеңме анда, австралиялеләр, мадьярлар яки румыннар дисеңме. Кайберләре иңенә винтовка аскан — болары социализм өчен, пролетариат диктатурасы өчен «җиңгәнгә кадәр» көрәшергә дип ант эчкән кешеләр. Әнә, кызыл байраклар астында мөселман социалистик батальон да якынлашып килә... Кремльдә җыелган халыкны шәһәр Советы исеменнән Яков Семенович Шейнкман котлады.

Төш авышкач кына, арып-талып, үзенең «хөҗрә»сенә кайтып ятты Шамил. Нияз исемле хезмәттәше белән икесенә коммуналь фатирдан бер кечкенә бүлмә биргәннәр иде,— аркылыга өч адым, буйга өч адым, ыслanып беткән стена почмакларына пәрәвез оялаган,— шуңа эченнән генә «хөҗрә» дип йөртә ул аны. Бүлмәдәге бөтен мебель — саздан тартып

чыгарган кебек күксеп-күгәреп беткән ике тимер караватъ, өч аяклы түгәрәк өстәл һәм икесенә бер урындык. Тәрәзәдә, пәрдә булырга тиешлеген искәртеп, өч кнопка белән каптырылган иске газета эленеп тора. Ул газета, байтак заманнар буе үзенә кояш нурын сеңдерә-сеңдерә, соргылт төскә кергән һәм инде бөтен язулары уелып, тәмам үтә күренмәлегә әверелгән.

Шулай да Шамил бу «хөҗрә»сеннән бик канәгать: шәһәр үзәгендә, Кече Казан урамындагы ике катлы кирпеч йортта үз почмагың булу — уен эш түгел!

Бераз сулыш алыйм дип кенә караватына кырын ауган иде,— үлгән кебек йоклады. Таң вакытында, тегермәннеке кебек тоныкланып калган тәрәзәгә кояшның беренче нурлары төшкәндә генә уянып китте.

Әле берсекөнгә генә эшкә чыгарсың дисәләр дә, килүен көткәннәр икән. Губчека рәисенең урынбасары Вера Брауде үзенә чакырып, Мәскәүдән пакет белән килгән хатны сузды. Шамил, һәр сүзгә игътибар итеп, әкрен генә укый башлады:

*«Казан, Гоголь урамы, 28. Ольkенищкийга.*

*Петроградта Свифт кушаматлы атаклы герман агенты тотылды. Россиягә 1913 елда ук оялаган. 1916—1917 елларда Казанда эш йөрткән: Карачкы кушаматлы агент белән бергәләп, Мәскәү — Казан тимер юлында составларны рельстан чыгару, корал төягән вагоннарны шартлату кебек диверсияләр оештыруда катнашкан. Бу агентларга Казан дары заводында да зур диверсия әзерләү йөкләнгән. Свифт раславынча, әлеге задание хәзергә кадәр үз көчендә кала. Рус офицерын эшкә ялларга маташып карагандa уңышсызлыкка дучар булганнан соң, Карачкы герман разведкасы күзеннән дә югалган. Карачкы 30—35 яшьләрдә, озын буйлы, нык бәдәнле, аксыл чәчле, зур коңгырт күзле, озынчарак йөзле. Холкы ягыннан кешеләр белән тиз аралашучан, бигрәк тә хатын-кыз белән. Белемле. Артистланырга ярата. Бик хәйләкәр һәм сак.*

*Карачкының югалу сәбәбе билгеле түгел. Дары заводында диверсия әзерләү эше хәзер бүтән агентка йөкләнгән булуы да ихтимал.*

*Петерс.»*

— Аны Мулюков та нәкъ шундый итеп тасвирлаган иде миңа,— дип куйды Шамил, хатны укып чыккач.

— Кемне? Карачкынымы?

Измайлов, «әйе» дигәнне аңлатып, ияк какты.

— Алай...— диде Брауде, хатны сейфка куеп.— Шуннан нинди дә булса яңа мәгълүмат өстәләме?

— Әгәр Карачкы белән Семен Семенович Перинов икесе бер үк кеше икән, ул чакта эзләүне берничә юнәлештә алып барырга мөмкин.

— Мәсәлән...

— Әйтик, үткән көзне Чистайда кәеф-сафа корып йөргән Алафузов компаниясе белән якыннанрак кызыксынырга кирәк була.

— Сезнеңчә, алар Казанда без килгәнне көтеп утыралармы? Зар-интизар булып...

— Күләсез, Вера Петровна... Миллионер Алафузовның, әлбәттә, табаны ялтырап кына калган, ә менә аның дус-ишләре әллә кая таралып бетә алмагандыр әле... Бигрәк тә кызлар...

— Әйе... Монда бер аяк белән генә булса да басарлык туфрак күренә...— диде Брауде, уйчан гына итеп.— Кем дә булса калгандыр, билгеле. Ярыкка кысылып яисә заманга яраклы төскә кереп. Теге сөйрәлчек кызлар да башларына тәүфикъ яулыгы бәйләгәннәрдер. Үзләрен гомерлек монашка итеп күрсәтергә тырышалардыр.

Вера Петровна беравыкка тынып, өстәлгә карандаш белән әкрен генә шакып торды. Аннары сорап куйды:

— Ә сез ничек, ул кызларны йөзгә танырсызмы?

Измайлов җилкәсен җыерды, аптырый төшебрәк әйтте:

— Күрсәм — танырмын дип уйлыйм. Ә болай, сүз белән генә сурәт-

ләп бирүе кыен.

— Аларны капшанып-кармаланып эзләргә туры киләчәк бит, Шамил. Анысын да уйлыйсызмы? Нәтиҗәсенә караганда азабы күбрәк булачак.

— Карачкыны эзләүнең икенче юлы — Дардиев кебек күселәр аша...— Шамил баягы фикерен дәвам итте.— Дардиев ишеләр, һәрхәлдә, аның турында бездән күбрәк беләләрдер. Аннары Карачкыны үзенең хуҗалары да югалткан икән, димәк, хәзер ул, су асты көймәсе кебек, диңгез төбенә төшеп яткан да җайлы вакыт җиткәнен көтеп тора... Ә «диңгез төбе»ндә ул һәртөрле җинаятьчеләр белән очрашмагандыр дип кем әйтә ала? Хәтта аларның уртак тел табулары да бик ихтимал.

Брауде баш кагып куйды:

— Кыскасы, капшап карарга ярый ул адәмчекләрне. Сез әйткән көймә диңгез төбендә дә мәңге ятмас. Бигрәк тә мондый болгавыр заманда...

## IV. Эт тыкрыгындагы тынгысыз көннәр

...Махно фатихасы белән юлга чыккан күңелле компания, биш тәүлек буе баржада кызынып, нәкъ шул көннәрдә Казанга килеп җитте. Билгеле, монда аларны кочак җәеп каршылаучы күренмәде. Әмма юлаучылар бер тамчы да күңелсезлеккә бирелмәделәр. Тозлы балык исе сеңгән багажларын уртага алып, ачык күк астында «чегән таборы» ясап урнашудан да кулайрак юл юк иде әлегә.

Менә алар, ерактан караганда дүрт ахири, хәтта дүрт бертуган кебек булып, яр буена тезелешеп утырганнар. Компания башлыгы — Махно йомышчысы Митька Сабадырев, Идел өстендәге акчарлаклар уенын күзәтә-күзәтә, иртәгесе көн турында уйлана. Юлга чыгар алдыннан гына аның хәләл җефете дип игълан ителгән чибәр Тоська, кайдандыр көзге кыйпылчыгы тапкан да, каш-күз төзәтү белән мәшгуль. Ә теге, циркта фокус күрсәткән өчен генә төрмәгә эләккән мескен Күзле Бүкән — Флегонтий, тезенә башын куеп, черем итеп маташа... Хәер, әлегә алар өчәү генә калган икән: баржада килгәндә Митьканы мәхәббәт газапларына дучар иткән Илья Грязинюк күренми. Аны, извозчик яллап, Покровская урамындагы утыз сигезенче йортка — анархистлар бюросына җибәргәннәр иде. Махно атакай, Казанга барып төшү белән, мондагы анархистларның башлыгы Тарасенконы табарга кушты бит...

Илья кичкә таба гына әйләнеп кайтты: адымнары алпан-тилпән, йөзенә байлар төсе кергән. Әмма дә ләкин шәп итеп кырынган; балыклы трюмда аунап килгән димәссең — хәзер хушбуй исе аңкый аңардан.

Салып кайту уңаеннан егеткә кисәтү ясыйсы килгән иде Митьканың — телен тешләп булса да дәшмәүне артык күрде. Баш урынында кәбестә күчәне түгел, яхшы аңлый: ходайдан сабырлык сорап, әлегә түзәргә кирәк. Әлегә аның — Митька Сабадыревның сәгате сукмаган.

Грязинюк, алпан-тилпән килеп, әкрен генә уртага кереп басты, күзләренә оятсыз төс чыгарып, һәркайсының йөзенә берәм-берәм текәлеп карады: әйтерсең, ул болар белән беренче тапкыр таныша һәм кемнең нәрсәгә яраклы икәнен чамаларга тырыша иде.

— Сузма, сөйләп җибәр, әйдә,— диде Сабадырев, үртәлүен тыярга тырышып.

Илья, аның сүзен ишетмәгән дә кебек, аркасы белән борылды. Нигәдер һаман китмичә торган олаучыга кул изәде.

— Ул хәзер атын мондарак тарттырыр. Җыеныгыз, безгә Эт тыкрыгында урын җәеп куелган,— диде. Боларын ул әле дә булса арты белән торган килеш әйтте. Ниһаять, борылды, беркемгә дә күтәрелеп карамыйча гына:— Иртәгә сәгать унда Тарасенко белән күрешәбез,— дип өстәде.

«Урын җәеп куелган» өй тәбәнәк түшәмле, ярым сукыр тәрәзәле булып чыкты. Тәрәзә дигәне дә кыйшайган — димәк, астагы бүрәнәләре черегән;

ә матчасы ике төштән терәү белән ныгытылган иде.

— Абзар дисәң дә абзар...— дип борынын җыерды Грязинюк, бу хәлләрне күреп. Үзе белгән тимер ятак астына сары саквояжын тибеп төртте.— Сөргенгә сөрелгәннәрне дә мондый шалашка урнаштырмыйлар, мөгаен.

— Урамы нинди тагын...— дип кушылды аңа Тоська.— Автомобиль түгел, арба да үтә алмас моннан. Эт тыкрыгы дип кенә әйтерлеге бар. Йорты да менә дигән эт оясы.

— Йә, йә, көйсез бала кебек балавыз сыгарга гына тормагыз инде,— диде Күзле Бүкән, баш астына пинжәген җайлабрак салып. Аның әледән-әле авызы ачыла иде.— Менә бер тәмләп йоклыйк әле; ә иртән, күзебезне ачканда, эт оясы дигәнебез хан сараеннан да шәбрәк булыр.

Әмма Илья белән Тоська, сүз куешкандай, әүвәлгедән дә битәррәк итеп бу йортны яманларга тотындылар.

— Майсыз тупса кебек шыгырдап, чистый тешкә тидегез бит, әй...— Сабадырев аларны йомшак кына итеп битәрли башлады.— Нинди чебен тешләде сезне, ә? Ышанычлы язулар, таныклыклар тапканчы, бер-ике көнгә түзәргә туры киләчәк инде, дусларым. Югыйсә, үзегез беләсез: чеканың тешләре крокодилныкыннан ким түгел, капкан төшеннән өзеп кенә ала.

— Нәрсә әле син монда, чекистлардан бүкәй ясап, куркытырга маташасың?!— Грязинюк, ятагыннан торып шырпы сызды, әмма шырпы кабынып китмәде — сынып читкә очты. Грязинюк тәмәкеле авызы белән сакауланып сүгенде.— Кабер такталарын... фәлән итим... Ун надан бергә җыелып: «Яшәсен Совет власте!» — дип бугаз ертудан гына аларның акылы артамы? Унысы бер инженер кадәр уйлый алмыйлар бит, җен алыштырган нәрсәләр. Шуңа күрә дә дошманның көчен арттырып күрсәтүгә каршы мин. Куркy — үз-үзеңне бетерү генә ул. Ничу шыр җибәрергә! Махсус әзерлекле контрразведчиклар бар дисезме әллә чекада?! Анда һәммәсе дә үзлегеннән өйрәнүчеләр, үз белдеге белән эш итүчеләр. Осталык ягыннан хәтта патша полициясенә дә тиңләшә алмый ул чека. Ә полицияне заманасында ничә тапкыр төп башына утыртып калдырганын абзагыз үзе генә белә...

Юк, Митькага үч итеп сөйләми бу сүзләрне Ильюха, ул хәзер бары тик Тоська алдында төкерек чәчә. Шуңа күрә Сабадырев аны тыныч кына бүлдерде:

— Кыскарак тот... Син соң нәрсә тәкъдим итәсең?

— Егетләр! Без бит анархистлар башкаласы дип әйтерлек бөек шәһәргә килеп җиткәнбез. Күреп калдыгызмы икән, Эт тыкрыгына борылганда, бер биек йортның балконына «Яшәсен Анархия!» дигән кара чүпрәк элеп куйганнар иде. Монда, гомумән, безнең братва качып-посып яшәми. Читтән килгән анархист халкы «Франция» номерларына тукталa. Бюрода миңа шулай диделәр...

— Йә, йә, син бит әле боларын безгә сөйләмәгән идең...— Күзле Бүкән дә яткан җиреннән торып утырды.— Тагын ниләр ишетеп кайттың?

— Тагын... тагын...— дип тотлыгып калды Ильюха.— Ни пычагыма әле мин бу кандала оясында кашынып ятарга тиеш! Кесәмдә — коммерческий училище бетерүем турында кәгазь бармы? Бар. Мин монда шундый ук училищега укытучы булып урнашырга килдем...

— Ха-ха-ха! — дип чын күңелдән хахылдады Тоська, хәтта бер күзеннән яшь атылып чыкты.

— Үз гомереңдә бер тапкыр дөрес сүз сөйлисең, шунда да ышанмыйлар! — Грязинюкның тавышында әллә чын, әллә юрамалый үпкә сизелде.— Ә мин чынлап та коммерческийны бетердем. Теләсәм, сездән аерылам да калам. Бигайбә!

Митьканың яңадан ачуы кузгала башлады. Көн кебек ачык: бу Ильюха тәртип-дисциплина дигәннең нәрсә икәнен дә белми. Шулкадәр дә анархист булыр икән! «Бәтенесен үзенчә мәтәштерәчәк бу...— дип уйлады

Митька.— Гел генә миңа каршы төшеп, чабата кайтарып йөриячәк». Мөгаен, аяк астында ул буталмаса, әйбәтрәк тә булыр. Ни игелек көтәсең калай әтәчтән? Шап-шоп канат кагуын беләү. Монда үзеннән акыллы кеше юк дип саный. Өстәвенә, Тоськаның янәшә генә булуы тилертә үзен. Иртәгә Тарасенко белән очрашсак, Ильюхадан башка да үлмәбез...

— Малайлар, сезнең урында булсам, мин дә куркып тормас идем! — почмак яктан Күзле Бүкәннең тәвәккәл тавышы ишетелде. Аның йокысы качкан, ахрысы, бик тырышып-тырмашып мич кабызырга маташа иде.— Ике дә уйламыйча, иң шәп номерларга күчәр идем мин, валлаһи әгәр. Теге, элеккерәк заманда Питер яисә Мәскәү дворяннары төшә торган берәр кунакханәгә. Ник, әллә ышанмыйсызмы?

— Флегонтушка, җанкисәгем! — дип сузды Тоська, пырых-пырых килеп.— Номер өчен бетең белән түләр идеңме аннары?

Сабадырев бик җитди кыяфәт белән уртага чыгып басты:

— Иртәгә... син, Илья, һәм син, Тося, икегез дә гостиницага китә аласыз. Ә без Күзле Бүкән белән хәзергә монда калабыз.

Тоськаның авызы — колакта, колак еракта иде. Шулай да, кеше әйтереннән, йөзенә кайгыртучан төс чыгарырга тырышып:

— Мин синең яныңа килгәләрмен, Димочка. Онытыр дип уйлама, җанкисәгем, яме,— диде.

— Ансыз булмас инде...— дип башлады Митька: «Минем арттан күзәтчелек итәсең дә бар ич»,— димәкче иде, ярый әле, вакытында тыелып калды. Бөтенесен белә икән, дип уйламасын, кара елан.

...Тарасенко иртәнге алтыларда ук Эт тыкрыгына килеп җитте. Сабадыревны уятты. Болай иртәләвен: ашыгыч кына Мәскәүгә китәсе булды, дип аңлатты.

Митька, күзләрен уа-уа, кунакларны яхшылабрак хәтерләп калырга тырышты. Казан анархистларының башлыгы урта яшьләрдәге ир заты икән. Ике яңагы, пәрәвез җебе кебек челтәрле-челтәрле булып, нечкә кан тамырлары белән капланган. Шуңа күрә йөзе тиктомалга бурлаттай янып тора. Тарасенконы озата килгән егет өстенә диңгезче бушлаты кигән, буйга-сынга базык кына булса да, таза беләкле күренә. Бушлат кесәләре шундый нык кабарган — урам ташларын тыгып килгәнмени. Бил каешында — агач каплы немец маузеры, ә каеш астыннан диңгез офицерлары тагып йөри торган хәнҗәр сабы тырпаеп тора.

«Тән сакчысы түгел, ике аяклы корал склады бу»,— дип нәтиҗә ясады Митька. Ул инде тәмам уянып җиткән иде.

Сөйләшү бик озынга сузылды. Шәт, өч сәгатьләп вакыт үткәндер. Тарасенко үзе белгәннәрне бик тәфсилләп сөйләде: эсерлар һәм монархистлар турында, чека һәм милиция хакында... Шәһәрдәге хәл белән таныштырды. Ниһаять, алтынның кайда саклануын әйтте. Атаклы Санька-анархистның шул юлда харап булуын искә алды. Миргазиянов Самат дигән бер кеше ярдәмендә банкка үтеп керү мөмкинлеген тапкан Санька. Әмма, шул юлны капшап йөргәндә, өсләренә чека килеп баскан.

— Миргазиянов чекистларны үзе чакыргандыр дигән уй да бар иде баштарак. Әмма минем кеше ишетеп калган... Саматның үзен кемдер ике ут арасына төртеп керткән булырга тиеш. Саньканың да холык дорфарак, хәйлә дигән нәрсә юк — әрәм булды ярын. Шул хәлләрдән соң чека да уяулана төште: безнең ниятне сизенделәр бит. Банкны хәзер икеләтә көчәйтелгән сак астына алдылар. Егерме кеше. Билгеле, аларны гына кырып салырга була. Тик ни мәгънә? — бездә ачкычлар юк. Андагы исәпсез-хисапсыз корыч ишекләрне ваткан арада... Купец Апанаевның элеккеге йортына Мөселман батальоны урнашкан. хәзер килеп җитәчәк тә, эт аткан кебек, барыбызны да чүкеп бетерәчәк. Шәһәрнең төрле өлешләрендә тагын берничә полк бар, үзәктән ераграк алары. шулай да, әгәр кирәк булса, сәгать ярым эчендә килеп бугазга басачаклар.

— Кыскасы, атка менеп, ялан кылыч айкап кына алтын ачкычларын табып булмый, дисез инде...

— Нәкъ шулай. Мүкәләп кенә барырга да, кәлтә кебек выжылдап кереп китәргә кирәк. Әлегә барып чыкмый бусы. Ач шакал көтүе кебек йөрибез менә, улыйбыз һәм теш шыгырдатабыз. Күргәнегезчә, яшерен фатирларыбыз да — шәһәрнең чүплек башында. Кем әйтмешли, эшче-крестьянча...

Митьканың сораулары күп иде, әмма кунак, ашыгуын белдереп, урыныннан кузгалды. Шулай да, ишегалдына чыккач, Тарасенко аны бер читкәрәк алып китү җаен тапты.

— Казан белән танышуны, беләсезме, кайдан башларга киңәш итәм? — диде. Митьканың дәшми генә тыңлап торуын күргәч, дәвам итте:— Кәҗә бистәсеннән. Анда, извозчик тукталышында, сине бер кеше көтеп торыр. Бүген төштән соң. Мусин Фаикъ, татар малае ул, ә кушаматы — Азман. Анархист ук түгел, угры-юлбасарлар дөньясыннан. Әмма экспроприацияләр вакытында безгә ярдәме күп тия — алдан юл күрсәтеп бара... Кыскасы, мировой егет. Танышуыңа үкенмәссең...

Эшне башлап җибәрү өчен Тарасенконың киңәшен тотарга булды Митька. Әмма очрашуга барыр алдыннан,— Грязинюкның гостиницага күченәсен дә белгәнлектән,— бер гөнаһлы уй килде башына. Иң элек Күзле Бүкәнне суга җибәрде. Аннары, Тоська белән Ильяның тәмәке тартабыз дигән булып болдырда әҗе-гөҗе килгән вакытларын чамалап торды да, тимер ятак астындагы сары саквояжны тартып чыгарды. Күз ачып йомган арада саквояж төбеннән бер уч алтын тәңкә чумырып алды.

«Әйдә, мөсафирханәдә таладылар дип белсен үзен... Минем хатын карап торганда янчыгын актарырга кыймас: аның алдында патша малае кебек чибәрләнергә ярата бит ул. Номерга урнашу белән дә, әллә саный, әллә юк әле».

Авырлыгы белән басып, күңелен кинәндереп торган алтынны Митьканың үзенә дә бераз соңрак санарга туры килде. Тарантасның арткы эскәмиясенә менеп кунаклагач. Кулын кесәсеннән алмыйча гына. «Бер айга җитә бу миңа — тәмле ашарга, тыныч йокларга була,— дип исәп-хисап корды ул.— Ә Тоська, әнә, Ильюхасын суырсын. Озакламый аның кесә төпләрен әйләндерәчәк әле ул котырган хатын. Менә шул чакта, анадан яңа гына туган кебек, шыр ялангач көе каршыма киләчәк Ильюха, күз яшьләрен сыга-сыга гафу сораячак».

— Килеп җиттек, гаспадин харуши,— дигән сүзләр генә Митьканың татлы уйларын бүлде. Такыр башына чигүле түбәтәй чәпәгән кәҗә сакаллы олаучы агай, дилбегә очын тәсбих кебек күтәреп тоткан да, икенче кулы белән аны сабырсызланып йолыккалый иде.

— Кәҗә бистәсе шул буламы инде? — дип сорады Митька.

— Самый үзе! Кузья слабада Казанда бер генә ул,— диде олаучы ашыгып.

Урык-сурык үтеп йөрүчеләр арасында Тарасенко тасвирлап биргән кыяфәтле ир-ат күренмәде. Сабадырев олаучы карттан үзен көтеп торуын сорады. Кәҗә сакал, ләм-мим бер сүз дә кайтармыйча, көрәктәй зур учын гына сузды. Тагын кесә төбен капшамый булмады. Ни эшләр хәлең бар: хәзер беренче күрүдә үк кеше кешегә ышана да алмый, тирә-юньне жулик баскан. Үзе дә жулик дигән уй, әлбәттә, беркайчан да аның башына килгәне булмады. Дөньядагы бөтен адәми затлар кебек, Митька да үзен тәрбияле, табигый бер кеше дип саный һәм моңа һич икеләнми иде.

Сабадырев аптырап басып торганда, каршыдагы зур тәрәзәле, матур агач йортның кече капкасы ачылып, аннан Мусин-Азманга охшаган бер ир килеп чыкты. Таза, киң җилкәле, ничә яшьләрдә икәнен чамалавы да кыен. «Рәхәт тормышта яши»,— дип уйлады Митька, чәчәкләп уелган тәрәзә йөзлекләреннән күзен ала алмыйча.

Сабадырев ашыкмыйча гына аның янына барды.

— Дмитрийны көтеп тормыйсызмы?.. Тарасенко кунагын...— диде.

— Синмени ул, анавы?..— диде теге, күптәнге танышын очраткан кебек һәм бер исе китмәгән төс белән. Шунда ук Митьканың җилкәсенә

кулын салды, урам чатындагы йорт тарафына ымлап:— Әйдә, шунда барып килик әле,— диде. Ярымпышылдауга күчте:— Иртәдән Балык базарына чыккан идем. Бер ата мәче тагылды бит чабуыма. Ычкынуын ычкындым үзе. Әмма күңел тыныч түгел. Кемнеңдер карап-күзәтеп торуын сизәм. Салкын бармагы белән муенга китереп басар төсле.

Амур урамыннан тар, тын тыкрыкка борылып, әлеге кырый йортның албакчасын гына узганнар иде, җилкапкадан өч ир-егет сикереп чыкты.

Ни булганын аңышып өлгергәнче, Сабадырев чынлап та «ялган чокыры»на баскан салкын бармакны — дөресрәге, пистолет көпшәсен тойды. Каршысында мунча мичедәй кара, килбәтсез гәүдәле бер адәм пәйда булды. Тәненең күлмәк изүеннән күренгән өлеше зәп-зәңгәр — энә белән кадап ниндидер сурәт төшерелгән.

— Шым бул, үләксә! — дип гыжлады Мунча Миче. Тыныңны чыгарсаң, баскан төшеңдә дөмектерермен.

Каршылык күрсәтергә соң иде. Ирләрнең берсе Азманның аркасына киселгән көпшәле мылтык терәде. «Ә» дигәнче, икесен дә җилкапкадан алып кереп, ниндидер сарайга каратып бастырдылар. Шунда ук тентеделәр дә. Азманның кесәсеннән пистолет килеп чыкты. «Көпә-көндез бит, майдан төк алган кебек кенә итеп!»— дип пошынды Митька. Шахмат уйнарга ни өйрәнеп тә, фигураларның ничек йөрүеннән артыкны белмәгән анархист бу хәлгә тарыгач, алга таба бер йөрешне дә күз алдына китерә алмый иде. Мунча Миче, танырга теләгәндәй, Сабадыревнең йөзенә иелде:

— Кем син? — Авызы кичә чөмергән кызыл аракы парыннан сасыган иде.— Мильтонмы?

— Мильтон булмый тагын, ярыктан карап иснәнеп йөрүче генә ич бу!— диде тимер тешле шадра егет.— Югыйсә, нишләп әле җиңенә пычак булса да кыстырып килмәгән!

Ул арада кесәдәге хәрәм алтынны да шудырдылар. Өстәвенә, әлеге Мунча Миченең бер күзе калайдан ясаган кебек йомылмый, шомлы итеп, туп-туры карап тора иде. Бу караштан, йөзенә револьвер көпшәсе төбәлгәндәй, өнсез калды Митька, аркасына салкын тир бәреп чыкты. Үз чиратында: «Кемнәр булыр бу?» — дигән уй миен бораулады. Чекистлар дисәң, нишләп әле кеше күзеннән качалар. Аннары, телләрендә — әшәке сүз дә сүгенү...

— Азман, сине Коська-Әтинең күрәсе килә. Сүзе бар.— Шадра егет револьверы белән Мусинның кабыргасына кадап алды.— Киттек.

— Ә минем аның белән сугап сатып утырырга вакытым юк,— дип аяк терәде тегесе.— И нинди сүзем калган?.. Берәүнең дә өлешенә кергәнем юк, анавы.

— Башыңны җүләргә салма, Азман.— Мунча Миче лач иттереп аяк астына төкерде.

— Син, хәшәп, Әтинең яраткан кызын — җырчы Груньканы йомдыргансың. Ә брильянт алкаларын кая куйдың? Колагы белән бергә йолкып алдыңмы? — дип өстәде Шадра.

— Мине белмисең әле син, брат.— Мусин, Шадрага таба борылып, кулларын күкрәгенә кушырды.— Валлаһи-таллаһи, дип әйтәм, тиямме соң үзебезнекеләргә!.. Баскан җиремдә ходай орсын...

— Азман... анаңны эт ялагыры!.. Яп инде шул ипи шүрлегеңне! — дип кычкырып җибәрде Мунча Миче. Мусинның каршысына ук килеп басты.— Сине мин беләм аңысы. Белмәгән кая! Чистай төрмәсендә бер сәкедә кандала симерттек, бер кәндидән лаеш шулпасы чөмердек. Әмма эш анда түгел...— Ул пистолет көпшәсе белән Мусинның маңгаена шакып алды.— син, бәгырь, кичә буш кисмәккә әйләнгәнсең. Йонлы тәпиле Флора алдында шапырындыңмы брильянт алкаң белән? Көмешкә пары телеңне чиштеме? Булдымы шундый хәл?!

Мусин иреннәрен кысты, тешен шыгырдатты:

— Бармыйм мин Коська янына. Бармыйм. Тегеләй дә, болай да —

тәре сызылган.

— Брильянт кайда? Бр-рильянт...— дип ырылдады Мунча Миче.— Китер монда, яхшы чакта. Йә??!

Йөзендә кан әсәре калмаган Мусин, әкрен-әкрен чигенә барып, сарай стенасына сөялде. Ул кинәт, бөтен ачыклыгы белән, хәлнең котылгысызлыгын аңлады. Бу — кабер якасы, моннан исән китү юк. Аларны биредә һичкем күрми, һичкем ишетми һәм йолып калырга җыенучы да булмаячак. Качарга тырышып карасаң? Өметсез. Артта сарай, каршыда өч газраил: икесе корулы револьвер төбәгән, берсенең кулында хәнҗәр. Атмасалар, әнә ул өченчесе, авызын яба алмый торса да, бер селтәнүдә эчәгеңне актарачак, дип уйлады Мусин, салкын хәнҗәр очына карап.

— Әй, Түбер,— диде Мунча Миче, хәнҗәрлегә ымлап,— безнең ахиринең, брильянт йоткач, корсагы үсә башлаган түгелме? Банка салып җибәр әле шуңа! Безне дә тешләп алмасын өчен, утыз ике рәшәткәсен коярга кирәк беррәттән. Башы булмагач, тешенең хаҗәте калмас барыбер. Теге дөньяда алтынны куйдырыр, бәгырь. Янсә кесәл генә ашатырлар анда...

«Банка салу» дигән сүз чыккач, Митька сөенеп куйды. Махно контрразведкасында өйрәнгәннәре дә монда ярап куяр төсле бит әле. «Банка салу»га каршы аның алдан әзерләп куйган алымы бар,— бер тапкыр шулай жандармнан, икенче юлы «яшелләр»дән котылып калган иде...

— Гафу итегез, Түбер әфәнде буласызмы әле сез...— Митька, беркатлы тинтәккә салышып, шул ук вакытта тавышына сизелер-сизелмәс кенә мыскыллау төсмере дә чыгарып, Түбергә таба ике адым атлады. Бу тәвәккәл адымнар аны Мусиннан аз булса да читкәрәк алып китте: димәк, икесен берьюлы сыта алмаячаклар. Ә иң әһәмиятлесе — хәзер Шадра да Мунча Миченең теге ягында калды, шахмат тактасындагы фигуралар кебек, алар бер-берсенә комачаулыйлар, әлегә моны үзләре генә сизми иде.— Шулай, Түбер бугай шул исемегез...— дип дәвам итте Митька.— Минем дуска нинди банка салырга уйлыйсыз инде сез, әй?..

Багана кебек үрә катып торган Түбер, хәнҗәрен биленә кыстырды, мәче кебек йомшак кына басып, Сабадыревның каршысына ук килде. Әлегә хәтле бер сүз чыкмаса да авызы һаман ачык, ул аны ничектер бер ачкан да, ябарга оныткан кебек иде. Гомерендә беренче тапкыр паровоз күргән авыл малае ничек шаккатса, Түбернең зур кара күзләре нәкъ шундый кызыксыну белән янып, Митьканы башыннан аягына кадәр капшады. Шуннан соң ул үзенең хуҗасына борылып карады. Мунча Миче, сары тешләрен ыржайтып, баш какты:

— Бакчы, ибдәшнең беренче булып банка алырга дәрте бар, кызыгып, селәгәен агызып тормасын, дәртен бас, әйдә.

Тегенең әйтеп бетерүе булды,— Түбер, гомерлек боксчы кебек, яшен тизлеге белән анархистның күкрәк авызына берне китереп тә бирде. Митька ни буласын алдан белеп торса да, бу кадәр үзәк өзгеч итеп сугар дип уйламаган иде. Корсак мускулларын киереп өлгерде, ә менә, алдан өйрәнгәнчә, алга таба тиз генә иелеп, йодрык көчен киметергә җитешә алмады. Эченә әйтерсең лә кызган таба китереп бастылар, кисеп авыртудан сулыш алырга да мөмкин түгел иде. Ул тынсыз калып, сыгылып төште, аннары җиргә чүгәләде.

Күз алдында ук алап авызлы йөз пәйда булды. Түбер, корбаны каршысында бишкә бөгелеп, тәмам гаҗәпкә калган төсле карап тора: нәрсә булды сиңа, дускай, янәсе. Авызы һаман ачык, ярга ташланган балык кебек, еш-еш һава сулый. Ияген күтәреп бәйләп куясы иде нәгъләтнең. Ирене иренгә тимәсә дә, алап авыздан ике-өч сүз бүселеп чыкты:

— Йә, ничек... Тагын кирәкме... Ә?..

Митька, авыртудан күзләрен йомып, башын чайкады, сул кулы белән күкрәк авызын кысты, ә уң кулы браунинг сабын капмалады. Ул шушы хәйләсен балтырына бот резинкасы белән беркетеп йөртә иде. Чалбар балагын бераз күтәрәсе генә — һич көтмәгәндә кораллы була да куя! Күкрәгеңә мылтык төрәп, һәр хәрәкәтеңне күзәтеп торганда, билгеле, бу һич тә

мөмкин эш түгел. Әгәр инде эчеңә китереп суксалар, менә ул чакта, бер шик тә уятмыйча, иелергә, чүгәләргә була. Шахматта әллә ни майтара алмаса да, язмыш тактасында «пат» хәлләре өчен Сабадырев әнә шундый газаплы, әмма дөрес чишелешне әзерләп куйган иде.

Митька, авыртудан тешен кысып, әкрен генә як-ягына каранды. Мунча Миче, әнә, пистолет сабы белән кабыргасын кашый-кашый, ихахайлап көлә. Бу әкәмәтне күрми калмыйм дигәндәй, аның артыннан Шадра үрелеп-үрелеп карый: үзенең бер күзе барыбер Азманда. Ә Түбер, бик зур эш кырган кыяфәт белән, биленә таянып тора. Авызы тагын да масаебрак ачылган.

«Ыһ» дип бер тирән итеп сулауга, Сабадырев, бот резинкасыннан браунингны суырып алып, чүгәләгән килеш кенә Мунча Миченә берне гөрселдәтте. Икенче пуля Түбернең эчен тишеп агызырга очты. Әмма ул, нәгъләт, кәҗә тәкәсе кебек читкә сикерде, бер уңайдан Митькага тибәргә өлгерде. Итек очы гына тиеп китте кулына: пуля адашты, браунинг лып итеп аяк астына төште.

Бер мәлгә генә каушап калган Шадра револьвер төкереге белән Сабадыревны җиргә сылыйсы иде. Төзәп атарга Мусин комачаулады. Шадраның өстенә сикереп, йодрыгы белән ияк астына кундырды. Револьверын алырга да маташты, тик Шадра көчле егет булып чыкты. Мусинны селтәп кенә атты. Мусин җан ачуы белән аның кулына килеп ябышты. Шадра, ярсып, шарт-шорт атты, аткан берсе һавага китте,— револьверында патрон беткәнче, Азман аның кулын ычкындырмады.

Ул арада Сабадырев сикереп торды, җирдән браунингын алып, сарай артына качып баручы Түбер артыннан ташланды. Шулай да эчендәге кату язылмаган, тын алуы авыр, аяклары камыр төсле йомшарган иде. Ул барып җиткәнче, Түбер сарай артында көтеп тормаган: рәшәткә арасыннан аның киң аркасы гына күзгә чалынып калды. Митька шул якка төзәп атарга өлгерде: ләкин Түбер, тиен кебек сикереп, күрше йорт коймасына ышыкланды. «Тагын да эзәрлекләп бару хәтәр»,— дип уйлап алды Митька һәм бик вакытлы туктап калган икән. Кире китә башлауга, койма артындагы Түбер аны ике-өч тапкыр револьвердан атып озатты. Беренче пуля ук башындагы кепкасын очырып төшерде. Сабадырев тиз генә җиргә сузылып ятты. Бәлки Түбер болай гына калдырмас иде әле, шул чакны Амур урамы ягыннан милиция сыбызгылары телгә килде. Коткаручы да, котны алучы да сыбызгы иде бу. Митька Мунча Миченең кесәсендә калган алтыннарын искә төшерде, каударланып сарай ягына йөгерде. Әмма анда да кинәт шарт-шорт аткан тавышлар ишетелде. «Кем — кемне: Мусин Шадраны чәнчелдердеме, әллә Шадра — анымы?..» Револьверлы кулын алга сузды Митька, сарай почмагыннан сак кына үрелеп карады. Ишегалдында җәелеп яткан Мунча Миченнән кала берәү дә юк иде. Анархист, күзләрен каракларча ялтын-йолтын китереп, мәет янына килде. Бармагындагы никах балдагын салдырып алды, аннары тиз генә кесәләрен әйләндерде. Үзенең хәләл хезмәте белән кайтарып алган алтын тәңкәләр өстенә бер кесәдән килеп чыккан чылбырлы сәгать тә өстәлде.

Әче тавышлы милиция сыбызгысы инде бөтенләй якында гына колакны яра иде. Сабадырев җил капкага таба йөгерде,— утыз-кырык адымда гына торган милиционерларны күреп алды. Кирегә ташланып, биек коймага үрелде. Күрше йортның иркен ишегалдында яшелчә бакчасыннан кала ышыкланыр урын да юк иде. Түтәлләр, сулы тагараклар өстеннән лап-лоп килеп өйгә таба йөгерде.

Урамда бер хатын-кыз шыр салып кычкырды:

— Шул якка йөгерде алар, шул якка. Күрше ишегалдыннан эзләгез!..

Өй ышыгына елт итеп керергә генә өлгерде Митька — артыннан ике тапкыр гөрселдәтеп аттылар. Ул инде шуннан соң ничә койма аша сикергәнен хәтерләми. Канатлар үстеме үзенә, әллә юлындагы киртәләр иелеп көч биреп тордымы — нәкъ кыр кәҗәсе кебек очты. Бары бер койма башы гына ботын тырнап, ыштан чүпрәген умырып калды. Аңына килгәндә, биек коймага барып терәлгән тар тыкрыкка барып эләгүен сизде үзенең. Эзәр-

лекләүдән тәмам күзләре әйләнгән бүре кебек, ул әле бер, әле икенче якка бәргәләнде. Олаучы карт көтеп калган турга чыгу иде аның нияте.

Кинәт, сул тарафта — еракта, Кәҗә бистәсенең аргы башында тагын атыш башланды. Бәш милиционерның өчесе Түбер белән Мусинны куа киткәнен белми иде Сабадырев. Әлеге атышның сәбәбе — инде стенага китереп терәгәч тә, ярсып каршылык күрсәтүче Түбер икәнен белми иде.

Бик каушаса да, Митька дөрес чамалаган икән: бер-ике тыкрыкны әйләнүгә, бистәнең олы урамына килде дә чыкты. Теге кырган башлы извозчик та ташлап китмәгән, тик инде кемнедер утыртып маташа иде. «Әй-һәй!» — дип кычкырып иде Сабадырев,— милиционерлар ишетер дип курыкты. Сөенечкә каршы, шул чакны тарантас кузгалып, нәкъ аңа каршы чаптырып килә башлады. Митька эченнән генә чукынып алды: алла бар икән чүтеки!

Ерактан ук шәйләгән иде, ялгышмаган икән: олаучыга ышыклана төшеп Мусин утыра, әледән-әле артына борылып карый! Бирим дигән колына чыгарып куяр юлына! Митька «ә» дигәнче читән арбага менеп тә кунаклады. Хәтәр пассажирларга тап булуын чамалаган олаучы атын Казан суы аша салынган күпергә таба һай-һулап куалады.

Бистә балчыгын изеп килгән тәгәрмәчләр шәһәр үзәгендәге мостовой ташларын шакырга кереште. Азман, кинәт йокысыннан уянган төсле, сискәнеп киерелде, извозчикка юлны өйрәтеп бара башлады. Сәгать буе кыска тыкрыклар, тар урамнар буйлап туллганып йөрделәр. Шуннан соң гына, кая барасыларын кинәт исенә төшергән кебек, Мусин соңгы тукталышны әйтте.

Олаучыны җибәргәч, Мусин үзенең мажараларын сөйләп алды. Икәүдән-икәү генә калгач. Шадра белән шактый нык тарткалашкан икән. Көчле булып чыккан дуңгыз. Азман аны хәйлә белән җиңгән, әмма барыбер качырган. Пуля белән кулын гына чәрдәкләгән булырга тиеш.

— Олаучы картны исән-имин җибәрү, мөгаен, безнең хатадыр...— дип сөйләнде Азман, як-ягына каранып.— Мин аны Казан күперендә чәкемәкче дә идем, каршыга килүче булмаса. Ярар, карусыз карт иде, хәерлегә булсын. Барыбер, аның эзеннән килсәләр, шушы урамнан да ары китмәсләр. Ә без хәзер икенче извозчик яллыйбыз... Тик синең белән юл уңмый әле нәрсәдер, гөнаһың күп бугай, анавы, аягың авыр!..— Ул, башын чөя төшеп, Сабадыревка мыскыллы караш ташлады.

Митька җавап эзләп кесәгә кермәде:

— Бүрәнә аша бүре кусаң, кычытмаган төшеңне кашыйлар инде ул,— диде ачусыз гына.— Шулай бер әләгә язганым бар минем дә, браунинг булмаса баш беткән иде.

Браунинг турында сүз чыккач, Азманның йөзенә тәкәббер-мәрхәмәтле елмаю җәелде:

— Ярый, ахир, син яшь кеше, үрдәк томшыгыннан су эчмәгәнсең әлегә. Әмма дә браунингны шәп яшергәнсең. Ул фокус-мокусны миңа да өйрәнәсе бар.

Икенче извозчикны әллә ни тинтерәтеп йөртмәделәр. Ниндидер ике катлы йорт каршына туктап, Мусин үзенең чүпрәк-чапракларын алып чыкты. Олаучы туры айгырның ялтырап торган сыртына яратып, шап-шоп сугып алды, җиргә төшкән дилбегәне күтәреп:

— Йә, малкай, йә, кузгалдык,— дип чөңгереп җибәрде.

Айгыр, башын чайкап, иренеңнән саргылт күбекне кагып төшерде, яңгыратып кешнәп алды: аннары, матур ялын җилдә уйнатып, таш җәелмәгән пычрак урам буйлап юыртты. Евангелистлар урамына җиткәч, тарантастан төшеп, җәяүләп кенә киттеләр.

— Син мине үлемнән йолып калдың, ахир. Моннан соң әтәч булып кунача гына утырырсың, яме,— дип сөйләнде Азман, извозчик күздән югалгач.— Тавык кетәклегендә, кош тизәге өстендә дип уйлама тагын, ходай тәгалә үзе биргән изге йортта, ягъни мәсәлән. Анда икебез бер түбә астында яшәрбез, боерган булса. Шайтан түгел, фәрештә дә эзләп таба алмас.

Сабадырев каршы бер сүз дә кайтармый тыңлап барды, үзе эчтән генә

исәп корды: бу адәм белән бергә тору нигә кирәк булыр. Эт тыкрыгын тик томалдан ташлап китү килешерме? Иске яра кебек йөрәген сулкылдатып, татлы дошман Тоська исенә төште. Ул хатынның мәхәббәт түшәгендә исәрләнеп яратулуы... Тыгыз кайнар имиләре белән ботларыңа елышып, аяклары белән муеныңнан кысып кочаклавы... Менә шулар күз алдына килгәндә, бөтен тәнеңне дерелдәтеп, ирлек тойгың үрә басмыймы! Ярату хисе белән бергә үк, хәнҗәр тыгып бутагандай, үпкә-бавырларыңны телгәләп, көнчелек хисе кузгала. Тоськаның баржа трюмында гөнаһлы ыңгырашкан тавышы ишетелеп китә.

«Фу, нәгъләт, иблис вәсвәсәсе кебек. һич уйламаганда күңелгә керә...— дип, авыр йокыдан уяныргa теләгәндәй, кулларын бутап куйды Митька.— Әгәр хәзер шул әнчекнең исен онытмасам, бетәм мин, бөтенләй энәталаксыз булып калам. Зиһенемне богаулый, аяк-кулымнан тота, тәмам сихерләгән төсле. Болай булса, Махно атакай кушканны ничек үтисең? Бу хәлдә чека тырнагына түгел, гап-гади уголовный розыск куенына барып керүең дә бар».

Сабадырев юлдашының нәрсәдер сөйләнеп баруын ишетте, әмма ул сүзләр аңына барып җитмәде: үз кичерешләре аны калын юрган булып урап алган иде.

— Нәрсә син, аяк өсте йокымсырап киттеңме әллә? — дип, хәленә керергә тырышып тагын сүз катты Мусин. Әмма ахиреңең зур булып ачылган күзләрендә мәгънә әсәре күрмәгәч, аның дәшмәвен үзенчә аңлады: — Күпме генә баш ватсаң да, шуннан да әйбәт урын тапмассың. Бигрәк тә мондый михнәтле-авыр заманда.

— Ул аллаһы тәгалә йорты кайсы тирәдә соң? — Митьканың сүз юктан сүз булсын дип кенә соравы иде әле бу.— Казанда атаклы Елантау монастыре бар, имеш. Шунда түгелдер бит?

— Сыер икәнсең, ахир, өстенә баса яздың.

— Монахлыкка язылабыз, димәк?

— «Цивильское Подворье» дигән мөсафирханәне ишеткәнең юктыр әле. Элек, монда духовный семинария эшләгән чагында, семинаристлар баскан иде аны, кандала кебек.

— Хәзер кемнәр капшанып ята инде анда? Өязләрдән килгән поплар да дьякларммы?

— Күбесенчә шул халык.

Поплар кунакханәсенең ике кешелек номерлары монастырьдагы монах хөҗрәсен хәтерләтә иде. Шундый ук калын кирпеч диварлар, мич авызы кебек кечкенә тәрәзәләр, биек ак түшәмле тар, озын бүлмәләр. Шулай да үзләренә тигән номер-хөҗрә Митькага бик ошады. Эт тыкрыгындагы тимер ятактан соң патша әгъзам галиҗәнапләренең йокы бүлмәсенә тиң булып күренде ул.

— Ничек әле син, иноверец-мөселман, православие белән уртак тел таптың? — дип гаҗәпләнде Сабадырев.— Әллә инде чиркәү хорына кушылып җырлаштырасыңмы?

Мусин, канәгать төс белән, мыек астыннан гына көлемсерәде:

— Сиңа шунысы да мәгълүм булсын, Митрий...— кылтаеп, монах тавышы белән сузды: — Нәкъ менә чиркәү хорына бүтән диндәге кешене алмыйлар. Ни өчен дигәндә, чиркәүдәге фәрештәләрне качырып бетерер дип курkалар. Күз алдыңа китер инде, йә: кичтән ачы бал чөмереп килгән бер антихрист, бөтен хор «Славься...» дип суза башлауга:

Аракыны кем эчкән? —
Иван белән Ычтапан...—

дип җырлап җибәрсә? Барча изгеләрегез чиркәүдән ыштансыз чыгып йөгерер дә, туп-туры тәмугка барып, шайтаннарның җилкәсен кашып торырга ялланырлар иде, шөт...

Сабадыревның йөзе караңгыланды:

— Слушай, ахир, мин диндар кеше бит. Үземнән көлсәң дә сүзем юк.

әмма динемнән көлгәнне күтәрә алмыйм. Исеңдә тот шуны.

Азман каш астыннан сөзеп карады:

— Ә мин көлмим,— диде. Тавышы коры, хәтта усал иде.— Бераз уенга борганмындыр. Әмма уены-чыны шунда, каны-сөле эчендә...

— Әйдә, ул хакта тел шомартмыйк,— диде Митька, килешергә теләп.— Иң яхшысы, ике сүз белән генә әйт тә бир: ничек монда килеп эләктең? Бусын да, хатыннар кебек, коры кызыксынудан гына соравым түгел. Көтелмәгән күңелсез хәлләр килеп чыкса, кем канаты астында яшәвемне белеп торыйм, димен...

Мусин, аякларын өстәл өстенә сузып, венский урындыкка иpләбрәк утырды. Бу аның шулай Сабадырев каршында үзен тулысынча бәйсез итеп күрсәтүе иде. Алан-ялан килгән күзләрен түшәмгә төбәде. Беркавым башын кашыган булып торды. Аннары исе китмәгән кыяфәт белән:

— Кушаматың ничек соң синең, анавы? — дип куйды. Сабадыревны ирештергән кебек: — Теге ни, көтелмәгән күңелсез хәлләр чыкса дип сорыйм... Конспирация өчен...— диде.

— Алаша булыр минем кушаматым,— диде Митька, аның үртәвен сизмәгәнгә салышып.

— Алайса белеп тор, Алаша: мин сиңа шестерка да, яисә половой да түгел. Мин фартовик[1] булам, ахир...

— Слушай, Фаикъ...— Сабадырев инде бу адәм белән кискенрәк тонда сөйләшүенә үкенә башлаган иде.— Алай сөйләшмик, зинһар. Печән арасына салам кыстырган кебек, блатной сүзләр дә кушма. Югыйсә, анархист ни дә, у... ба...— дип тотлыгып калды: «Уголовник-бандит ни» дип әйтсә, Мусинның тәмам хәтерен калдырган булыр иде. Ярый әле: — анархист ни дә, башкалар ни: безне аера да алмаячаклар,— дип төзәтте.

Мусин аның ник тотлыгуын чамалап алды, билгеле; шулай да, килешү ягына борылып, кулын селтәде:

— Бетте, бетте! Безнең бүлешер нәрсә юк, ахир. Бик якын анархист дустым бар иде минем сиңа хәтле... Атаклы Санька-анархист! Күз алдымда чека ботарлады... Мин дә ничек котылганымны белмим. Әй, язмыш мине күп кыйнады, бәгыремне ташка әйләндерде. Төрмәдә генә биш тапкыр утырдым. Төрмә академиясе миемдәге ялкаулык күгәреген кырып алды, ахмаклык тузанын ду китереп туздырды. Хәзер мине яңадан анда тыгар өчен, беләсеңме, нәрсә кирәк? — Миңа каршы адәмнәрнең, агент-мильтоннарның миендә Азманныкыннан күбрәк сыр булуы кирәк! Әлегә мин андый кешене күрмим. Мин узган тәмуглар аша бүтән берәү узса, куркудан чәчләре берәм-берәм коелып бетәр иде. Башта акшар кебек ап-ак төскә кереп, кәнишне. Менә мин сизеп торам: син тәвәккәл җегет, хәйләкәр җегет, хәтта башлы җегет. Әмма турысын әйткәнгә үпкәләмә — ярты сәгатьтән ни буласын белмисең. Ишкәксез-нисез салда йөзеп барасың кебек. Ә мин — мактаудан булмасын — шахмат чемпионыннан да болайрак, ун йөрешкә алдан бөтенесен исәпләп куймасам, тыныч йоклый алмыйм. Без менә теге олаучыларны исән-имин җибәрдек, ә мин белеп торам: нәкъ шул эздән иснәнеп киләчәк әле сабакылар, ике бүрене камап алырга тырышачаклар... Әйткән иде, диярсең. Шуннан соң белерсең минем кадеремне, анавы, әмма соң булыр.— Мусин аягын өстәлдән алып куйды.— Кем канаты дигәндә, күңеленә шик кермәсен, ахир: монда минем үз кешем бар.

Шуннан соң Азман озын бер тарих сөйләде. Имештер, Чистайдагы ниндидер караклар шайкасына башлык булып йөргәндә, икенче бер шайканың шәһәр чиркәвен һәм бер очтан шул чиркәүнең побын талау нияте барлыгын белеп алган бу. Тоткан да шуны попның колагына пышылдаган. Ни өчен дигәндә, теге шайканың башында күптәнге дошманы — «Әти» кушаматлы Коська Балабанов тора икән. «Әти»не, поп ярдәме белән, полиция эләктереп ала; һәм, иплән кенә, биш ел бирәләр үзенә.

---

[1] Шестерка, половой, фартовик — караклар телендә иң түбәннән башлап югарыга таба дәрәҗә-ранглар.

— Мин җүләр түгел: мондый эшкә һич бармаган булыр идем, әгәр ул, кабих, үзе шуның алдыннан мине дүрт ел буе арестант күлмәге белән агач башмак киеп йөрергә мәҗбүр итмәсә. Мин аңа бурычымны гына кайтардым.— Мусин тәмәке кабызды, бөҗра-бөҗра итеп зәп-зәңгәр төтен җибәрде.— Әмма... Утыртуын утырттылар, ә Вакытлы хөкүмәт, үткән елның февралендә амнистия ясап, шул Балабановны ирекка чыгарды. Хәзер ул, әнә, Казанга күчеп килде. Үзең күрдең, юлларыбыз тагын кисешә башлады.

— Аның каравы, син Чистай побы белән дуслашып калгансың. Яхшылыгыңны онытмаган, димәк.

Мусин тәмәке көлен өстәл читенә койды:

— Бер сүз дә әйтер хәл юк: әйбәт мужик. Варсанофий атакай диләр аны. Бу октябрь Рәсәйне болгатып ташламаган булса, еракка китәсе иде ул. Утыз яшең ту лар-тулмаста Чистай кебек өяз шәһәрендә кафедраль соборның протоирее булып кара әле! Ул сиңа шухыр-мухыр гына түгел! Дөньялар үзгәргәч, итәк-чабуын җыярга да Казанга килеп сыенырга мәҗбүр булды. Баштарак Казан һәм Зөя митрополиты Иаков канаты астында яшәде. Аннары монда күчерделәр Варсанофий атакайны. Ул биредә үзе баш, үзе муен. Инде үзенә мәхәллә биргәнне көтә. Изге Варвара чиркәвенә өмет баглап тора, дигән сүзләр йөри: митрополит Иаков ризалык та биреп өлгергән, имеш. Кайберәүләр, Кабан күле буендагы Өч Евангелист чиркәвендә эшләячәк, дип сөйлиләр.

— Ә үзе, Варсанофий атакайны әйтәм, ни уйлый икән? Таянырга буламы соң аңа?

— Астыртын батюшка ул. Әлегә тын тартмый. Әмма ләкин, башымны кисәргә бирәм: ышанычлы мужик. Кемнең кем икәнен күзенә карап аера. Советка каршы чыккан һәркем аның хәер-фатихасына ирешә.

— Анысы аңлашыла...— дип кулын селтәде Митька.— Тарасенко миңа сөйләгән иде инде... Митрополит Иаков яшенле яңгыр яуган саен дога кыла, имеш: имансыз большевикларның башына ходай орсын, дип. Побына күрә — мәхәлләсе: Варсановий гына әллә кая сикерә алмас. Шулай да таныштыр әле мине аның белән...

Азман аларны һичшиксез очраштырырга сүз бирде, шул ук вакытта кисәтеп тә куйды: батюшка бик сак кеше һәм бик зур «ерудит» икән. Аның белән сөйләшүе җиңел түгел, әмма кызыклы. Бер кочак тел белә. Французны, латинны... Хәтта ки татарчаны.

— Ә татар теле — аның ана теле.— дип куйды Мусин.

Сабадыревның күзләре маңгаена менде:

— Ул нәрсә: мөселманмыни, Варсанофий ата... ата...

— Юк. Чын православный. Аның бабалары — татарлар — императрица Елизавета Петровна заманында христиан динен кабул иткәннәр.

— Шундый православный мөселманнар бик күпме Казанда?

Мусин бер мизгелгә генә каушаган төсле булды, җилкәсен сикертте: бу — кем санаган инде аны, дигәнне аңлата иде. Икенче мизгелдә ул яңадан үз рәвешенә кайтты, ни белгәнен сөйләп калырга ашыкты:

— Нужәли, ахир, синең ишеткәнең дә, укыганың да юк — чукынган татарлар хакында?.. Мин, зур гыйлемле булмасам да, җае чыкканда укыштырырга яратам. Билгеле, күбрәк закон-хөкем китапларын карап барырга туры килә.— Ул күз кысып алды.— Квалификацияне күтәрим дисәң, бүтән китаплардан да өйрәнми хәл юк. Быел менә Конан Дойльга утырдым әле. Тотылган җинаятьчеләрнең хатасын тикшерә-тикшерә укыйм. Бик гыйбрәтле китап, мин сиңайтим.

— Чукынган татарлар турында да язамы ул анда?

— Кем, Конан Дойльме?..— Бу юлы да үзенең өстенлеген сизү Азманны тәмам канатландырды.— Беләсең килсә, башы эшләп җиткермәгән ул рус патшаларының. Чукынуны үзләренә хезмәт иттерү өчен төп шарт итеп куйганнар. Мин, мәсәлән, беренче министр итәбез дисәләр дә, динемнән язмас идем...

«Синең диндарлыгың инде — ташкүлчим».— дип уйлады Митька.

— Ә бит акыллы гына кешеләр күчкән. Атаклы князьләр Мстиславский, Кочубей, Юсуповлар... Һәммәсе дә татардан. Мин инде князь Семион Бикбулатовичны әйтеп тә тормыйм. Бервакыт, үзе Мәскәүдән киткәндә, Усал Иван аны үз тәхетенә утыртып калдырган. Һәм шул Семион ел буе Рәсәй белән идарә иткән.

— Менә күрәсеңме, Фаикъ, ниндидер Семионга бөтен Русия баш игән... Ә син Казанны гына булса да — Казанның караклар дөньясын, димен — үзеңә карата алмыйсың. Әллә син Семионнан кимме? Без, анархистлар, тәхеткә утырырга булышыр идек...

Мусин тамак кырып куйды:

— Караклар дөньясы — дәүләт тә, шәһәр дә түгел. Безнең брат тегендә — Европада гына, су асты көймәсе кебек, тирәнгә чумып, үзалдына яши ала. Ә Рәсәйдә андый корабны төзи калсаң да, рәхәтлек диңгезендә бик ерак йөзә алмыйсың. Шунда ук арабызда күсе-тычкан ишеләр пәйда булып, корабыңның төбен кимерә башлый. И... җаның-малың белән төрмә чоңгылы суырып ала.

Сабадырев үзе утырган урындыкны шыгырдатып киерелде, астыртын көлемсерәде:

— Берәү дә нәкъ менә үзен күсе-тычкан дип санамый, бәланең башын бүтәннәрдән күрә инде, ә?..

Митька инде мыегына чорнап куйган иде: Азманның серкәсе су күтәрми, бигрәк тә үзенә төрттереп әйткәнне яратмый. Нәкъ дары мичкәсе: әз генә көлү-ирештерү очкыны чыксын — ул шунда ук шартлап кабынырга тора. Аннан соң инде үзеңә үпкәлә! Менә тагын хата китте...

— Алаша, ахирием-алтыным,— дип элеп алды Мусин,— беләсең килсә, анавы, мине — тычкан, ә үзен мәче дип санаган бәгъзыларнең койрыгын шарт итеп кистеләр инде. Мыегымны бер селкетү җитә — ул песиләр, тычкан тотуны гомумән онытып, үз үләксәләре белән туена башлаячаклар...

Бу — Митькага тагын бер сабак бирү булды. Уртаүдән туктарга кирәк, дип борынына киртләде ул. Тарасенко инде бу адәмгә юллап җибәргән икән, димәк, Нестор Иванович кушкан эшне үтәү аңардан башка бик кыен булачак. Ә Махно атакай каршына буш кул белән кайту турында уйларга да ярамый. Ирештерергә, кимсетергә түгел, юк, киресенчә — җае чыккан саен мактарга иде моны. Чынлап та, буш егет түгел бит.

— Син хаклы, Фаикъ... Әмма Россия зур, анда юк-юкта акыллы башлар, хәтта бөекләр дә туып тора. Бары тик аларны үсендерү, канат астына сыендыру җитми бездә. Минем менә шуңа җаным кыйнала. Һәм синдәй булдыклы егетләрнең сыеныр төшләре булмау — Россиянең шуннан да зуррак казасы юктыр дип уйлыйм. Талантлы кеше, нинди генә юлны сайласа да, яклауга лаек. Даһи хөкемдарлар гына түгел, даһи җинаятьчеләр дә кирәк дөньяга... Мин, ихлас әгәр, сиңа кулымнан килгәнчә ярдәм итәр идем. Казанның караңгы эшләр патшалыгы синең кулда булырга тиеш.

Сабадыревның болай озаклап, бормалап сөйләвен игътибарсыз гына тыңлап утырды Азман, бер сүзенә дә ышанмавын белдереп, чыраен сытты:

— Тәхеткә таба беренче адымны ничек ясарга икәнен беләсеңме соң син, Алаша? — диде.— Иң элек Суконный бистәсенең чабаталы падишаһы Коська Балабановны юлдан алырга кирәк. Чөнки ул үзе тау башына үрмәли. Көндәшен юк итү өчен бернидән дә чирканмый... Әле шушы араларда гына, әнә, үзенең кешеләрен милиция киеменә киендереп, Пелатән төрмәсенә үтеп кергән. Ялган язулар белән төрмәчеләрнең башын әйләндергән дә, шунда утыручы дошманы Гришка Сержантовны кулга төшергән. Аны төрмәдән алып чыккан! Казанка буена алып төшеп, атып үтергән. Менә нинди ул! — Азман урыныннан торды, калтыранган куллары белән чәчен сыпырды.

— Димәк, хәзер синең чират...— дип куйды Митька гамьсез генә, берни дә булмаган кебек.

— Әз генә көндәш булырдай кешене йомдырмаса, Коськаның дөньясы түгәрәк түгел. Өч юлбасарын җибәргән минем җанны алырга. Ә бер-ике атна элек кенә чекистларга тотып бирә язды...

— Ничек, чекистлар белән дә бәйләнештә торамыни ул?

— Әйткән идем ич инде. Мировой җегет Санька-анархист шунда әрәм булды, дип.

Митькага ул хакта Тарасенко сөйләгән булса да, үзе шул фаҗигадән исән-имин котылган кешене тыңлау кызыклырак иде. Мусин да, аның кызыксынуын сизеп, «Франция» номерларында булган хәлне бик тәмләп, тәфсилләп бәян итте. Бары тик Саньканы үзе үк атып киткәнен генә яшереп калды.

Анархистларның картасын яхшы ук бутаган әлеге хәлне ахыргача ачыклап бетерү кирәк иде Митькага. Өстәвенә, тере шаһит белән кара-каршы утырганда.

— Нишләп әле чекистларны Коська Балабанов өсләткән дип уйлыйсың? Һәм, имеш, нәкъ менә сине чека табасында куыру өчен? Әгәр дә Санькадан котыласылары килгән булса? Син үзең бит анда ялгыш кына, Санькага ияреп кергәнсең...

Сорауларны, менә шулай, кабыргасы белән куйды Митька. Бу кадәр төпченүне көтмәгән Мусин, йөзенә сугудан сакланган кебек, сул кулын тырпайтып каш турысына күтәрде.

— Йә, йә...— диде ул, ниһаять, телгә килеп,— берьюлы ул хәтле күп тондырма. Минем инде биш ел булганым юк сорау алуда. Ничек итеп җавап бирәсе икәнлеге дә онытылган... Азман әйтсә — белеп әйтә, ахир. Мин бүген бер кешене таныдым. Чекистлар безгә тозак әзерләп куйган көнне мин аны «Франция»дә күргән идем. Ул әнә шул Коська җибәргән өчәүнең берсе — Шадра булып чыкты, бик беләсең килсә.

— Син үзеңә ышанмый дип уйлама,— Митька урындыгыннан торып киерелде-сузылды: — Балабановның сине аулавы көн кебек ачык.— Ул караватка барып утырды.— Шулай да, минемчә, тикшереп карарга кирәк. Бәлки, ул Шадра анда эшли торгандыр. Янсә шунда яшидер. Әгәр инде, чынлап та, син әйткәнчә булса...

— Менә шул чакта Коська Балабановка кисәтү ясарга мөмкин,— дип элеп алды Мусин.— Иң яхшысы: ул котырган аюның кая кереп оялаганын белергә дә...

— ...Эт көтүен өсләтеп, җенен өздерергә! — «Үзе кебек үк»,— дип әйтеп бетермәкче иде Митька, тик ашыгып нәтиҗә ясаудан тыелып калды. Кемнең кем икәнен беләсе бар әле, дип уйлады ул. Бәлки, Азманның үзен дә юлга төшәргә туры килер тиздән?...

Йөзенә чыгармаса да, Сабадыревның кәефе бик нык кырылган иде. Беренчедән, төп максатка, ягъни дәүләт банкысына таба илтердәй тар гына сукмак та күренми әлегә. Икенчедән, көндезге атыш аның тынычлыгын алды. Теге Шадра белән Түбер милициядән качып котыла алдылар микән? Бигрәк тә Шадра — яралы кулы белән... Әгәр дә эләккән булса, ул бит авызына су кабып тормаячак. Телен бик тиз чишәчәкләр. Эшкә керешеп тә өлгермәс борын, уголовный розыск игътибарын җәлеп ит инде... Әх, егетләр! «Өйдә» — Эт тыкрыгында ниләр бар икән хәзер? Саксыз кыланмый микән теге исәр башлар?..

Алашаның уйга калуын Азман үзенчә аңлады.

— Беренче көнне үк сиңа авырга килгәндер, ахир. Ятыйк, булмаса, яраларны ялаштырып,— диде.— Монда ут алып тору гадәте юк,— дип өстәде.

Кечкенә тәрәзәдән көн үзәгендә дә әллә ни яктылык кермидер. Чыннан да, кич җиткәнен сиздереп, бүлмәдә инде күз бәйләнә башлады.

— Гаепләштән булмасын, ахир...— диде Митька, эчке калтырануының кул-аякларына да күчә баруын сизеп.— Миңа кайтып әйләнеп килергә кирәк. Иртәгә кичкә, йә берсекөнгә иртән шушында ук очрашыйк, ә? Бүген күргәннәрне берәүгә дә тишмә.

Сабадырев, тизрәк кайтып җитәр өчен, тарантас алдына үзе чыгып йөгерергә әзер иде. Эт тыкрыгына якынлашкан саен, йөрәге авырттырыбрак типте. Акылы белән ышанмаска, үз-үзен «барысы да әйбәт булыр» дип юатырга тырышса да, күңеле нидер сизенә иде аның, сизенә иде...

* * *

Икенче көнне иртүк уголовный милиция идарәсе башлыгы өстәлендә шундый кәгазь ята иде инде:

*Иптәш Г. С. Гофштадтка.*

*Сезгә мәгълүм булсын: кичә төштән соң, сәгать 3 ләрдә, Амур урамында ату тавышлары ишеттек. Каракларның ике шайкасы узара чәкәләшкән булып чыкты.*

*Атышучылар: бер яктан — аталы юлбасар Балабанов Константинның (кушаматы «Әти») «Күк күгәрчен» исемле шайкасыннан өч бандит: Пупохватов Борис, Губернаторов Фома һәм Маньков-Морский Иван; икенче яктан — бүтән шайка башлыгы Мусин Фаикъ һәм кем икәнлеге әлегә билгесез бандит.*

*Бәрелеш вакытында «Әти»нең ярдәмчесе, уң кулы — Губернаторов Фома атып үтерелгән.*

*Пупохватов (кушаматы «Түбер») кулга алынды. Ул, әзәрлекләп барганда, бер мунчага бикләнеп, патроны беткәнче каршылык күрсәтте.*

*Калган өч бандит качып өлгерделәр.*

*Мусин (кушаматы «Азман») ялган бриллиант һәм алтын әйберләр сату, кибет һәм йорт басу белән көн күрә. Аның шайкасы Балык базары тирәсендә эш итә.*

*Мусинның иптәшен Пупохватов танымаган. Тышкы билгеләре: озын буйлы, коңгырт чәчле, соры күзле, калын иренле. Яше 25—30 тирәсендә. Карадан киенгән. Сөйләме буенча, Казан кешесе түгел. Мусин янына ул тарантас белән килгән. Шәһәргә шул ук извозчик белән кире кайтуы да ихтимал.*

*Уголовный розыск хезмәткәре*
*Ф. Мурашкинцев.*

Гофштадт, беренче эш итеп, бу хәбәрне чекага җиткерде. Шунда ук Балык базары тирәсен дә күзәтү астына алдылар. Билгесез бандитны Кәҗә бистәсенә илтеп куйган олаучы эзеннән берничә агент китте.

Коммуналь хуҗалык идарәсендә теркәлгән извозчиклар исемлеге бик зур булып чыкты. Әмма, бәхеткә каршы, озак азапланырга туры килмәде. Дөресрәге, олаучыларның «чыбыксыз телефоны» ярдәм итте. Ике-өч сәгать тә үтмәгәндер, кирәкле кеше милиция идарәсенә килеп керде.

Җамалетдин абзый үз белгәнен тезеп-тезеп сөйләп бирде: Кәҗә бистәсендә ни гомер көтеп торганын да, аннан соң юлда ничек бормалап-сырмалап барырга туры килгәнен дә, ниһаять, «Зур Аркылы Чүлмәк» урамына илтеп куйгач, исән-имин генә котылганын да.

«Эз яздырырга тырышканнар икән, олаучыны ничек үтереп китмәгәннәр әле...— дип уйлады Гофштадт.— Җамалетдин картны эзләп табу, эзәрлекләү ихтималын алдан күргән бит Мусин. Шуңа күрә иртәрәк төшеп калган да ул. Барасы җирләренә әле шактый ерак булгандыр. Димәк, ким дигәндә, тагын бер извозчик яллаганнар...»

Җамалетдин абзыйдан сораштырганда, кичәге хәлләрдә катнашкан Федор Мурашкинцев белән Хәсән Зарипов та тыңлап торды. Милиция башлыгы икенче извозчикны табу бурычын шунда ук Мурашкинцевка йөкләде.

— Бу вакыйгадан тагын ике төрле нәтиҗә ясарга кирәк,— диде Гофштадт, сынаулы карашын үзенең егетләренә төбәп. Тегеләр исә башлыкның тел төбен аңлап җиткермәделәр, ахрысы, сүзгә кушылмадылар. Гофштадт фикер сөрешен алга таба дәвам итте:

— Олаучы картка юлны кем күрсәтеп-әйтеп барган? Олырагы, тазарагы, дидеме? Мусин, димәк. Ә яшьрәге, буйга озынрагы дәшми-тынмый гына утырган... Ни өчен олаучыны Мусин әйдәкләп барган, дип уйлыйсыз?

— Юл өйрәтү, дилбегә кагу — мәртәбәле эш түгел бит,— дип икеләнеп кенә телгә килде Мурашкинцев.— Башлык-түрәләр, гадәттә, извозчик белән вакланып тормый. Бигрәк тә янында үзенә буйсынган кеше дә барганда.

Ихтимал, «кунак егет» яшь булса да, Мусиннан эрерәк җанвардыр?..

Гофштадт, җавапны хуплап, баш какты, үзе:

— Тәк, тәк,— дип Зариповка таба борылды.

— Монда төрлечә уйларга була, Григорий Соломонович,— диде Хәсән, имтихан бирүче гимназист кебек каушап.— «Кунак егет»нең, чынлап та, Казанны белмәве, ә Мусинның аны тагын кем янынадыр алып баруы да мөмкин ич. Әгәр баш бүре булса, извозчик яллап, Мусинны үзе эзләп килмәс иде ул.

«Йә, инде сез ни әйтерсез?» — дигән кебек, икесе дә Гофштадтның күзенә карадылар. Милиция башлыгы бу ишарәне аңлап:

— Икегездә дә хаклык бар, бөркетләр,— дип елмайды.— Шулай да, мин икенче фикерне куәтли төшәм...— Мурашкинцевны үпкәләтмәс өченме, аңа күз кысып куйды: — Лукич, рапортында үзең дә шулай язган идең бит. Сорау алганда теге «Түбер» яңадан кабатлады: «Аның теле безнеке төсле түгел, килмешәк булса кирәк»,— диде. Әгәр шулай икән, исемсез бандит — сез әйткәнчә, «кунак егете» — шәһәргә нindидер йомыш белән килгән һәм, вакытлыча торырга булса да, үзенә сыенер урын эзләячәк. Моны, һичшиксез, мыекка урап куярга тиешбез.

Григорий Соломонович, башын иеп, бер ноктага караган килеш, шактый вакыт уйга бирелеп торды. Егетләрнең барлыгын бөтенләй онытты кебек. Аннары, кинәт башын күтәреп, фикеренең хаклыгына ышанган төс белән, акрын гына дәвам итте:

— «Кунак егете» извозчикны Эт тыкрыгында туктатып утырган. Шулаймы? Бу вакытта әле аны беркем дә куа чыкмаган һәм ашыктырмаган дип уйлыйк. Димәк, ул Эт тыкрыгында инде үзенә сыену урыны тапкан. Яисә шунда аның үз эшләре бар, ул аларга — кунаккамы, эш беләнме — нindидер сәбәп табып килгән... Мин моны тиккә генә сөйләп тормыйм, Хәсән. Эт тыкрыгын хәзердән үк керфек тә йоммый күзәтә башларга кирәк.

Зарипов җәһәт кенә урыныннан сикереп торды.

— Ул адәмнең төсен-битен ачыграк күз алдына китерергә тырыш. Җамалетдин карт белән дә тагын бер кат сөйләшеп,— дип киңәш бирде Гофштадт.— Аннары берәр егетең йортлар идарәсенә сугылып чыксын. Ташландык өйләр, яисә шушы арада гына сатылган йортлар юкмы. Аларга элек җен иләнәшсә, хәзер җыен карак, юлбасар җыелып ятучан.— Милиция башлыгы, саубуллашырга дип, егетләргә кулын сузды: — Кыскасы, аң булыгыз, бөркетләр, уйламыйча бер адым да ясамагыз. Бигрәк тә очып кунарга җыенсагыз. Югыйсә, бөркет түгел, суга төшкән тавык хәлендә калырсыз. Канатыгызны каерып, муеныгызны борырга да күп сорамаслар...

Берничә минуттан Мурашкинцев үзенең егетләре белән икенче извозчикны эзләүгә керешге, ә Зарипов төркеме Эт тыкрыгына юл тотты.

...Бүген иртәдән үк май кояшы бөтен дөньяны җылы, юмарт нурларына чумырган иде. Күк йөзе офыктан-офыкка кадәр зәп-зәңгәр; шау чәчәктә утырган алмагачлар, чияләр генә ерактан караганда җиңел ак болыт булып күренде. Әмма табигатьнең бу кадәр кинәнеп, ачылып көлүенә күз тиде, ахрысы. Төш авышканда Бишбалта ягыннан килеп чыккан кара болыт отыры зурая, киңәя башлады. Җете төсләр, якты бизәкләр кинәт төссезләнде сүнде, нindидер афәт килер дип куркып көткән төсле, барысы да йомылып, тынып калды. Озакламый күк касәсе болыт белән мөлдерәмә тулды. Әмма кысыр болыт булып чыкты бу, сирәк кенә булып тамчы төшкәләгән иде,— ничә көннәр инде күпереп, мамыкланып беткән тузан ул тамчыларны һап итте дә йотты. Кичкә таба офык Идел ягыннан бераз агарып, инде көмешсыман болытларга өретелде, көн ачыла башлады һәм... һич көтмәгәндә вак яңгыр сибәләргә тотынды.

— Вәт, нәгъләт,— дип сукранды Зарипов, авызын ачарга торган иске итегенә карап.— Инде узып киткән кебек иде бит... Ява!

Кыек астына кереп ышыкланмый булмады. «Караңгы төшкәләгәнче, халыкны әзрәк кымтырыклап карарга кирәк. Күрше хәлен күрше белми булмас...» — дип уйлады Хәсән. Алай да, егетләрнең берсен сакка калдырды:

— Уяу бул. Авызыңа чыпчык очып кермәсен,— дип шаяртты. Үзе, ике егетен алып, каршыдагы йортка юнәлде.

Инде ул тарафтан тәрәзә-ишек шакыган тавыш ишетелде. Хуҗа ишек ачарга ашыкмый. «Кем сез, нәрсә кирәк булды?» — дигән сораулар белән егетләрнең тәкатен корыта. Өстәвенә, колакка катырак та булып чыкты, каһәр, бөтен урамга ишетелерлек итеп кычкырырга туры килә.

Анархистларның яшерен очраша торган өе шул чукрак агайның күршесендә генә дип кем уйлаган.

Нәкъ шул мәлдә Флегонт Күзле Бүкән үз йомышы белән ишегалдына чыгып чүгәләгән иде. Күрше йортта: «Милициядән без! Ачыгыз!» — дип кычкыруларын ишетеп, үзенең балагына баса язды. Аннары, чалбарына ут капкандай сикереп торып, ишеккә ташланды.

— Мильтоннар!! — дип сөрән салды ул бусагадан ук.

Өйдәгеләр, өсләренә кайнар су сәккән тараканнар кебек, дәррәү шыбырдаша башладылар:

— Кайда? Кайда?! — дип өчесе дә аякка басты.

— Күрше йортта йөриләр...— Күзле Бүкән ян тәрәзәгә барып сыланды.— Әнә, әнә, койма аша башлары күренә. Хуҗа ишектән кертми әле үзләрен.

— Һәй, җен табагачы, өнемне алдың,— дип күзенең агы белән карады Тоська.— Безгә түгел бит алар, тинтәк.— Ул яңадан урынына барып, аякларын идәннән алмаган көе генә, мендәргә башын төртте.

Митька, тәрәзә янына үзе килеп, сак кына үрелеп карады. Хәлнең ни дәрәҗәдә җитдиләгән, алга таба нишләргә икәнен чамаларга тырыша иде ул.

Грязинюк белән Флегонт, кемнәндер әмер булган кебек, ишегалдына йөгерделәр. Күршедәниләр барганын икесе ике койма ярыгыннан күзәтә башлады. Хуҗа инде ишекне ачкан, тегеләр өйгә кереп киткән иде. Аларның чыкканын көтәргә туры килде. Дөрес, шул арада да Күзле Бүкән тик тормады — бер читкә барып чүгәләде, өстәвенә, авызына тәмәке капты.

Милиционерлар чыкканчы, шәт, биш минутлап вакыт узгандыр. Хуҗа, чынлап та, саңгырау икән, аның колагына да шактый каты кычкырып сөйлиләр иде:

— Алайса, күршедәге җимерек йортта кемдер яшәп ята, дисез?

— Әйе, шушы арада гына күренә башладылар,— дип раслады хуҗа.

— Безнең шалашны әйтә, үләт.— Грязинюкның тавышына боз салкыны чыккан иде.— Хәзер инде монда сөйрәлеп керәчәкләр. Ну каһәреңне! — Ул, кулын селтәп куйды да, өйгә йөгерде.

Күзле Бүкән дә атылып кергәч, Илья ишеккә эчтән бик салды. Үзе нигәдер чоланга кереп китте, анда шалдыр-шолдыр килеп актарына калды. Флегонт карават астыннан юл капчыгын тартып чыгарды, шуны кулына тоткан килеш, ишекле-түрле йөгерә башлады. Аннары кече якка чыгып, әле дә булса урын өстендә назланып яткан Тоськаны күреп алды.

— Әй син, Эт тыкрыгының прынцэссасы, койрык сөягеңә типкәнче, рәхим итеп, түшәгеңнән төш. Ильюха дуңгыз галиҗәнапләре монда эшче-крестьян милициясе хөрмәтенә кабул итү мәҗлесе уздырачак.

— Авызыңны төймәлә, алла бозавы! — Прынцэсса»ның күзләрендә яман ут кабынып сүнде. Икенче мизгелдә инде Тоська мендәр астыннан бәләкәй браунинг тартып чыгарган иде.— Югыйсә, тотып печәрмен,— дип кычкырды ул.

Өскә сикерергә торган зәһәр еланга тап булгандай, Флегонт каушап, агарынып калды: бу хатынның шундый усал-ямьсез төскә керүен ул беренче тапкыр күрә иде. «Күзен дә йоммас — атып үтерер... Имансыз... Кансыз...» — дип үзалдына сөйләнде Флегонт. Шулай да, ишектән кире чыгып китмәде, кырын-кырын чигенеп, ян тәрәзәгә таба авышты.

Бая игътибар итеп калган иде Флегонт: ул тәрәзәдән, сиздермичә генә, ишегалдына төшәргә була. «Сукыр як»ка. Аннан койма аша — күрше йортка. Һәм — син күр дә, мин күр — бәладән котылдың дигән сүз.

Сабадырев та, нәкъ шуны чамалап, ян тәрәзәнең кышкы рамын каерып

алырга азаплана иде.

Шул чакны тышкы ишекне каты итеп дөбердәттеләр. Барысы да шым булды. Сүз куешкандай, дүртесе дә әчтән бер төрле уйладылар: илаһым, болар әле өйдә юк икән дип кенә белсен иде милиция. Өйдә юклар дип белсен дә, китеп барсын иде.

Ләкин милиционерлар китәргә җыенмыйлар иде. Өйнең дәшмәве аларны ишегалдында әрле-бирле йөрергә, каралты-кура тирәсенә күз салырга мәҗбүр итте. Койма белән ике арада да кулына наган тоткан милиционер күренде.

— Тәрәзә янынннан кит,— диде Сабадырев, Күзле Бүкәнне читкә этеп.

Икесе ике якка басып, стенага сыендылар.

Милиционер тәрәзәгә килде, тарткалап карады — иске булса да, рамы нык тора иде әле. Тәрәзә төбендә бераз таптангач, иптәшләре янына атлады.

Милиционерлар, мөгаен, инде чыгып та киткән булырлар иде. Кайсысыдыр койма буендагы эзләргә, шунда ук әле һаман төтәп ятучы тәмәке төпчегенә игътибар итте. Бу — бая Күзле Бүкән ашыгудан ташлап калдырган тәмәке иде.

Ишеккә, капка ягындагы тәрәзәгә тагын да катырак, үҗәтләнеебрәк бәрә башладылар. Бусы инде аңлаган кешегә аңламаслык түгел иде: димәк, өйдә кеше барлыгын чамалап алды милиция.

Кычкырган, дөбердәткән тавышларга ышыкланып, Митька белән Флегонт кышкы рамны каерып алдылар, аннары җайге рамны ачып җибәреп, тәрәзәдән ашык-пошык чыга башладылар.

— Әнә теге чатка бас,— дип пышылдады Сабадырев, өйнең ишегалды ягындагы почмагына ымлады.— Без киткәнче ышыклап торырсың. Алай-болай булса — тавыш-тынсыз гына...

Тәрәзәгә, Тоськаны этеп, Грязинюк килеп тыгылды. Тегесе дә, бирешергә теләмичә, Ильяның чәченнән умырып тартты.

— Тукта, башта Тоська чыксын,— дип Митька араламаса, Грязинюкның тәмам башы-күзе әйләнгән иде.

Ике йорт арасындагы койма шактый биек булып чыкты. Митька белән Ильюха тиз генә ике тактаны каерып чыгардылар. Өченчесе ычкынырга теләми иде. Икәүләп көч белән этмкач кенә, иске кадак сурылып чыкты, әмма бик каты тавыш белән ыңгырашты. Койма ярыгына өчесе бергә ташланып, берсенә-берсе терсәк белән дә булыша торгач, өчесе берьюлы диярлек теге якта пәйда булдылар.

Нәкъ шул вакытны артта нәрсәдер дөпелдәп ауды, кемдер ухылдап куйды... Койма тавышын ишетепме, ян тәрәзәгә шакырга дипме, ишегалды ягыннан Күзле Бүкәннең каршысына ук бер милиционер килеп чыккан иде. Күзле Бүкән, әлбәттә, каушап калмады, аны искәртмәстән сукты да екты. Шуның белән төп вазифасы үтәлгәнгә санап, ул моннан тизрәк ычкыну чарасын күрде: тегеләр чыгып шылган койма ярыгына барып кысылды... Кинәт кенә ул үзен берьялгызы калган итеп тойды. Аның турында берәү дә уйламый. Митька белән Ильюха куяннан да җитезрәк чабалар, ә Флегонт... Йа алла, ул бөтенләй артта калган лабаса! Куркудан башын яка эченә яшергән анархист шул мәлдә үзе дә җитез куянга әверелде, атлаган саен абындыра һәм аякка ябыша торган шиндидер түтәлләр өстеннән йөгереп китте.

Йөгергән шәпкә колак төбендә генә мылтык шартлады, аннары кызган без белән җилкәгә бик каты итеп китереп кададылар төсле. Авыртудан күз аллары караңгыланды. Әмма Флегонт тешен кысып булса да түзде, болдыр артына барып ышыкланганчы туктамады.

Аңардан ун-унбиш адымда гына Илья белән Митька биек койма өстенә менеп басканнар да, Тоськаны кулыннан тотып тарталар. Тиздән алар өчәү. Флегонтның ярдәм сорап ялваруына игътибар да итмичә, капкага таба элдерттеләр. Капкадан чыгулары булды — урамда атыш кузгалды. Шунда ук өчесе дә бәрелә-сугыла ишегалдына кире борылып керделәр. Митька капканы бикли калды, Ильюха исә, беләгенә ябышкан Тоськаны да өстерәп,

утын әрдәнәсе артына йөгерде.

Ул арада Күзле Бүкән болдыр стенасына сөяп куйган баскычны күреп алды, башына бик акыллы фикер килеп, тиз генә өскә үрмәләде. Түбәгә менеп җиткәч кенә, аста, инде бик якында, үзен куа килүче милиционерны күрде: атты — тидерә алмады. Милиционер, түтәл арасына сузылып ятып, шарт-шорт ата башлады. Аңа карап торырга вакыт юк иде.— Флегонт йөгереп килеп сикерде: болдыр түбәсеннән коймага кадәр бер метр чамасы ара булыр,— ул, шулай итеп, биек койманың теге ягына, куршe йортның түтәлләре өстенә лып итеп очып төште. Тиз генә торып, ике-өч сикерүдә утын әрдәнәсенә барып җитте. Анда инде беркем дә юк, алма бакчасының аргы башына җиткән анархистларның җилкәләре генә күренеп калды.

«Ничек тә алардан аерылмаска»,— дип уйлады Флегонт. Шушы уй аякларына дәрман бирде. Бераздан инде ул Тоськаны куып җитте. Яшь хатын, сыер кебек, аякларын ике яктан алдырып чаба, шуңа күрә адымнары бик үрчеми, ә үзе авыр сулый иде.

— Аллага шөкер, котылдык! — дип кычкырды Күзле Бүкән йөгергән уңайга. Тоськаның күңелен күтәрәсе килә иде аның.— Мин инде мильтон бугазга басты дип торам. Җилкәмне ваттылар пуля белән, каһәр. Ну үзем дә бирсен...

Ул сүзен әйтеп бетерә алмады, арттан коры чыбык сынган шикелле генә шартлау ишетелде. Күзле Бүкән, аяк чалып еккан кебек, Тоськаның каршысына ук, юеш чирәм өстенә барып төште.

— Туганнар! — дип еламсырап кычкырды Флегонт.— Ташламагыз! Аякны бетерделәр...

Әүвәл Тоська, аннары Митька белән Ильюха да теләр-теләмәс кенә туктап калдылар. Өчесе дә аптырашып кире борылып килде.

— Әнә алар!..— Грязинюк кичке эңгергә урала башлаган алма бакчасы ягына кул изәде.— Әзгә басып киләләр!

Анархистларга бу мәлдә бер нәрсә бик ачык иде: яралыны өстерәп качу мөмкин түгел. Флегонтны калдырып китәргә дә ярамый: бик күп белә, чека аны кәҗә урынына савачак.

— Туганнар! — анархист, тезләнеп, ике кулын да иптәшләренә таба сузды.— Сез юл ала төшкәнче, мин үземнең гәүдәм белән каплап тордым. Бәладән чыгарыштым. Инде сезнең чира...

Аның сүзе шунда киселде. Тоська, браунигын суырып алып, Күзле Бүкәннең маңгаена төрәп атты.

— Авыр туфрагың... авыр туфрагың...— дип ишетелер-ишетелмәс кенә кабатлады Тоська, яңадан абына-сөртенә йөгергәндә. «...җиңел булсын» дип әйтә алмады. Баш өстеннән генә сызгырган пулялар зиһенне чуалта, телне бәйли иде.

Алар кая таба йөгергәннәрен үзләре дә чамалый алмадылар: ниндидер тыкрыклар, чокырлар, куаклыклар артта калды; күпме вакыт үтүе дә сизелмәде. Инде тирә-юньдә караңгылык куерды, аяк асты бөтенләй күренми башлады, әле берсе, әле икенчесе егыла, аннары тора да йөгерә... Милициядән котылуларына тәмам ышанып җиткәч кенә, ниһаять, өчесе дә, хәлдән таеп, юеш чирәм өстенә сузылдылар.

— Гомеремдә бу хәтле йөгергәнем булмады,— диде Тоська, авыр мышный-мышный.— Тез асларым пешеп чыкты...

Каяндыр ерактан трамвай кыңгыравына охшаган тавыш ишетелеп китте.

— Трамвай йөри ахрысы бу тирәдә...— Шылт иткән тавышка да сискәнеп башын боргалаган Ильюха урыныннан сикереп торды.— Бик җәелеп утырмагыз әле, әй. Дөм караңгы булганчы шунда таба юл тотыйк,— диде.

Сабадырев башын чайкады:

— Андый юләрлекне эшләргә ярамый.— Үз генә тынып торды да өстәде: — Милиция хәзер безне шул тирәдә көтеп алачак. Безнең исән-сау котылу — аларның баягы хатасы. Хәзер ул хатаны аңлап, төзәтергә тырышачаклар.

Сабадырев эчтән генә үз-үзенә гаҗәпләнеп, сокланып куйды: менә шундый, башны ташка бәрердәй чакта ул һәрвакыт дөрес карар кабул итә. Шунда әллә ничек кенә зиһене ачылып китүчән аның. Дөрес, кайчакта салкын акыл дер-дер иткән куян йөрәкне җиңә алмый... Андый чакта йөгерек аякларга рәхмәт,— уч төбенә йомарланган җанны алар коткара.

Тоська белән Ильюха да акыллы киңәшкә колак салмый булдыра алмадылар: трамвайга утырмаска карар иттеләр.

Мондый еламсырап торган көнне гадәттә извозчиклар аз була һәм аларның кадере дә шуңа бәрабәр арта: урамда караңгырак, һава-көн начаррак булган саен, бәяне югарырак куялар. Шуңа да карамастан, Грязинюк беренче олаучы белән үк уртак телне тиз тапты. Әле бит аның барасы юлы да шактый ерак: кичәге көнне ул бушка уздырмаган, Үтәмешевның кунак йортында үзенә бер номер килешеп кайткан иде. Дөрес, Казанда хәзер андый мөсафирханә юк,— яңа власть тартып алган,— әмма Үтәмешев үзенә торак өчен дип берничә бүлмәсен саклап калган икән. Менә шул бүлмәләргә ул, шәп кенә бәягә, кунакларны үзе сайлап керткәли, ди. Кеше-кара күзенә чалынасы килмәгән һәм дә янчыгы авыр булган кунакларны...

— Тоська өчен борчылма. Мин аңа да бер урын сөйләшеп кайттым,— диде Ильюха, ничектер кыюсызланып.

Әйе, Сабадырев хатынын барыбер үзе белән ала алмый — Грязинюк моны яхшы чамалый.

— Без сине дә чакырыр идек, Митенька,— дигән булды Тоська оялмыйча да.— Тик, Ильюха әйтә, бүтән урын юк шул, ди...

«Бертуган абыйсы янына барамыни... Мине тишек кәвеш урынына да күрми. Елан белән баканың теле бер,— дип уйлады хәтере калган Митя. Хатынының Күзле Букәнне терәп аткан чагы күз алдына килде дә, тәне куырылып куйды.— Мине дә шулай шапылдатырга мөмкин бит ул елан бервакыт. Әйдә, ник җәһәннәмгә олакмый шул Ильюшасы белән!»

Шулай да, тегеләр читән арбага утырып кузгалып киткәндә бер ялгызы басып калгач, Сабадыревның суларга һавасы беткәндәй булды — ачу, үч һәм көнчелек буып алды аны. «Икегезне бер мунчага җибәрәм»,— дип калган иде бит атакай...

Кинәт артларыннан куып тотасы, Махно бүләк иткән чибәр, кайнар хатынны үзенә кайтарып аласы килде. Түзә алмыйча, тарантас эзеннән йөгерде, ләкин бик тиз хәлдән таеп, тиргә батып туктады. Шунда ук пистолетын алып, ераклаша барган кара шәүләләргә төбәде. Ярый әле, вакытында аңына килде: тидерүен тидерә алмас, ә үзен харап итәр иде. Милиция каядыр якында гына иснәнеп йөри, хәзер килеп җитеп, якадан алыр, ә качарлык рәт-чама калмаган иде инде.

Янәшәсендә үк торган телеграф баганасын ике куллап кочаклап алды Сабадырев, кайнар маңгае белән салкын, юеш бүрәнәгә сыенды. Тешләрен шыгырдатып, яралы бармагын баганага бәрде... (Милиция пулясы бая аның сул кулындагы бер бармагын, пәке белән кырып алгандай, өзеп ташлаган иде). Авыртудан акырып җибәрде, күзеннән утлар күренгәндәй булды, тезләре сыгылып куйды. Әмма йөрәк әрнүен хәтта шундый кыргый авырту да баса алмады...

Извозчик яллап, Азман-Мусин янына — «ходай биргән йорт»ка кайтып барганда, дөньядагы иң әшәке сүгенү сүзләре белән эченнән генә барысын да рәттән сүгеп чыкты Митька: бу ят шәһәрне һәм инде ике тапкыр куышып йөргән милиционерларны да, әрсез Ильюханы һәм үзенең туя белмәгән хатынын да...

Митька андый-мондый мәҗараларсыз гына кайтып җитте. Әмма ул кичне тагын да бер каза күрәсе булган икән әле.

Мусинны да өйдә туры китермәгәч, эч пошканнан гына, үзенең күптәннән кузгатмаган кием-салымын, бүтән әйберләрен таратып салган иде. Караса — яшерелгән хәзинәләр планы юк! Махно атакайның үз куллары белән биреп җибәргән «манускрипты»! Яшен суккандай, җаны-тәне белән дер калтырап куйды Митька. Тынычланырга, өметен бөтенләй өзмәскә

теләп, чүпрәк-чапрагын берәм-берәм аралады, селкеп-селкеп карады. Юк, беркайда да юк теге кәгазь!.. Митька әсселе-суыклы булып калтыранды, маңгаеннан елга булып тир акты, күлмәге манма суга чумып аркасына ябышты. Авыр юеш киез итек белән китереп органдай, башы гүләп торды.

Апанаевтан калган серле документ капчыкның төбендә үк булырга тиеш иде. Яхшы хәтерли Митька: ул аны Казан буенча юл күрсәткеч китап эченә тыгып куйды. Китап үз урынында, ә планнан җилләр искән. Болай гына югалырга һич мөмкин түгел бит ул! Димәк, чәлдергәннәр. Кем эше булыр бу?.. Хәер, баш ватып торасы да юк,— өчесенең берсе, әлбәттә: йә Грязнюк, йә Күзле Букән, яисә хәләл Тоськасы. Аларның берсенә дә ышанып булмый. Теләсә кайсысы кеше малына кул сузарга гына тора иде бит. Барыннан да битрәк — Ильюха мөртәт. Юккамыни, баржада чакта ук шул сары кәгазь кисәген нинди кыйммәт бәягә сатып алырга маташты. Шул кабихның гына эшлеге бу, бүтән беркемнеке дә түгел!..

Турысын әйткәндә, планның башка берәү кулында булуын теләми дә, моны күз алдына китерергә курка да иде Митька. Әгәр, әйтик, Күзле Букән эләктергән булса — хәзер ул документ милиция өстәлендә ятарга тиеш. Ул чакта бөтен хыяллар таш идәнгә төшкән бәллүр касә сыман челпәрәмә килә.

Батып баручы кеше саламга ябышкан төсле, Митька үз-үзен алдап булса да, тынычланырга тырышты. Мильтоннар кулына төшсә ни, дип сөйләнде ул үзалдына,— хәзер аларның кайгысы шул гынамы, иске кәгазьләр белән маташып тора торган чакмы?! Әле бит анда нинди хикмәт төшерелгәнен беләсе, аңлыйсы бар. Кыскасы, теләсә кемнең теше үтәрлек эш түгел!.. Аннары Митьканың күңелен тагын бер юаныч җылытып тора. Әлеге табышмаклы планны ул бөтен нечкәлекләре белән хәтеренә сеңдереп калган иде: җиде төн уртасында уятып сорасыннар — ап-ак кәгазьгә нәкъ булганынча төшереп бирә ала.

Киселгән бармагы үзәк өзгеч сызлап, соңгы хәлен алса да, Сабадырев, читлектәге җанвар кебек, янә ишекле-түрле йөри, бәргәләнә башлады. Планның Ильюха кулында булуы барыбер шәп түгел, дип, һаман шул ук тәлинкәне әйләндерде. Үзе югында әйберләрен Күзле Букәнгә ышандырып калдыра иде бит, сакларга. Бүтәннәргә ышанмаганны аңа ышана иде. Әллә соң ул алла бозавы да, акчага-алтынга кызыгып, урлап саттымы икән Ильяга?..

Күңелендәге шундый авыр уйлар, Эт тыкрыгында үткәргән тынгысыз көннәр Митьканың дәртен, дәрманын шактый сүрелдерде. Менә хәзер бүлмәдә әйберләре таралып-чәчелеп калды, ишеге бикләнмәгән, уты да сүндерелмәгән... Ә ул — хәлсезләнеп, яңагын мендәргә куйган иде — йокы, төпсез сазлык кебек, башы-аягы белән суырып кына алды.

* * *

Митька Сабадырев һәм аның компаниясен тагын бер тапкыр качыру милиция хезмәткәрләренең мин-минлегенә шактый нык тиде. Әмма көн арты көн үтте, үртәлеп-үҗәтләнеп эзләүдән бер нәтиҗәгә дә ирешә алмадылар. Шайка, суга төшкән балта кебек, күздән югалды.

Ниһаять, шактый азап белән булса да, икенче извозчикны таптылар. Ул сүзен сүзгә ялгап әйтә алмый торган бәндә булып чыкты. Шулай да, Мусин белән «кунак егете»н тасвирлавы нәкъ Җамалетдин абзыйныкына туры килә иде. Димәк, әлеге ике бандитны Евангелистлар урамына хәтле алып баруы да хак булырга тиеш.

Милиция идарәсе башлыгы Гофштадт боерыгы белән, Евангелистлар урамы тирәсендә тәүлек буена күзәтү оештырылды. Ләкин моның юкны бушка авыштыру гына икәнлеге аңлашылды: «Азман» да, аның ахирләре дә үз аяклары белән капкынга килеп керергә ашыкмыйлар иде.

Атна ахырында Чистай төрмәсеннән Мусинның фоторәсемен җибәр-

деләр. Соңгы тапкырында ул анда утырып чыккан икән. Гофштадт, рәсемне күбәйтеп, шәһәрнең бөтен милиция бүлекләренә таратырга кушты.

Менә әле Мусин сурәтенең бер нөсхәсе Григорий Соломонович өстәлендә, ниндидер газета өстендә ята. Газетаның фото белән капланмаган өлешендә берничә юл чекерәеп, күзгә ташланып тора:

«Цивильское Подворье» номерлары руханилар оешмасына карагаилыктан, шәһәр хуҗалык Советы аларны халык файдасына конфискацияләргә карар итте...

Гофштадтның күзләре дә укып үтте ул юлларны, әмма мәгънәсе аңына барып җитмәде: башында катлаулы уйлар өермәсе дулый иде. Ә күз янә шул эздән йөгерде:

«Цивильское Подворье» номерлары...

Ниһаять, баш миенең кайсыдыр буразнасына кереп кысылды: «Цивильское... Цивильское...» — дип үзенекен тукып тора.

— Чү, ул номерлар Евангелистлар урамыннан ерак түгел ләбаса! — дип үз-үзенә сөйләнде Гофштадт һәм шунда ук телефонга үрелде. Аннары газетаны да әйләндереп карады: «Знамя революции» нең бүгенге саны икән.

Биш минуттан инде милиция башлыгы каршында Мурашкинцев басып тора — кызарган, бүртенгән; хәлне үзенчә аңлатырга, акланырга тырыша иде:

— Григорий Соломонович... Шәһәрдә андый мөсафирханә барлыгын кайдан беләсең... Коммуналь хуҗалык карамагында булмагач...

— Их сезне...— дип башын чайкады Гофштадт.— Кунак егетләре поп чапаны астында яталар, ди, әнә. Җылыда, корыда. Сездән, бездән көлеп.

— Булмас ла! — диде Мурашкинцев, ышанырга теләмичә.— «Ходай тәгалә йорты» нда җиде ятка кем сыену урыны бирсен? Үзләренчә тәртип хисап бар ич инде аларда да.

— Ә нинди заманда яшәгәнебезне онытып җибәрдеңме, Лукич? — Гофштадт ашыгып тәмәке кабызды.— Башны эшләтергә кирәк бераз. Югыйсә, алар безне шулай адым саен кәкре каенга терәтеп калдырачаклар. Аңлыйсыңмы: соңгы вакытларда чиркәү «җиде ят» дип борын җыермый...

Җинаятьче козгыннар үзләре бик җайлы урын табып оя корган булсалар да, шәһәр хуҗалык Советының карары һәм бүгенге газетадагы белдерү аларны куркытып очырган, әлбәттә.

Григорий Соломонович моны яхшы чамалый һәм оттыруны авыр кичерә иде. Шуңа да, ахрысы, тавышына кырыслык чыгарып әйтте:

— Әйдә, бөркет, кешеләреңне ал да оч шул тарафка. Түйдан соң дөмбергә барып кара әле тагын бер. Һич югы үзеңә сабак булыр,— диде.

...Ике катлы борынгы кирпеч йорт Мурашкинцев һәм аның кешеләрен колач җәеп каршы алмады. Кызганычка каршы, Гофштадт юраганнар юш килде: коридор һәм бүлмәләрдә җан әсәре юк иде. Ләкин монда барыбер ниндидер хуҗа булырга тиеш бит инде! Буявы купкан агач идәнгә дагалы итекләре белән сак кына басарга тырышып, Мурашкинцев коридор буйлап китте. Башкалардан кайсыдыр ягы белән аерылып торган бер ишеккә күзе төште. Шакыды. Җавап кайтаручы булмагач, көч белән тартып җибәргән иде,— авыр имән ишек гаҗәп җиңеллек белән ачылып китте. Шундый ук озынча бүлмә, өстәлдән кала җиһаз юк; ә өстәл өстендә, иллә тәкәббер кыяфәт белән, купшы-йөнтәс койрыклы зур кара мәче генә утыра иде.

— А-а... Үзе!..— дип мәче каршында шамакайланды бер яшь милиционер.— Каратун Иваныч монда көтә-көтә зар булган, ә без тагын кемнедер эзләп йөрибез.

Каратун үзенең дәрәҗәсен бик белеп утыра, һәрхәлдә, чакырылмаган кунаклар алдында йөз суын түгәргә — итекләренә килеп сырпаланырга һич тә җыенмый иде.

Ниндидер илаһи көчләр тәэсир иткән кебек, тавыш-тынсыз гына урта ишек ачылды. Җил өрсә очып китәрдәй чандыр гәүдәле, ап-ак чәчле, ап-ак сакаллы бер карт килеп чыкты. Аның сөйләвеннән шул аңлашылды: конфискация турындагы хәбәрне кичә генә алганнар, бирелә сыену урыны тап-

кан кешеләр бүген үк кайсы кая таралышып беткән. Варсанофий атакай үзе митрополит Иаков янына юл тоткан булса кирәк. Ә Владыка Иаков бу көннәрдә Кабан күле буендагы Әрхәрәй дачаларында яши икән.

Колакка саграк булса да, картның күзләрендә нур сүнмәгән, зиһене дә шактый ачык күренә. Мусин фоторәсеменә бер күз салу белән, шунда ук җитдиләнеп китте, тешсез авызын беркавым чәпелдәтеп торгач:

— Ул алла колы монда яшәде. Икенче катта, баскыч янында,— диде. Кулы белән ишарәләп, каядыр өскә күрсәтте.— Соңгы көннәрдә аның белән бер хөҗрәдә нindидер ир-ат та күренде. Аларның икесе дә рухани зат түгел иде, ахрысы. Миңа шулай тоелды.

— Алайса, ничек монда килеп эләктеләр икән алар? Мурашкинцевның дулкынланудан тамагы кипте, тавышы карлыгып чыкты.— Кем урнаштырды ул ирне?

Карт бу җәһәттән мәгълүматсыз иде.

— Сез миңа карамагыз, балалар,— диде ул акланган сыман.— Бөтенесе качып беткәч кенә ихтыярсыздан хуҗа булып калдым. Ә болай төнге каравылчымын. Җил иркенә ташлап калдырып булмый бит.

Мусин яшәгән бүлмәне карадылар. Тимер карават астында аунап яткан ниндидер журналдан кала берни дә күренмәде. Яшь милиционер итек очы белән генә эләктереп тартып чыгарды журналны. «Воскресный день» дигән, атна саен чыга торган дини басма иде бу. Бик күптәнге — 1910 елны ук басылган 40 нчы саны. Беренче битендә — Казан кремле рәсеме. «161565 кешесе булган Казан шәһәре — Идел буеның башкаласы...» — дип укыды Мурашкинцев. Әллә бу сан безнең шәһәргә багышланган инде дип, кызыксына калды, бүтән битләрен дә ачып-ачып карады. Шәһәрнең сурәтле планын бик матур итеп төшергәннәр иде. Казан суы, Кабан күлләре, чиркәүләр, Кремль... Сөембикә манарасының очыннан төрле тарафка беленер-беленмәс кенә сызыклар сузылган. Биш сызык. Берсе Әрхәрәй дачаларына, икенчесе — Урта Кабанга, өченчесе элек Елантау монастыре торган төшкә, дүртенчесе Казан суы аша салынган агач күпергә барып тоташа. Бишенче сызык аска ук төшеп киткән. Анда, симез хәрефләр белән, журналны чыгаручы адресы басылган: «Мәскәү, Мясницкая урамы, Николай чиркәве протоиреенең квартиры...» Нәрсәне аңлата икән бу сызыклар? — дип уйлап куйды Мурашкинцев һәм шул чакта гына аларның кулдан сызылган булуын абайлап алды. Кемдер эч пошканнан гына карандаш белән уйнап утырганмы соң?..

Көчен-җегәрен кая куярга белмәгән яшь милиционер килеп кысылды:

— Нәрсә, Федор Лукич, шәрә кыз рәсеме бармы әллә анда? Син карт кеше инде, безгә күрсәт,— дип, башлыгының җилкәсе аша үрелеп карады. Шәһәр панорамасы гына икәнен күреп, берочтан теге сызыкларга да игътибар итеп: — Оһо, мәхәббәткә илтүче юллар планы икән! — дип теләнә салынды.

— Чыннан да, бу сызыкларда бер-бер хикмәт булуы бар бит,— дигән уй сукты Мурашкинцевның башына. Шунда ук журналны кесәсенә тыкты.

Бүтән бүлмәләрне, подвал-чардакларны, Варсанофий атакай яшәгән бәләкәй өйне дә караштырдылар. Шәһәрне дошман явы алыр алдыннан нинди ыгы-зыгы купса, монда да нәкъ шулай — ашык-пошык җыенып качу эзләре калган иде: асты-өскә әйләнгән иске тумбочкалар, сынык аягын өскә күтәреп яткан өстәл-урындыклар...

Һәртөрле чүп-чарда казынуның мәгънәсез икәнлеге ачык. Мусинны эзләүне дәвам итәргә кирәк, дип уйлады Мурашкинцев. Нечкә генә булса да җеп очы эләкте кебек, хәзер бөтен өмет — Варсанофий атакайда. Каравылчы карт та әйтеп тора: бу йортка бүтән диндәге кешенең аяк басканы юк иде, ди; сез эзләп килгән адәм мөселман булгач, атакайның ризалыгыннан башка мотлак урнаша алмас иде, атакай ул мәсьәләдә һәрвакыт бик каты куллы, ди. Нишләп әле үзенә-үзе каршы барган Варсанофий? Димәк: йә Мусин аны бөтен гөнаһлары белән бергә сатып алган, йә аларның электән танышлыгы булган... Йә әлеге бандитның ни өчендер попка кирәге чыккан. Кайсы яктан

гына карасаң да, алар бер-берсенә бәйләнгән булырга охшый.

Мурашкинцев бүлмәләрдә казынуны туктатырга кушты.

— Элек заманда бөтен юллар Римга илткән булса, хәзер безгә митрополит Иаков хозурына барудан кала башка чара юк.— диде.— Григорий Соломонович әйтмешли, шул тарафка очыйк, бөркетләр. Варсанофий атакай Әрхәрәй дачаларында озак кызынып ятмас. Ул эш кешесе, митрополиттан фатиха алырга гына киткән. Ә бәлки Азман белән «кунак егете»н дә, ике иңенә ике фәрештә итеп, үзенә ияртеп йөридер?..

Барысы да тиз генә чыгып, ачык түбәле машинага төялделәр. Яшь милиционер рульгә утырды:

— Әрхәрәй дачаларына күптән барасым килеп йөри иде. Җае чыкты бит, әй! — дип сөйләнә-сөйләнә, машинаны кабызды.

«Тукта, митрополитның шәһәрдән читтәге резиденциясе — элеккеге Воскресенский монастыре иде түгелме соң? Нишләп әле ул Әрхәрәй дачаларына барып чыккан? Бәлки, каравылчы карт буташтырадыр? — Мурашкинцев кинәт икеләнә калды.— Әллә журналны юри калдырып киткәннәрме?.. Җеп очы дигәнең үлем элмәге булып чыкса?..» — дип уйланды ул.

Күптән түгел генә берничә милиционер шулай капкынга эләккән иде бит. Алар да хәтәр җинаятьче артыннан куа чыкканнар, ә теге, юри, белеп-беленмәс кенә эз калдырып, бер монастырьга кереп качкан. Ә «ходай йорты»нда милиционерларны тозак-засада һәм газаплы үлем көткән.

«Әрхәрәй дачалары да кеше-кара күзеннән читтә; кем белә, анда әллә нинди контралар оялап ятадыр әле,— дип фикер йөртте Мурашкинцев.— Сөембикә манарасыннан шул тарафка сузылган җеп тә очраклы булмаска мөмкин.»

Беркөнне Эт тыкрыгы тирәсендә үз иптәшләре үк атып үтергән җинаятьче исенә төште. Аның кесәсеннән сәер генә бер нәрсә килеп чыккан иде — саргаеп беткән кәгазьгә төшерелгән Казан картасы. Анда да шул рәвешлерәк, Сөембикә манарасының очыннан төрле якка таба сызыклар сузылып китә иде. Сызыклар күбрәк булгандыр кебек, әмма берсе, журналдагыча ук, Әрхәрәй дачаларына барып тоташкан иде. «Ничек онытып торам соң әле мин моны?!» — дип маңгаена сугып куйды Мурашкинцев. Инде бер нәрсә ачык: журналга карандаш белән сызгалаган адәм теге үлгән бандит кесәсендәге карта белән таныш булган; димәк, алар, бүреләр кебек, бер үк эздән йөриләр һәм нәрсәдер эзлиләр. Нәрсәдер эзлиләр...

— Федор Лукич, килеп җиттек ләбаса! — дигән тавышка сискәнеп, Мурашкинцев башын күтәрде. Ах, наян шофер, «дөньяңны онытма» дип, кузгалып китмәс борын ничек төрттерә.

Мурашкинцев уч төбе белән аның күн тужуркасына шапылдатты:

— Әйдә, бөркет, бас газга, ку тарантасыңны: миңа тизрәк телефон кирәк!

## V. Канлы эзләр

Әлегәчә йортлар, кибетләр басу белән мәшгуль булган Азман-Мусин чын-чынлап азды. Уголовный милиция генә түгел, чекистлар да игътибар итсен әле дип, юри тырыша диярсең. Соңгы вакытларда йә тегендә, йә монда аның эзе кала башлады. Гофштадт күбәйтеп тараткан сурәтне кулына алу белән, Шамил Измайлов та чак кына кычкырып җибәрмәде: бу бит — Чистай базарында ук аның белән чәкәләшкән, аннары Миргазиянов Самат янында очрашкач, үзенең дустын — Санька-анархистны атып качкан бандит! Инде бу көннәрдә Кәҗә бистәсенең Амур урамында һәм Эт тыкрыгында килеп чыккан атышларда да аның кулы уйнаган, имеш...

Уголовник Мусин, Константин Балабанов, Санька-анархист, бүтән кеше кулы белән утлы күмер чүпләүче Дардиев, хәтта контрразведка башлыгы Кузьмин... Болар барысы да ничектер үзара бәйләнгәндер шикелле, «немец агенты Перинов-Карачкы» дигән кара йомгакка алар бик нечкә

генә җепләр белән булса да килеп ялганалар төсле. Һәрхәлдә, Шамилнең күңелендә шундый сизену көчәйгәннән-көчәя бара иде.

Бүген ул көне буена элеккеге губерна жандармерия идарәсе архивларында казынды. Тау-тау булып торган папкаларны актара торгач, кызыклы гына бер документ килеп чыкты. Майланып, бөгәрләнеп беткән ул кәгазь кисәге белән кемдер пычрак өстәл өстен сөрткән кебек иде.

Донесениене Костя Балабановның яшерен фәхешханәсендә «кунак каршылап торучы» бер агент язган. «Тфу» кушаматлы бу шымчының бүтән кәгазьләре дә очраштырды. Әмма алары болай ук игътибарга лаек түгел иде.

Шамил, бөтен нечкәлекләрен хәтерләп калу өчен, язуга тагын бер күз йөртеп чыкты. Тәҗрибәле шымчы булган «Тфу» үз эшенә бик җитди караган, күргән-белгәнен төкми-чәчми язган:

*«...Кичә 31 декабрь көнне «Эти» йортында яңа ел каршылаучы кунакларның берсе бик шикле күренде. Үзен Михаил дип атаган ул адәм чибәр Флора белән кич утырырга сорады. Аның тәмам сәрхүш икәнлегени күреп, «Эти» бәяне күтәрә башлады. Мишель: «Хакыннан тормыйм, товарың гына шәп булсын»,— диде. Балабанов инглиз акчасы белән 50 фунт стерлинг сорады. Тегесе кесәсеннән чыгарды да бирде.*

*Аннары мин йозак тишегеннән күреп тордым: Флорага да шундый ук «стерлинг» эләкте. Михаил аны үзенә кияүгә чыгарга кыстады. Акча бездә бер букча, дип мактанды.*

*Властька каршы сүз сөйләмәде. Киресенчә, өстәл янында утырганда Николай Икенче атакай белән мәрхүм Григорий Распутинны мактады. Кайзер Вильгельмны телгә алып, ул — рус патшасына кардәш тиешле, диде. Мин колакны торгызып тыңладым: безнең патша дип түгел, р у с патшасы, дип әйтте. Сөйләшкәндә немец сүзләрен дә кыстыргалый. Флора белән юанганда исә әллә ничә немец сүзен бергә кушып әйтүен ишетеп калдым... Флора аны электән белә, ахрысы. Күрү белән: «Мишель!» — дип, кочаклап алды.*

*Әлеге адәмнең фамилиясен «Эти»дән сорашып белдем — Тряпкин икән, әгәр кирәксә — килеш-килбәтен дә тасвирлап бирермен.*

*1917 елның 1 гыйнвары.*

*Тфу.»*

Шымчының немец сүзләренә игътибар итүе кызыклы бит, дип уйлады Шамил. Шулай да анысы ул кадәр әһәмиятле түгел, курыкканга куш күренүе дә бар. Ә менә инглиз акчасының Казанга хәтле килеп җитүе һәм бер җилбәзәк хатын өчен кушучлап таратылуы — бусы сәеррәк. Әлеге Мишельнең ниндидер бәйләнешләре бар, димәк, чит ил кешеләре белән... Мондый бай клиентны Балабанов та кармактан ычкындырмаска тырышкандыр. Чибәр Флораның итәк җиле белән ымсындыра алмаса, бүтән юлларын табар ул бандит, һичшиксез.

Әлегәчә Константин Балабановның эзенә төшә алганнары юк. Чибәр Флора, мәхәббәтен сатып, хәзер кайларда йөри икән?.. Тукта, ә Михаил... Мишель... Флора... Теге чакта Алафузов кампаниясе белән Чистайда типтереп киткән кунаклар түгелме соң икесе дә?.. Димәк, полковник Кузнецов үлеменең дә шаһитлары?! Әгәр чынлап та шулар булса... Ә нигә турыдан-туры Тряпкинның үзен эзләп карамаска?.. Иске танышлык хакына?..

Шәһәр милиция идарәсендә Тряпкин Михаил Федоровичның кайда торганын бик тиз әйтеп бирделәр. «Кызыл Чүгендер урамы, 23...» дип кабатлады Шамил, адресның җиңел табылуына сәерсенә төшеп. Биге нык түгел икән — гадәттә, ул сандык бүш янсә ике төпле булучан бит...

Тряпкин яшәгән урамны эзләп чыкканда көн инде кичкә авышкан, вак кына яңгыр сибәли иде. Күк йөзен тоташ болыт каплап алганга күрә, бик тиз караңгы төште. Яңгыр да көчәйгәннән-көчәя барып, калай түбәләргә шыбыр-шыбыр бәрә башлады. Кире борылырга инде соң иде: Шамил, кепкасын батырыбрак киде дә, караңгы урам буйлап алга таба йөгерде. Фонарь заты юк, шуңа күрә йорт номерлары, яңгыр белән юылган кебек, текәлеп караганда да күренми. Берән-сәрән каршыга килүчеләр исә, юеш койма-

ларга сыена төшеп, як-якка карана-карана гына атлыйлар. Шамил бер-икесеннән юл сорап карады,— ишетмәмешкә салышып, тизрәк китәргә ашыктылар.

«Кызыл Чөгендер урамы, 23» — такта белән тышланган ике катлы агач йорт булып чыкты. Коридордан сызык кына булып яктылык төшсә дә, тыштан керү ишеге бикле иде. Звоногы кайда икән моның, дип торганда, бауга асып куелган фарфор тотканы абайлап алды Шамил. Шуны тартсаң, эчтә кыңгырау чылтырый торгандыр, мөгаен... Тиздән теге якта кемнеңдер ишеге шыгырдап ачылды, ашыкмыйча гына бирегә таба килүче башмаклар лыштырдавы ишетелде.

— Кем йөри анда? — диде йокылы-уяулы ир-ат тавышы.

— Тряпкин... Михаил Тимофеич... өйдә микән? — дип каушап сорады Шамил.

Ишек ачылды. Чылбыр сөяме хәтле генә булып.

— Ни йомыш? Нәрсә булды?

— Миңа иптәш Тряпкин...

— Кемгә кирәгем чыкты?

Шунда гына Мишельне танып алды егет. Бер ел эчендә ул шактый нык үзгәргән: йөзенә карт чырай кергән, күз төпләре капчыкланган, икенче ияк үскән. Теге чактагы җегетләрчә төсе булмаган да кебек.

Измайлов мандат тоткан кулын ишек ярыгы аша сузды:

— Чекадан мин. Сүз бар,— диде.

— Шул гына җитмәгән иде...— дип мыгырданды хуҗа. Ачаргамы-юкмы дип икеләнеп торгандай, бик иренеп кенә чылбырны ычкындырды.

Киң коридор буйлап аргы башка хәтле атладылар. Тряпкин кубалакланган сары буяулы ишек каршында туктап калды. Кулы белән ишарә ясады:

— Узыгыз, әйдә.

Күн белән тышланган шәп диванга утырышкач, чекистның йөзенә текәлеп карады Тряпкин:

— Кайдадыр очрашканыбыз бар сезнең белән,— диде. Күренеп тора: ашыга-ашыга хәтер сандыгын актара иде ул. Әмма барыбер тәгаен генә искә төшерә алмады, ахрысы, янә битараф төскә кереп:

— Хуш... Инде ни әйтерсез? — диде.

Измайлов үгезне мөгезеннән алырга булды. Кинәт кенә:

— Алафузов кайда хәзер? — дип сорады.

— Валериймы?

— Шул үзе.

— Ә-ә... Сезне ул кызыксындырамыни...— дип, җилкәсеннән авыр йөк төшкәндәй, җиңел сулап куйды хуҗа.

Чекист турыдан җавап бирмәде:

— Күптән беләсем килеп йөри,— дип кенә әйтте.

— Франциягә барып элгәшкән, дип ишеттем мин аны. Йорт-җирләрен, завод-фабрикаларын ташлап сызган иде. Янчыгын гына алып. Инде Россиядәге фетнә басылганын көтеп ята бугай.

— Фетнә түгел, революция дип атала бу, иптәш Тряпкин.

— Әй, тел нияләшә алмый һаман...— Тряпкин, ашыгып, хатасын төзәтте.— Сезнең белән безгә революция булса да, фабрикант Алафузов өчен фетнә инде. Дөньясының асты-өскә килде бит аның.

— Франциягә үк барып җитәрлек булгач, җәяүләп чыгып качмагандыр әле?

— Юк, билгеле. Ике палубалы пароходы һәрвакыт пух-пух килеп утыра иде, кайнап чыккан самавыр төсле. Өстәвенә, шактый җитез нәрсә — агымга каршы да сәгатенә егерме чакрымнан күбрәкне колачлый. Менә шул пароход белән Әстерханга сыпырткан. Фетнә... пардон... революция кузгалганның икенче көнендә үк.

— Сез хәтта аның киткән юлларын да беләсез...

— Чакырды ул мине үзе белән. Гел әйтәдер иде: «Үз кадерен үзе белгән

кешегә шәхси врачы һәм шәхси юристы булу — ике кул, ике күз кебек кирәк нәрсә», ди иде.

— Алайса, сыңар күзле, сыңар куллы килеш кенә җибәргәнсез икән фабрикантны...

— Юк, Валерий юристны үзе калдырып китте... Бик ертлач, оятсыз бәндә иде тегесе. Кандала кебек теләсә нинди ярыкка кереп китәр дә, теләсә нинди әҗәтханә төбеннән ялт итеп килеп чыгар, берни дә булмагандай. Хәер, хуҗага шул ягы белән ошый да иде. Ул булганда Алафузов Кытай стенасы артына кереп поскан кебек яшәде.

— Шундый ышанычлы кешесен дә калдыргач инде...

— Нәрсәдер килеп чыкты ул юрист белән. Бик танылган бер аксөякнең хатынын көчләгән диме шунда. Ә үзе...Ханымның намусын керләндергән өчен тиешле сумманы да түләмәгән. Шуның белән бөтен дөньяга рисвай булды. Хәтта Алафузовка күләгәсе төшә башлады...

— Ярый, юрист белән читен хәлләр чыккан. Ә сез — әле врач та икәнсез — нигә хуҗагызны язмыш иркенә ташладыгыз?

— Кыска гына итеп әйтимме? Чит илдә солтан булганчы, үз илемдә олтан булу артык, дип уйладым. Шапырына дип уйламагыз, ихлас шулай. Аннары шунысы да бар бит: Валерий белән еш кына ырлаша торган идек. Кайбер көннәрне ул, Николай Икенче яисә Александр Керенский булып уяна да, мине «лекарь, имче» дип кимсетә башлый. Әз генә артыграк төшерсә дә, үзен-үзе әллә кемгә куя. Миндә дә тәкәбберлек аз түгел, авырткан сөяләмә баскач, фабрикант дип тормыйм. Бигрәк тә салган баштан...

Күз төбендәге капчыклар бу кешенең «салу» җәһәтеннән уразасын шактый еш бозуын күрсәтеп тора, әлбәттә. Бүлмәсендә дә хатын-кыз кулы, хатын-кыз җылысы җитмәү сизелә. Шул хакта уйлаганга, ахры, Шамил кинәт кенә сорап куйды:

— Җәмәгатегез бармы, Михаил Тимофеич? — диде.

Күренә: хуҗага ошамады бу сорау, йөзеннән кара күләгә шуып узды. Сөальгә каршы сөаль белән, дорфа гына җавап кайтарды:

— Чеканы мәсьәләнең ул ягы да кызыксындырамы?

Шулай да, тешләшүнең мәгънәсез икәнлеген аңлады бугай:

— Бүтән ирне миннән артыграк күрде. Хәзер аның белән яши,— диде.— Рәхмәт инде: өстемнән йөрмәде, ачыктан-ачык әйтеп, тавыш-гаугасыз гына аерылыштык. Икәү бергә тапкан малны калдырды, ә яшәвемнең мәгънәсен алып китте. Шуннан бирле хатын-кыз ни дә, телеграф баганасы ни — барыбер минем өчен.

— Ә Флора?..

Тряпкинның яңагы тартышып куйды. Әмма берни дә сиздермәскә тырышты.

— Хатыннан аерылгач, бик каты авырып киттем. Гарьлектән, ачудан, көнләшүдән... Нервылар сынатты. Менә шул чакта Флора миңа чын-чынлап шәфкать туташы булды. Юк, авыр сүз әйтмәгез аның турында...

Кыланамы, ихластан сөйлиме — һич аерырлык түгел, боларга тикшермичә генә ышанып та булмый иде. Дөрес, Алафузов яисә Флора хакында кушучлап борчак сипсә дә, хәзергә әллә ни зарары юк... Ә менә бәгыренә шырпы булып кадалган бер сорау бар — аңа ачык җавап ишетәсе килә Измайловның. Сүзне ул кинәт шул якка борды.

— Чистайда булгалыйсызмы, Михаил Тимофеич?

Мондый борылышка бүлмә хуҗасы игътибар да итмәде шикелле:

— Юк, нибары бер тапкыр. Былтыр. Көзге якта бугай.

— Төгәлрәк әйтеп булмыймы?..

Тряпкин аңа туп-туры, усал итеп карады. Яңак бизләре уйнаклый башлады.

«Сөзәргә җыенамыни,— дип уйлады Шамил аның бу кыяфәтен күреп.— Сагаеп калды бит. Чистай ягыннан гел яман хәбәрләр генә көтәме? Ул тарафта, үзе әйтмешли, берәр аксөяк хатынын көчләп качканмы әллә?»

Тряпкин торып ук басты:

— Бу нәрсә дип атала: төпченүме, әллә миннән сорау алумы? — Тел төбендә ачыктан-ачык янау, җиңел генә бирелмибез без, дигән кисәтү ишетелеп китте.

Шамил үзен бик тыныч тотты.

— Ихтыярыгыз, Михаил Тимофеич. Телисез икән — сорау алу дип аңлагыз.

— О, сорау алумыни бу? Алайса, мандат булса да күрсәтер идегез. Югыйсә, чекист халкы турында төрле имеш-мимешләр генә ишетеп туйган. Минем күрше, әнә, караңгыда капка баганасын күрсә дә чекист дип өне китә. Ә үзе шымчыдан бер дә ким түгел...— Тряпкин кинәт, аяк очларына гына басып, ишеккә таба китте, тырпаеп торган колагын йозак тишегенә турылады. Ишеген кисәк кенә ачып җибәргән иде,— коридорда кемнеңдер аяк тавышлары ишетелде.— Менә бит, нинди күрше белән яшибез,— дип башын чайкады Тряпкин.— Һәрвакыттагыча уяу. Күз-колак булып кына тора. Әле ярый, миңа кунаклар сирәк килә, югыйсә, бер дә ял күрмәс иде, мескен. Үзе үк әйтеп тора: элеккерәк заманнарда полиция шымчысы булган. Сезгә дә файдасы тимәсме, сүз салып карагыз әле шуңа.

— Бик урынлы киңәш. Истә тотмый булмас. Ул сез сөйләгәннәрне дә тулыландырыр, бәлки,— дип, тырнак астына энә тыгып алды Шамил. Мандатын тагын бер кат чыгарып күрсәтте.

— Ә-ә, менә хәзер исемә төште, Шамил Мәгъсүмович...— Тряпкинның тавышы йомшарды.—— Үткән елның октябрендә булганмын икән Чистайда. Әйе, әйе, Камада инде пароходлар йөрүдән туктаган иде... Сезне дә шунда күрдем шикелле.

— Хәтерегез ачыла бара, гражданин Тряпкин, күз тимәсен. Без нәкъ шул чакта очрашкан идек. Нәкъ шул чакта сез мине үлем җәзасына хөкем иттердегез.

— Үлем җәзасына?! — Мишель куллары белән кагынып куйды.— О, сез нәрсә сөйлисез?.. Андый хәлнең булуы мөмкин түгел.

— Мөмкин, бик мөмкин. Ат башында сез идегез, урам уртасында кеше таптатып үтергәнсез, ә миңа...

— Булмас ла!.. Алай димәгез, Шамил Мәгъсүмович! Безнең кузлада Перинов Сема утыра иде. Атларны уйнатып кына алып бара, мин сиңайтим; һич көтмәгәндә ниндидер карт офицер юлыбызга каршы төште, исерек булды, ахрысы: егылгач, бәладән баш-аяк дип, Сема дилбегәне ташлап качты. Минем Чистайда беренче булуым, дилбегәне тотсам да, юлны белмим, шуңа күрә сездән ярдәм сорарга туры килде. Андый хәлләр килеп чыгар дип башыбызга да килмәде, валлаһи. Ялгышмасам, мин сезне пароходка да чакырдым бит әле. Шунда бергә китәсебез калган. Алафузов та ошаткан иде сезне. Исегездәдер, хәтта үзенә эшкә димләде... Ә теге офицер... Ул чынлап та үлгәнмени?

Шамил җавап кайтармады. Беразга авыр тынлык урнашты. Аннары ул Тряпкиннан «Сема»ның тышкы кыяфәтен тасвирлауны сорады.

— Мин нишләптер бик хәтерләмим. Нибары бер генә тапкыр күргәнгәдер инде. Ул безнең компаниягә анда, Чистайның үзендә генә кушылды. Башта әле мин аны кучер дип торам; без кәеф-сафа корып утырган чәйханәгә туп-туры пар ат, тарантас белән килде.— Тряпкин, төгәлрәк күз алдына китерергә теләгәндәй, күзләрен учы белән каплады.— Ә аның булмышы: арык кына гәүдәле, кыска буйлы, кара чәчле, йөзгә чибәр димәс идем... Истә калганы менә шул. Тагын берәр үзгәлеге бармы икән?.. Адымнары җиңел, хәтта йөргәндә очып-очып китә кебек.

— Күзе нинди, күзе?

— Күзләре... зур түгел, кысыграк. Төсен хәтерләмим... Кара иде шикелле...

Саубуллашканда Тряпкин янә Чистайда булган хәлләргә әйләнеп кайтты. «Без бит белмәдек, ярдәмебездән ташламас идек»,— дип сөйләнде.

Тышта яңгыр басылган иде инде. Гоголь урамына кайтып җиткәләгәнче, кап-кара күлдәвекләрдә уйдык-уйдык булып вак йолдызлар калыкты.

Айсыз төн барыбер күзгә кара тасма булып сылана, шуңлыктан, Шамил дымланып бүртенгән ботинкасы белән әледән-әле суга кереп китә, ә күлдәвектәге йолдызлар аның аяк астыннан очкын булып чәчриләр иде.

Юл шактый озын: Михаил Тряпкин белән булган сөйләшүне яңабаштан күз алдыннан кичерергә вакыт җитәрлек булды. Мишельнең сискәнүләре, ишекле-түрле йөрүләре, ул арада ишеген ачып «шымчы» тотулары... һәм, сорауларга шома гына җавап биреп, асылда, судан коры чыгуы... Болар барысы да нигәдер эчне пошыра, күңелне баса иде. Канәгатьсезлек, хәтта алдану кебек бер авыр тойгы кайта-кайта көчәя генә барды.

Гирш Ольkeницкий янына кергәндә дә Измайлов шундый күңелсез уйлардан арына алмады.

Соңгы арадагы йокысыз төннәр нык сиздерә,— губчека башлыгы, кабинетындагы урындыклар өстенә генә сузылып ятып, бераз черем итәргә чамалаган иде. Җеп бөртегенә кадәр чыланган, йөзеннән каны качкан егетне күреп, ул аякка басты:

— Нәрсә булды, Шамил?..

Измайлов, идән уртасына баскан да, бер ноктага карап тик тора.

— Белмим, Гирш Шмулевич, бәлки, берни дә булмагандыр. Әмма күңелем тыныч түгел...

— Ни әйтергә теләвең бу? Рәте белән генә сөйлә әле, йә.

Яшь чекист, көне буе архивта утырып, анда Михаил Тряпкин өстеннән бер доноска тап булуы, шуннан соң ул докторны эзләп өенә баруы хакында бәйнә-бәйнә сөйләде. Чистайдагы танышлыкларын да искә алды.

Бу шактый озын хикәятне Ольkeницкий бер дә бүлдерми тыңлады. Иң соңыннан гына, гадәтенчә:

— Алай...— дип куйды.— Димәк, бер генә түгел, ике Семен Перинов булып чыга. Тряпкин тасвирлавы белән ВЧК пакетында әйтелгән билгеләр берсенә-берсе ялганмый.

— Якын да килми,— диде Измайлов.

Гирш Шмулевич өстәл янына таба берничә адым атлады; туктап, кысасыз күзлеген салды, аны кире борынына атландырганчы, озак итеп күзләрен уды. Әкрен генә әйтте:

— Ул докторың хак-дөресен сөйләгән булса, Петроградта тотылган агентка ышанычы бетә. Әгәр инде Тряпкин шыттырган икән, димәк, аның теле бәйле: муенын Семен Перинов, ягъни «Карачкы» салган элмәк кысып алган. Менә шундый ике яклы медаль, дустым. Ә безгә кирәкле мәгълүмат аның бер ягына гына язылган...— Ольkeницкий өстәл янына барып утырды. «Кил, утыр» дигән ишарә белән Шамилгә дә урын күрсәтте. Сүзеннән бүленмичә дәвам итте:— Әйдә, бергәләп капшап-кармалап карыйк: кайсы ягы уң, ә кайсысы сул икән... Исеңә төшер: аның сөйләвендә, үз-үзен тотышында очы-очка ялганмаган, шик уяткан нәрсәләр булмадымы?

Измайлов, фикере, тупларга тырышып, имән бармагы белән өстәлгә берничә тапкыр «Т» хәрефе ясады.

— Тряпкин бер тамаша күрсәтеп алды алуын,— дип әкрен генә исенә төшерә башлады.— Имештер, аның күршесе — элеккеге шымчы икән, хәзер дә, янәсе, йозак тишегеннән тыңлап-күзәтеп йөрүен ташламаган... Күршедәге ишекнең ачылып-ябылганын мин дә чамаладым, андый чакта эчке стена сизелер-сизелмәс кенә калтыранып куя. Тряпкин, нәкъ шул мәлне туры китереп, үз ишегенә йөгереп барды, күршесенең бу бүлмә турысына килеп җитүен тыңлап-көтеп торды да, ялт кына ишекне ачты. Билгеле, анда кемнеңдер узып барганы ишетелде...— Шамил үзе үк икеләнеп туктап калды.— Бәлки, миңа гына бүрәнә аша бүре күренәдер хәзер...

Ольkeницкий сейфтан ВЧК пакетын алды.

— Мәле, Карачкының кыяфәтен тасвирлаган төшен генә кычкырып укы,— диде.

— 30—35 яшьләрдә, озын буйлы, нык бәдәнле, аксыл чәчле, зур коңгырт күзле, озынчарак йөзле...— дип укыды Шамил.

— Хәзер, шундый эзлеклелектә, Михаил Тряпкинны сурәтләп бир.

— Яше — утыздан узган... буе озын... таза-нык гәүдәле... аксыл чәч...

Измайлов шып итеп туктап калды, йөзенә куе кызыллык йөгерде:

— Йа хода...— дип пышылдады.— Бөтен билгеләре туры килә!

Губчека рәисе, өстәл тартмасыннан маузер тартып алып, кесәсенә тыкты. Шамил дә, сикереп торып, нигәдер ишеккә ташланды. Ольkenицкий, өстенә күн пинжәген кия-кия, аның артыннан кычкырып калды:

— Машинаны тизрәк әзерләсеннәр! Һәр минут кадерле.

...Караңгы урамнарның ике ягына тезелеп баскан йортларда ут әсәре юк иде.

— Зират ташлары арасыннан барган кебек,— дип куйды шофер егет.

Адмиралтейский бистәсе тарафында винтовкадан, пистолеттан атышкан тавышлар ишетелде. Машинадагыларның игътибары шул якка күчте.

— Безгә сызгыралар... Әллә чакырган җиргә барыйкмы? Караңгы урамнарда йөргәнче...— диде кайсыдыр.

Шофер, нәрсә әйтер икән дип, Ольkenицкийга карады. Ольkenицкий дәшмәде.

Егерме өченче йортка килеп җиткәндә инде төнге бер иде. Ишекне Тряпкинның кайсыдыр күршесе ачты. Ул бик аптыраган кыяфәт белән бусагада басып калды, ә чека егетләре, коридор буйлап тиз-тиз үтеп, сары буяулы ишекнең ике ягына бастылар.

— Өйдәме? — диде Измайлов, бүлмәгә ым кагып.

Күрше дигәне куркып стенага сыенды:

— Ю-у-ук...

Тряпкинның ишеге бикләнмәгән, ә бүлмәсендә, давыл узып киткән кебек, бөтен әйберләр пыран-заран килгән иде.

Ольkenицкий, бүлмәдән тиз генә кире чыгып, тораташтай басып торган күрше абзый янына килде.

— Нәрсә булды соң монда? — дип тыныч кына сорады.

Абзый дерелдәгән кулы белән бугаз төенен сыпырды: тамагына нәрсәдер тыгылган да аңа сүз әйтергә бирми кебек иде. Тавышы баягыча ук калтыранып-хырылдап чыкты:

— Алып киттеләр... Алып киттеләр аны...

— Кем алып китте? Кайчан? — диде Ольkenицкий. Кул ишарәсе белән генә ике егетне тышкы ишек төбенә сакка җибәрде.

— Милиционерлар. Икәү иде алар. Кулларында наган. Михаил Тимофеич каршы торды, сугышты. Тегеләр аны типкәләп...

— Өсләрендә форма идеме?

— Әйе, әйе. Форма. Кулларында наган. Берсе атам дип куркытты, әгәр телең тик тормаса, диде. Тегеләр бүлмәдә казынган арада, Тимофеич миңа пышылдап өлгерде: «Властьларга бөтенесен сөйләп бир, ничек булганынча»,— диде.

— Кайчан килделәр алар? — диде Измайлов, маңгаеннан тирен сөртеп.

— Шәт, унике булгандыр. Шайтаннар кузгалып чыккан мәлдә.

«Мин киткәч берәр сәгатьтән икән»,— дип уйлап алды Шамил.

— Мандатларын күрсәттеләрме?

— Кулларында наган иде.— дип, инде ничәнче тапкыр кабатлады күрше абзый. Аның әле һаман куркуы узмаган иде.

Бүтән күршеләрне кузгатып, алардан сорашу да әллә ни нәтиҗә бирмәде. Бер генә яңалык өстәлде: Тряпкинны пар ат җигелгән җиңел арбада алып киткәннәр.

— Шамил, машинаны ал да, иң якындагы телефонга барып кил,— диде Ольkenицкий.— Милиция идарәсенә шалтыратып белеш: Тряпкинны кулга алырга кемне җибәргәннәр? Тиз бул!

Озакламый Измайлов әйләнеп кайтты. Хәбәр кыска: Михаил Тряпкинны милиция кулга алмаган иде.

*Ахыры киләсе санда*

## ШИГЪРИЯТ

# Нур Әхмәдиев

## Васыять

Алтын сарай мирас итә алмыйм,
Кичерерсең инде, и улым!
Юк, кызганмас идем синнән аны,—
Улым, син бит — минем уң кулым.

Алтын сарайларны үзең төзе,
Минем мирас — бәһа биргесез:
Йөз аклыгын байрак итәр җирле —
Татарстан дигән илле сез!

Мин калдырам сиңа рух ныклыгы,
Моңнар ташып торган телемне.
Шушыларны кабул итсәң генә,
Тыныч каршылармын үлемне.

Мирасымда — тапланмаган Намус
Йөз сыналган Иман калдырам.
Җиде буын бабам бәхиллеге
Сиңа кала бар да, ал, олан!

Тик онытсаң туган моң-телеңне,
Мин хыянәт диеп аңлармын.
Каберемнән сикереп чыгалмасам,
Ләхетемдә көе каргармын!

Алтын сарай мирас итмим сиңа,
Кичерерсең инде, и улым!
Соң сулышка кадәр халкың белән
Аерылмас булсын үз юлың.

## Колыма

### I

Мин — Колыма...
Ләйсән яңгыр түгел,
Кан-яшь белән кат-кат юылд. м.
Җирнең авыр яра-җәрәхәте,
Кешеләрнең
Зират кебек соңгы юлы мин.

Мин — Колыма...
Кеше язмышларын
Төенләдем, ләкин чишмәдем.
Тиран гипнозында мин дә корбан —
Тыныч яши идем, нишләдем?

Иң каһәрле сүзгә әверелдем,
Әйтерсең лә мин бер бәддога!
Гаебем ни, аңлатыгыз, зинһар,
Керегезче хәлгә чак кына.

Җәһәннәмнән курка белмәгәннәр,
Ишетелсә минем исемем,
Ток тоткандай куя калтыранып,
Сизгер дә соң жаны кешенең...

Куркаклыкта гаеплисем килми,
Аларның да хәлен аңларлык:
Килгән эзләр чутсыз,
Кайтканнарын
Бармак белән генә санарлык.

Мин дә корбан,
Битем тоткыннарның
Каны, тире белән юылган.
Атлантида сыман, су астына
Китәр идем, килсә кулымнан.

---

Нур ӘХМӘДИЕВ (1946) — *шагыйрь, прозаик; берничә китап авторы. Әлмәттә яши.*

Ярлыкагыз,
Ләгънәт, каһәр тыңлап,
Язганмыни яшәү гомергә?

Мин — Колыма.
Беркөн оятымнан
Әйләнермен янып күмергә...

II

Каберләре кайда?
Ыңгыраштш тайга:
— Телмә, телмә, сорап, бәгырьне!
Черкидән күп иде ул корбаннар,
Каян җиткерсеннәр каберне?

Һәр киселгән агач — кеше җаны,
Һәр салынган шпал — гомердер.
Ничек салынганын аңлый алса,
Түзмәс рельс, түзмәс, бөгелер.

Тепловозлар калтыраныр иде,
Куырылыр иде аһыннан.

Мең процент файда алынгандыр
Политкаторжаннар җаныннан!

Иң зур зират — мин ул.
Әйе, мин ул —
Тоташ зират, ялгыз каберсез.
Кеше кебек кем бар галиҗәнаб,
Кеше кебек кем бар кадерсез?..

Җавап табу җиңел түгел монда,
Сорау арты сорау — күп алар.
Сталинга охшап, бертуктаусыз
Төрепкәсен тарта сопкалар...

Халыкларның була аз санлысы —
вак һәм кече түгел,
Хакыйкать гел ачы була —
баллы, төче түгел.
Милләтеннән һәм теленнән йөз чөергән
Кем буладыр, белмим,
ләкин Кеше түгел!

## Төнге шом

Инде Әлмәт тәмле төшләр күрә
Шәһәр чумган татлы йокыга.
Төн җитүгә, һәрчак борчу били,
Пошаманга төшәм, куркуга.

Кап-караңгы.
Сыңар йолдыз да юк,
Ай күренми тагын бүген дә.
Болыт түгел,
Тауда нефть яна,
Төтен, сөрем Әлмәт күгендә.
Төтен, сөрем көннең көнендә.

Торбалардан очкан цемент, тузан,
Шымчы кебек керә ярыктан.
Сулыш юлын күкерт исе буа,
Саф һавага халык зарыккан.

Тизрәк узса иде шомлы бу төн,
Якты керсен иде өйләргә.—
Трибунага чыгып басар идек...
Бар да әйбәт, диеп сөйләргә!

# Эльс Гадел

## Туган авылны сагыну

Кеше баласы микән мин,
бүре баласы микән? —
ник күңелнең иң түрендә
һаман Салагыш икән?

Җитмәгәнме миңа Казан,
Мәскәве җитмәгәнме?
Бүреккә салмаганнар бит,
базарга китмәгәнмен.

Урманны сагына күңел,—
хет үтер, хет ела син,
Нигездән аерма икән
хәтта бүре баласын.

Елат әле, елыйм әле,
сал җаныма, сал сагыш! —
Гел яктырсын күз төбемдә
күз яшедәй Салагыш.

## Көзге шаяру

Аһ, кышкы җылы салкыннар!
Аһ, шарыкъ наяннары!
Ачтыгыз күңелем, ачтыгыз...
Ә аннан соң? Аннары?

Җаннары булган кешенең
Дөрләмәсме каннары?!
Бер күз генә ташла сезгә,—
«Беттем» диген аннары!

Аннан син — син түгел инде:
Уттай янып гыйшкыңда,
Кереп үк ятыр булырсың
Көртнең итәк астына.

«Менә бит...» дигәндәй булып,
«Менә бит, ә!» дигәндәй,
Көләрләр көлемсәр җилләр,
Тел шартлатып көләрләр.

Тик, адәм көлкесе түгел,
Син — җил көлкесе генә,
«Көрт астына җен качты»,— дип
Җил, әй, өркесен сәнә.

...Аһ, менә нишләтәсез сез,
Туган як наяннары!
Бер күз генә ташла сезгә,—
«Беттем» диген аннары.

## Шәһәр аты

...Юлда егылып үлгән шәһәр аты.
Машиналар белән ярышканмы,
йөге әллә артык карышканмы,—
юлда егылып үлгән шәһәр аты.

Ялларына, күз тимәсен диеп,
кызыл чүпрәк кушып үргән йөкче.
...Күзләрендә атның —
буй җиткереп,
өлгереп кенә килгән
яшькелт солы төсе.

---

*Эльс ГАДЕЛ — танылган радио һәм телевидение дикторы, редакторы. Шигырьләре көндәлек матбугатта басыла килде. Журналыбызда беренче тапкыр тәкъдим ителә.*

## Соңгысы

Мең кат кадалгач хәнҗәрең,
Мин сабыннан тоттым да
Эчкәрәк аны батырдым,
Сау калудан курыктым да.

## Сау бул!

Сау бул, чабаталы егет,
Без киттек, башмак киеп,
Без күргәнне дошманнар да
Күрмәсен башка, диеп.

Киттек!
Башмак башлары да
Таш юлда туза икән...
Елап та гомер,
Җырлап та
Башыңнан уза икән.

Мин бүген, чабата киеп,
Болыннан уздым әле,
Өнемдә түгел, төшемдә
Сиңа кул суздым әле.

Их, чабаталы малай чак,
Тилекәем, хыялый!
Бәхетле күк көннәремә
Сиңа житү каяле!

## Ике җылы

Кул җылымны бирәм сезгә, дисең...
Ә күңлеңә халкың җыйганны?
Тән җылысы — шәм җылысы гына,
Җан җылысы җылыта җиһанны.

## Сездә — салават күпере

Сездә — салават күпере,
бездә — яңгырлар...
Яшен авазы, бәлки, анда да
барып яңгырар.

Үксү авазым булырмы,
укенүемме ул,
шатлыгымнан күкләргә бер
сикерүемме ул,—
ишетелсә шундый аваз,
«ул — синдер» диген...
күперегезгә нурларны
мин бит иңдердем.

# Көз

Көн йөзләре бигрәк сары — моңдыр инде:
Көзнең шәмдәй калгып сүнәр соңы килде.

Кыштыр-кыштыр хушлаша җәй сукмакларда,
Бик тиз кайтмас инде җылы бу якларга.

Күкнең битен юучылар уңган икән,
«Бу зәңгәрлек безнең китәр юллар микән?» —

Дип муенын сузган өскә киек казлар,
Җырлыйлармы, елыйлармы, белмим, алар.

Ә тәхтеннән Кояш һаман көлгән була,
Салкын алтын белән Җирне күмгән була.

Юк, җылытмый алтын, алтын вакытың киткәч,
— Дәрт-дәрманың кай дәрьяга акты, бикәч?

Йокы аралаш Җир сораудан мышнап куя,
Сары яфрак белән тунын тышлап туя...

Бу хикмәтне күреп йөреп җил дә арый,
«Төшме бу, өнме?» — дип, борынын капшап карый.

# М. Ю. Лермонтов

## Болытлар

Сез, болытлар,— мәңге мөсафирлар!
Энҗе тезмә булып агыласыз.
Газиз төн ягыннан, минем кебек,
Сөрелгәнсез күя көньякка сез.

Кемнәр куа сезне: явызлыкмы?
Язмышыгыз сезнең шундый мәллә?
Әллә дусларыгыз, яла ягып,
Төшердеме сезне шушы хәлгә?

Юк, буш кырлар туйдырганнар сезне...
Аңламыйсыз кеше кайгысын сез.
Мәңге ирекләләр, сез яшисез
Сөргенсез һәм мәңге туган илсез.

*1840*

## Васыять

Яныма кил әле, туган,
Тыңла: яна бәгырь,
Көннәрем санаулы, диләр,—
Дөрес сөйлиләрдер!
Син өйгә кайтырсың тиздән,
Ә мин... Бу язмышым белән
Һичкем кызыксынмас,
Үзен, борчып тормас.

Кемдер ялгыш сорап куйса,
Яраланды, диген,—
Патша өчен җанын бирде,
Ятып калды, диген,
Ә табиблар начар, диген,
Тырышмады алар, диген,
Һәм әйт: юллады сезгә, дип,
Соңгы сәламнәрен.

Исән түгелләрдер, шаять,
Әти белән әни...
Мин аларны, аңлыйсыңмы,
Елатасым килми;
Әгәр исән була калса,
Син әйт: хат язарга ялкау,
Ул походта, диген,
Бик еракта, диген.

Күршедә бер кыз бар... Ара
Өзек аның белән...
Минем турыда ул кызый
Сораштырмас, беләм!
Ләкин аңа сөйлә дөресен,
Буш йөрәкне җәлләмә син;
Елап алсын бераз,—
Аңа берни булмас!

*1840*

I

Мин ялгызым гына юлга чыгам;
Юл җемелди алда төн аша;
Чиксез күкне тыңлап, дөнья тынган,
Йолдыз белән йолдыз серләшә.

2

Күкләр тантаналы, күкләр сәер!
Ә җир йоклый күксел томанда...
Нигә сыкрый әле минем бәгырь?
Нәрсә көтәм? Ни хис бу җанда?

3

Мин тормыштан һични көтмим инде,
Үкенмичә карыйм үткәнгә;
Мин гел тынлык эзлим! Теләр идем,
Онытылып, йоклап китәргә.

4

Тик кабердә түгел! Теләр идем
Рәхәтләнеп, мәңге йокларга:
Күкрәгемдә йөрәк типсен иде,
Җиңел булсын иде суларга.

Гыйшык җыры яңгырап торсын иде,
Йөрәгемә үтеп һәм сеңеп,
Мәгърур имән гел шауласын иде,
Баш очыма минем иелеп.

*1841*

*Камил МОСТАФИН тәрҗемәләре.*

**Арво Валтон**

# ЯШЕЛ БИШТӘРЛЕ КЕШЕ

ХИКӘЯ

Вокзалның киң, бөркү залына төш вакытында озын буйлы бер ир-ат килеп керде. Төсе уңган костюмнан, галстуктан. Юлаучылар арасыннан түрдәге почмакка узды да, аркасындагы яшел биштәрен пычрак паркет идәнгә куеп, якындагы эскәмиягә урнашкан юлаучылардан бүтән җиргә күчеп утыруларын үтенде. Бушаган эскәмияне тагын да түргәрәк этеп җибәрде. Аннары шуңа менеп басты да, залдагыларның бөтенесе ишетерлек итеп, биштәреннән алган китабын дәртле тавыш белән укый башлады.

Әүвәл аңа якын-тирәдәге күршеләре генә игътибар итте. Эскәмиягә менеп баскан бу кешегә алар ирексездән генә колак салды. Гүелдәү тынарак төшкән чакларда укучының көчле тавышы бөтен залга яңгырый, юлаучыларның барысы да аны ишетергә, тыңларга мәҗбүр иде.

Вокзалның көтү залы гадәти тормышы белән яши иде: берәүләр поездан төшә, икенчеләр поездга утыра. Зал аша перронга, аннан кире якка пассажирлар өзлексез агылып тора. Берәүләр кычкырып сүз алыша, кулларын изи, икенчеләр ишектән-ишеккә тыз-быз йөгерә. Зал түрендәге эскәмияләргә генә юлаучылар озакка урнашкан: кем тамак ялгый, кем баласын чүлмәккә утырта, кайсылары эше юктан көнбагыш яра, кайсылары исә йокыга талган. Юлаучыларның нинди генә юк! Буфет дип аталган сәүдә шүрлеге аша күпне күргән апайлар юынтык су төсендәге суынган кофе һәм товарлыгын атна буе саклаган тимер юл кабартмаларын сата иде.

Көтү залының гаять әчпошыргыч көндәлек хәятендә кычкырып китап укучы ир-ат үзенең гайре табигыйлеге белән ачуны да китерә иде. Монда утырган кешеләрнең бүтән эше булмаса да, эскәмиягә менеп баскан укучы вакыт уздырырга бик ярап торса да, барыбер аны ятсытыла, чөнки бу залда болай кычкырып уку гадәткә кермәгән иде. Зал аша ашыга-ашыга узучыларга бу әле комачаулый да. Һәммәсе ниндидер хәбәр ишетеп калырга омтыла: кайберәүләр моның өчен хәтта туктап та тора: аннары тагын адымнарын тизләтә иде, чөнки уйлап чыгарылган шаһзадәләр һәм батырлар, мавыктыргыч маҗаралар, дәртле хисләр, кайнар мәхәббәт тасвирланган урта кул гына бер әсәр укыла иде. Урыны белән үткен сүзле, урыны белән әчпошыргыч күңелсез бу әсәр — гөнаһлы дөньяның үзе кебек иде. Ир-ат ачык тавыш һәм шактый ук ясалма пафос белән укыганлыктан, тасвирланган җиһан һәм дәртле хисләр шау-шу килгән яки шыпырт кына утырган юлаучылар арасына сеңә бара иде. Залдагы гүелдәү бөек хакыйкатьне һәм чеп-чи ялганны, ачы хәсрәтне һәм юаткыч хыялларны бердәй йота.

Залдагы кайберәүләр, ахыр чиктә, игътибарын чуар ыгы-зыгы биләмәгәндә, укучыны комсызланып тыңлый башлады. Тормышта очрамаган каһарманнар язмышын күзаллап, кемнеңдер поезддан калуы да бик ихтимал иде. Әмма зал аша кабаланып атлаучы һәм юл уңаенда гына сүзгә колак салучыларның күпчелеге дуамал куышу маҗарасына яки төрле бөек хакыйкатьләргә — берәүләр назлы мәхәббәт балына, икенчеләр фәлсәфи фикерләүләр томанына туенып китә иде. Тик һәммәсе ары таба атлый, чөнки аларга каядыр барып җитәргә кирәк. Бигрәк тә яшел эскәмиядәге ир-ат шунсыз яши алмаслык берни дә хәбәр итмәгән бер мәлдә шулай бу.

Ләкин залда бу эшкә бөтәнчә караган, аның белән чын-чынлап кызыксынган кешеләр дә пәйда булды. Барыннан элек идәндәге пычракны юеш чүпрәк белән көненә ике мәртәбә бер урыннан икенчесенә ягып китүче зәңгәр халатлы җыештыручылар. Укып торучы ир-атны күргәч, алар үзара карашып, рөхсәт ителмәгән нәрсәдер эшләнүен шундук чамалап алдылар.

— Тапкан вәгазь укыр җир,— диде апайларның өлкәнрәге.

Икенчесе, эшем кешесе буларак, тәвәккәл генә укучыга якынлашты һәм ачулы төстә:

— Бу ни инде тагын? — диде.

Ир-ат әлеге сорауга керфеген дә селкетмәде. Бу минутта ул әсәрнең көлкеле җирен укый һәм елмая иде.

Җыештыручы бер адым кире чигенде, биленә таянып, күкрәген киерде, үзенчә иң сугышчан кыяфәткә кереп:

— Яле, төшеп кит эскәмиядән!.. Эскәмия аяк белән менеп таптар өчен түгел, утырыр өчен куелган! — диде.

Ир-ат эскәмиядән төште, әмма көлемсерәвен дә, укуын да өзмәде. Җыештыручы эскәмияне дырк иттереп элекке урынына күчерде, аннары җиңгән кыяфәттә залга күз ташлады.

Ләкин аның хәрәкәтләренә берәү дә аерым игътибар юнәлтмәде. Берәү дә сүз катмады, хупламады. Җыештыручы үз иптәше янына килгәч, тагын үзара күзгә-күз карашып алдылар. Вокзал тәртибен саклаучылар бу хәлдән бер дә канәгать түгел иде. Табигый ки, ир-атның ни укуына алар колак салып маташмады. Теләсә-кайсы юньсезнең вәгазен тыңлап вакланырга, поезд көтүче пассажир түгел ич алар, шушында эшләүчеләр, хәтта җитәкчелекнең күзе-колагы, вәкиле диярлек!

Зал тиклем залда болай уку ярамавы да ачык. Әмма бу апайларның укымышлылыгы чамалы булганлыктан, ир-атны тыяр өчен берәр закон яки кагыйдә таба алмадылар. Ә яңасын, үз законнарын уйлап чыгарырга шулай ук базмадылар: ни әйтсәң дә, алар тимер юл системасында гына эшлиләр ләбаса.

Шуңа күрә алар, бергәләп, туп-туры вокзалда кизү торучыга килеп:

— Тегендә, залда, бер ир-ат кычкырып китап укый,— диделәр.

Дежур абзый, кызыл фуражкасын салып, маңгаен кашыды:

— Нәрсә укый соң ул? — диде.

— Белмибез,— дип кискен җавап бирделәр.

— Кем соң ул ир-ат? — диде кизү торучы.

Тавышларына патриотик уяулык төсмере салган җыештыручылар бу юлы да беравыздан:

— Белмибез,— диделәр.

Эш җитди тоелганлыктан, кизүче уйга чумды. Аннары, кызыл фуражкасын киеп, зал ишегенә юнәлде. Ерак почмакта, чыннан да, озын буйлы бер ир-ат залга йөз биреп басып тора һәм, гүелдәү басылган мәлләрдә аерым сүзләрен кизү торучы да ишетерлек итеп, китап укый иде.

Дежур торучы ишек яңагына сыланды. Әгәр залга барып керсә, аңа җәмәгатьчелек алдында мондагы хәлгә үз мөнәсәбәтен ачыктан-ачык белдерергә кирәк булачак. Бу мөнәсәбәтнең нинди булырга тиешлеген ул әле фәһемләми, шуңа күрә залга керергә дә ашыкмый иде. Аның эшләү дәверендә бу залда әле кемнең дә булса кычкырып китап укыганы юк, бу ва-

кыйганы җитди рәвештә бизмәнләп карарга кирәк иде.

Хәл тикшерелер, дип җыештыручыларны ышандыргач, кизү торучы тузган өстәле янына килеп утырды. Фуражкасын салды, маңгаен кашыды. Әмма башына юньле берни дә килмәде. Шуннан соң тәртип саклаучы полицейскийга шалтыратты.

Аныңсы полициягә хас пошмас кыяфәттә килеп керде дә, бильярд уенын уйнап бетерергә өлгермәвен әйтеп, ни булды, дип сорады. Вокзал дежуры:

— Көтү залында ниндидер бәндә кычкырып китап укый. Ни галәмәт ул, ачыклагыз әле шуны,— диде.

— Ачыкларбыз.

Тәртип саклаучы шундук көтү залына юнәлде. Эскәмияләр арасыннан атлаганда ул барысына да хуҗа шикелле сөзеп карап барды. Аның сыны күренүгә, залдан шыбырдау җиле искәндәй булды. Юлаучылар әйберләрен җыебрак, көнбагыш кабыкларын яшеребрәк куярга, эскәмиягә сузылып утыручылар аякларын идәнгә төшерергә ашыкты. Власть иясе, укучыга мәгънәле карашлар ташлап, тирәсеннән әйләнеп чыкты. Аннары каршыдагы эскәмиягә килеп утырды да, аякларын сузып, кулларын күкрәгенә кушырып, ир-атка төбәлде. Барысы да, хәзер нәрсә булыр икән, дип кызыксынып көтә башлады. Хәзер инде тыңлаучылар укылганны юньләп аңламый, бөтен уйлары тәртип саклаучыга күчкән иде.

Хәлнең үзгәрүен сизмәүче бердәнбер кеше, күрәсең, укучы үзе генә иде. Ул хәзер аеруча үткен җирен укый: каһарман мөшкел хәлгә төшкән, ул аннан, аңлашыла ки, котылырга тиеш. Ир-ат мавыгып киткән, тизтиз укый һәм кулларын әллә ничек болгалаштыргалап ала.

Тәртип саклаучы әүвәл аның кычкырып китап укуында җәмгыятьне хәвефләндерерлек берни дә тапмады. Шулай бераз утыргач, хәленең аныксызлыгыннан үзе дә уңайсызлана калды. Бәлки бу залдагы тыңлаучыларның аңа күнегүенә, бүтән шыбырдамый һәм аңа игътибар итми башлавына бәйледер. Ул үзен гади пассажир хәленә төшкәндәй һәм, балачага кебек, укыганны тыңлар өчен килгәндәй бер халәттә тойды. Шунлыктан, вокзал кизүчесе янына кире өстерәлеп килде дә:

— Аны җавапка тартырлык нигезем юк,— диде.— Сугышмый, акырмый-бакырмый, хулиганланмый. Идәнгә төкеренми, эскәмиягә аягын куймый, сасы ис таратмый.

Бу арада кизү торучы инде, төрле-төрле дистәләгән эшне хәл итеп маташып, әлеге укучыны тәмам онытырга өлгергән иде. Исенә төшергәч, тагын фуражкасын салды, йөзен чытты һәм кулына телефон трубкасын алды. Аптырап тирә-ягына каранды: кемгә шалтыратырга?

— Димәк, сугышмый да, төкеренми дә? — Ул, тәртип саклаучыга төбәлеп, тагын бер кат сорамый булдыра алмады.

— Шулай шул.

Кизү торучы тимер юл юристына шалтыратты:

— Берәр гражданин көтү залында сугышмаса, төкеренмәсә, бары кычкырып китап кына укыса, нишләргә безгә? — дип сорады.

Ап-ачык шушы сораудан соң, хокук вәкиленә вокзалдагы хәлне бутала-бутала тәфтишләп аңлатырга туры килде. Юрист моңа каршы бик күп нәмәгълүм атамалар кыстыра-кыстыра сүз ташкыны яудыргач, кизү торучының кәефе тагын да бозыла төште. Юрист аңа асылда берни дә аңлата алмады; аптырагач, ярдәмгә фәннең үзен чакырып, китап сүзләрен җөпләде.

Кизүче, трубканы куеп, маңгаен кашыды. Бөтенесе дә аны язмыш иркенә ташлады, мәсьәләне ул үзе генә хәл итәргә мәҗбүр сыман тоелды аңа. Әллә соң бу кешегә килеп: «Тыңла әле сүземне, монда кычкырып укыма, иң яхшысы — вокзал мәйданына чык та шунда теләсәң ни эшлә, ул мәйдан өчен бүтәннәр җавап бирә»,— дип әйтсенме икән? Тик бу акыллы тәкъдимгә теге, мөгаен: «Нигә?» — дип җавап бирер. Бар, үзең дә белмәгәнне аңлатып кара аннары. Бәлки укыса да ярыйдыр, шулай да аның

моннан китеп олагуы әйбәтрәк булыр. Ул чакта инде берәү дә һичнәрсә әйтә алмас иде һәм...

Кизү торучы, кабат телгә килеп, җәмәгать тәртибен саклаучыга әйтте:

— Нишлибез соң инде? Кемгә шалтыратырга икән тагын? — диде.

— Белмим,— диде тегесе, мәсьәләне тулысынча колачлап.— Бу хакта миңа бернинди күрсәтмә дә бирелмәде.— Бераз уйлап торгач, өстәде:— Бәлки шәһәр җитәкчеләре ни дә булса эшләр? Монда, вокзал мәйданында, аларның ике кешесе тәртип сакларга тиеш.

Кизүче, өметләнеп, шуларны чакырырга кушты.

Полицейский үзе кебек ике хезмәткәрне ияртеп керде. Кизү торучы аларга:

— Көтү залыбызда берәү кычкырып китап укый. Бәлки сез берәр чара күрерсез? — диде.

Вокзал полицейские өстәде:

— Миңа күрсәтмә бирмәделәр.

Шәһәрнеке әйтте:

— Җәмәгать тәртибен бозамыни? — диде.

— Әйтүе кыен,— диде кизүче, иңнәрен сикертеп.— Кычкырып китап укый.

— Бу — сезнең биләмә,— диде шәһәр полицейские.— Әгәр ул мәйданда, вокзал ишеге төбендә кычкырынса, безгә катнашы булыр иде.

Вокзал сакчысы кизү торучының колагына пелде:

— Бәлки аны хәйләләп тышка чыгарып җибәрергәдер? — дип пышылдады.

Пышылдашу мәйданнан керүчеләргә ошамады, кизүче тагын маңгаен җыерды. Аннары башын чайкап:

— Сез, ичмаса, бер багыгыз аңа, бәлки нindидер киңәш бирерсез? — диде.

Тегеләр үзара карашып алдылар. Беренчесе әйтте:

— Нәрсә, таза егетме әллә? — диде.

Хәзер инде тимер юлчылар күзгә-күз караштылар.

— Каршылык күрсәтмәс, дип уйлыйм,— дип тынычландырды кизү торучы.

— Җитди гражданин, китаплар укый,— дип өстәде вокзал полицейские.

— Алайса, безне нигә чакырдыгыз соң сез? — диде тыштан керүчеләр.

— Инструкциябез юк шул безнең,— дип иңнәрен җыерды вокзал хезмәткәре.

— Бездә инде бигрәк тә юк... ят җир өчен.

— Бәлки ул рөхсәт ителмәгән берәр нәрсә укыйдыр? — дип аңлатты кизүче.

— Анысын ачыкларга махсус оешма бар ич!

Кизү торучы уйга калды. Чакырылган тәртип саклаучыларга күтәрелеп карады да әкрен генә:

— Сез азат. Борчыган өчен гафу итегез,— диде.

Ят хезмәткәрләр чыгып китте. Кизү торучы үз тәртип саклаучысына шулай ук:

— Сез дә китә аласыз,— диде.

Тегесе, җиңел сулап, бильярд таягы белән шарга бәргәндәй, кулын өскә күтәреп, күздән югалды.

Ялгызы калгач, укучыны шыпырт кына карап алыр өчен, кизү торучы янә зал ишеге төбенә китте. Теге мәзәгрәк җирне укый идеме, залдагыларның кайсылары көлә башлаган иде. Укучы үзе исә кулларын болгый-болгый сиптерә генә!

Шалтыратырга туры килер, дип уйлады вокзал дежуры. Ахыр чиктә, китапта рөхсәт ителмәгән нәрсә булу-булмавын ачыклау аның вәкаләтенә керми, моны белер өчен тиешле агайлар бар, рәхәтләнсеннәр тикшереп.

ә ул вокзал өчен генә җавап бирә (Аның дежурлыгына туры килүен генә күр инде бу хәлнең). Юкса, күтеп утыручыларның берәрсе — алар арасында төрле кеше була — аннан әлегрәк... (шул гына җитмәгән иде!), хезмәт урыныннан файдаланып, шикле бәндәгә шундый мөмкинлек, фәлән-фәсмәтән биргән, дип эшне бозып күрсәтә башлавы да мөмкин... Хатынын, нәни балаларын мөшкел хәлдә калдырырга...

Йөрәге сыкраган дежурный, бүлмәсенә кереп, телефонга ябышты.

Тиздән вокзалда тыйнак кына киенгән шома хезмәткәрләр пәйда булды. Алар, кизүче кабинетына кагылгач, артык күзгә чалынмыйча гына, берәм-берәм залга чыга башладылар. Анда китап укучыга колак сала торган тагын берничә кеше өстәлде. Аларның берсе йоклаганга сабышты, тик үзе ярым ябык керфекләре арасыннан укучыны күзәтүендә булды.

Кизүче кабинетында телефон челтер-челтер килә, анда елдам һәм ышанычлы хәрәкәт кабынуы сизелә иде. Элемтәче берничә мәртәбә шәһәргә дә барып килде. Тиздән өстәлдә төрле-төрле мәгълүматлар, фотосурәтләр һәм бер китап та ята иде инде.

Ул китапның тиешле органнар рөхсәте белән басылганлыгы һәм аны укытмаска бер сәбәп тә булмавы ачыкланды.

Әмма моны белүдән вокзал хезмәткәрләренә бер файда да тимәде. Ир-ат укуын һаман дәвам итте. Станция кизүчесе:

— Шулай да нәрсә эшләргә соң? — дип борсалануында иде.

Бу юлы әлеге ят хезмәткәрләр кечелекле төстә: «Кирәксә, булышырбыз,— диделәр.— Вокзал эшчеләре берниндн кыенлык та кичермәсен. Алар, аңлашыла ки, үз вәкаләтләренә кергәнне күз уңында тотар, әгәр вокзал җитәкчелеге укучыга карата теге яки бу чара күрергә теләсә, комачауламаслар».

Кизүче авыр сулап куйды. Соңгысын искәртмәсеннәр иде инде, болай мәсьәлә тагы да четереклегә әйләнә ләбаса...

Ят хезмәткәрләр күздән югалды. Залда китап укучының үзеннән ни дә булса өстәп җибәрү-җибәрмәвен тикшерер өчен, берсенең шунда утырып калуын кизүче абайлады, әлбәттә. Шул кемсә укучы саташкан урынны, хатаның нинди-леген, юри ясалганмы-юкмы икәнлеген соңыннан ачыклау максатында китабына кызыл кара белән билгеләр сырлап куя.

...Вокзал кизүчесе кыен хәлгә эләккән, җаваплылык янә бары аңа гына өелеп калган иде. Ул, ирексездән, вокзал шикелле катлаулы нәрсә белән идарә итү чамадан тыш кыен шул, дип уйлады. Бигрәк тә төрле көтелмәгән хәлләр булганда. Ул тимер юл идарәсе түрәләренә һәм җәмәгать оешмалары җитәкчеләренә шалтыратырга керешге.

— Кычкырып китап уку кем беләндер килештерелгәнме соң? — дип сорадылар. Вокзал дежурные авыр сулап:

— Юк шул,— дип танырга мәҗбүр булды.

Вәкилләр үзара киңәштеләр дә кизүчегә:

— Без, киңәшмә җыеп, карар кабул итәрбез,— диделәр.— Уку барышында үзгәрешләр килеп чыкса, шундук хәбәр итегез.

Дежур торучы җиңелрәк сулап куйды. Ниһаять, төп җаваплылык аңардан төште сыман. Әлбәттә, аның дежурлыгында булганлыктан, бу хәлне күз уңында тотарга кирәк. Әмма ул барын да тиешле җирләргә вакытында хәбәр итмәдемени?

Эш көне тәмамланып килә, теге ир-ат әле һаман китабын укый иде. Кизүче аны вакыт-вакыт барып караштыргалады. Залда утыручыларның күбесе укучыга колак сала һәм үзеннән-үзе кайбер фикерләрне һәм гыйбарәләрне хәтеренә беркетеп бара иде шикелле. Әмма кизү торучы мондагы тыңлаучылар арасында вокзал эшчеләре һәм пассажирларның рухи сәламәтлеген саклар өчен көрәшүче янә бер уяу, ышанычлы кеше барлыгын да онытмый иде.

Эштән кайтып киткәндә дежурный үзенә алмашка килүчене мондагы хәл белән таныштырды һәм, нинди дә үзгәреш булса, шундук өенә шалтыратуны үтенде.

Телефон төнлә чылтырады. Йокы баскан вокзал кизүчесе китап укучының әле генә залдан чыгып китүен хәбәр итте. Билгесез юнәлештә күздән югалган. Аның артыннан ниндидер бер бәндә дә ияргән, имеш.

— Китүенә нәрсә сәбәп булган икән? — дип кызыксынды җитәкчелек.

— Китабы укылып беткәндер,— диде дежурный.— Өченче яртылар чамасы иде инде. Юлаучылар эскәмиядә йокымсырап утыра, кайберләре, гражданин каты кычкырып укый, дип сукрана да башлаган иде. Әмма аның укуы төнге каравылчыбызга файдалы да булуын әйтер идем.

Инструкция буенча, көтү залында йоклау тыела иде. Төнлә шушы күрсәтмәнең үтәлүен аеруча җентекләп күзәтәләр — залда махсус каравылчы йөреп, йокымсыраучыларны озын таягы белән төртеп уята. Бу пассажирлар иминлеген күздә тотып, берәрсе йокыга оеп, поездыннан калмасын өчен эшләнә иде.

Өендә йокысыннан уятылган түрә:

— Ходайга шөкер, димәк, бар да тәртиптә,— дип канәгатьлек белдерде.

Кизү торучы, иртән җитәкчелеккә һәм җәмәгать оганнарына шалтыратып, киңәшмә ясау ихтыяҗы бетүен шатлык белән хәбәр итте.

Әмма вәкилләр бу эшне тикшерү өчен инде комиссиянең төзелүен, тикшерүне ахырына җиткермичә, аны тарата алмауларын белдерделәр.

— Гражданин юкка чыккач, сез нәрсә тикшерерсез соң? — дип гаҗәпләнде дежурный.

— Анысы инде комиссия эше,— дип җавап бирделәр.— Бүген юкка чыккан, иртәгә пәйда булуы ихтимал. Проблема барыбер калачак.

Вокзал хезмәткәре болай уйлый торган вәкилләрнең хаклы икәнлеген танырга мәҗбүр булды. Кичәге көнгәчә мондый әхвәлнең тумавы рас. Әмма киләчәктә шулай дәвам итәчәген берәү дә гарантияли алмый. Шунлыктан кизүче тимер юл идарәсендәге җитәкчеләрнең теоретик фикерләү тирәнлегенә сокланмый булдыра алмады.

Яшел биштәрле ир-ат иртәгесен төш чагында яңадан вокзалга килеп керде. Кичәге урынына барып басты да бүтән китап укырга тотынды. Гүелдәү кичәгечә үк. эскәмияләрдә төнен йокы күрмәгән юлаучылар йокымсырап утыра, зал аша пассажирлар агыла, поезд көтүчеләрнең күпчелек өлеше яңа кешеләр иде. Әмма гомуми күренеш элеккечә калган. Ашыйлар, сабыйларын чүлмәккә утырталар, сөйләшәләр, беркатлы мәзәкләр, шаярулар кабатлана. Монда һәркем үз үе белән мәшгуль. Бер сүз белән әйткәндә, алар яшиләр иде.

Шул ук җыештыручылар китап укучының килүен хәбәр иттеләр. Кизүче, башын учлары белән тотып, ыңгырашып җибәрде. Бильярд уйнарга иптәш таба алмаганлыктан дежур бүлмәсендә утырган тәртип сакчысы тыныч кына:

— Килер дип уйлаган идем мин аны,— дип белдерде.

Дежурный аңа сораулы карашын төбәп:

— Нигә алай уйладыгыз? — диде.

— Ул иртәгә дә киләчәк әле. Бәлки көн дә шулай килер,— дип җавап бирде тәртип саклаучы, пәйгамбәрләрчә тыныч кыяфәттә.

Вокзал кизүчесе ыңгырашып куйды:

— Ни өчен? — диде.

— Психология! — диде тегесе серле рәвештә.

Дежурный аңа гаҗәпләнеп күз салды. Полицейский аңа ышанычлы төстә:

— Дөньяны төзәтү, халыкны агарту һәм башка әнә шундый бәйләнчек уйлар кымырҗыта инде кешене,— диде. Кизүче, тәртип саклаучының тирән мәгънәле сүзләрен ишетеп, тәмам тетрәп калган иде. Һушына килгәч, вәкилләргә шалтыратты һәм зәгыйфь тавыш белән:

— Ул тагын килеп җитте,— диде.

— Бик әйбәт,— диде вәкилләр.

Шуннан соң дежурный озак икеләнеп торды, әмма ахырда кичәге

шома хезмәткәрләргә дә шалтыратты. Тегеләр аңа бу хәлне белүләрен, моннан ары хәбәр итүнең кирәкмәячәген искәрттеләр.

...Шулай берничә көн дәвам итте. Көтү залында әлеге ир-ат яшел биштәреннән яңадан-яңа китаплар чыгарып укыды да укыды. Булганнарын бетергәч, ул яңаларын алып килә, йә искеләрен кабат күздән кичерә иде. Вокзал хезмәткәрләре хәзер инде аңа күнегә төште. Ләкин кайдадыр еракта, тимер юллар идарәсендә комиссия эшләвен дәвам итте. Поезд көтүчеләр генә битараф иде. Шулай булырга тиеш тә, аларны бүтән бер нәрсә биләве гаҗәпмени?

Вокзал дежурныен әледән-әле комиссия эше белән таныштырып тордылар. Тикшерүнең беренче баскычында комиссия вакыйгага бәя бирде. Үзбаш барлыкка килгән күренешнең төрле яхшы һәм яман яклары бар иде. Беренчесенә иң элек һәвәскәр китап укучының поезд көтүче пассажирларга вакытны культуралы уздыру мөмкинлеге бирүен, аларны әдәбият белән таныштырып, мәгълүм дәрәҗәдә аңнарын үстерүен кертергә кирәк. Бу эшнең кимчелегенә беренче нәүбәттә аның тимер юллар идарәсе җитәкчелеге һәм җәмәгать органнары белән килештерелмәве, аннан да бигрәк, эш алымнарының ялгыш нигезгә корылуы һәм гыйльми оештырылмавы керә иде.

Икенче дәвердә бүтән карарлар да кабул ителде. Әгәр вокзалның көтү залында һәвәскәрләрнең китап укуын кирәксез яки зарарлы дип табылганда, аның белән көрәшү стратегиясен һәм тактикасын эшләргә хаҗәт иде. Әгәр инде нигездә файдалы дип табылганда, аны фәнни нигездә уздырырга һәм кычкырып укуның тәрбияви тәэсирен исәпкә алырга кирәк иде. Эшнең шушы баскычында комиссиянең бер яшь әгъзасы: көтү залында китап укуны үз кулларына алырга һәм шуның белән пассажирларны һәвәскәр китап укучыларның шикле рухи йогынтысыннан коткарырга тәкъдим кертте (комиссиянең бу яшь әгъзасына шундук игътибар иттеләр һәм ары таба аны төрле-төрле комиссияләргә сайлый башладылар).

Тикшерү комиссиясе эшенең өченче баскычында тагын берничә комиссия корылды. Репертуар комиссиясе уку өчен тәкъдим ителә торган китаплар исемлеген төзергә тотынды. Аның нигезенә тәрбияләү канунының тулы бер системасы салынды. Кычкырып укуны уздыру буенча комиссия уку тәртибе, вакыты, тавыш көче һәм аһәңлелек дәрәҗәсе турында инструкция төзергә кереште. Кадрлар сайлап алу һәм әзерләү комиссиясе укучыларны өйрәтү буенча махсус курс оештырырга алынды. Югарыда аталган комиссияләрдән тыш, социологик төркем дә эшли башлады. Ул китап укуның пассажирларга ниндирәк йогынты ясавын өйрәнүне максат итте. Укуны фәнни өйрәнү төркеме әле ни белән шөгыльләнәсен ачыклап җиткермәгән, әмма аның үсеш һәм ары таба киңәю перспективасы гадәттән тыш зур икәнлеге анык иде инде; аннары — арадаш күренешләрне анализлый торган күркәмлек төркеме, психологлар, математиклар, тагын әллә кемнәр җәлеп ителгән бүтән комиссияләр дә барлыкка китерелеп, шуларның бер-икесе яшерен эшкә билгеләнгән иде.

Күп баскычлы оешмалар, шул исәптән, башкала комитетлары да әдәбият тәкъдим итү исемлеген раслаганчы, берничә ай узды. Укучыларны өйрәтү, остаханәләр тарафыннан тиешле трибуналар ясау, уку тәртибен фәнни нигездә юлга салу һәм раслау, үтәлгән эш хакында хисапларны калын текмәгә тегү тагын шактый ук вакыт таләп итте. Ниһаять, газетада тимер юлчыларның кыйммәтле башлангычы турында беренче хәбәрләр дөнья күрде.

Яшел биштәрле кеше исә әүвәлгечә китаплар укый бирде. Фән күпме генә бәхәсләшмәсен, ул кычкырып укуның фәнни нигезе турында белми иде. Шул вакыт дәвамында вокзалга поезд көтәр өчен түгел, аны тыңлар өчен генә даими килә торган берничә әдәбият сөюче пәйда булды. Бу хакта хәбәр биргәч, комиссиянең эше тагын да көчәйде. Әгәр бу укуны дәвам итсәң, көтү залында пассажирларга урын калмау ихтималы хәвефләндерә башлады. Китап укуны бүтән бинага күчерергә тәкъдим иттеләр, ләкин ул очракта бу эш пассажирлар өчен эш-

ләнмәячәк иде. Шуңа күрә махсус инструкция төзергә, поезд көтмәүчеләрне бу залга кертмәскә киңәш бирделәр.

Ахыр чиктә эш шул кадәр алга китте ки, укый башларга да мөмкин иде инде. Аны барыннан да элек яшел биштәрле кеше укыган залда үткәргә, рухи көндәшлек җирлегендә һәвәскәр китап укучыны моннан кысрыклап чыгарырга кирәк иде һәм бу ниятнең уңышлы үтәләчәгенә бер генә галим дә шикләнмәде.

Бөтенесе әзерләнеп җиткәч кенә, яшел биштәрле кеше вокзалдан юкка чыкты. Аның кая китүен берәү дә белми иде.

Вокзал кизүчесе бу хакта тимер юллар идарәсе җитәкчеләренә һәм җәмәгать органнары вәкилләренә хәбәр итте. Алар һәммәсе аптырашка калды. Тимер юлда тәртип саклаучылар ул кешене кире вокзалга алып килер өчен эзләп табарга тырышты, әмма бу эш нәтиҗә бирмәде. Комиссияләр, котәргә кирәк, дигән карар чыгарды. Кемнедер вокзалдан рухи нигездә ярышып кысрыклап чыгару ихтыяҗы калмагач, яңа китап укучының эшкә керешүе мәгънәсен югалта иде.

Шулкадәр шәп башланган чараның гамәлгә ашырылмавына, ихтимал, бүтән нәрсә дә сәбәп булгандыр, моңа әле, мөгаен, ниндидер гомуми закончалык та йогынты ясагандыр. Ничек кенә булмасын, теге ир-ат күзгә-башка чалынмады. Махсус әзерлек алган китап укучылар үзләренә яраклы бүтән эш эзли башлады. Трибуналар келәттә тузан җыеп ята, инструкцияләр сейфларга бикләп куелган иде. Комиссияләр берәм-берәм таркалды. Дөньяда бик күп нәрсә баш калкытты. Шул исәптән, тимер юлда да. Теге комиссия әгъзалары инде байтактан күп кенә бүтән комиссияләр эшенә тартылган иде. Бу кешеләр шундый вазифаны башкарыр өчен туган, аларның инде теге иске, янәсе, гомере озайтылган, чынлыкта исә, таркалган комиссияләрдә катнашырга вакытлары калмаган иде.

Вокзал әүвәлге тормышы белән яши башлаган иде. Кешеләр ашый, сөйләшә, тормыш-көнкүрешне тикшерә, элекке заманнарны искә төшерә. Вокзал кизүчесе тынычланган, чөнки хәзер гомер искечә бер көе ага иде инде. Төнге каравылчы йокыга китүчеләрне, гадәтенчә, таягы белән төртеп уята. Җыештыручылар вакыт-вакыт җитәкче вазифасын үтәргә маташа, һәм, уңышсызлыкка очрагач, үчләрен бичара пассажирлардан ала. Залда китап уку исә бүтән берәүнең дә башына килми иде.

Бары фән генә әле һаман моның белән кызыксынуын дәвам итә. Берәүләр эшкә ашмаган тәҗрибә тарихы буенча диссертацияләр әзерли; икенчеләр, фаразларын киләчәккә күчереп, аны яңа мөмкинлекләр нигезендә гамәлгә ашырырга җыена. Ә кайбер язучылар шул хакта хикәяләр яза иде.

*1967.*

*Т. ЭЙДИ тәрҗемәсе.*

## Пауль-Эрик Руммо

### Тыңлыйм болыт агышларын

Дымык үләндә мин ятам күзем йомып.
Көн ташыдай синең йөрәк күкрәгемдә.
Бөре ача билгесез бер сөю хисе.
Ул — бурычым. Катлам-катлам сагыш миндә.

Тыңлап ятам болытларның хәрәкәтен.

Ябалдашлар чайкалалар, шаулый чаган.
Бал кортлары күче сыман гүли болыт,
Томалана күкнең соңгы ачык төше,
Язылмаган шигырь юлы килә тулып.

Тыңлап ятам болытларның хәрәкәтен.

Кансыз ботакларны кисә кошлар өне.
Ялтыр корыч сыман кояш ала балкып,
Гөрли миндә ярсып аккан кан ташкыны,
Болытларны тыңлыйм үләнгә мин ятып.

## Яан Каплински

Бик тә кысанайдың син, замана,
корт кимерде безнең тарихларны:
күз алдында чикләр чиксез безнең,
миналар да гөлдәй яфрак ярды.

Сыер һәм танклар көтүлектә,—
Нигер елгасы һәм Босфорның
тын култыгы безнең күкрәкләрнең
сул ягында һаман тырпылдаша;
ике Кеннединың һәм абыйсы Мартның,
бабасының җаны күккә аша.

Икмәк амбарлары һәм диварлар
өстендә ач сабыйларның кулы.
Чирү кебек алар һәммәсе ач,
күзләрендә бетмәс хәсрәт тулы.

*

Үткен пычкыдай кырыс җил
яндыра битне уттай.
Аста елга — боздан хасил
булган туң боламыктай.

Карашларым иңли ярын
бу ямансу елганың;
Юаныч юк җанга җирдә,
кирәге дә юк аның.

*ЗӨЛФӘТ тәрҗемәләре.*

# Дебора Ваарандн

## Кышкы төн

Чатный суык,
карлы көртләр ыңгыраша.
Ак төннәргә
текәлгәнмен дүрт күз белән.
Йөзе ап-ак булган шәһәрләрнең
кулыннан эш төшкән —
эндәшмиләр.

Миндә зеңли кышкы төн тынлыгы.

Тәрәз өлгесендә
утлы җиләкләрнең тәлгәшләре.
Идән ярыгыннан күтәрелгән
чәчәк бәйләмнәре куләгәсе
хәтерләтте миңа тоныкк суда
су кыслаларының хәрәкәтен.
Йорт ниргәләренең арасыннан
шыгырдавык юллар килеп керә,
агач ыргыткан күк чәрдәкләгән
куләгәсен читкә —
юл иркенә.
Уянып килгән ай әнә шулай
сурәтемне ясый төн битенә.

Тыңлап ятам балкыган бу җирнең,
салкын йолдызларның хикәятен.
Ләззәтләнеп шатлык белән чумам
бу тынлыкның ап-ак диңгезенә.

Биеклеккә дәшеп, янып тора
якты булып Киек казлар юлы.
Тынлык белән бергә
үсә бара,—
ул —
минем бүлмәдәге кәүсәр суы.

*Мөдәррис ӘГЪЛӘМОВ тәрҗемәсе.*

# Арви Сийг

## Таш назы

Мин — Төньяк улы:
озын буйлы,
кырыс, эшлекле чырайлы...
Нишлим, шул — булмышым минем!
Ә син, мине аңламыйча,
киттең сазлык тарафына,
наз эзләргә җаныңа!

Нинди киңлекләр ачылды
ул сазлыктан бүген сиңа?
Моңаерга мөмкин:
мүкле, торфлы җирдә син.
Каршыңда әнә
зәгыйфь каен ботаклары,
усакларның ләпелдәве,
йоп-йомшак тал песиләре...

Ташлар да бар кырыйда.
Әнә зур соры таш,
утыр шунда.
Ул таш гүя күп «юк» арасында
Калкып торган зур «Бар!» сыман.
Сыенырсың аңа —
кушылырсың таш назына:
кулларың тезеңне кочкан,
тезеңдә — ияген...
Һаман мине уйлап,
кырыс ул, каты...— диярсең...
Ә бит без —
Төньяк ирләре һәм ташлары —
бер үк нәселдәнбез!

Бу таш та,— бел:
кырыс назлы минем күңелем ул!

*Рәдиф ГАТАШ тәрҗемәсе.*

# Вийви Луйк

## Ишекле көзгеләр

Үз теләгең дәште микән сине монда —
Бер чынаяк салкын кофе көтте сине.
Һәр ишеге көзгеләнгән бу кафеда
Бер чынаяк салкын кофе көтте сине.

Февраль җиле үзе өшеп төшеп калды
Елтыр ишекләрне ачып кергән чакта.
Төшеп калды әйбәт җылы бияләең
Елтыр ишекләрне ачып кергән чакта.

Ашыга-ашыга чишенгәндә, бер очтан син
Салып бирдең кебек хәтта гомереңне дә.
Көзге йотты бүрегеңне, йөрәгеңне —
Салып бирдең кебек хәтта гомереңне дә.

Сорау бирде сиңа кемдер: «Кай тарафтан?..» —
Син аңлаттың бер чынаяк гозереңне.
Һәм әйттеләр, ишекләрне ябабыз, дип.
Аңлатырга теләдең син гозереңне.

Озаттылар сине куып. Ә урамда
Ак болытлы төшләреңне таныдың син.
Җан кадерен, яр кадерен, ил кадерен —
Ак болытлы төшләреңне таныдың син.

Ир язмышы, яр язмышы, ил язмышы
Шул болытлар арасында чагылды бит.
Чагылырмы алар синең күзләреңдә?
Көзгеләрнең ишекләре ябылды бит...

*Нияз АКМАЛ тәрҗемәсе.*

# ПУБЛИЦИСТИКА

## Җәмит Рәхимов

# АККОШЛАР ЧАЛПЫДА КАЛА

Сеңдереп кенә ләйсән явып үтте. Яңгыр артыннан ук чалт аязып, күк йөзе ачык зәңгәргә манчылды. Чәчүгә төшәр чак бу! Дулап-ташып алган елгалар ярларына кайта, дымлы буразналардан пар күтәрелә. Авыл артындагы урман зәңгәрсу томан эчендә — куаклардагы җиз алкалар серкә очыра.

Кинәт көмеш кыңгыраулар чыңлагандай булды. Аваз урман эченнән түгел, өстән — зәңгәр киңлектән ишетелә иде. Кыр казлары һәм аккошларның кайтып барышлары икән. Аларның дистәгә якыны, олы төркемнән аерылып, берaз түбәнәйде дә Атау күле өстендә әйләнергә тотынды. Затлы кошлар авыл халкы кодрәте белән барлыкка китерелгән бу күлне тәмам үз итте. Әнә әле дә, инде монда хуҗа булырга өлгергән чүрәкәй үрдәкләрне өркетеп, су өслегенә килеп тә төштеләр һәм, тагын да дәртләрәк чаңгылдашып, түргә йөзеп киттеләр. Һәр хәрәкәтләрендә иркәлек тә, наз да, горурлык та бар.

Шул арада кайсы күреп алгандыр — сөенечле хәбәр инде бөтен Чалпыга таралган иде.

— Атау күленә аккошлар төшкән!!!

Чалпы — Ык буендагы зур авылларның берсе. Егерменче-утызынчы елларда моннан Баланлы-Бүләк, Камышлы, Наратлы һәм Каенлы күл авыллары аерылып чыккан. Әмма Чалпы үзенең олпатлыгын саклап калган.

Соңра исә замананың зәхмәтле җиле кала-станцияләрдән, поселок-пристаньнардан шактый еракта яткан Чалпыга да килеп җитә, авылга «кырау тия». Яшьләр, беләкләренә букча асып, шәһәр юлларына чыга, кайбер йортларның тәрәзәләренә аркылы такталар кадаклана. Боегып, моңсуланып кала Чалпы, юмарт иген кырларыннан бәрәкәт китә башлый.

Әнә шундый шомлы көннәрнең берендә авылга килеп төшкән Илдус Гыйлаҗев беренче күренешләр тәэсирендә:

*Комсыз көя кергән бу авылга,*
*Казыгына хәтле кимергән.*
*Алмагачлар үскән бакчаларда*
*Әрем белән билчән симергән, —*

дип язып куя дәфтәренә.

Туган авылы булмаса да, Чалпы Илдуска ят түгел иде. Әле кайчан гына ул шушындагы урта мәктәптә укыды, яшьтәшләре белән бергә ваемсыз мизгелләр кичерде. Бүген исә ятимләнеп калган авылның бөтен моң-зарын аның җилкәсенә салдылар. Отчет-сайлау җыелышыннан соң урамнарны озак урады Гыйлаҗев, ярыкларыннан көзге җил сызгырып торган фермаларга барып керде, янә сагышлы урамнарга әйләнеп кайтты, үзе туктаусыз баш ватты. Фермадагы сыерларны бер саудыру өчен, район җитәкчеләре, Азнакайдан килеп, өлкән яшьтәге җиңгиләрне үгетләп йөргәннәр — шул хуҗалык хакында ни дисең инде?!

Тын калган боек урамнарда бәрелеп-сугылып йөргәндә уйларына шигъри юллар сарыла яңа председательнең. Ачулы юллар:

*Бәгыреңне чагып алыр төсле,*
*Кычытканнар үскән үчекләп;*

*Кайтарасы килә хуҗаларын*
*Кычыткannар белән «пешекләп».*

Чалпының яшьлеген кайтару, үзән-кырларга бәрәкәт иңдерү кирәк иде...

Кичке урам. Тик ул без тәгәрәшеп үскән авыл урамы түгел инде. Уртасына асфальт түшәлгән, ике яклап таш пулатлар төзелгән. Хәер, бүген — июль кояшы шашып тантана иткәндә — әлеге гүрничәләр күзгә чалынмый диярлек. Алма, чия бакчалары аларны кеше күзеннән яшергән. Арттарак — абзар-кура.

Авыл урамы да, шәһәрнеке дә түгел, киләчәк проспекты икән ләбаса бу! Каршыга, чыр-чулап чабышып, бер көтү бала-чага килеп чыкты. Санап кына бетерерлек түгел үзләрен. Колхозның профсоюз оешмасы председателе Рузалина ханым Гаффарова дөресен әйткән икән. «Бер урамда йөзләп бала», — дигән иде ул.

Әйе, бала-чага байтак монда. Өченче ел утыз биш сабый тууы теркәлгән Чалпыда, былтыр — утыз өч. Башлангыч классларда укытучысы Мәүлиха ханым Шәрипова белән юлда булып узган сөйләшүебез искә төшә. Өченче ел Чалпы урта мәктәбенә уникe бала башлап аяк баскан, аннары — унҗиде, 1990 елда алар инде егерме дүрт булачак.

Бала-чаганың ишәя баруы Чалпының яшен-картын, игенчесен, укытучысын куандыра. Ачык тәрәзәләрнең берсеннән бишек җыры ишетелә. Яшь ана бәбиен йоклата бугай:

*— Кук-ку, чыпчык!*
*Тәрәзәдән керен чык.*
*Минем газиз балама*
*Тыныч еллар бирен чык.*
*Минем тәти балама*
*Имин еллар бирен чык!*

Күр инде, Илдус Гыйлаҗевның беркөн өлкә газетасында басылып чыккан шигыре ич! Яңа сүзләр аналар күңеленә хуш килгән, димәк. Председатель үзе дә, хатыны Рәйсә ханым белән, бер оя кызлар-малайлар үстерәләр шул.

Кичке урамга да балалар хуҗа булып алган. Чыр-чу киләләр. Балаларны аралап атлый-атлый, күз төшкән беренче капкага борылабыз. Бөтен уңайлыклары булган өйдә Хәснетдиновлар гаиләсе яши икән. Йорт хуҗасы Илдус — колхозның машина-трактор утарында токарь. Шушы Чалпы урта мәктәбен тәмамлаган һәм мәктәптә тәрбияче булып эшләүче Гөлсинәгә өйләнгән. Яшь гаиләгә колхоз квартира биргән. Мондагы гадәт буенча, башта ике бүлмәле фатирда яшәгәннәр, әле күптән түгел өч бүлмәле өйгә күчкәннәр. Тормышлары матур, күңелле. Бар да җитү, мохтаҗлыклары юк. Илдусның әти-әнисе дә гомер бакый туган авылында яшәгән, иген иккән икән.

Сөйләшә торгач, авылга төс биргән мондый яшь гаиләләрнең шактый икәнлеге ачыкланды. Менә Бәрия белән Гыйззетдин Гыйлаҗевлар гаиләсе. Шушы хуҗалыкта эшли-эшли, җиде бала үстергәннәр. Узган ел гына урта мәктәпне тәмамлаган кызлары Ләлә терлекчелектә эшли башлаган. Урта белемле абыйлары Марат һәм Иршат белән өчәүләп, гаилә подряды оештырып җибәргәннәр, биш йөз баштан артыграк терлек симертәләр. Марат кибетче кыз Гөлнарага өйләнгән. Колхоз идарәсе аларга бөтен уңайлыклары булган фатир ачкычы биргән.

Саттаровлар нәселе дә авылда төпләнүчеләрдән. Династия башы Миңлемөхәммәт — нефтебаза мөдире, хатыны Флера сыерлар сава. Шофер һәм тракторчы һөнәрләренә ия булган уллары Самат, Совет Армиясе сафларында хезмәт итеп кайтканнан соң, 1984-85 елларда колхоз комсомол оешмасын җитәкләде, хәзер — бригадир. Читтән торып техникум тәмамлаган. Савымчы Раушания белән матур тормыш корып җибәргәннәр алар. Гаилә мәшәкате арткач, Раушания җиңелрәк эшкә, идарәгә күчкән. Саттаровларның быел гына армиядән кайткан икенче уллары Марат автомобиль руле артына утырган, унынчыга күчкән кызлары Рәмзия, классташлары белән бергә, бик тырышып кәбестә үстерә.

Авылда Фазлыевлар, Камалиевлар, Зәкиевләр, Хәбибуллиннар, Сафиннар, Гаффаровлар, Шәрәфиевләр, Хәйруллиннар хакында да сокланып сөйлиләр. Нурулла ага Хәйруллин үзе атказанган колхозчы иде. Гомеренең соңгы көннәренә кадәр тынгы белмәде, сиксән яшенә кадәр эретеп ябыштыруда эшләде. Унбер бала табып үстергән һәм шуның өчен Герой ана исеме алган Әнисә исә кибеттә сату итте, инде пенсиягә чыкты. Уллары — механизаторлар. Өйләнеп, күркәм гаилә кордылар...

Ата-баба һөнәрен уз иткән яшь гаиләләрне күпме генә санасаң да, очына чыга алмас идең. Нигә дисәң, алар айның-аенда арта тора. Гаиләләр ишәя, шатлык үрчи

бара авылда. Чөнки, председательнең шигырьләрендә әйтелгәнчә:

*Чират — бездә: борынгыдан*
*Иген игү — ирләр даны.*
*Зур өметләр баглап, чәчеп,*
*Бик кадерләп җыям аны...*

Үзәк урамга аеруча купшы йортлар салынган. Игезәкләрдәй бертөсле булулары гына эчне пошыра пошыруын. Алай да күплегенә күңел сөенә. Колхоз маясына төзелгән бу көяз өйләрнең саны җитмешләп. Баштарак әнә шулай зурдан кубып тотынганнар Чалпыда. Илдус Сабирович исә, председатель булып эшли башлавына, андый өйләрнең авыл өчен уңайсыз икәнен абайлап ала һәм аларны салуны туктата. Крестьян тормышына бик үк кулай булмаса да, ике катлы өйләр дә буш тормый тагын. Яңа өйләнешүче яшьләргә квартираны башта шул йортлардан бирәләр.

Егетләрнең уңганы колхоз җилкәсенә генә салынып ятмый, үзләре бил буып, ата-баба нигезен яңартучылар да шактый. Димәк, авылга ныклы тамыр җибәргәннәр яшьләр. Шулай, туган җирендә гомергә төпләнергә ниятләгән кеше өй сала, абзар-курасын тутырып мал асрый. Шик тә юк, авылга мәңгелеккә дип төпләнгән болар! Егетләрнең һәм кызларның тамырны тирәнгә җибәрүләре тагын шуның белән дә раслана: гаиләләр тату, нык, аерылышу дигән хәлне белмиләр икән Чалпыда.

— Минем килен булып төшүемә инде унбиш ел, — дип сөйли Рузалина ханым Гаффарова, — шул гомер эчендә таркалган бер генә гаиләне дә хәтерләмим.

Өстәвенә, Чалпы авыл Советы җитәкчеләре дә, ил картлары да гаиләләрнең дуслыгы өчен өзлексез һәм җитди көрәшәләр монда. Авыл күмәк тырышлык нәтиҗәсендә үсә, яңара, яшәрә! «Коммунизмга» колхозының иксез-чиксез кырлары буйлап йөргәндә бу хәлгә тагын бер кат инанасың. Куәтле комбайннарның күбесендә — Айдар, Дамир, Раушан, Айрат, Зиннур, Равил, Хәлил кебек училище бетергән яисә әле таныклык алырга да өлгермәгән яшь егетләр. Комсомол-яшьләр агрегатының берсе янында колхоз комсомол оешмасы секретаре Хәлил Хәлимов белән очрашырга туры килде. Ул әле 1982 елда ук, урта мәктәпне тәмамлагач, «Этиләр җире — безнең җир!» — дип оран салган һәм, авылда калып, әйбәт кенә эшләгән. Совет Армиясеннән соң хуҗалыктагы илле алты тракторның берсен аңа тапшырганнар. Хәзер Хәлил — комсомол җитәкчесе. Әмма эш өстендә йөрәге түзми механизатор егетнең, ашлык язмышы өчен көрәш мәйданына керә. Өстәвенә, Казан авыл хуҗалыгы институтының механика факультетында укый да икән ул. Кыскасы, гәпләшеп торырга вакыты юк Хәлимовның. Алай да авылдагы 436 колхозчының 130 ы комсомол яшендәге кызлар һәм егетләр булуын, оешмада йөздән артык әгъза икәнен әйтергә өлгерде.

— Колхозда эшче куллар җитешмәүдән зарланмыйбыз, — дигән иде Илдус бер сөйләшеп утыруыбызда.

Чыннан да, шулай икән. Кайчандыр моннан чыгып сызучылар да, авыл күлләренә аккошлар төшүен, басуларда бәрәкәт артуын ишетеп, кире кайта башлаганнар. Раушан Латыйпов, хатыны Ританы һәм ике баласын җитәкләп, Калинин өлкәсеннән үк кайтып төшкән. Колхозда автомеханик хәзер. Гариповлар да шәһәр фатирына кул селтәгәннәр.

Башка кала-сала кешеләре дә, колхозга алуын үтенеп, Илдус Гыйлаҗевка килгәлиләр. Әмма председатель кешеләрне читтән җыю ягында түгел, бөтен өмете — Чалпының үз яшьләрендә һәм бу өмет елдан-ел аклана бара.

Шулай да моңа ничек ирешә соң ул? Ничек итеп игенче һөнәренә күңелләрен утырткан яшьләрнең? Соравыбызга җавап эзләп, Үзәк урам буйлап түргәрәк узыйк! Як-яктагы корылмалар кинәт үзгәрде, биекләре калкып чыкты. Болары — җәмәгать биналары: кунакханә, элемтә бүлеге, көнкүреш йорты, аптека, шифаханә, ашханә, сәүдә үзәге... Дүрт кибеттә азык-төлек, промышленность, хуҗалык һәм культура әсбаплары сатыла. Китаплар өчен дә аерым бүлек бар. Нәкъ шәһәрдәгечә! Ике катлы административ бина, аңа каршы гына — культура-спорт комплексы. Халык өчен бик мөһим булган Культура йорты, стадион, бию мәйданчыгы, китапханәсе, ачык сәхнә кебек объектларны берләштергәндә шулай атала икән ул.

Чалпыга газны баллоннарда гына ташыйлар иде, хәзер егерме биш чакрым арага торба салып, урамнарга сузалар. Асфальт түшәүлек астындагы су һәм җылылык челтәре янына газ юлы ята. Әмма бурычларның яңадан-яңалары туа тора. Колхозның санаторий-профилакторие дә булачак икән! Аның ачылу көннәре дә ерак түгел. Кымыз әчетергә өйрәнәләр. Җыйнак кына таш бина янында, нәкъ шәһәрдәгечә, бензоколонка көйләнә. Мотоциклларга, шәхси машиналарга хезмәт күрсәтеләчәк. Колхоздагы планнарның тагын берсе — ипподром булдыру, ат спортын җайга салу. Баланлы-Бүләк бригадасында атлар үрчетү башланган.

Авылда шушы яңарышны күргәч, яшьләрнең авылга ябышып яту сере ачыклангандай була. Тик, монда көн дә бәйрәм, көн дә туй, дип ялгышмыйк. Эш шартлары-

ның әйбәт булуы, хезмәттәге авыр процессларның машиналарга тапшырыла баруы да бик мөһим. Машина-трактор утарында берсеннән-берсе мәһабәт биналар төзелгән: комбайннар өчен гаҗәеп зур корылма салынган, тракторлар — җылы гаражларда, тырма, культиватор кебек тагылма машиналардан кала бөтен техника коры, җылы урыннарда саклана. Теләсә нинди маркадагы машинаны төзәтү өчен барлык җайланмалар бар. Мәйданы тулысынча асфальтланган бөртек хуҗалыгы, КамАЗлар бик иркенләп борылып йөрешле ябык ындыр табаклары, берсеннән-берсе шәбрәк саву, су бирү, тирес чыгару җайланмалары, өсте ябулы стадионнарны хәтерләткән терлек азыгы саклау биналары — барысы да кешенең мәшәкатен киметүгә, тормышын бизәүгә юнәлтелгән.

Мәктәпкәчә яшьтәге балалар «Чулпан» исемле бакчада тәрбияләнә. Башлап күзгә бәрелгәне — шәһәрчәлек: тигез, киң аллеялар, чәчәк түтәлләре, көймәле арбалар... Ул башта ук олы калалардагы бакчалар проекты белән, зурдан кубып 140 урынлы итеп салынган. Чалпы өчен бер дә артык булыр сыман түгел. Биредә инде бүген үк 105 бала тәрбияләнә.

Махсус белемле музыка укытучысы Резеда Гыйлаҗева (колхоз председателенең өлкән кызы) пианинода бик шәп, грамоталы итеп татар һәм рус композиторларының әсәрләрен уйный, балаларны җырларга өйрәтә, аларны гүзәллек дөньясына әйди.

Резеда гына түгел, бакчадагы ун тәрбиячөнең һәркайсы махсус белемле. Алты яшьлекләрне укыту һәм аларны мәктәпкә хәзерләү дә шушы педагоглар җилкәсенә төшә. Кыскасы, барысы да нәкъ шәһәрдәгечә. Бераз аерылса да, биредәге тәрбия эшләренең ана телендә алып барылуы, аш-суның гел яңа ризыклардан әзерләнүе белән аерыладыр, мөгаен. Юк, юк, «Чулпан»ның тагы бер үзенчәлеге бар икән әле: бакча ишегалдында нәни-нәни түтәлләр тезелеп киткән. Аларның берсендә суган кыяклаеп утырса, икенчеләрендә шалкан, кишер күтәрелеп килә... Яшелчә һәм чәчәкләрне балалар үзләре су сибеп, утап-карап үстерәләр. Менә бит хикмәт нәрсәдә: җиргә, авылга мәхәббәт шушында — балалар бакчасында ук бөреләнә икән ләбаса! Сабыйлар, билгеле бер сәгатьләрдә, урман-кырларга, фермаларга да барып йөриләр, әти-әниләренең эшләрен күреп үсәләр.

Урам аша гына тагын бер нурлы бина. Як-якта җиләк-җимеш агачлары — урманмыни?! Куелыктан бала-чага тавышы ишетелеп киткәндәй булды. Мәктәп бакчасы ике ярым гектар икән. Укучылар алма, чия, кура җиләге, карлыган кебек җиләк-җимеш һәм яшелчә үстерәләр. Узган ел үзләренең ашханәләре өчен центнердан артык варенье кайнатканнар, калган җиләк-җимешне авыл халкына сатканнар. Халык табынына балалар көче белән үстерелгән унике центнер суган һәм сарымсак та куелган.

Укучылар бик теләп әти-әниләренә дә булышалар, кырларда, ындыр табагында, фермаларда эшлиләр. Директор Рөстәм Исламов: «Безнең бер дигән остаханәбез, Т-40 маркалы тракторыбыз, саву агрегатыбыз бар, — дип сөйли. — Колхозның машина-трактор утары, фермалары шулай ук безнең карамакта. Аттестат белән бергә, механизатор һәм савучы оператор һөнәрләре дә алып чыгалар бездән. Урта мәктәпне тәмамлаганнарның яртысы колхозда кала хәзер».

Мәктәпнең музеенда авыл тарихын яктырткан әйберләр һәм борынгы китаплар күп. Биредә теләсә кем ике-өч сәгать вакыт эчендә Чалпы тарихы белән яхшылап таныша ала. Борынгы кульъязма һәм басма китаплар муллыгына карап, авыл кешеләренең электән үк белемгә, яктылыкка-нурга омтылуын тоясың.

Әйе, Чалпыда бөтен нәрсә җир-суга, авылга мәхәббәтне бишектән үк тәрбияләүгә юнәлтелгән. Мәктәптә уку-укыту эшләре ана телендә алып барыла, җыр-рәсем дәресләренә, үзешчән сәнгатькә, гомумән, матурлык дөньясына аеруча әһәмият бирелә. Тик монда да чишеләсе мәсьәләләр — муеннан.

— Балалар өчен татарча җырлар бик аз, — дип офтана Лениногорск художество-музыка педучилищесын, аннан соң Казан дәүләт университетының тарих факультетын тәмамлаган Исламов. — Җыр-рәсем дәресләре буенча адәм рәтле программа юклыгы да эчне пошыра...

Азнакай якларында юллар такыр, тик соңгы елларга хәтле алар бер яклы гына эшләде — Чалпы суын эчеп үскән урта белемле яшьләр китә тордылар, әйләнеп кайтучылар юк иде. Бу хәлгә иң нык өзгәләнүчеләр мәктәпнең элекке директоры Мөстәкыйм ага Салихов белән колхоз председателе Илдус Гыйлаҗев булгандыр, мөгаен. Башлап мәктәптәге бөтен укыту-тәрбия эшен авыл хуҗалыгына якынайтырга кирәк иде, әлбәттә. Тәҗрибәле педагог җитәкчелегендә укытучылар моңа ирештеләр — укучылар мәктәптән әти-әниләре һөнәрләрен алып чыга башлады. Инде, колхоз идарәсе белән

киңәшеп, конкрет эшкә тотынырга мөмкин иде. Көннәрнең берсендә Мөстәкыйм Салихович, әзер уй-исәпләре белән, колхоз председателе кабинетын ачып керде.

Уй-теләкләре уртак иде, бәхәсләшергә туры килмәде. Урта мәктәпне тәмамлаган егет-кызларны, бер генә елга булса да, туган авылларында калдырырга мөмкин, дигән карарга килделәр алар. Эш балаларның үзләренә һәм эти-әниләренә кайтып калды. Укучылар һәм өлкәннәр арасында алар сүзен хуплаучылар көткәндәгедән күбрәк булып чыкты. Бу — 1982 елның язы иде.

— Шуннан бирле укучылар авылда эшкә кала, — дип сөйли Салихов аганың эшен дәвам итүче Рөстәм Фәүзелович. — Бер елга гына да түгел. Яшьләрнең яртысы монда бөтенләйгә төпләнеп кала. Теләүчеләр, колхоз исәбенә, югары уку йортларында укый...

Сөйләве ансат ансатын, тик моңа ирешү җиңел генә булмый. Мәктәп дирекциясенә, колхоз идарәсенә һәм җәмәгать оешмаларына гамәл-шөгыльләрен тамырдан үзгәртеп корырга, байтак кына чыгымнар тотарга да туры килә.

— Булмагае, — ди, бу хакта сүз чыккач, Илдус Сабирович, — кадрлар хәстәрен күргәндә, акча кысудан файда юк.

Әйтик, авылда калган кызларга беренче елда, төп тияренә өстәп, хезмәт хакының илле проценты, икенче елда — кырык проценты, өченче елда — утыз проценты түләнә. Егетләргә исә өстәмә түләү беренче елда — кырык процент, икенче елда — утыз, аннан инде — гомуми нигездә. Беренче карашка, гаделсезлек кебек тоелган бу чараның үзенә күрә сере бар. Хикмәт шунда: кызлар әле һаман да кителгәннән азрак кала колхозда.

*«...Ябык букча асып беләгенә*
*Тагы бер кыз китә авылдан»*, —

дип юкка пошынмый шагыйрь председатель. Уфтанырсың да, колхозның бер Баланлы-Буләк бригадасында гына да бүген уналты егет кәләш эзли. Булачак киленнәрнең байтагы исә әле да кала торакларының тол тормышлы ягын каера. Шуңа да сыкранып кына утырмый Гыйлаҗев, кызларның күңелен авылда утырту өчен яңадан-яңа юллар эзли. Чалпыда ачылачак тегү цехы — әнә шул чараларның берсе.

Хәер, егетләр өчен дә махсус ташламалар каралган. Мәсәлән, колхозда калган егет, вакыты җитеп, армия сафларына китә икән, аның исәбенә ике ел буе ай саен егерме бишәр сум акча салып баралар. Инде кайтып, авылда ярты ел эшләгәннән соң, аның кулына берьюлы җыелган 600 сум акча бирелә. Яңа өйләнешүчеләргә чиратсыз квартира бирелүен дә кабатласак, «Коммунизмга» колхозында егет-кызлар өчен никадәр уңайлыклар тудырылуы күз алдына килә булыр.

Яңа никахлашучыларга өч көнлек ял, һәркемгә — атнага бер ял көне эш стажына карап, елына 18—24 көн ял бирү гадәткә кергән монда. Санаторий, ял йортларына путевкалар да бирелә. Узган ел гына да җитмешләп колхозчы илебезнең төрле курортларында көч туплап кайтканнар. Исәнлегенә карап, кешене җиңел эшкә күчерү, эш киемнәре, сәламәтлек өчен зарарлырак хезмәттәгеләргә бушлай сөт бирү, халыкка печәнен-саламын, утынын-ташкүмерен кайтару хезмәт хакының бер өлешен икмәкләтә түләү, бөртекне махсус тегермәндә тарттырып алу һәм башка күп кенә чаралар авыл кешесе кинәнеп яшәсен өчен эшләнә.

Бу якның басулары бормалы инешләр, дымык яткыллар, сөзәк чагыл-кашлаклар белән ергаланган. Алар тирәсендә ләкә-ләкә чирәмлекләр. Араларында сабан керешләре дә юк түгел. Шуларның берсе авыл читеннән үк башлана.

— Боларны ничек сөрми торасыз соң әле? — дип сорадым Гыйлаҗевтан.

— Нигә сөрергә?! — диде ул. — Анда маллар йөри. Аннан...

Авылдан еракта гы исемсез инешләрнең берсе буйлап сазлыклар, алардан өстәрәк текә булмаган кашлак сузылган. Бер булса да яңгыр явып үткән, күрәсең, шушындый коры җәйдә дә тыгыз булып үлән күтәрелгән. Ул арада печәнчеләр янына килеп чыктык. Председатель:

— Пенсионерлар. Терлекләренә печән чабалар, — дип аңлатты.

Икенче юлы бикле идарәгә туры килеп, тагын да гаҗәпләндем. Уттай эш өстендә бит!

— Бүген берәүне дә очрата алмассыз шул, — диде миңа бер ханым. — Бала-чагадан алып аксакалларга кадәр берьеллык үлән басуында. Чапкычлар егып ташлаган печәнне бүлделәр.

Тагын чирек сәгатьтән Баланлы-Буләккә бара торган олы юл буендагы кырда идем мин. Басу тулы халык, кипкән печәнне чүмәләләргә куеп мәш киләләр. Һәр эшләүчегә егермешәр «сотый» исәбеннән биргәннәр икән.

— Бер сыерга күпмегә җитәр дисез инде моны? — дим, чүмәләләргә ымлап.

— Саграк тотканда, ике кышка тартыр.

Бераздан монда Гыйлаҗев үзе дә килеп чыкты. Мин аны сукраныр, шушы кадәр кешенең колхоз эшеннән аерылуыннан зарланыр, дип көткән идем. Ул исә, тирән бер канәгатьләнү белән бөтенләй башка сүз әйтеп куйды:

— Көзен берәр машина салам да бирсәк...

Әйе, кеше турында кайгырту, аның кадере һәрчак беренче планда монда. Өлкәннәр исә — аеруча. Кем дә булса пенсиягә китә икән, аны бик зурлап лаеклы ялга озаталар. Культура йортында яисә «Болгар» кафесында, бөтен авылдашлар алдында, иң матур, иң изге теләкләр әйтелә аңа, истәлеккә затлы бүләк бирелә. Сугыш һәм хезмәт ветераннарына елына бушлай бер машина утын, печән-салам китертелә. Һәркайсы икмәк һәм карабодай ярмасы белән тәэмин ителә. Мохтаҗлыгы булганнарның өйләрен төзәтеп торалар. Электр энергиясенә дип, елына уникешәр сум акча түләнә. Бәйрәмнәрдә алар хөрмәтенә чәй мәҗлесләре үткәрелә, бүләкләр тапшырыла.

Кадер-хөрмәт берәүне дә читләтеп үтми: һәр айның мәгълүм бер көнендә «Шәфкать көннәре» билгеләнгән. Бу көнне барлык депутатлар, агитаторлар һәм башка активистлар карт-коры, карчык-корчыкның өйләренә барып хәл белешәләр, мохтаҗлыкларын, кемгә нинди ярдәм кирәген ачыклыйлар.

Җитез «Нива» тигез таш юлдан Камышлы авылына ашыга. Як-ягына яшел чаршау булып агачлар күтәрелгән әлеге юл колхоз көче белән салынган. Каршына без килеп туктаган бина — кырык-илле йортлы авыл өчен салынган, ике катлы заманча клуб икән. Бинаның бер башы ярдәмчесез калган карчыкларга тәгаенләнгән, мондагыча әйтсәк, «Картлар йорты». Тугызынчы дистәне куучы Мәүрүрә Миңлеголова, Мөнирә Әхмәдуллина, Гайфә Хәбибуллина кебек сигез ятим әби тәрбияләнә икән монда. Алар инде кайсы аксак, кайсы сукыр... Алай да күңелләре көр, йөзләрендә канәгатьлек билгеләре. Нигә дисәң, иркен бүлмәләре (алар бер бүлмәдә икешәр кеше яши) җылы, чиста. Ап-ак урын-җир. Ашау-эчү, балалар бакчасындагы сыман ук, саф-чиста ризыклардан. Радио, телевизор кебек техника могҗизалары гадәти әйбер монда. Карчыклар даими рәвештә медицина күзәтүе астында.

— Башлыкларга рәхмәт яусын, — дип сөйләп китте Мәүрүрә әби, безнең хәл-әхвәл сорашуыбызга каршы. — Өебезне, урын-җиребезне үзегез күрдегез. Инде тәрбиягә килгәндә, артыгын сөйләп тормастан, мөдиребез Гөлүзә Ибраһимованың җитәкләп мунчага алып баруын, үз куллары белән чабындыру-юындыруын гына әйтсәк тә, җитә булыр.

Үзе пенсия яшендәге атказанган колхозчы, элекке ферма мөдире Гөлүзә Ибраһимовага гына түгел, тәрбияче Флера Вафина белән аш-су остасы Ләйсән Галиевага да ихлас мактау сүзләре, рәхмәтләр ява.

Камышлы авылы хәзер башка колхозга керә, әмма «Картлар йорты» «Коммунизмга» карамагында калган.

— Аңа елына унике мең сум тотабыз, — ди Илдус Сабирович. — Сүз җаеннан гына әйтүем. Кеше өчен акча җәл ди мени?! Беркайчан да мохтаҗлыкта калмаячакларын күреп үссеннәр яшьләр.

Чалпыда илле бер кешенең исеме — колхозның Почет китабында. Без анда гомерлек комбайнчы Мөхлис Шәфигуллин, Хезмәт Кызыл Байрагы орденлы Даимә Гатауллина, Татарстанның атказанган механизаторы, «Почет билгесе» орденлы Әхәт Шәехов, күкрәгендә хөкүмәтебезнең өч олы бүләген йөртүче коммунист Әҗүәт Нуретдинов, гомерлек терлекче, колхозның персональ пенсионеры (бу исемгә ирешкәннәр, төп пенсиягә өстәп, ай саен тагы егерме бишәр сум акча ала) Тәнзилә Мөхәммәтҗанова һәм башкаларның фамилияләрен укыйбыз. Егерме ике кеше исә «Атказанган колхозчы» исемен йөртә. Сиксәнгә кадәр күмәк эштә эшләгән Әхмәт Гарипов, Хаҗи Гаффаров, Гата Вафин, Фахразый Кәримов, Әгаз Ярмиев, Нәфис Идиятов, Галимә Вәлиуллина, Мөсәлия Мөэминова, Нәҗибә Шаһина һәм башкалар әнә шул мактаулы исемгә лаек булган.

Шунысын да әйтергә кирәк, югарыда телгә алынганнарның күбесе әле бүген дә колхоз эшеннән туктаганнары юк. Әнә, авылдагы җитмеш өч пенсионер бу җәйдә дә, яшьләр белән иңгә-иң торып, ил муллыгы өчен тырыша. Аларның барысы да диярлек осталар. Җөмләдән, Социалистик Хезмәт Герое Фахразый Кәримов ел саен өч-дүрт егетне комбайнчы һөнәренә өйрәтми калмый. Башкалары да шулай.

Уртак кайгыртудан берәүнең дә мәхрүм булмавын кабатлап әйтәсе килә. Хәтта үлгәннәрнең дә. Берәү дөнья куйса, бөтен авыл куба монда. Карты-яше аны, йола кушканча, олылап-хөрмәтләп соңгы юлына озата. Авыллардагы зиратлар шәп итеп рәшәткәләп алынган, каберләр төзек, чиста. Илебез азатлыгы өчен шәһит киткәннәр рухы аеруча хөрмәттә. Авыл саен һәйкәл куелган. Яннарында — чәчәкләр, мәңге яшел агачлар.

*Үз тарихын үзе оныткannар*
*Таба микән җирдә кадерне?*

*Йорэк эши, курсэң онытылган,*
*Алабута баскан каберне...*

Әгәр дә җирдә оҗмах булса, аны шушы Баланлы-Бүләктә ачарлар иде, мөгаен. Авылны дүрт ягыннан да хәтфә кырлар, бөдрә урманнар урап алган. Яшел дулкын йортлар арасына ук килеп кергән. Төп урамны затлы келәмдәй бәпкә үләне каплаган, өйләр — көяз алмагачлар ышыгында. Тып-тын, һәр тарафта — хөрлек, иркенлек. Монда яшәүчеләр дөньяның иң бәхетле кешеләредер дип, көнләшеп куясың хәтта. Элегрәк, Баланлы-Бүләк үзбаш колхоз чакта, чыннан да, үзләрен җәннәттәгедәй хис итүчеләр бирелдегеләр.

Вакытлар үтеп, авыл «Коммунизмга» колхозының бер бригадасы булып калгач, шау чәчәккә күмелеп утырган Баланлы-Бүләккә кырау төшкән, аңа «перспективасыз» дигән тамга сугылган.

Беренче тапкыр Баланлы-Бүләкне, әйткәнебезчә, әнә шул хәлендә килеп күрә Гыйлаҗев һәм, йөрәге сыкрап, нәүмизләнеп кала. Аның «Ятим зиратлар» шигыре әлеге борчулы, әрнүле төннәрнең берендә ак кәгазьгә төшкәндер:

*Басу уртасында яшел утрау,*
*Учма-учма каен, наратлар.*
*Яшел сагыш булып сибелгәннәр*
*Авылларсыз калган зиратлар.*

Дөрес, Баланлы-Бүләк андый ук хәлгә төшмәгән әлегә. Алай да, чарасын күрмәгәндә, авыл урынында ятим зират кына каласын көт тә тор. Шуңа да ул чараны кичекмәстән тормышка ашырырга кирәк иде...

Бригадир Ясир Ярмиевнең шактый күңелсез «увертюра»сын тыңлаганнан соң, урам буйлап алга таба китеп бардык. Атлаган саен баягы сүзләр онытыла, күңел канатлана бара. Монда инде ябык тәрәзәле йортлар юк диярлек. Өйләр биек, нык, абзар-куралар төзек, капкалар буяулы. Чалпыдагы сыман ук, бөтен шарты китереп салынган өч өй колхоз маясына күтәрелгән. Аларда җиңнәрен сызганып колхозда эшләүче Муллин, Бәхтиев кебекләрнең яшь гаиләләре яши. Йортлар бригаданың җылылык казанына тоташтырылган, суы да кайбер өйләрнең аш-су бүлмәсенә үк барып кергән. Инде газ линиясе сузарга җыенып йөриләр.

Урталыктагы иркенрәк урынга җиткәч, канәгатьлек хисе гаҗәпсенү белән алышынды. Шәһәр корылмаларыннан һич кенә дә кайтыш булмаган ак кирпеч бина — кибет икән! Мондый иркен сәүдә учагын зур-зур авылларда да сирәк очратасың. Сатучысы — Баланлы-Бүләк килене Илсөяр Шәйхуллова. Илсөярнең ире Шамил Шәйхуллов комбайнда эшли. Кыскасы, авылда ныклап тамыр җибәргән гаилә бу.

— Медпунктыбыз да үзебезнеке! — дип өстәп куя бригадир. — Бик әйбәт җиһазландырылган. Анысында уңган киленнәребезнең тагын берсе — Рәмзия, минем ярдәмчем Муса Габидуллин хатыны. Карты-яше канәгать үзеннән.

Илле биш хуҗалыктан торган шушы авылның җыйнак кына ике катлы тәрбия йорты да бар. Аның беренче катында биш бала башлангыч белем алса, икенче катта мәктәпкәчә яшьтәге унике сабый тәрбияләнә. Мөдир Сәрия Муллина белән тәрбияче Зөлфия Шәйхуллова бала-чаганың арта баруы хакында сөйлиләр. Әле моннан алтыҗиде ел элек кенә нарасыйлар чыр-чуы бөтенләй тынып калган Баланлы-Бүләктәге яшь гаиләләрнең һәркайсында өчәр-дүртәр бала!

Авылның клубы да чын мәгънәсендә культура учагы икән. Китапханәсе дә, спорт залы да шунда. Штанга һәм герләр, баскетбол җайланмасы. Клуб ягында — телевизор, бильярд, шахмат-шашка кебек өстәл уеннары, баян, магнитофон, башка музыка кораллары, төсле музыка... Яшьләр, даими кинофильмнар белән генә канәгатьләнеп тормыйча, клуб мөдире Рузалин Садыйков җитәкчелегендә концертлар куялар, ял кичәләре оештыралар. Бәйрәмнәрдә чәй мәҗлесләре үткәрелә, яңа елны чыршы янында бергәләп каршылыйлар.

Бәләкәй авылның зур мәсьәләләре, социаль хаҗәтләре тулысынча хәл ителгән. Шуңа да мондагы кешеләр илебез алдында куелган олы бурычларны үтәүдә дә бердәм катнаша. Авыл карамагына 1200 гектар җир, дистәләгән машиналар тапшырылган. Алар барысы да бригаданың үз механизаторлары белән тәэмин ителгән. Техниканы төзәтү-көйләү өчен дә Чалпыга чапмый егетләр. Үзләрендә үк әйбәт җиһазланган алачык бар. Монда, тотрыклы рәвештә һәр гектардан 26-28 әр центнер бөртекле ашлык, 12-14 әр центнер карабодай уңышы җыеп алалар. Чәчүлек орлыклар бер дигән амбарларда саклана.

Авылның зур-зур ферма каралтылары, терлек азыгы урыннары, саву җайланмалары — берсе дә колхоз үзәгендәгедән ким түгел. Инде ферманың асылына килгәндә, ул, Чалпы өчен генә димим, бөтен район, хәтта республика өчен гыйбрәтле. Хикмәт шунда, 1986 елда бригада терлекчеләре «Айршир» токымлы йөз егерме сыер алып

кайтканнар. Инде сыерлардан көр, таза бозаулар алып үстергәннәр, тирә-күрше колхозларга сата башлаганнар. «Айршир» сыерларының һәркайсы елына 6700 әр литр сөт биргән. Йөкләмәләре — җидешәр мең литрга җиткерү.

Бригаданың егерме биш аты да бар. Шуның алтысы — савым бияләре. Колхоз профилакторие өчен шифалы эчемлек нәкъ менә Баланлы-Бүләктә әчетелә. Авылга килеп үк терәлгән урман буена җыйнак кына алты почмаклы «Кымыз йорты» да салып куйганнар.

Авылга «кырау суккан» теге заманнарда мондагы умарталык һәлак булган. Тынгысыз егет Фәрагәт Вәлиев аны юктан бар иткән. Хәзер аның карамагында — кырык күч бал корты.

Бригада бүген теләсә нинди бурычны уңышлы башкарып чыгарлык бердәм коллектив булып ныгыган. Һәр эшне башлап йөрүчеләр — яшьләр, билгеле. Бригадирның үзенә дә утыз биш кенә яшь. Чалпыда урта мәктәпне тәмамлауга, Ясир атказанган колхозчы әтисе Әгаз һәм шундый ук уңган әнисе Тәгъзимә кебек үк фермада терлекче булып эшли башлаган. Армиядә танк училищесын тәмамлаган старшина туган авылына тагын да канатланып кайта. Солдат гимнастеркасын салмас борын Т-4 тракторына утыра, аннан комбайнда эшли. Башта курсларда укый Ярмиев, соңрак Минзәлә колхоз-совхоз техникумын тәмамлый. Инде сигез ел бригадага җитәкчелек итә. Иш-ише белән дигәндәй, хатынның да авыл җанлысы туры килә аңа, Кәүсәрия инде ничә еллар сыерлар сава. «Эштән аерылмый» гына биш бала үстереп яткан көннәре Ярмиевләрнең. Гомумән, әйбәт гаилә бу. Ясирнең сеңлесе Рузалия күп еллар сыерлар сауган. Аннан күршедәге Камышлыга кияүгә чыккан, анда да ферманы үз иткән. Без барган көнне Ярмиевләрнең алтынчы классны бетергән баш балалары Илнур, башкалар белән бер сафта, ферма акшарлап йөри иде.

Хәер, уңган гаиләләр байтак монда. Шундыйларның тагын берсе — Габдрахмановлар. Габдерәүф үзе — мактаулы тракторчы, хатыны Тәскирә — савымчы. Өлкән уллары Габделхәй — авыл Советы председателе. Илшатлары әле яңа гына армиядән кайткан, машинага утырмакчы. Ирле-хатынлы Зөфәр һәм Дания Кашаповлар, Рәис һәм Зөлфия Нуретдиновлар, Газинур һәм Раузия Бәхтиевләр — бригаданың алтын терәкләре. Агалы-энеле Радик һәм Фаяз Муллиннар, хатыннары Сәрия һәм Насиха белән бергәләп, гаилә подряды оештырып җибәрделәр: сиксән баш «Айршир» сыерын савалар, алардан туган илле баш тананы да үзләре үстерә.

Сүз дә юк, Баланлы-Бүләкне аякка бастыру өчен колхоз идарәсе һәм колхозчылар күп көч куйган. Әгәр дә төзелеш һәм төзекләндерү эшләре бер Баланлы-Бүләккә генә кагылса, бу хакта тәфсилләп сөйләп тору кирәкмәс тә кебек. Эш шунда ки, әүвәл «Коммунизмга» колхозына Камышлы һәм Иректе авыллары да керә иде. Аларында да әнә шулай зурдан кубып, клуб, мәктәп, кибет, медпунктлар, самолет ангарлары сыман ферма каралтылары, амбар, гараж, мастерскойлар, юллар салынды. Кайчандыр өметсезләр исемлегенә кергән кече авыллар шулкадәр үскәннәр ки, Иректе белән Камышлы, аерым колхоз булып, «башка чыкканнар». Председатель ышана: Баланлы-Бүләкне үстерүгә тотылган чыгымнар да тулысынча акланачак.

Игътибар иткәнсездер: Чалпыда тормышны кала аршины белән алып барырга тырышу үзен нык сиздерә. Һәм, әйтергә кирәк, күп кенә тармакта моңа ирешкәннәр дә. Авылдагы музыка мәктәбе, стадион, спорт заллары, Культура йортындагы инструменталь ансамбль, төсле музыка, хореография, вокаль, драма түгәрәкләре... Авыл тулы мотоцикл, аларны иярләгән чая яшүсмерләр, шәхси гаражлар һәм автомобильләр... Өйләрдәге җайлылыклар! Хат ташучылар йорт саен кочак-кочак газета-журналлар тарата. Сүз дә юк, шәһәрләшә авыл, дөресрәге, кала белән ике арада яшәп килгән зур аерманы бетерә бара. Монысы ифрат күңелле күренеш, әлбәттә. Әмма ничек кенә булмасын, нинди генә чорда-заманда яшәмәсен, авыл — авыл булып калырга тиеш. Ә авылны авыл иткән нәрсә — табигать ул.

Бәхеткә, колхоз җитәкчелеге бу хакыйкатькә нык төшенгән икән. Башкача була да алмый, чөнки монда барыбызны да туендыручы Җир белән, чишмә-елгалар белән һәрвакыт күзгә-күз очрашып, аларның яралары өчен әрнеп, шушы матур дөньяда табигатьне каһәрләүче ваемсыз җаннар да буталып йөрүенә гасабиланып яшиләр. «Көлеп йөри шулай егетләр» шигырендә Гыйлаҗев бу мәсьәләгә карата үзенең программасын ачыктан-ачык әйтә:

*Нәтиҗәсе хәзер күз алдында:*
*Корып бара урман-чишмәләр.*
*Ни әйтербез, әгәр яңа буын:*
*«Нәрсә карадыгыз?» — дисәләр?*

«Нәрсә карадыгыз?» соравы әле теге елларда — авылларга «комсыз көя кергән»,

җимерек фермаларда шыксыз җилләр елашкан, савылмаган сыерлар акырышуыннан тирә-юнь иңрәп торган чакларда ук җанын телә председательнең. Хуҗалыкта мең мәшәкать барында да табигатьне саклау хакында онытмый ул. Беренче эше итеп, урамнарда тракторлар йөртүне тыя. Аннан инде урамнарны, мәйданнарны, юл буйларын яшелләндерү мәсьәләсен күтәрә. Елның-елында таләп итә торгач, йортлар каршында янбакчалар, культура-көнкүреш биналары тирәсендә яшеллекләр, парк, үзәк урамда чәчәк түтәлләре барлыкка килә — өйләр-биналар яшел дулкынга күмелеп кала.

Председатель тәкъдиме буенча олы юл белән Чалпы арасына да агачлар утыртыла. Унике чакрымлы бу яшел хозурлыкка һәр кеше соклана. Шундый ук яшел юл Чалпы — Баланлы-Бүләк, Чалпы — Камышлы, Чалпы — Ирекле юнәлешләренә дә сузыла. Колхозда яңадан-яңа урман киңлекләре утыртыла, искеләре тәртипкә китерелә.

— Теге елларда: «Шауласыннар яшел урманнар», — дип җырлый-җырлый, табигый урлар булдыру буенча башланган олы эштән юкка гына суындылар, — ди председатель. — Иманым камил — урман буендагы басулардан уңыш бермә-бер артык җыела.

Табигатьне саклау буенча киң мәйданда эш башкарыла Чалпыда. Җирнең уңдырышлы өске катламын баету, җил-су эрозияләре белән көрәш һәм башка күп чаралар керә аңа. Баланлы-Бүләк буендагы бер дигән бодай басуында кап-кара киңлек күреп, сәерсенеп калдым. Ясир Ярмиев аңлатты: газ магистрале сузганнар икән. Шуннан инде әлеге буш яткан җиргә икенче күзлек аша карарга туры килде. Ник кенә бер уч сары балчык булсын!

— Чиста эшләгәннәр, — дим, үземчә төзүчеләрне мактап.

— Эшләми карасыннар! — дип күтәреп алды Ясир. — Җирне бозсалар, Илдус Сабирович җаннарын алачак ич аларның.

Мондый чаралар — һәркем эшләргә тиешле нәрсәләр кебек. Ә менә Баланлы-Бүләк авылының өч җыйнак кына буа ясап куярга колхоз идарәсен берәү дә мәҗбүр итмәгән, әлбәттә. Янгынга каршы саклануны күздә тотып буылган булса кирәк алар. Киңрәк уйласаң, бу күлләрнең нинди зур хәзинә икәнен дә аңлавы кыен түгел. Бихисап каз-үрдәкләренең суда кинәнүләрен карап торучы әби-чәбинең шатлыгы тагын!

Буалар — Гыйлаҗевның да сөенеч-куанычы. Ул аларга, беренче чиратта, табигать байлыгы дип карый. Инде зур хуҗалыкның башлыгы буларак, ясалма күлләрнең экономик куәтен дә онытмый. Буалар биредә басуларга су сиптерү һәм карп балыгы үрчетү өчен файдаланыла. Шул максатны күздә тотып, колхозда дүрт зур буа бөялгән.

Ясалма каршылыклар булмаганда, табигатьне саклау, җирне, урман суларны яклау үзе бер хозурлык. Тик менә, дөнья булгач, һич уйламаган-көтмәгән казалары да килеп чыга бит аның. Колхоз басуларына килеп кергән нефть коелары — үзе бер афәт. Шулар тирәсендә эшләүче кайбер гамьсез бәндәләр үзәккә үтә:

*Күрү белән, шартлар чиккә җитеп,*
*Тын алалмый тордым шаккатып.*
*Чатыр тавы кадәр бер бульдозер*
*Игеннәрне бара таптатып.*

Буровойларның берсе Баланлы-Бүләк янына ук күчеп утырды. Гыйлаҗев, гадәте буенча, бораулаучылар белән башта ук очрашты, җир хуҗасы буларак, таләпләрен әйтте. Ләкин тегеләрнең бораулары мәгълүм бер тирәнлеккә җитүгә, авылны туендырып торучы артезиан коесында су юкка чыкты. Янә килде председатель алар янына, су кытлыгы туунын нәкъ менә бораулаучылар гаебе икәнен исбатлап күрсәтте. Борын асларыннан гына елмайдылар тегеләр, бу якларда чишмә-сусыз калучылар бер сез генә түгел, янәсе. Җитмәсә, яңа кое казып бирүдән баш тарттылар. Шуннан инде колхоз башлыгы гына түгел, РАПО советы председателе һәм Татарстан Верховный Советы депутаты булып та сөйләшергә туры килде Гыйлаҗевка. Нәтиҗәдә, яңа кое борауладылар, фермаларга су килде.

Бервакыт, җанына якын кырларын урап кайтышлый, «Нива»сын асфальттан читкә борды Илдус Сабирович. Инеш буйлап сузылган ат юлына килеп кердек. Аның бер ягында — пар җире, икенчесендә ямь-яшел бодай калыккан. Мин председательнең болайга борылу сәбәбен аңларга тырышып баш ваткан арада, машина кисәк туктап калды — нәкъ буфер алдында гына «туннары» елык-елык итеп торган ике суыр баласы әүмәкләшеп уйный. Суырлар күп булып чыкты монда — көтү-көтү яшиләр, куркуөркүне онытканнар, безне күрәсезме дигәндәй, арт аякларына басып, безгә туп-туры карап торалар.

Илдус Сабирович эшенең иң тыгыз чагында да, вакыт табып, күл буйларын урый икән. Машинасыннан төшеп, бераз аякларын яза. Һәркайсы: «Мин кем?!» — дигәндәй горур бакылдашкан бакалар авазын тыңлый, балыклар чупылдавына колак сала, су өстендә кайнап, нидер даулап йөрүче киек каз-үрдәк ояларына карап, хозурланып тора. Машинасыннан төшкән икән — ул инде китәргә ашыкмый, ерак-еракларга сузыл-

ган су өслегенә, камыш баскан утрауларга карап, нидер эзли сыман. Юксынганы — аккошлар инде. Нигә дисәң, «кемдер аткан» дигән шомлы хәбәрдән тынгылыгын җуйган көннәре. Шуңа да бу арада Атау буасы янына ешрак туктала ул. Аккошлар юкка чыкса, балаларга ни диярбез?! Ниһаять, көннәрнең берендә камышлар куелыгыннан чыгып килүче илаһи кошларны күреп алды ул. Аккошлар исән! Китмәгәннәр дә, югалмаганнар да, җиребезгә бәрәкәт иңдерүче шигърият кошлары Чалпыда калганнар икән.

Чалпы якларындагы берсеннән-берсе күркәм яңалыкларны карап, сөенеп-куанып, горурланып йөрисең дә, ихтыярсыздан сорап куясың: каян килә бу акча? Түзмәдем, шул ук сорауны Илдусның үзенә дә бирдем.

— Анысын инде баш экономист белә, — диде ул.

Менә без бихисап саннарга чумган Рузалия ханым Әхмәдиева белән шул хакта сөйләшеп утырабыз.

— Каян дисезме? Кырлардан һәм фермалардан, әлбәттә. Колхоз 1982 елдан бирле планнарын арттырып үти. Узган ел гына да 272 мең сум саф табыш алдык. Керемнең байтагы кырчылыктан: шикәр чөгендереннән, карабодайдан... Товарлыклы сөтчелек фермаларыннан алынган табыш — 335 мең сум. Хуҗалыкның рентабельлелеге сигез процент тәшкил итә. Сөт җитештерү 30 процент, чөгендер игү 41 процент рентабельле. Ә дуңгызчылык зыянга эшли. Алай да керемнәр күбрәк. Шуңа да тулы хуҗалык исәбенә һәм үзфинанслауга күчә алдык. Колхозның экономик яктан нык булуы киң күләмдә төзелеш алып бару мөмкинлеген бирә.

Бу хәтлесе аңлашылды кебек. Әмма иң әһәмиятлесе — акчаны акыллы тота белү. Җитәкченең зирәклеге нәкъ менә шунда ачыла да инде. Җөмләдән, заманында «Коммунизмга» колхозы да дәүләткә байтак бурычка кергән. Шунысы әйбәт, алынган акча юкка әрәм-шәрәм ителмәгән, тулысынча авылның социаль проблемаларын хәл итүгә тотылган. Берәүгә дә сер түгел: республикабызның байтак хуҗалыклары бурычлы дәүләткә. Аяныч ки, кайберләре миллионнарны вак-төяккә исраф итә. «Коммунизмга»-да исә кредит акчасы авылларны үстерүгә, халык тормышын тамырдан яхшыртуга тотылды. Кешеләр моны аңлый һәм бише белән кайтарырга тырыша.

Гыйлаҗев бу хуҗалыкка килгәнче дә таркау бер колхозны алдынгылар рәтенә чыгарган бит әле ул. Ихтыярсыздан уйлап куясың: гадиен гади, бер үк вакытта бөтенебез сыман да түгел, димәк, үзенә генә хас тагын ниедер бар аның. Тик нәрсә ул? Әнә шул сорауга җавап табарга тырышып, байтак кына колхозчылар белән сөйләштем. Берәве әйтә:

— Башлы инде, «Безнең Сократ хәким» дип йөртәбез үзен, — ди. — Безнең бәхеттән булгандыр ул. Үзебезнең Чалпы мәктәбен генә бетергән егет югыйсә.

— Гыйлаҗев бүгенге көн белән генә яшәми, — ди икенчесе. — Ул киләчәккә карап яши. Бу аның бөтен гамәл-шөгылендә күренеп тора. Шул ук төзелешләргә генә кайтыйк: барысы да, зурдан кубып, иркен итеп җиткерелгән. Алар киләчәк буыннарга да әйбәт хезмәт итәчәк. Басу-кырларның бәрәкәтен арттыру, терлекләрнең нәселен яхшырту, табигатьне саклау кебек чаралар да киләчәкне күздә тотып эшләнә.

Хәтеремдә председательнең:

*Дәвам итәр изге һөнәр,*
*Орлык белән тулы бурам.*
*Кырга чыксам, уйларымны,*
*Килер буын, Сиңа борам, —*

дигән юллары яңара. Илдус Сабирович эштәге яңа ысулларга да теше-тырнагы белән ябышкан. Колхозда гаилә һәм коллектив алымы белән эшләүче игенчеләр, терлекчеләр барлыкка килде. Хәзер инде аларның уңышлары турында бөтен республика сөйли. Әнә, өч бертуган Сәйфетдиновлар үгез симертә. Егетләрнең һәркайсы елына иллешәр тонна сыер ите җитештерә. Республиканың уртача күрсәткеченә караганда, тугыз мәртәбә артыграк! Гаилә подряды белән эшләүче терлекчеләрдән Муллиннар, Кәримовлар, Гыйлаҗевлар, кырчылыкта 740 гектар җирне арендага алган Ринат Гәрәев, Азат Гыйззәтуллин звенолары да күркәм уңышларга ирешә.

Күпләр, председатель турында сөйләгәндә, аның гаҗәеп мәгълүматлы булуына аерым туктала. Илдус Сабирович экономист та, инженер да, социолог та, статистик та, филолог та, оештыручы да, бер дигән киңәшче дә ул, диләр. Шулай булуга карамастан, игелекле эшчәнлегендә хуҗалыкның белгечләренә һәм бригадирларга таяна. Бер генә зур мәсьәләне дә ялгызы хәл итми, идарә членнары, авыл Советы депутатлары, партком, коммунистлар белән киңәшмичә эшкә тотынмый. Аның ярдәмчеләре — белгечләр, бригадирлар һәм ферма мөдирләре, чагыштырмача, яшьләр әле. Алай да берәүнең

дә иреге чикләнми, куллар бәйләнми, тәкъдим-теләкләргә киң юл бирелә.

— Татар халкының мәкален беләсездер, — диде яшен яшәгән тәҗрибәле бер аксакал. — Булырныкы әллә каян билгеле. Син аның өс-башына гына күз сал. Һәрчак пөхтә, җыйнак. Кешеләргә мөгамәләсе тагын: кычкырмас, җикеренмәс, барын салкын акыл белән хәл итәр.

Дөрестән дә, көннәр буе тузан, тирес арасында кайнавына карамастан, өстендә ап-ак күлмәк, муенында галстук булыр Гыйлаҗевның. Костюмы үтүкләнгән, ботинкалары чиста. Хәрәкәтләрендә — эшлекле сабырлык. Шул ук вакытта беркатлы «яхшы абзый» да түгел Илдус Сабирович. Кирәк чагында тиешле кешеләрдән таләп итү, аларны инандыру куәте бар аңарда. Председатель, әйтерсең, эш кушмый, ә киңәшә синең белән.

Һәркөн иртә таңнан кара төнгәчә аягында Гыйлаҗев. Хуҗалыкта бер-бер нәрсә «шылт» иткәнне дә белми-сизми калмый ул. Авыл белән, халык белән бергә сулап, бер үк мәнфәгатьтә яши. Колхоз председателенең берсеннән-берсе асылрак сыйфатларын атады игенчеләр: гаделлек, намуслылык, әхлаклылык, туры сүзлелек... Тик бары бер аның иң үзенчәлекле тагын нидер булырга тиеш иде кебек. «Коммунизмга» колхозында үткән көннәрдә һаман шул хакта уйландым һәм, ниһаять, анысын да таптандай булдым. Болар бар да Гыйлаҗевның гамь туфрагыннан яратылуыннан киләдер, мөгаен. Ә гамьле булу — бар халыкны борчып торган зур мәсьәләләр, олы мәшәкатьләр белән янып яшәү, ирешелгәннәр белән генә канәгатьләнмичә, яктыдан-яктыга, камиллеккә омтылу, кеше күңеленең тынгысызлыгы, йөрәгенең ярсып тибүе ул. Әйе, Илдус Сабировичның уңыш-табышлары, якты хыял-омтылышлары аның шагыйрьлегендә дә бугай. Кешеләрне тәрбияләүдә, катлаулы мәсьәләләрне хәл итүдә, җайга салуда үткен теле, йөгерек каләме белән дә тырыша әле ул. Шагыйрь председательнең бар гаме, яну-көюләре 1989 елда Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан шигырьләренә дә иңгән.

Гамь дигәч тә, гел сыкрау, аһ ору, күз яшьләре кебек тоелмасын бу. Ирешкән хәтлесенә сөенгән, булдырган кадәренә хаклы рәвештә горурланган минутлары күп аның. «Түтәлләр» дигән шигыре нәкъ шундый күңел күтәренкелеге тәэсирендә язылган шикелле:

*Бүген эшли торган җирем —*
*Ун мең гектарлы түтәл.*
*Басуларым юлларыннан*
*Генерал булып үтәм!*

Хезмәтеннән, кешеләргә игелек кылудан тәм, ләззәт тапкан кешенең ихлас горурлыгы бу!

## Хәмзә Бәдретдинов

# ТУФРАКСЫЗ БАСУ

ОЧЕРК



— Бу такта җирне алмаштыра...

Күргәзмә залындагылар, әлбәттә, моңа ышанып бетмәделәр, экскурсоводның әлеге сүзләрен шаяртуга алдылар.

— Тактага яшелчә орлыгын ничек күмәләр соң?

— Үсемлек тамыры үтеп керә алмый ич анда. Борау түгел лә ул...

Моңарчы меңәрләгән кунакларны күргәзмә белән таныштырырга өлгергән мөлаем ханым әлеге фикерләрне сабырлык белән тыңлап бетерде. Аннары, дәлилләр китереп, күңелләрдәге шик-шөбһәне таратып ташлады:

— Бу тәҗрибәләрне С. М. Киров исемендәге текстиль һәм җиңел промышленность институты галимнәре ясады. Электр үткәрүче җепселле-кузәнәкле материаллар да кытай кәбестәсе, төче торма үстерделәр. Яшелчәләр утызбиш-кырык көндә уңыш бирде.

Экскурсовод, ниһаять, хикмәтле тактаны кулына алды:

— Менә нинди җиңел ул! Очыргыч кебек. Үзе урынны да күп алмый. Химик эшкәртүләргә һәм җылылыкка бирешми, суны тигез тарата...

Гаҗәп күренеш! Кеше акылы нинди генә ачышлар ясамый. Җирнең дә алмашын булдырганнар бит! Кемнең башы җитте икән моңа?

«Интенсификация-90» күргәзмәсенә куелган серле экспонатның тасвирламасына авторларның фамилияләре язылган. Исемлектә Г. М. Мөбарәкшин да бар.

Гаделша Мөбарәкҗановичның мондый күргәзмәләрдә беренче мәртәбә катнашуы түгел. Халык хуҗалыгы үсешенә өлеш кертkәне өчен ул Бөтенсоюз халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсенең көмеш медаленә лаек булды. Ленинград дәүләт текстиль һәм җиңел промышленность институтының химик җепселләр технологиясе лабораториясенең өлкән фәнни хезмәткәре, химия фәннәре кандидаты Гаделша Мөбарәкҗанович дүрт дистәдән артык фәнни хезмәт бастырырга да өлгерде. Кырык өч яшьлек галимнең унбер ачышы «Авторлык таныклыгы» белән ныгытылды. Махсус рөхсәт алып, яңалыкларның кайберләрен Америка, Англия, Франция, Швециядә куллана башладылар.

— Гаделшаны галим булыр дип кем уйлаган?! — дигән иде берчак аның авылдашы Габделхак Минкин.— Урта белем алгач, ул Сатмышта укытып йөрде әле. Бер очрашкач әйттем үзенә: «Энекәш, укырга кирәк сиңа!..».

Гаделша Апас районының Югары Акхуҗа авылында яшәүче мөхтәрәм авылдашы Габделхак абый сүзләрен ихтирам белән искә төшерә:

— Акыллы киңәше өчен рәхмәт инде аңа!

Хәер, Г. Мөбарәкшинның рәхмәт әйтәсе кешеләре байтак. Ни дисәң дә, игелекләре белән күңелгә кереп калучылар беркайчан онытылмый. Андыйларны искә төшерәсе килеп кенә тора. Федровский урта мәктәбе химия укытучысы М. К. Опылева турында Гаделша кемнәргә сөйләмәде инде. Маргарита Константиновнаның көчле химик икәнен хәзер аның студентлары да беләләр. Гаделша С. М. Киров исемендәге Казан дәүләт химия-технология институтын да хәтерендә бик еш яңарта. Институт

ректоры П. А. Кирпичниковның мавыктыргыч лекцияләре үзе генә дә ни тора! Ул аларны дәфтәрендә кадерләп саклый. Укытучысы Н. С. Әхмәтовның Мәскәүдә басылган «Неорганик химия»се кулыннан төшми. Институтны бетергәч, «Органик синтез» берләшмәсенең газ бүлеп чыгару җайланмасын монтажлаганда Гаделша күпме дуслар тапты! 1969 елда алар егетне Ленинградка озатып калдылар.

Дөньядагы иң гүзәл шәһәрләрнең берсе булган Ленинградта Гаделшаның апасы яши. Ул энесен үзе белән «Киров» заводына алып килә. Гаделша сыек азот һәм сыек кислород җитештерүче цехка урнаша. Производство процессларының, технологиянең камиллектән ифрат ерак торуы гаҗәпсендерә аны. Аларны ничек җайга салырга соң? Нишләргә? Шуңа охшаш сораулар егеткә тынгылык бирми башлый. Аларга җавап эзләү исә Гаделшаны зур фән дөньясына китереп чыгара.

Ачышларны, әлбәттә, коры теләк белән генә ясап булмый, моның өчен шартлар кирәк. «Киров» заводы белән фәнни бәйләнештә торучы текстиль һәм җиңел промышленность институтында андый уңайлыклар бар. «Әйдә, безгә кил,— ди беркөнне профессор Л. А. Вульфсон Г. Мөбарәкшинга. — Тәҗрибәләреңне лабораториядә үткәрерсең!»

Чакыру кабул ителә. Фәнни җитәкче белән аспирант үз алларына: «Ион үткәрүче җепселләр җитештерүнең иң гади ысулын табарга!» — диген максат куялар. Ни өчен дигәндә, технология катлаулы, беренчел чималны җепсел хәленә китергәнче дүрт мәртәбә эшкәртергә туры килә. Моның өчен дүрт сәгать вакыт сарыф ителә. Әгәр җепселләрне «төзү» һәм юу процессларын берләштерсәң? Отышлы булачак. Үткәргән тәҗрибәләр нәкъ шуны раслыйлар: эшкәртү вакыты уртача бер сәгатькә калгач, экономик чыгымнар биш-алты тапкыр кими!

Лаборатория шартларында ясалганнан соң да әле, ачышны производствога керткәләгәнче, күп вакыт үтә. Мәсьәлә никадәр тизрәк хәл ителсә, аның халык хуҗалыгына файдасы шулкадәр күбрәк булачак бит. Бу хакыйкатьне Г. Мөбарәкшин кемнәрнең генә исләренә төшермәде. «Союзхимпласт» производство идарәсе начальнигы Вячеслав Сергеевич Антипов белән очрашты. «Пластмасса» фәнни-производство берләшмәсе директоры Рубен Агасеевич Макартчян белән бәхәс куертты. Монда бөтендөньяга атаклы галим, ион үткәрүче сумала ясау серләрен өйрәнгән техник фәннәр докторы Кирилл Максимович Солдатзе белән танышты. Аларның хуплауларына ирешкәч Гаделша СССР химия промышленносте министры урынбасары Владимир Сергеевич Смирнов янына керде, мәсьәләне кистереп куйды:

— Ачыш Германия, Америка, Англия, Франция, Япония, Финляндия хөкүмәтләрен дә кызыксындыра инде, аны алдан үзебездә кулланышка кертмәсәк, сәер булыр бит? — диде.

Ниһаять, Мәскәүдән килгән телеграммада ион һәм электр үткәрүче җепселләр җитештерүнең СССР химия промышленносте планына кертелүен хәбәр итәләр. «Союзхимпласт»ның Новопольск шәһәрендәге «Полимер» производство берләшмәсенә аны ясау бурычы йөкләнә. Биредә ел саен мең тоннага кадәр продукция җитештерү күздә тотыла.

Мондый җепселләр нәрсәгә кирәк соң? Мондый сорау бирелсә, Гаделша Мөбарәкҗанович тагын да ачылып китә. Өстәлгә төрле төскә буялган материалларны җәеп сала да, сүзен дәлилләп, ак кәгазь битләрен сызымнар белән чуарлый, ачышлары турында ялкынланып-кайнарланып сөйли:

— Иң мөһиме — җепселле-күзәнәкле материал бик гади ысул белән җитештерелә, арзанга төшә. Үзфинанслау, хуҗалык исәбе турында сүз барганда, бу бик әһәмиятле! Икенчедән, кулланучыларның теләкләрен искә алып, аны теләсә нинди формада «коярга» мөмкин. Химик яктан да нык — уалмый, күләмен һәм авырлыгын югалтмый...

— Ул нинди тармакларда файдаланыла?

— Җепселле-күзәнәкле материалны күп җирдә фильтр буларак кулланалар. Ул химия, электроника, металлургия предприятиеләреннән чыга торган агулы матдәләрне йота, табигать чисталыгын саклый. Агымсулардагы буяуларны, сирәк очрый торган төсле металларны сеңдерә. Промышленностька суны минераль матдәләрдән арындырып бирә ала, торбаларны юшкыннан, тутыгудан саклый. Дөрес, хәзергә бу максатта күбесенчә сумаладан файдаланалар. Аның исә яртысы чит илдән сатып алына. Өстәвенә, үзе тиз уала, күләмен үзгәртә. Җепселле-күзәнәкле материал бу яктан бик тә ышанычлы. Ә теплицаларда ул туфракны алмаштыра. Җепселләр медицинада да кулланыла — Апас хирургы Үзбәк Гайнуллин полипропен җеп белән яраларны тегә...

Һичшиксез, әлеге арзан материал киләчәктә башка тармакларда да урынын табар. Ни дисәң дә, хәзер аның үзенчәлекләрен өйрәнүче галимнәр күбәйде. Гаделша Мөбарәкҗанович җитәкчелегендә диплом яклаучы Ташкент, Бөгелмә, Түбән Кама егетләре дә зур тикшерүләр алып бара. Ихтимал, тиздән Казан химия-технология инсти-

туты студентлары да үз сүзләрен әйтер әле. Казанга соңгы кайтуында Р. Мөбарәкшин синтетик каучук кафедрасында җепселле-күзәнәкле материалларның бик күп үрнәкләрен калдырып китте. Эзләнергә генә кирәк!

Тикшеренүләр күп җирдә алып барыла дип, Гаделша үзе дә тынычланып калмаган, билгеле. Лабораториядә көннәр буе мәш килә. Төрле шәһәрләрнең химия заводларында еш була: ачышларын производствода тикшереп карый. Кайчакта атналар буе югалып тора. Хатыны, программист-математик Әлфия ханым, мәктәптә укучы кызлары Динә белән Диләрә зарыгып көтәләр үзен.

— Әле яхшы кайтып җиттең,— дип каршылады аны соңгы сәфәрдән хатыны.— Казаннан җырчы Илһам Шакиров килгән, билетлар алып куйдым.

Гел «биш»легә генә укучы Динә дә шатлыгын уртаклашырга ашыкты:

— Әти, әти, Апастан татарча китаплар җибәргәннәр!

Марка, конверт, открытка җыючы филателист Диләрәнең дә әтисе белән уртаклашырдай сөенечләре бар:

— Әти, кара әле, мондый маркалар бездә юк иде бит! — дип, яңа табышларын күрсәтә.

Аларга кызыгып карап торасың: нинди бәхетле гаилә бу! Болай бер-берсенең күңелләрен, рухларын баетып яшәгәч, Мөбарәкшиннар әллә нинди ачышларга ирешер әле!

## ӨМЕТЛӘНЕП КӨТӘБЕЗ

Безнең язучылар гомер-гомергә, матур әдәбият әсәрләре белән беррәттән, публицистик мәкалә, очерк, документаль хикәя-повестьлар да иҗат итә. Мондый ихтыяҗ тормыш таләбеннән килеп чыга. Соңгы вакытта исә, илдә барган революцион үзгәртеп коруларга бәйле төстә, бу жанрга игътибар тагын да арта төште. Язучыларыбыз, күңел түрендәге сүзләрен халыкка бүген үк ирештерү өчен, инде башлаган әдәби әсәрләрен читкә куеп торып, мәкалә яки очеркка тотына, укучы үтенече буенча юлга ашыга, радио яки телевидение аша чыгышлар ясый.

Кызганыч ки, бездә, татар әдәбиятында, бары тик публицистика белән генә шөгыльләнүче язучылар юк дәрәҗәсендә. Шунлыктан без һәр яшь публицистны тансыклап көтеп алабыз, аңа кулдан килгәнчә ярдәм итәргә тырышабыз, аларга зур өметләр баглыйбыз. Журналның бу санында бирелгән «Туфраксыз басу» исемле очерк авторы Хәмзә Бәдретдинов — шуларның берсе. Ул укучыларга яхшы ук таныш. Журналда аның берничә әсәре басылды. Автор 1987 елда яшь очеркистларның Пицунда шәһәрендә уздырылган VII Бөтенроссия семинарына җибәрелде. Ул анда, үз әсәрләрен РСФСРның күренекле публицистлары хөкеменә тапшырып, хуплаулар һәм бик кирәкле тәнкыйть сүзләре ишетеп кайтты.

Инде «Туфраксыз басу» очеркына карата берничә сүз. Автор бу язмасында укучыны Ленинградта яшәп иҗат итүче галимебез, Апас егете Гаделша Мөбарәкшин белән таныштыра. Язма үзенең җыйнаклыгы, мәгълүматларга шактый бай булуы ягыннан ифрат отышлы. Гаделша кебек якташларыбыз, аларның дөньякүләм әһәмиятле гамәлләре турында белгәч, туган халкыбыз өчен табигый горурлык хисе уяна.

Әмма, очеркны укып бетергәч, Хәмзәнең шушы табышлардан тулысынча файдаланып җитмәгәнлеген дә тоясың. Авторның кыю-кыю фикерләрен ишетәсе килә: әйтик, ни өчен шундый да талантлы галим әлеге ачышларны Татарстанда яшәгәндә үк ясый алмаган? Ник соң без сәләтле кешеләребезне һаман тибәрәбез? Дөпдөресен әйткәндә, бу — бердәнбер генә егет түгел бит. Безнең игътибарсызлыктан гаҗизләнеп әллә кайларга (хәтта чит-ят илләргә) китүче һәм анда бик тә күркәм эшләр башкаручы талантларыбыз шактый. Алар Татарстанда артыкмыни соң?! Кеше кадерен санга сукмавыбыз, ваемсызлыгыбыз, милли кадрларны җилгә очырып утыруыбыз тагын кайчангача дәвам итәр? Аннары, очерк каһарманы, химик буларак, иң четереклеләрдән саналган мәсьәләгә — табигатьне саклауга, экологиягә нинди-рәк караштa икән? Аның «Туфраксыз басуы» адәм балаларының сәламәтлегенә зыян салмасмы? Автор бүгенге көннең үзәгендә торучы бик тә мөһим шушындый мәсьәләләрне куертып җибәрсә, әлеге язма укып туймаслык булыр иде. Бу очракта аның укучыга үз фикерләрен гомумиләштереп бирергә дә, теләктәшләр һәм бәхәсләшүчеләр тупларга да мөмкинлеге артачак иде.

Күрәсең, бу кадәресе тәҗрибәдән киләдер. Шулай фараз кылыйк та, авторга уңышлар теләп, аның яңадан-яңа кызыклы язмаларын көтеп калыйк!

Кояш ТИМБИКОВА.

# ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

## Рәшит Ягъфәров

# УЙНАГЫЗ, НӘНИЛӘР

Балалар уенын күзәтү һәм алардан такмаклар язып алу — кызыклы шөгыль. Кызыгы шунда: бу вакытта фольклорчыга алар мохитендә «шпионлык» итәргә дә, сакаллы сабый булып шар сугып йөрергә дә туры килә.

Безнең фольклор экспедицияләре җәй көннәрендә уза. Билгеле инде, бу вакытта бала-чага су буенда чупырдаша. Авылга барып урнашкач, мин дә алар янына китәм. Балаларга якынрак җиргә тәгәрим дә, ятам шунда китап тоткан булып, укыган кыяфәттә. Ә үземнең кәгазь-каләм әзер, колак торган, күзем тирәләрдә: ни уйныйлар, ни сөйләшәләр, берәр кызыклы такмак-такмаза ычкындырмаслармы дим...

Озак көттермиләр. Менә авыл ягыннан бер малай йөгереп килеп җитә дә, ярга басып, такмаклый башлый:

*Исәнлеккә-саулыкка,*
*Тазалыкка, байлыкка,*
*Бакаларга ярлыкка.*
*Су анасы, сукыранма:*
*Миңа — саулык,*
*Сиңа — ялык.*

Шулай ди дә бу малай «чулт» итеп суга чума. Ә мин аның такмагын тиз генә кәгазьгә теркәп куям һәм тагын китапка «чумган» булам.

Менә бервакыт су коенып арыган бер төркем кыз балалар түгәрәккә басалар да:

*Без, без, без идек,*
*Без уникe кыз идек,—*

дип, «Кап-коп, Якуб» уенын башлыйлар. Такмаклыйлар-такмаклыйлар да болар, авызларын йомалар һәм, төрлечә кыланып, бер-берсен көлдерергә тырышалар. Арадан берәү пырхылдап җибәрә. Иптәшләре аңа җәза эзли башлыйлар. Берсе әйтә: «Җырла»,— ди, берсе әйтә: «Бие»,— ди. «Юк,— ди теге «пырхылдык» кыз,— әкият сөйлим әле мин сезгә»,— ди. Бик җитди кыяфәттә башлап та китә бу әкиятен:

— Борын-борын заманнарда булган, ди, бик бай бер кеше — авызында булган, ди, бары бер теше. Аның булган, ди, бик олы бер эшләпәсе. Көннәрдән бер көнне бу эшләпәсен элеп куйган, ди, киртәгә — калганын сөйләрмен иртәгә!

Кызлар үртәлеп: «Сөйләле берәр юньлерәк әкият»,— дип, аңа ябышалар. Ә «пырхылдык»: «Ярар, сөйлим», ди дә, тагын шул ук әкиятне башлап китә. Тегеләрнең үртәлеп ачулары ук килә башлый.

*Көлмә кешедән,*
*Авызың өшегән.*
*Анаң мәрхүм дә*
*Көлде-көлде дә,*
*Авызын ерып үлде,—*

ди аңа берсе үпкәләгән булып.

Шулчак кызлар янына суда озак уйнаудан туңып, каз йоннары калыккан бер малай килде. «Нәрсә, әкият сөйлә дип тинтерәтәләр мәллә?»,— ди ул тешләрен шакылдатып.— Синең өчен үзем генә сөйләп бирим булмаса». Шулай диде дә бу эре генә кыяфәт белән тезеп тә китте:

*Шулай бервакыт җиктем чикерткә,*
*Киттем урманга, азрак утын урларга.*
*Килеп чыкты бер кеше, авызында бер теше:*
*— Чей парень, да, чей парень?*
*— Чиен түгел, корысын карыйм.*
*Сугып җибәрдем колак төбенә —*
*Барып төштем куак төбенә.*
*Өйгә кайттым — хатын бәрәңге пешергән:*
*Эреләрен үзе ашаган, вакларын миңа калдырган.*
*Шул вак бәрәңгеләрне кесәгә тутырдым дагын,*
*Эт өрдереп, кеше көлдереп,*
*Ындыр артлатып, бармак шартлатып*
*Чыгып киттем тагын.*
*Барып кердем бер өйгә — тегермәнче Гурийгә.*
*Тегермәнче Гурий бай чыгарып куйды май.*
*Чыгарып куйды катык, утырам катып;*
*Чыгарып куйды кашык, утырам баш кашып...*
*Шуннан пешерделәр чумар, кеше саен унар.*
*Килеп керде Зәйнәп, сумаласын чәйнәп,*
*Килеп керде Кашшаф, сукыр чикләвек ашап,*
*Килеп керде Максим, ашап бетерде сапчим,*
*Килеп керде Гали, таба төбен ялый,*
*Килеп керде Вәли, «Миңа юк»,— дип әрли,*
*Килеп керде Мортаза, сугып екты бик таза.*
*Чыгып киттем буага, борын канын юарга,*
*Ике черки, бер кигәвен тотындылар куарга...*
*Көчкә кайттым өйгә, туным әлдем чөйгә.*
*Абый дулый башлады, тунны алып ташлады.*
*Шуннан киттем ауга, бүрегә каршы яуга.*
*Очырады аю, минем уем — таю.*
*Кайтып килә идем, таптым чумадан.*
*Чумаданда — наган!*
*...Бу ялганны тыңлаучылар барысы да надан!*

Малай сөйләп бетерде дә кукыраеп кына китеп тә барды. Кызлар чыркылдашып көлә калдылар. Тик бераздан, «надан» дип үртәп китүе ошамады ахры, малайларга таба карап хор белән такмаклый башладылар:

*Малайлар, малайлар —*
*Чүплектәге калайлар!*
*Кызлар, кызлар —*
*Һадагы йолдызлар!*

Тик малайларның моңа исләре китмәде. Кызлар, үртәшүне күтәреп алучы булмагач, малайларга кул селтәп, чирәмгә тезелешеп утырдылар да күргән-белгәнне сөйли башладылар. «Мин күрше авылдан хат алдым бит әле,— дип сүзгә кушылды берсе,— укып күрсәтимме?» «Укы, укы!»— диеште иптәшләре. Ул укып китте:

*Хат башы, иске мунча ташы,*
*Кара кәҗә башы.*
*Сәлам бездән сезләргә,*
*Чепи күзләргә; чүбек башларга —*
*Рөхсәт итегез сезгә хат яза башларга.*
*Сезгә исмәгән җилләр аша*
*Суганлап, тозлап, борычлап,*
*Чабатага тычкан җигеп,*
*Сәламнәр төяп җибәрәм.*
*Үземнең хәлгә килгәндә,*
*Исән-сау яшәп торам,*
*Көнгә биш-алты ипи орам.*
*Эшләрем авыр — тик торудан бушамыйм.*
*Хат язсагыз, минем адрес:*
*Город Казан, улица Рамазан.*
*Әбиләрдә кунам, бабайларда торам,*
*Бирсәләр ашыйм, бирмәсәләр җилкә кашыйм.*
*Урамыбыз улица, тавыгыбыз курица,*
*Капка номеры ишектә, үзем йоклыйм бишектә.*

Кызлар, көлә-көлә эчләре катып, чирәмгә тәгәрәшәләр. Минем дә түзәр әмәл калмады, кычкырып көлеп җибәрүемне сизми дә калдым. Кызлар дәррәү миңа таба борылдылар һәм аптырашып бер-берсенә караштылар. Батырраклары яныма ук килеп, сораштыра да башлады: кем мин, каян килгән, ни эшлим, янәсе. Сизеп торам: минем «шпионлыгым» фаш ителде. Ярый, тотынабыз танышырга, фикер алышырга. Шул арада минем янга бөтен бала-чага җыела. Сүз артыннан сүз китә, акрынлап халык иҗаты тарафынарак юнәлтәм мин әңгәмәне, балалар фольклоры турында сөйлим. Аннан тотынам алар ярата торган такмак-такмазалар сибәргә. Рәхәтләнеп көлә болар. Ә мин һаман саен сөйлим дә сөйлим, тегеләр көлә дә көлә. Бервакыт сизелә башлый: үзләренең дә миңа сөйлиселәре килә башлый боларның. Кайберләре сүз арасында: «Ә бездә аны икенче төрлерәк әйтәләр»,— дип тә ычкындыргалыйлар. Тоеп торам: вакыт җитте, «ташы кызды» боларның, хәзер үзләреннән дә сөйләтергә була. Магнитофонны тоташтырам да: «Әйдәгез, сез сөйләгез инде, кем күбрәк белә?»— дим. Балалар бер-берсен уздырып китәләр сөйләп, китәләр сөйләп:

*— Әтәч менгән читәнгә,*
*«Кикерикүк» итәргә.*
*Әтәчкә дә хәбәр килгән*
*Армиягә китәргә.*
*Әтәч әйтә: «Бармыйм»,— ди,*
*Чебеш әйтә: «Калмыйм,— ди,—*
*Син армиягә китсәң,*
*Бер кукай да салмыйм»,— ди.*
*Әтәч армиягә китте,*
*Чабатага утырып.*
*Чебеш мескен карап калды*
*Күзкәйләрен тутырып.*

Шулай балаларның ишеткән-белгәннәрен язып, уеннар уйнап, көннең кичкә авышканын да сизми калабыз. Нәни дуслар өйләренә тарала. Мин дә, көннең бушка узмавына сөенеп, авылга таба атлыйм.

Балаларның үз көнкүреше, үз гореф-гадәтләре, үз традицияләре, әгәр шулай әйтергә яраса, үз этнографиясе бар. Нәниләр көнкүреше, зурлар тормышы белән тыгыз бәйләнештә булуга карамастан, үзгәчәрәк калыплашкан. Бу үзенчәлекләр алар мохитендә кулланыла торган халык иҗаты әсәрләрендә дә чагыла.

«Балалар фольклоры» зурларның балалар өчен башкарыла торган һәм нәниләрнең үз мохитендә башкарыла торган әсәрләрне үз эченә ала. Татар балалар фольклоры составында һәрберсенең үз поэтик үзенчәлекләре булган егермеләп жанр бар.

Балалар фольклорының үзенчәлекле төркем булып оешу процессы зурларның поэтик иҗаты белән тыгыз мөнәсәбәттә барган. Кешелек җәмгыяте иҗтимагый һәм фикри үсешнең югарырак баскычка күтәрелгән саен, халык репертуарында яшәп килгән фольклор әсәрләренең бер өлеше тормыш-көнкүрештә үзенең кыйммәтен югалта килгән һәм балалар мохитенә күчкән. Шулай итеп, гасырлар дәвамында кешелек җәмгыяте үзенең «балалык» чорында кулланган фольклор әсәрләрен яшь буынга «бүләк итә» барган. Аларның күбесе зурлар репертуарыннан бөтенләй төшеп калган һәм нәниләр телендә хәзерге көнгә кадәр килеп җиткән. Шуңа күрә, балалар фольклоры халкыбызның борынгы халык поэзиясе үрнәкләрен, гореф-гадәтләрен, ырымышануларын, тел үрнәкләрен, тормыш-көнкүреш картиналарын күзаллау өчен дә әһәмиятле чыганак булып хезмәт итә.

Балалар фольклорының тәрбияви әһәмияте гаять зур. Ул әсәрләр, язма әдәбият әле булмаган чорларда, бик күп гасырлар буенча яшь буынның рухын тәрбияләп килгән. Аларның әһәмияте безнең чорда да югалмый. Балалар фольклоры, гасырлар дәвамында нәниләрнең эстетик зәвыкларына яраклашып формалашкан әсәрләр буларак, бер яктан, халык тәҗрибәсе белән сыналган тәрбияви чараларның саекмас чишмәсе ролен үтәсә, икенче яктан, балаларның рухи дөньясын танып белүдә әһәмиятле хәзинә булып хезмәт итә.

Нәниләр дөньясын, аларның эстетик ихтыяҗларын тирәнтен белү балалар әдәбияты өлкәсендә эшләүче әдипләр өчен бигрәк тә мөһим. Бу нәүбәттән, галим һәм язучы Г. Толымбайскийның сүзләрен искә төшерү урынлы булыр. «Безнең өстебездә һәрвакыт балаларга матур әдәбият тудыру бурычы тора бит,— дип язды ул.— без инде балалар әдәбиятын балалар теле белән бирү, балалар кызыгырлык итү өчен, әлбәттә, балалар фольклорын яхшы итеп өйрәнмичә булдыра алмыйбыз». Чыннан да, балалар фольклоры — нәниләр әдәбиятының нигез ташы ул.

Балалар әдәбияты кебек үк, халкыбызның гасырлар буенча тупланып килгән бай фольклор хәзинәсенә таянып үсеп киткән.

Татар балалар поэзиясе үсеше тигез юлдан гына бармады. Вакыт-вакыт балалар шигъриятен әйләнә-тирәлекне үтә гадиләштереп тасвирлау рәвешендәге яисә коры дидактика, декларатив әсәрләр күмеп китте. Бу, беренче чиратта, балалар психологиясенең нечкәлекләренә төшенә алмау, аларның эстетик ихтыяҗларын белмәү һәм балалар фольклорыннан килгән шигъри канунnарга игътибар җитенкерәмәү нәтиҗәсе иде. Соңгы утыз ел эчендә татар балалар поэзиясе нәниләр психологиясенә һәм аларның эстетик ихтыяҗларына шактый якынайды. Әмма аерым шагыйрьләрнең гап-гади рифмалы тасвирламалар корып, нәни укучыларга тәкъдим итү очраклары хәзерге чорда да еш очрый. Шуның өчен балалар фольклорының кайбер төп поэтик үзенчәлекләрен күзаллап узу файдалы булыр дип уйлыйм.

Балалар фольклорында игътибарны иң җәлеп иткән нәрсә шул: нәниләр теленнәге егермеләп жанрның көнкүрештә кулланылыш максаты, ягъни төп функциясе — уйнау, җорлану, уен төсмере булмаган бер генә әсәр дә юк. Кыскасы, фольклор әсәрләре балаларның күңел ачу, уйнау чаралары ролен үтиләр. Әмма ул максатсыз мәгънәсез уен түгел. Нинди генә әсәрне алма, аның эчтәлегендә эстетик, педагогик яки баланың акыл һәм физик үсешен оештыруга юнәлдерелгән ният, идея салынган. Балалар фольклорының бу функциональ үзенчәлеге тиктомалдан гына килеп чыккан нәрсә түгел. Ул күп гасырлар дәвамында халык иҗатының балалар психологиясенә һәм эстетик ихтыяҗларына яраклашып формалашуы нәтиҗәсендә туган.

Аларның уен төсендә формалашуы гаҗәп тә түгел, чөнки нәниләрнең төп шөгыле — уен. Алар уен аша әйләнә-тирәлекне танып белә, уен аркылы хезмәт күнекмәләре ала, уен аша яшәргә, тормыш көтәргә өйрәнә. Балалар җисми объектлар белән генә түгел, сүзләр белән дә уйный. Фольклор әсәрләре дә баланың сүз-тел сферасында уйнап, юаныч ала торган «уенчыклар»ы алар.

Әдипләр тарафыннан иҗат ителгән әсәрләр дә шул «уенчыклар» вазифасын үтәргә тиеш дип уйлыйм мин. Әгәр дә син нәни укучыга шигъри телдә фикер әйтергә телисең икән, әйтәсе сүзеңә уен төсмере сал. Сүзең калейдоскоптагы бизәкләр шикелле төрләнеп, алмашынып, баланың игътибарын тартып, уйнарга кызыктырып, «кытыклап» торсын. Аңа бернинди бизәге булмаган рифмалы тасвирлама тәкъдим итү — курай сораган балага юнылмаган агач таяк тоттыру белән бер ул.

Нәниләр шигъриятенә ничек уен төсмере бирергә, аларны кызыктыра торган нинди бизәкләр табарга? Бу сорауларга җавап бирүе җиңел түгел. Әмма балалар фольклоры шигъриятенә күз салу бу мәсьәләгә беркадәр ачыклык кертә ала. Балалар телендә формалашкан халык иҗаты әсәрләренең һәм хәзерге язма балалар шигъриятенең поэтикасын чагыштырып караганда, шул нәрсә күзгә чалына: балалар фольклорында оешкан күп кенә матур поэтик чаралар язма әдәбиятта дәвам иттерелеп, үсеп китә алмаганнар. Балалар поэзиясен төрләндереп, балкытып җибәрердәй чаралар нәниләр әдәбиятының нигезе — балалар фольклорында калып, онытылганнар һәм үзләренең күреп алып, үстереп җибәрүчеләрен көтеп яталар.

Шундый «онытылган» поэтик чараларның бер өлеше әсәрнең композиция корылышына карый. Балалар фольклорын бу яктан анализлау шуны күрсәтә: гадәттә, ул әсәрләрдә экспозиция бик кыска булып (ул кайчакта бер яки ике сүздән генә торырга мөмкин), вакыйгалар үстерелеше динамик төстә кульминациягә омтыла һәм чишелеш «капылт» кына, көтмәгәндә килә. Чишелеш еш кына очракта абсурд булып чыгарга да мөмкин.

Сюжет төзелешенә караган үзенчәлекләр дә бар. Балалар фольклоры әсәрләре күп вакыйгалы хәлләр яисә тасвирлау объекты кечкенә генә такмаза эчендә дә әллә ничәгә төрләнергә мөмкин. Бу балаларның психологик халәтеннән килә торган сыйфат булса кирәк. Алар бер объектта яки вакыйгада озак тукталып тора алмыйлар, тизрәк икенчеләренә, өченчеләренә күчәләр. Еш кына әсәрләр вакыйга һәм объектларны санап китү рәвешен ала. Кыскасы, алар, калейдоскопта бизәкләр төрләнеп торган шикелле, гел алмашынып торалар.

Сюжетны тормыш-көнкүреш картиналарын «астан өскә» китереп тасвирлау, бер әйбер сыйфатларын юри икенчесенеке белән бутау, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешен чуалту, бер төрле хәбәр әйтеп, шундук инкарь итү рәвешендә төзү дә — балаларның яраткан алымы. Н. Исәнбәт мондый әсәрләрне «чуалтмышлар һәм киреләмешләр» дип атады. Менә шундый әсәрләрдән бер өзек:

*Борын-борын чакта,*
*Мин бай чакта,*
*Бер салмалык*
*Он бар чакта,*
*Әти яшь чакта,*

*Үзем карт чакта,*
*Бөгелмәгән җәя белән,*
*Юнылмаган ук белән,*
*Атып салдым саескан.*

1920 елларда, вакыйгаларны шулай «зир-зәбәр» китереп тасвирлау тибындагы әсәрләр нәниләрнең интеллектуаль һәм рухи үсешенә зыян китерә, дип исбатларга тырышучы педагоглар булды. Алар шундый дәгъва белән башлыча К. И. Чуковский иҗатына ябырылганнар иде. Язучы хаклы рәвештә аларга каршы чыкты. К. И. Чуковский үзенең «Гакыллы акылсызлыклар» («Лепые нелепицы») һәм «Икедән бишкә кадәр» («От двух до пяти») дигән атаклы хезмәтләрендә чуалтмышлар кору балаларның закончалыклы бер психик һәм эстетик зарурияттеннән килеп чыккан булуын, нәниләрнең рухи һәм гакыл үсешендә аларның зур әһәмият тотуын исбат итте. «Әгәр дә чуалтмышлар чынбарлыктагы идея һәм объектларның үзара мөнәсәбәтен томаласа, бала өчен бу куркыныч булыр иде,— дип язды ул.— Ләкин алар каплау түгел, киресенчә, күпертеп, ачыклап, ассызыклап күрсәтәләр. Алар баланың чынбарлыкны танып-белүен... көчәйтәләр» [1]. Хәзерге заман педагоглары да аның фикерен куәтлиләр. «Бала (чуалтмышларны — Р. Я.) сөйләү барышында «кирегә әйләндерелгән» нәрсәләрне күңеленнән үз урынына куярга тиеш,— дип яза мәсәлән, профессор Я. И. Ханбиков.— Бу аңарда үзенчә бер төрле интеллектуаль канәгатьләнү хисе уята» [2].

Сюжетны чуалтмышлар формасында кору — аерым шагыйрьләр тарафыннан уйлап чыгарылган алым түгел. Ул балалар поэзиясенең нигезе булган нәниләр фольклорында халыкның эстетик, педагогик ихтыяҗлары нигезендә формалашкан. Бу хәтта бер татар фольклорына гына хас әйбер дә түгел. Славян халыклары, инглиз, француз, немец һ. б. балалар фольклорында да шундый ук хәл.

Балалар фольклорында сюжетны чылбыр рәвешендә төзү алымы да бик популяр. Ул, гадәттә, берәр объектның сыйфат үзгәрешләрен санау яки башта күренешнең нәтиҗәсен күрсәтеп, соңыннан аны тудырган сәбәпләрне санау — шулай итеп, билгеле бер логик тезем ясау рәвешендә була. Бу бигрәк тә такмазалар жанрына хас алым. Менә шундый әсәрләрнең берсе:

*Ай-ли, чумадан,*
*Әби битен юмаган.*
*Әби битен юар иде,*
*Комганда су булмаган.*
*Комганда су булыр иде,*
*Кызы суга бармаган.*
*Кызы суга барыр иде,*
*Көянтәсе булмаган.*
*Көянтәсе булыр иде,*
*Әтисе ясамаган.*
*Әтисе ясар иде,*
*Агачлары булмаган.*
*Агачлары булыр иде,*
*Лесник агач бирмәгән.*
*Шуның өчен әбекәй*
*Битен юмый башлаган.*

Әйтергә кирәк, бу рәвештәге сюжет кору алымының татар балалар шагыйрьләре тарафыннан гамәлгә кертелгәне юк әле.

Сюжетны диалог (әйтеш) формасында төзү алымы турында да шуны әйтергә туры килә. Андый әсәрләрдән бер мисал китерик:

*— Тем, тем, Темофей,*
*Төнлә кая барасың?*
*— Яңавылга яу килгән,*
*Шуны куа барамын.*
*— Аның өчен ни бирәләр?*
*— Бармак башы ит бирәләр.*
*— Аны кая куясың?*
*— Кызган ташка куямын.*
*— Кулың пешсә, нишләрсең?*
*— Агымсуда юармын.*
*— Агып китсәң, нишләрсең?*
*— Ауный-ауный елармын...*

Балалар фольклорында бик популяр булган мондый сюжет кору алымы язма әдәбиятта да дәвам иттерелергә бик лаеклы.

Балалар фольклорының образлар системасында да бер үзенчәлек күзгә ташлана. Нәниләрнең психик һәм эстетик ихтыяҗлары шуны таләп итә, күрәсең: әсәрләрдәге барлык объектлар, предмет һәм күренешләр җанлы итеп тасвирлана. Балалар кай-

---

[1] Чуковский К. И. От двух до пяти. Киев, 1959, 305 б.
[2] Ханбиков Я. И. Из истории педагогической мысли татарского народа. Казань, 1967, 109 б.

вакыт җансыз предметларны да башка сыймаслык эшләр эшләргә «мәҗбүр итәләр». Мәсәлән, әлеге такмактагы кебек:

*Трактор менгән читәнгә*
*Тыпырчына китәргә.*
*Өй артына мунча килгән,*
*Юл сорыйдыр китәргә.*

Хайваннар, кош-кортлар, җәнлекләр образы балалар фольклорында төп урынны алып тора. Тик алар үз сыйфатларында түгел, ә кеше сыйфатларына ия итеп тасвирланалар. Алар кешеләр кебек үк тормыш көтәләр, уйныйлар-көләләр, ашыйлар-эчәләр. В. И. Ленинның әкиятләр турында әйткән кызыклы фикере бар. «Әгәр сез балаларга сөйләгән әкияттә әтәч белән песи кешеләрчә сөйләшмәсә,— ди ул,— балалар ул әкият белән кызыксынмаслар иде». Бу — балалар фольклорының бөтен жанрларындагы образларга да карый. Сөйләшмәгән, хәрәкәт итмәгән җансыз объектлар һәм образлар юк балалар фольклорында.

Шигырь төзелеше һәм шигъри форма ягыннан караганда да нәниләр фольклорының аерым хасиятләре бар. Нәниләрнең поэтик иҗат әсәрләре, нигездә, ике төрле алым белән төзелә һәм башкарыла: такмаклау һәм такмазалау. Әйтергә кирәк, бу шигъри формалар фольклорчы һәм әдәбиятчы галимнәр тарафыннан әлегә кадәр ныклап өйрәнелмәгән.

Гадәттә, без «такмак» дигәннән бию вакытында башкарыла торган яки тиз ритм белән кыска көйгә җырлана торган шаян эчтәлектәге әсәрләрне аңлыйбыз. Мондый әсәрләр нәниләр фольклорында күп. Әмма аларның репертуарында тагын бер төркем такмаклар бар. Алар — сөйләм такмаклары. Бу төр шигъри әсәрләр көйләп яки җырлап түгел, ә нәкъ менә сөйләп башкарылалар. Алар, гадәттә, төгәл һәм саф ритмрифмалы булып, гаять тә динамик төстә һәр иҗек аша басым ясап төшереп такмакланалар. Мәсәлән:

*Әби коймак пешерә,*
*Бабай кабык төшерә.*
*Мин дә коймак сорасам,*
*Кабык белән төшерә.*

Такмазаларның үзенчәлеге шунда ки, алар барлык шигъри кануннарга да буйсынмый. Такмазаларда шигъри үлчәм һәм ритмика даими булмый, ул бер әсәр эчендә әллә ничәгә төрләнергә, ә кайвакытларда бөтенләй югалырга мөмкин. Ләкин әсәрне шигъри калып эчендә тотучы бер компонент даими кала. Ул — рифма. Шуның өчен такмазалар кайчак рифмалаштырылган прозага охшап кала:

*Барып кердем бер йортка,*
*Анда утыра бер кортка...*
*Мич артында белен,*
*Мин аның берсен элдем.*
*Мин чабып чыгып киттем,*
*Әби куып чыгып китте.*
*Әби килә арттан куып,*
*Мин барам аркамны уып,*
*Әби куып җиталмый,*
*Кулда белен беталмый.*
*Әби куып җитте,*
*Кулда белен дә бетте.*

Бөек пролетар язучы М. Горькийның язучыларга әйткән бер канатлы сүзе бар. «...Сүз сәнгатенең башы — фольклорда. Үзегезнең фольклорыгызны җыегыз, аңардан өйрәнегез...»— диган ул. Бу сүзләр балалар әдәбияты өлкәсендә эшләүче әдипләргә дә турыдан-туры кагыла.

Татар балалар фольклоры бөтенләй үк кул тимәгән өлкә түгел. Аны җыюга, өйрәнүгә язучы һәм галим Нәкый ага Исәнбәт зур көч куйды. Әдипнең «Балалар фольклоры» (1941), «Нәниләр шатлана» (1967), «Балалар дөньясы» (1970), «Балалар фольклоры» (1984) дигән җыентыкларында урнаштырылган материаллары һәм фәнни күзәтүләре зур әһәмияткә ия.

Моннан тыш Х. Бәдигый, Г. Рәхимнәрнең архив материаллары арасында, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының һәм Башкорт дәүләт университетының татар филологиясе кафедрасы фольклор фондында да байтак материаллар бар. Алдагы көндә шуларны туплап, «Татар халык иҗаты» сериясендә «Балалар фольклоры» дигән китап чыгару да күз алдында тотыла. Әгәр әдәбият сөючеләр арасында нәниләр фольклоры белән кызыксынучылар булса, язып алынган әсәрләрен Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының халык иҗаты секторына **(420111, Казан, Лобачевский ур., 2/31. ИЯЛИ)** җибәрә алалар.

**Китап күзәтү**

# МИЛЛИ МАТБУГАТЫБЫЗ ТУРЫНДА

Республикабыз галимнәре татар халкының культура мирасын өйрәнү, аңа заманча бәя бирү юлында активлыкларын арттырдылар. Ләкин шунысы бар: берәүләр бу өлкәдә һаман да утызынчы елларның вульгар-социологик бәяләрен күтәреп йөрсә, икенчеләр мирасыбызның тарихи кыйммәтен җәмәгатьчелеккә объектив рәвештә җиткерергә омтыла.

Шушы көннәрдә генә Мәскәүдәге «Наука» нәшриятында тарих фәннәре кандидаты Равил Әмирхановның матбугатыбыз тарихына багышланган «Татарская демократическая печать (1905—1907 гг.)» исемле китабы басылып чыгу культура мирасыбызны өйрәнүдә игътибарга лаек бер хезмәт булды. Аның җаваплы редакторы — тарих фәннәре докторы Х. Хәсәнов.

Татар матбугатын тудыру юлында алдынгы татар һәм рус укымышлылары тарафыннан бер гасыр дәвамында алып барылган көрәш 1905 елгы буржуаз-демократик революция казанышлары нәтиҗәсендә уңышлы хәл ителде. Россиядәге бер генә халык та үз матбугатын булдыру юлында шулкадәр көч куеп тартышмагандыр. 1905 елгы революциядән татар халкы театр, матбугат һәм чикләнгән булса да политик ирекләр алды.

Матбугатыбызны тудыру һәм аны үстерү өчен көрәш тарихы Октябрь революциясенә кадәр үк беркадәр дәрәҗәдә өйрәнелә килде. Шул чорлардан бирле татар матбугатына багышланган төрле белешмәләр, монографияләр, аерым проблемаларны, матбугат ветераннарыбызның эшчәнлеген яктырткан мәкаләләр һәм «Урал», «Кызыл байрак» газеталарына, «Чикерткә», «Уклар», «Чүкеч», «Карчыга», «Туп», «Яз» кебек сатирик журналларга багышланган хезмәтләр дөнья күрде. Ул хезмәтләр, нигездә, Казанда, беразы Уфада татар, рус, башкорт телләрендә чыккан иде. Тик алар бөтенсоюз укучысына барып җитмәделәр дисәк тә ялгыш булмас.

Равил Әмирхановның югарыда искә алынган хезмәте исә татар матбугаты тарихы белән ватандашларыбызны таныштыру юлында беренче хезмәт. Шул ук вакытта бу хезмәт үзгәртеп кору чорында, революциягә кадәрге татар матбугатына озак еллар дәвамында сугыла килгән төрле яман ярлыклардан котылу нисбәтендә язылуы белән дә әһәмиятле. Хезмәт матбугатыбыз тарихының баштагы ике елын өйрәнүгә багышланган. Аны язганда автор марксизм-ленинизм классикларының культура мирасын өйрәнү методикасын истән чыгармаган. Куелган мәсьәләләргә сыйнфыйлык, партиялелек позицияләреннән якын килгән.

Равил Әмирхановның китабы проблеманың куелышы буенча этрафлы язылган кереш белән башланып китә. Галим татар матбугатының урынын, эчтәлеген гомумроссия матбугаты яктылыгында күзәтә һәм аның шул бер бөтеннән аерып каралырга тиеш түгеллеген раслый. Бер уңайдан керештә матбугатыбыз үсешендә цензураның тоткан роле турында кыскача, ләкин әһәмиятле фикерләр әйтелә.

1905—1907 елларда Россиядә татар телендә чыккан 21 газета һәм 12 журнал барланып, шулардан автор тарафыннан 12 басма өйрәнелгән. Болардан тыш Идел буенда, Мәскәү һәм Петербургларда рус телендә чыккан шул чор матбугаты, архив материаллары, махсус әдәбият та җитәрлек дәрәҗәдә, тиешле югарылыкта өйрәнелгән.

Хезмәтнең беренче бүлеге татар демократик матбугатының тууы һәм ныгуы проблемаларына багышланган. Бүлеккә кереш итеп бирелгән тарихи экскурста татар милләтенең эшчеләр сыйныфы турында мәгълүмат бирелә һәм аның таралыш географиясе күрсәтелә. Автор, XX гасыр башында Россиядә рус, украин, латыш пролетариатыннан кала, татар эшчеләр сыйныфының дүртенче зур милли отряд булуын күрсәтә. Эшчеләр сыйныфының үсүе исә алар арасында эш оештырырлык революционер кадрларның да килеп чыгуына сәбәп була. Шунлыктан татар пролетариаты XX йөз башында Х. Ямашев, Г. Сәйфетдинов, Г. Коләхметов кебек марксистларның һәм күп санлы профессиональ революционерларның барлыкка килүенә нигез булган. Бу революционерлар татар пролетариатына туган телләрендә русчадан тәрҗемә ителгән политик әдәбиятны җиткергәннәр. Шул сәбәпле татар пролетариаты белән Россия пролетариаты арасында рухи туганлык ныгыган, демократик фикерләр киң таралган.

Хезмәттә революция дәверендә барлыкка килгән милли матбугатның эчтәлегенә, политик төсмеренә анализ ясала. Автор, тарихчы буларак, иң беренче чиратта матбугатыбызда революция шартларында киң үсеп киткән революцион-демократия идеологиясенең үзгәрешен өйрәнә. Шушы идеологиянең төрле юнәлешләрен барлый. Аның иң алдынгы рәтендә татар демократик әдәбиятының Г. Тукай, Г. Камал, М. Гафури, Ф. Әмирхан кебек вәкилләре торуын күрсәтә.

Алардан кала, икенче демократик платформаны Кәлимулла Хәсәнов, Һади Атласов һәм Әхмәтһади Максуди кебек II Дәүләт думасында рус трудовикларына якын торган төркем тәшкил итә.

Өченче төркемгә исә татар крестьяннары идеологиясен алга сөрүче Г. Исхакый, Ф. Туктаров, Х. Әбүзәров, С. Рәмиев һ. б. кертелә.

Хезмәттә татар демократик хәрәкәтенең халыкта иҗтимагый-политик аң үсешенә уңай йогынты ясаганлыгы ачыла. Әлбәттә, бу хәрәкәт вәкилләре шул дәвернең җитешсезлекләреннән дә азат булмаган.

1904 елның ахырында Камил Мотыйгый Җаек шәһәрендә татар телендә «Әл-гасрелҗәдид» исемле журнал чыгару артыннан йөри башлый. Ул журналны чыгарудан төп максат — татар һәм рус халыклары арасында булган рухи якынлыкны арттыру, дип күрсәтә. Ләкин властьлар, бу максатның дәүләт интересларына туры килүен аңласалар да, рөхсәт бирергә ашыкмыйлар. Аны чыгаруга рөхсәт бары тик 1905 елның июнендә генә алына. 1905 елның 2 сентябрендә исә Петербург шәһәрендә Идел буе татарларының беренче газетасы «Нур» чыга башлый.

Изелгән милләтләрнең матбугаты туу — ул, һичшиксез, прогрессив күренеш. Чөнки газеталар, журналлар — иҗтимагый аңны үстерүгә ярдәм итә торган көч.

Хезмәтнең 79—81 битләрендә бирелгән өч таблицада ул еллардагы газета-журналлар хакында бик тә кыйммәтле фактик материаллар бар. Әлеге мәгълүматлар культурабызның төрле тармакларында эшләүчеләр өчен аеруча кирәкле һәм кыйммәтле.

Китапта, матбугатыбыз тарихында беренче буларак, газета-журналларның үз укучылары белән бәйләнеше дә тасвирлана. Автор татар матбугаты битләрендә казах, кыргыз, азәрбайҗан һ. б. халык вәкилләренең дә язышуын дөрес билгели. Татар матбугатының хәбәрчеләре бөтен Россия буенча йөреп, хәтта чит илләргә дә барып җиткән. Китапта демократик матбугат идарәләренең укучылар белән бәйләнештә бай тәҗрибә туплаганлыгы ачыла. Бу тәҗрибәне бүгенге татар матбугаты хезмәткәрләренә дә файдалану комачауламас иде.

Үсеп килүче демократик татар матбугатына каршы патша хакимияте төрле чикләү һәм кысу чараларының системасын оештыра. Хезмәттә бу киртәләр бай архив чыганаклары белән күрсәтелә. Патша цензурасының иң күренекле вәкилләреннән Пинегин, Ашмариннарның милли матбугатны кысулары хакында хәтта рус матбугаты битләрендә дә гаепләп чыгалар.

Хезмәтнең икенче бүлегендә милли матбугатның идея юнәлешләре анализлана. Татар матбугатында барган идеологик көрәшләрнең иң әүвәлгесе демократия өчен була. Автор бу хәрәкәтнең барышын «Фикер» газетасы материаллары нигезендә күрсәтә. Әйтергә кирәк, «Фикер» татар газеталарының иң демократик юнәлештәгесе санала. Шулай ук «Таң йолдызы», «Азат халык», «Туп», «Дума», «Тавыш», «Карчыга» һ. б. газета-журналлар тарафыннан демократия өчен алып барылган көрәш сәхифәләре дә читтә калмаган. Татар матбугатының әлеге басмалары халык массаларының 1905—1907 елгы революциядә куелган теләкләрен чагылдырган, аларны демократия өчен көрәшкә мобилизацияләгән.

Матбугатыбыз бу елларда татар демократик культурасын үстерү, аның яңа тармакларын булдыру өчен көрәш алып бара. Бу көрәш Р. Әмирханов хезмәтендә яңа аспектта һәм яңа сәхифәләр яктылыгында ачыла. Китапның 119 битендә Дума депутаты Кәлимулла Хәсәновның татар телен, әдәбиятын һәм мәктәбен яклап Россия трибунасыннан карагруһларга каршы ясаган кыю чыгышы китерелә. Кәлимулла Хәсәновның үткен фикерләре дошманнарны урыннарыннан сикертеп торгыза һәм, аның сүзләрен хуплап, Тукай тарафыннан «Китмибез» дигән шигырь язылуга сәбәп була.

Автор үз хезмәтендә «Тавыш», «Әльислах» кебек газеталарның материалларын да киң файдаланган. Билгеле, кайбер проблемаларда автор белән бәхәсләшергә дә мөмкин булыр иде. Мәсәлән, рәсемгә төшү, рәсем ясауга мөнәсәбәт — татар тормышында, татар культурасында өйрәнелмәгән мәсьәлә. Берничә мулланың бәхәсе генә, әлбәттә, бу өлкәдә соңгы сүзне әйтергә җирлек бирми. Аның сәбәпләре тирәндәрәк ята. Безнең кулыбызда XIX гасырның соңгы чирегендә татар кешеләренең Казанда эшләгән фотографияләре шактый. Шул исәптән, мөфти Мөхәммәдьяр Солтановның 1886 елда төшкән фоторәсеме дә саклана. Шунлыктан, Лаеш ягындагы караңгы Кабан авылыннан Казанга килеп урнашкан Әхмәтҗан Сәйдәшев фикере бөтен татар иҗтимагый фикерен чагылдыра, дип белдерү тулы хакыйкать булмас. Культура мәсьәләсендә Галимҗан Ибраһимов тарафыннан вульгар-социологизм җирлегендә бирелгән бәяләр дә аны тулыландыруга хезмәт итә алмый. «Таң йолдызы» газетасы мәсләген билгеләгән фикерләрне дә махсус өйрәнү кирәклеге үзен сиздереп тора.

Демократик татар матбугаты фикеренең

янә бер әһәмиятле ягы, аның реакцион руханилар һәм буржуаз милләтчеләргә каршы көрәшендә чагыла. Р. Әмирханов бу мәсьәләне дә өйрәнә. «Уклар», «Фикер», «Эльислах», «Азат» һ. б. органнардагы материалларны автор иркен файдаланган. Р. Әмирханов әлеге өлкәдә Габдулла Тукай эшчәнлеген югары бәяли.

Ләкин яңа гына туган, политик тормыш һәм көрәш тәҗрибәсе булмаган татар матбугатын 1905—1907 ел эчендә генә бөтен яктан өлгергән итеп күрергә тырышу һәм аңа тәҗрибәле марксистларга, партия органнарына куела торган таләпләрдән карау урынсыз булыр иде. Моңа кадәр шулай булып килде. Тарихчыларыбыз яңа туган татар матбугатыннан төрле җитешсезлекләр табарга тырышып, аңа бүгенге татар матбугатына куела торган таләпләр югарылыгыннан догматикларча якын килделәр. Равил Әмирханов бу алым белән эшләүдән баш тартучыларның беренчеләреннән булды. Мәсәлән, «Таң йолдызы» газетасының тоткан юлы моңа хәтле чыккан әдәбиятта дөрес каралмады, тискәре бәяләнде. Равил Әмирханов бу газетаның халыклар дуслыгын пропагандалауга керткән һ. б. уңай эшләрен ачык күрсәтә.

XX гасыр башы татар матбугаты битләрендә экономик проблемалар яктыртылуы хакында бездә аз язылды. Тикшерелә торган хезмәттә бу мәсьәлә буенча бүлекчә бар. Татар экономик фикеренең торышы хакында, тарихчы Фәйзелхак Газизуллинның хезмәтеннән башка, бу темага каләм тибрәтүче әлегә күренми иде. Аның хезмәте, нигездә, «Урал» газетасы материалларына таянып язылган булса, Равил Әмирханов, «Урал», «Фикер», «Әльислах», «Азат халык» материаллары белән фактик базаны киңәйтеп, яңа төркем чыганакларны әйләнешкә кертә. Көчле цензура шартларында да татар матбугаты битләрендә үткәрелгән марксистик экономика фикерләрен күрсәтә.

1905—1907 еллар революциясе буржуаздемократик юнәлештә барды. Революциянең хәрәкәтләндерүче көчләре эшче-крестьяннар һәм буржуазия булды. Ярымфеодаль Россиядә бу сыйныфларның үзләрен канәгатьләндермәгән күп төрле киртәләр бар иде. Ә революция барышында һәр сыйныфның идеологиясе, көрәш ысуллары формалашты. Татар җәмгыятендә дә Россиянең сыйныфларга бүленеше, аларның идеологик карашлар системасы кабатланды. Россия эшчеләренең алдынгы карашларын берләштергән социаль-демократик идеология 150 меңлек татар пролетариаты һәм алдынгы татар интеллигенциясе арасында үзенә уңай җирлек тапты. Тарихчы Равил Әмирханов хезмәтендә социал-демократия фикерләренең татар матбугаты битләрендә урын алган материалларына анализ ясала. Әлеге фикерләрне автор «Азат», «Азат халык» газетасы битләрендә таба. Г. Камал, Г. Коләхметов, Х. Ямашев һәм башкаларның мәкаләләрендә марксизм өйрәтүләренең чагылышы тикшерелә. Автор татар матбугаты битләрендә пролетариат диктатурасы, аның бердәмлеге, яхшы һәм начар хөкүмәтләр турында һ. б. темаларга мәкаләләр басылуын күрсәтә.

Инде килеп, хезмәттә кайбер кимчелекләр дә бар. Беренчедән, кайбер урыннарда тарих ягы басып китә (мәсәлән 43—59 бб.). 62—66 битләрдәге «Матбугат туунын алшартлары» сәхифәсе исә керешкә күчерелергә тиеш булгандыр. Автор татар культура мирасын бәяләүдә һаман да вульгар-социологизм позициясеннән торып ярлыклар сугу белән мавыгып ала. Мәсәлән, 68 биттә мондый фикер бар. «Одновременно возникали органы черносотенцев и клерикалов, выражавшие классовые интересы кадимистов, оправдывавшие средневековую отсталость, религиозный фанатизм и косность. Начали выходить газеты «Баянуль-хак», «Эл-галями-эль-ислами», «Дин ва магишат» («Религия и жизнь»), «Эддин ва эльэдэп» («Религия и этика» и др.) Бу газеталарда татар тормышында барган искелек белән яңалык тартышы чагыла. Аларны нин дидер безгә мәгълүм булмаган партияләрнең органнары итеп карап булмый. Газетаның аерым саннарында ниндидер Әхмәтҗан Сәйдәшевләрнең анахронизм дәрәҗәсендәге фикерләре басылып чыгу гына бөтен «Бәянел-хак» газетасын карагруһ дип атарга нигез бирми. «Бәянел-хак» газетасы битләрендә аерым, кадимчеләр позициясеннән торып язылган мәкаләләрдән тыш, халык өчен файдалы һәм информатив меңнәрчә материал да чыгып килгән. Шул ук «Дин вә мәгыйшәт» журналының баштагы саннарында социализм, конституция, демократия, республика кебек политик терминнарны халыкка аңлаткан материаллар да басылган.

Исемнәре саналып үтелгән органнарны ныклап өйрәнми торып, тибеп кенә үтәргә ярамый. Аларның һәркайсы халыкны дөньякүләм әһәмиятле проблемалар белән таныштыруга хезмәт иткән.

Мирасыбызны өйрәнгәндә аның йөзендә һаман да ак һәм кара төсләр генә күрү безгә файда китермәс. Бу — фәндәге үзенә күрә бер «дальтонизм» чире.

Хезмәт татар матбугаты тарихын өйрәнү юлында фәннең яңа сүзе булып тора. Аның Мәскәүдә рус телендә дөнья күрүе дә уңай күренеш. Димәк, безнең мирас мәсьәләсе гомумсоюз күләмендә яктыртыла дигән сүз. Тик китапның кечкенә тираж белән чыгуы гына күңелдә канәгатьсезлек хисе калдыра.

**Марсель ӘХМӘТҖАНОВ,**
филология фәннәре кандидаты.

# ГҮЗӘЛЛЕККӘ ТУГРЫЛЫК

Шагыйрь Әмир Мәхмүдовның «Мәңгелек моң» дип исемләнгән икенче шигъри җыентыгы басылып чыкты[1]. «Бу китабында да ул «Матурлык тантанасы» исемле беренче җыентыгында игълан иткән фәлсәфи-эстетик принципларына тугры калган. «Мәңгелек моң»да шагыйрьнең гүзәллеккә тугры җаны, гүзәллек кануннарына нигезләнгән кыйбласы шактый тулы ачыла. Бу җыентык таләпчән һәм нечкә зәвыклы укучыны гүзәллек һәм явызлык хакында, яшәешнең асылы, җиһан улы — Кешенең тормыштагы урыны турында уйландыра, шагыйрьнең кабатланмас, үзенчәлекле шигъри дөньясына чакыра.

Әмир Мәхмүдовның лирик гүзәллек кануннарыннан төзелгән шигърият дөньясында яши. Аның идеалы — җир шарында яшәүче бөтен милләт халыклары һәм һәрберсенең үз тәртипләре булган мәмләкәтләр арасында дуслык һәм туганлык җепләрен тоташтыру, җир кайгысын бетерү өчен, аның моң-зарын киметү өчен көрәшү:

*Күңелемдә чиксез илләр дә юк,*
*Үлем белмәс мәшһүр телләр дә юк.*

*Таш зинданнар, серле бикләр дә юк,*
*Көчле түрәләр һәм бәкләр дә юк.*

*Күңелемдә үлемсез тел — Җир теле бар,*
*Кешеләрнең уртак иле — Җир иле бар!*

Җир һәм кешелек язмышы, шагыйрьнең иҗатында мөһим урынны били. Җир язмышы өчен борчылу аның һәр шигырендә дә чагыла. «Җир кешеләрнең йөрәге», «кешеләрнең уртак иле» һәм җир кешеләре тынычлык, матурлык тәрәге булуына шагыйрь зур ышаныч белдерә. Ләкин матурлык идеалы чынбарлыкта үз кануннарын урнаштырып бетерә алмаган әле. Анда җирнең тәнен суытырга омтылучы, яки адәм балаларын шундый коточкыч фаҗига белән өркетеп, үз файдаларын кайгыртучы явыз көчләр дә бар. «Тынычлык дошманнарына СССР гражданины, биш бала атасы Әмир Мәхмүдовтан ачык хат» шигырендә шагыйрьнең золым чыганагы булган явызлык ияләренә кискен мөнәсәбәте ачык чагыла. Бу әсәр күпмедер дәрәҗәдә Һади Такташның «Лорд Чемберленга СССР крестьяны Һади Такташтан хат» шигыренә дә аваздаш төсле. Сәяси-социаль җегәре ягыннан бу ике әсәр дә сәяси шигъриятнең матур үрнәкләре булып саналырга хаклы.

Гүзәллекнең иң саф һәм иң садә хасияте булган мәхәббәт лирикасы Ә. Мәхмүдов иҗатына ямьле бер төс биреп тора. Гомумән, шагыйрьнең мәхәббәт турындагы шигырьләре күңелгә наз өсти, аны илаһи пакьлеккә дәртләндерә. Шагыйрьнең «Мәңгелек моң» исемле икенче китабына кергән шигырьләре арасында «Йөрәктәге экватор» циклына тупланган мәхәббәт лирикасы нәкъ менә шундый. Шигырьләр һәрвакыт диярлек фәлсәфи нәтиҗә белән тәмамлана. «Ике йөрәк», «Мәхәббәткә мәдхия», «Яралар», «Гүзәл», «Элеонорага» исемле шигырьләрдә бу бигрәк тә ачык күренә. Сөйгәненә йөрәк хисләрен ачып саламы ул, әллә аның белән кавыша алмау ачысын татып сыкранамы, шагыйрьнең лирик герое шул илаһи саф халәтнең асылы хакында да уйлана, сөю, сөелү кебек бөек мизгелләрнең дә «яшендәй бик тиз узуын», аларның фани булуын яхшы аңлый, бары яшәеш белән мәхәббәтнең генә бакый икәнлегенә төшенә.

Ә. Мәхмүдов иҗатта туктаусыз эзләнә, нәрсәдер таба, бер урында таптанып тормый, шулай ук күз буяп, «бер урында йөгерми» дә. Форма өлкәсендә булсынмы, стиль үзенчәлегенә кагылсынмы, шагыйрьнең иҗади эзләнүләрен күрергә мөмкин. Ә. Мәхмүдов стиле үзенчәлекле. Ул традицион калыпта гына язмый. Аның әсәрләрендә Көнбатыш шигърияте йогынтысын да, Көнчыгыш әдәбияты җәүһәрләре җемелдәвен дә сизәргә мөмкин. Шушы ныклы нигезгә таянып, һәм милли шигъриятебезнең бай мирасыннан да өйрәнеп, Ә. Мәхмүдов үз шигъри стилен тудыра. Шигырь формасын гадәттә бер әдәби деталь оештыра. Ә. Мәхмүдовның язу алымы да кызыклы — үрелеп барган, бер-берсенә ипле береккән фикерләр, сурәтләр чылбыры. Мондый алым эчке рифмалар булганда гына туа. Ә. Мәхмүдовта исә, шундый эчке, тышка бәреп чыкмаган рифмалардан төзелгән шигырьләр байтак.

Ә. Мәхмүдовның янә бер иҗат үзенчәлегенә тукталып китик. Ул саф шагыйрь генә түгел әле. Әдәби хәрәкәтнең үткен мәсьәләләренә беренчеләрдән булып игътибар итүче тәнкыйтьче һәм халкыбызның эстетик фикере үсешен ныклы бер системага салып өйрәнүче галим дә. Җентекле галим хезмәте белән шагыйрьлек вазифасы. Төзек логик категорияләр һәм нәфис образлардан торган хисләр дөньясы бер шәхестә әнә шулай янәшә, бер-берсен тулыландырып яши. Алай гына да түгел әле, шигъри дөньяга фән интеллектуаль байлык, лаконик, төгәл детальләр өсти. Шигърият үз чиратында исә, галим тикшергән эстетика фәненә полемик рух, кайнар пафос, эмоциональлек алып килә.

Әхмәт СӘХАПОВ

[1] Мәхмүдов Әмир. Мәңгелек моң: Шигырьләр.— Казан: Тат. кит. нәшр., 1987. 87 бит.

# Н. Г. ЧЕРНЫШЕВСКИЙНЫҢ ТАТАРЧА КУЛЪЯЗМАЛАРЫ

СССР Үзәк Дәүләт Әдәбият һәм Сәнгать архивы фондында Н. Г. Чернышевскийның иске имлябыз белән гарәп графикасы нигезендә язылган берничә берәмлек татарча кулъязмалары саклана[1]. Аларның язылган вакыты Н. Г. Чернышевскийның Саратов дини семинариясендә укыган елларга туры килә. Кайберләре исә соңрак та язылганнар. Мәсәлән, 896 номер астында саклanучы кулъязманың сиксән җиденче битендә — З. П. 1849; 88—89 битләрендә «Касыйдәи шәриф» исемле бәеттән соң шулай ук гарәп графикасы белән: «Николай Чернышевский тарих 1260 елында яздым» дип күрсәтелгән. Кулъязмаларның барысы да татар телендәге чыганаклардан күчерелгән булуларына шик тумый. Аларның күпчелеге тарихи, ә кайберләре дини эчтәлекле текстлар, мөнәҗәтләрдән гыйбарәт.

Н. Г. Чернышевскийның тәрҗемәи хәленнән мәгълүм булганча, ул Саратов семинариясенә укырга 1828 елның 24 июлендә керешә. Бу вакытта аңа ундүрт яшь була. Семинариядә ул Көнбатыш Европа, Шәрык һәм татар телләрен өйрәнә. Шәрык һәм татар телләрен семинариядә Г. С. Саблуков укыткан. Үзенең остазына Н. Г. Чернышевский гомере буена тирән ихтирам хисен саклап кала.

Татар телен камил белү өченме, әллә инде тарихны күбрәк яратканга күрәме Н. Г. Чернышевский тарихи эчтәлекле чыганакларга күбрәк игътибар биргән. Аның кулъязмалары арасында Ибраһим Хәлфин төзегән «Әхвале Чыңгыз хан вә Аксак Тимер» исемле китаптан күчереп алынган текстлар да шактый урын алып тора. Текстлар тоташтан күчерелмәгән. Мәсәлән, кереш өлешендәге кайбер тарихи мәгълүматлар кулъязмада урта өлештә урын алганнар, текстлар да шактый гына кыскартылып бәян ителәләр.

И. Хәлфин китабындагы баб, ягъни бүлек исемнәре дә беркадәр үзгәртеп бирелгән. Н. Г. Чернышевский аларны текстларның эчтәлегеннән чыгып атаган. Мәсәлән, 91—94 битләрдә «Әүвәл Җучи ханны бәйан кыйлале» дип, ә 95—100 битләрдә «Үзбәк хан үлгәндин соң Җанибәк ханны хан кыйлдылар» дигән исем астында хикәя ителә. Бу текстларның күчерелешләрендә кыскартулар юк дияргә була. Йөзенче битнең икенче ягыннан башлап «Я рабби» хикәясе башлана. Бу хикәядә «Кыйссасел әнбия» (Пәйгамбәрләр тарихы) китабыннан алынган сюжетлар да шактый. Башка дини китаплардан, яисә риваятьләрдән алынганнары да бар: «Фазыйләтел кадир» (Бөек көч) исемле хикәя әнә шундыйлардан. Соңгысын без Әбелмәних Каргалыйның (1782—1833?) «Хикәяте сәни» исемле әсәре белән чагыштырып чыктык. Н. Г. Чернышевскийның «Фазыйләтел кадир» һәм Ә. Каргалыйның «Хикәяте сәни» әсәре икесе дә бер үк сюжетка корылган. Ш. С. Садретдинов фикеренчә «бу сюжетка нигезләнеп, Көнбатыш Европа әдәбиятларында күп кенә әсәрләр язылган»[2]. Бу хикәятнең күләме зур түгел, шуңа күрә без аны тулысынча китерәбез.

### Фазыйләтел кадир[3]

Бәни Исраил заманында Шәмсүн исемле кеше бар ирде, үзе вәлиләрдән ирде. Бәгъзе галимнәр пәйгамбәрләрдән дип әйтделәр. Ул Шәмсун кяферләре берлән сугыш кыйлды. Меӊ ай аның сугыша торган коралы тәвә йаңагы ирде. Хәтта кяферләр бик гаҗиз булдылар, һич тәкатьләре калмады. Кяферләр хатынына әйтделәр: әгәр йоклагач иреңнең кул вә аякларыны багълясаң, без сиңа телә-

---

[1] СССР Үзәк Дәүләт әдәбият һәм сәнгать архивы. I ф., I тасвирлама, 298 эш. Алга таба — ҮДӘСА.
[2] Миңнеголов Х., Садретдинов Ш. XIX йөз татар әдәбияты ядкярләре. Казан, 1982, 98 б.
[3] СССР ҮДӘСА. Iф., I тасв., 298 эш, 90 б.

гән кадәре мал бирер идек диделәр. Хатыны риза булды. Бу көн сугыш кыйлуп кич кайтып ятды, уйкуга китде. Хатыны килеп кул-аякларыны йеб берлән багълады. Йокыдан уйганса, кулларын багълаулы күрде. Хатынына әйтде: Минем кулларымны кем бәйләде? Хатыны әйтде: Мин бәйләдем, куәтеңне сынамак өчен. Кулларыны тетрәткәч, йебләр парә-парә булып өзелде.

Ул көн йәнә сугыш кыйлуп күп кяферләрне харап кыйлып кайтып арып ятды. Йоклап булды. Хатыны тимерчедән зәнҗирләр ясатып кул-аякларын багълады. Шәмсүн уйгануб әйтде: Минем кул-аягымны кем багълады? Хатыны әйтде: Мин багъладым, синең куәтеңне сынамак өчен. Шәмсүн әйтде: Әй хатын, мин аллаһ тәгаләнең вәлиләренденмен. Дөньяда һич нәрсә тәкать тотмас, мәгәр үз толымыңны (толымымны?) кисеб бәйләсәң, аны өзалмасмын дип кулларыны тибрәтде, зәнҗирләр парә-парә булды. Хатыны залим бу сүзне эченә салды. (Шәмсүн) өйүдән газага барды, күп кяферләрне харап кыйлып кайтып ятды. Йокыга киткәч хатыны толымыны кисеп кул-аякларыны багълап кяферләрә кычкырды. Кяферләр килеп Шәмсүнне шәһид итделәр.

Кульязмаларда битләрнең номерлары бары тик бер яктан гына куелган. Мәсәлән, «Әүүәлге баб» 108 биттән башлана һәм «Ходай тәгаләнең Адәм галәйһи сәләмне яратканының зикре» дип атала; 112 биттә «Төрек, Хәзәр, Сакалиб, Рус, Мин, Чиң, Кимари тарихы» турында язылa; 114 биттә «Татар ханның зикре» башлана. Болардан соң 116—130 битләрдә төрле эчтәлектәге шигъри мөнәҗәтләр язылган. Шактый гына зур татарча сүзлек тә бар.

Текстлар иске татар имлясы белән башкарылган дидек. Гарәп хәрефләренә нигезләнгән татар әлифбасының хәрефләре Н. Г. Чернышевский тарафыннан аның үзенә генә хас ысул белән язылган булуын да искәртеп үтәсе килә. Ул борынгы славян язуы элементларын да кулланганга охшый. Хәрефләр бик тигез һәм пөхтә итеп язылганнар. Биредә күбрәк «нәсх» язуы төре кулланылган, ә мөнәҗәтләр исә фарсы язуы буларак билгеле булган почерк төре «тәгъликъ» белән башкарылган. Н. Г. Чернышевскийның татарлар арасында киң таралган гарәп язуы төрләреннән яхшы хәбәрдар булуына ишарә ясый торган дәлилләр кульязмада аз түгел. Текстларда гарәп, фарсы теленнән кергән сүзләрнең күләме шул заманда гамәлдә булган татар әдәби телендәгечә үк, ягъни тиешенчә генә кулланылган.

Н. Г. Чернышевскийның улы Михаил Николаевич этисенең көндәлегендә аның үзенә генә хас шартлы система белән язылган кыен, аңлашылмый торган сүзләрнең, гыйбарәләрнең күплеге турында әйтә[4]. Мондый күренеш татар телендәге кульязмаларга кагылмый дисәк тә була. Чөнки барлык текстлар да иркен укыла торган итеп язылган.

Н. Г. Чернышевскийның кульязмаларыннан укучыларга тәкъдим ителә торган өзекләр фактик материал буларак китерелә. Аларга әдәби яки грамматик анализ ясау максат итеп куелмады. Гәрчә татар әдәбиятында, татар матбугатында Н. Г. Чернышевскийның татар телен өйрәнгән булуы турында язылып килсә дә, аның кульязмаларыннан үрнәкләрнең бирелгәне булмады.

Кереш сүзебезне Мәскәү дәүләт университеты профессоры М. Всеволодованың «Правда» газетасында басылган мондый юллары белән тәмамлыйсы килә: «Милли телләргә һәм мәдәниятләргә ихтирамны тәрбияләү — мәктәптә үк башланган булуы мөһим. Н. Г. Чернышевскийның Саратов дини семинариясендә укыганда татар теленнән бишле булуын искә төшерик. Дини семинария өчен уку планын төзүчеләр дин эшлеклеләренә күрше халык телен өйрәтүне тиешле тапканнар...» (1989, 6 март, 68 сан). Тирән мәгънәле, гыйбрәтле һәм уйланырга мәҗбүр итә торган, игътибарга лаек сүзләр.

**Җәмил ЗӘЙНУЛЛИН,**
филология фәннәре кандидаты.

[4] Чернышевский Н. Г. Полн. собр. соч., 1 том, М., 1939, 782 б.

Сүзлек: тавә — дөя; вәлиләреннән — аллаһның якыннарыннан, изгеләрдән; бәгъзе — кайбер; кяферләр — ислам динендә булмаган халыклар; тәкатьләре — көчләре; зәнҗирләр — чылбырлар; газа — сугыш; шәһид итделәр — үтерделәр.

### Әүвәл Җучи ханны бәйан кыйлале [5]

Җучи хан анасының атын Бөртә Кучын диерләр. Бөртә Кучын хамилә ирде. Чыңгыз ханның ераклыкында Миркәт халкының ханы Чыңгыз ханның өйүнә чабды, оланча кыйлып алып китде. Уң ханның хатыны Бөртә Кучынның ийкәчесе ирде. Уң хан берлән Миркәт ханның арасында дустлык бар ирде. Ул сәбәбен Уң хан Бөртә Кучынны теләп алды, Чыңгыз ханга йибәрде. Аның өчен кем Уң хан берлән Чыңгыз ханның атасы Йәсүки баһадир дуст ирде. Әлкыйсса Бөртә Кучын Җучи ханны тугурды. Ул йирдә кәһуарә йук ирде. Кем аны салгайлар әйтте: агырмазсун дип хәмердин бер нәмәрсә тәгъбийә кыйлып, аның эчигә салып алып килделәр. Чыңгыз хан бер угылны күреп хушхаль булды, кем безгә Җучи килде тиде. Магул телендә Җучи тип йаңлы килгән миһманны әйтерләр. Ул сәбәбдән әйтте: Җучи куйдылар. Мәгълүм булсун кем, Җучи хан атасындан борын үлде. Аның зикре Мөхәммәд Чыңгыз ханның дастанында тәхрир табып ирде.

Чыңгыз хан Җучи ханның үлгәнене ишеткәндин соң гаҗәп пәришан булып газа тотды. Ул вакытда мәмләкәт маслахате өчен угъланлары вә өмараларыга һәммә пәнд мәслихәт итә башлады, вә васыйәт-әмиз сүзләшә башлады. Фил җөмлә газадин соң Үтәчкингә әйтдекем син Дәште Кыпчакка баргыл, Җучи ханның икеләнче угълы Бату, ләкабе Саин хан торыр, атасының тәхетендә ултуртып энеләрене, өмараларыны аңа табигъ кыйлгыл. Әгәр энеләре вә өмаралары сүзеңне тотмасалар, үзең анда торгыл, миңа гарасә дәште йибәргел, без аның фикрене кыйлале тип ийбәрде...

Сүзлек: Хәмилә ирде — йөкле иде; кәһуарә — бишек; Хушхаль булды — шатланды; Тәгъбийә кыйлып — каптырып, тутырып, салып; миһман — кунак; зикре — искә алу; тәхрир табып — язылып; пәришан булып — кайгырып, хәсрәтләнеп; маслахате өчен — тынычлыгы өчен (мәнфәгатьләре өчен); пәнд — киңәш; нәсихәт; Табигъ кыйл — буйсындыр; гарасә дәште йибәр — чакыру җибәр, ярдәм сорап атчабар җибәр.

### Үзбәк хан үлгәндин соң Җанибәк ханны хан кыйлдылар

... Бәркәдән соң Меңгү Тимур хан булды. Ул ил вә олысны забт кыйлмакга мәшгуль булды вә агасы Батухан дәстуреге гамәл кыйлды. Тәкый Ак Урда тикән мәмләкәтне Баһадурхан бин Шәйбани ханга бирде, Кырым вилайәтене Уран Тимур бин Тукай Тимурга бирде вә үзе Болгари мәмләкәтегә барды. Тәкый ике йылдин соң мозаффар булып кайтып килделәр. Андин соң сансыз чириге берлән Абка хан өстигә атланып Иран мәмләкәтегә барды, тәкый Абка хан берлән солых кыйлып кайтып килде. Һәмишә бер берегә пәшкәшләр берлән барыш-килеш кыйлыр ирделәр. Тарих алты йөз сиксәндә Абка хан дөньядин нәкъль кыйлды, аның урныга Әхмәд хан мөселман ирде берничә вакытдин соң Аргун бин Абка ханның кулында шәһид булды... (97—98 битләр).

Сүзлек: Забт кыйлмак — басып алу; дастуре — үрнәге, кануны; тикән — дигән; мозаффар булып — җиңеп; һәмишә — һәрвакыт; пәшкәшләр — кыйммәтле, зиннәтле бүләкләр; нәкъль кыйлды — күчте (үлде).

### Касыйдәи шәриф

...Вөҗүдем җөмләсе гысьян нәмән миндә хәйр нә ихсан
бу халәт берлән йә гыйфран.

Халаекның кеме заһид, кеме галим, кеме габид
кеме суфый, кеме мөршид.

[5] ҮДӘСА, I ф., I тасв., 298 эш, 91 б.

Кеме гыйлмен гайан кыйлгай, кеме зөһдин бәйан кыйлгай
гамәллекләр аман булгай.

Әгәр фазлың берлән сөйүрсәң, котылгаймын гафу кыйлсаң
вә кәррә гаделең белән сөйүрсәң.

Тәнемдин туным суйганда, җаным ләхеткә куйганда,
башымдин суны койганда,


Ата-ана башы берлән углыгыз күз яше берлән
булыр башлыг башы берлән,

Уша көн йа Рәсүл аллаһ сәвенүрсәң сиңа валлаһ
шәфәгать кыйлмасаң нягаһ,

Алайы Шәмседдин үзе китде, камугъ яранларың йанды

---

Сүзлек. Касыйдәи шәриф — олугъ (бөек, гүзәл) поэма; Вөҗүдем — барлыгым, бар булуым; гысъян нәмән — буйсынмаучы мин түгел; ихсан — шәфкать, яхшылык; гыйфран — бәхилләү, гафу итү; халаек — кешеләр; заһид — аскет, дәрвиш; габид — кол; мөршид — җитәкче, хуҗа; зөһд — пакьлек, сафлык; кәррә — кабат, тагын; ушал көн — шул көн; нягаһ — кинәт; камугъ — барлык, барысы.


اول جوجی خان نی بیان قیلالی
جوجی خان ننک آناسی ننک آتین بورته قوچین دیرلار بورته
قوچین حامله ایردی چنکز خان ننک یوقلقنده مرکت خلق یننک
غانی چنکز خان ننک ایونی چابدی تقی بورته قوچین نی اولنچه تیب
الیب کتدی اونک خان ننک خاتونی بورته قوچین ننک ایکاچسی
.ایردی ایونک خان برلن مرکت خان ننک اراسنده دوستلیق

*Н. Г. Чернышевский кулъзмаларыннан бер үрнәк*

## Тансык Нәҗметдинов

# БУ ЭШ НИЧЕК БУЛДЫ?

«Казан утлары» журналының 1988 елгы 12 санында А. Яхинның күренекле язучы һәм революционер Шамил Усманов турында мәкаләсе басылды. Әнә шул мәкаләдә автор әтиемне — язучы Кави Нәҗмине дә искә алып, аның хакында болай дип яза:

«Усмановка һөҗүмнең икенче баскычында йөгәнне кулга Кави Нәҗми ала. Башта ул әдипнең «Легион юлы» әсәрендә политик хаталар барлыгын әйтә, милли чикләнгәнлектә гаепли. Монысы инде махсус әзерләнгән, шул заман өчен бик зур нәрсәдә гаепләү иде. Бу сүзләрен ул язучылар җыелышындагы докладында сөйли, йомгак ясаганда тагын бер кабатлый. Шул ук 1936 елны «Совет әдәбияты» журналында бастырып та чыгара. Шундый абруйлы җыелышта ташланган гаепне тикшерү өчен К. Нәҗми тырышлыгы белән комиссия төзелә, 1937 елны комиссия карары басылып чыга. Анда («Совет әдәбияты», 4 сан) Шамил Усмановка дүрт гаеп ташлана. Татар халкының горурлыгы булган каһарман, комиссар, җәмәгать эшлеклесе, талантлы язучы шул дүрт гаеп белән хөкем ителә. Юк итәргә ниятләгәндә кешегә нинди генә яла ягып булмый да, нинди генә ахмаклыкны хакыйкать дип атап булмый. Игътибар итегез, менә алар:

«1. «Сөембикә» журналы редакторы Сөләймановага пенсия ходатае булып йөрде. 2. Мин эсперантист дип, Төркиядәге әллә кем белән хат алышты. 3. Кытай газеталарында эсперанто телендә мәкаләләр белән чыкты. 4. Әтнә районы колхозларында йөри. «Милли юл» журналында алар турында мәкалә язды».

Әйе, А. Яхин менә шундый өзек китерә һәм Кави Нәҗмине берсүзсез гаепләү ягына баса. Ләкин, ул елларда чыккан матбугат органнарын игътибар белән укыганда, эшнең бүтәнчәрәк булганы ачыклана.

Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе булып эшләүче Кави Нәҗмине 1936 елның башыннан алып даими рәвештә ВКП(б) өлкә комитетына чакырып торалар. Мондый чакырулар вакытындагы үгет-нәсихәтнең юнәлеше бер була: Татарстан Язучылар союзына буржуаз милләтчеләр кереп оялаган, шуңа күрә аларны бертуктаусыз фаш итәргә кирәк, тамырларын корытырга кирәк. Язучылар союзы җитәкчесе булган Кави Нәҗми үзе исә аларга каршы җитәрлек дәрәҗәдә актив көрәшмәүдә, кайберәүләрне яшереп калырга теләүдә гаепләнә. Шул уңайдан Шамил Усмановның «Легион юлы» повесте дә искә алына. Бу әсәр Кави Нәҗми редакциясендә баштарак «Кызылармеец» газетасында, аннары «Совет әдәбияты» журналында басылган икән.

ВКП(б) өлкә комитеты, әлбәттә, дошманнарны фаш итмәгән җитәкчедән канәгать кала алмый һәм 1936 елның 27 октябрендә өлкә комитеты бюросы «Татарстан совет язучыларының эше турында» карар чыгара. «Совет әдәбияты» журналының шул елгы 10 санында басылган ул карарда түбәндәгеләр әйтелә:

«Большевистик үзара тәнкыйть союзның һәм аның правлениесенең эшендә әле төп методка әйләнмәгән. Әдәби тәнкыйть союз эшендә иң йомшак урын булып тора. Байтак хәлләрдә идеологик бозулар ачылмаганнар (Ш. Усмановның «Легион юлы», Туфанның «Ант» әсәре).

Татарстан Совет Язучылар союзы правлениесенә, партгруппасына һәм Кави Нәҗми иптәшнең үзенә, әдәбият фронтына сырышкан троцкийчы буржуаз-милләтче дошман элементларына либераль караш күрсәтүе өчен, аерым язучыларның әсәрләрендә булган идеологик бозуларга актив көрәшнең булмавы өчен кисәтү ясарга...»

Бу карар чыкканнан соң иҗат союзының җитәкчесе, әлбәттә, кичекмәстән җыелыш үткәрергә тиеш була. Ләкин чынлыкта андый җыелыш бары тик 5 декабрьдә генә үтә. Җыелышта Кави Нәҗми «Олы иҗат юлы белән» дигән доклад сөйли. «Совет әдәбияты» журналының шул елгы 11 санында басылган әлеге докладтан күренгәнчә, Кави Нәҗми анда берәүне дә фаш итми, ә татар әдәбиятының 20 ел эчендәге уңышларын сөйли, яшьләр белән эшләүдә кимчелекләр хакында тәнкыйть һәм үзтәнкыйть фикерләре әйтә. Ә Шамил Усманов уңаеннан докладчы бары тик югарыда искә алынган ВКП(б) өлкә

комитеты карарын гына китерә. Кызыксынган иптәшләр карар белән докладны чагыштырып карый алалар.

Татарстан Язучылар союзында узган җыелышның барышы һәм анда кабул ителгән карарлар белән канәгатьләнмичә, ВКП(б) өлкә комитеты союзның эшен тикшерү буенча махсус комиссия төзи. Аны өлкә комитеты аппаратының хезмәткәре Т. Имаметдинов дигән кеше җитәкли. Кабат искәртеп үтәм: бу комиссия Кави Нәҗми инициативасы белән төзелми, чөнки кайсы гына җитәкченең үз теләге белән комиссия төзетеп, үзенең үк эшен тикшерттерәсе килеп торсын икән! Ул чорда әле бигрәк тә!

Әнә шул комиссия тикшерүләреннән чыгып, ВКП(б) өлкә комитеты 1937 елның 28 апрелендә икенче бер карар кабул итә. Ул карар «Татарстан совет язучылары союзы турында» дип атала һәм шул ук елны «Совет әдәбияты» журналының 4 санында басылып чыга. Әлеге карарның 2 пунктын бирердә сүзгә-сүз китереп үтик:

«2. Союз җитәкчелеге, аерым алганда союз правлениесе председателе ип. Кави Нәҗми, ВКП(б) өлкә комитеты бюросының 1936 ел, 27 октябрьдагы җитди кисәтүләреннән бер нинди нәтиҗә дә ясамаганга күрә, ВКП(б) өлкә комитеты түбәндәгеләрне кирәкле дип таба:

а) Ип. Кави Нәҗмине союз правлениесе председательлегеннән азат итәргә...»

Югары органның менә шушы карарын тикшерү өчен Язучылар союзында зур җыелыш җыйнала. Ул 28 апрельдә башлана һәм 3, 4, 5 май көннәрендә дәвам итә. Җыелышта Т. Имаметдиновның һәм өлкә комитеты секретаре Г. Мөхәммәтҗановның докладлары тыңлана. Бу докладлар «Совет әдәбияты» журналының 1937 елгы 4 һәм 5 саннарында басылып чыккан.

Әлеге җыелышны Татарстан язучыларының иң фаҗигале җыелышы дип атарга мөмкин. Анда татар язучыларын тезләндерү һәм юк итү өчен барысы да диярлек эшләнә. Бик күпләр «халык дошманы», «троцкийчы», «буржуаз милләтче» дип тамгалана. Һөҗүмнең иң үзәгендә — Кави Нәҗми. Хәзер инде председательлектән алынган Кави Нәҗми... Аны нәрсәдә генә гаепләмиләр җыелышта?!

Ул ВКП(б) өлкә комитеты карарының бер пунктын да үтәмәү генә түгел, киресенчә, аңа каршы торган, тәкереп караган, янәсе. Ул халык дошманнарына каршы көрәш җәелдермәү генә түгел, киресенчә, аларны яклаган да, аларга мораль һәм материаль ярдәм күрсәткән, үз канаты астында тоткан. Ул язучылар союзында гаиләчелекне көчәйткән. Театр сәхнәләрендәге идеологик яктан зарарлы спектакльләр аны борчымый.

Өлкә комитетыннан килгән ике докладчы да Кави Нәҗми исемен сүз саен диярлек телгә алып сүгәләр, аны зур-зур контрреволюцион җинаятьләрдә гаеплиләр.

Ә инде Шамил Усманов уңаеннан Т. Имаметдинов болай дип белдерә. «Совет әдәбияты» журналының 1937 елгы санында басылган докладтан өзекне китерәм:

а) К. Нәҗми газеталарда үзенә карата чыккан тәнкыйтьләрне нигездә дөрес, ди. Сезгә билгеле, нигездә, дигән сүзнең астына күп нәрсәләр яшерелә. Бу сүз белән ул ялгышларын танырга теләмәвен яшереп калдырырга тырыша. Шушы көнгә кадәр аның үз иҗатындагы ялгышларын тәнкыйтьләп матбугатка чыкканы юк әле.

Болай карауга ул үзенең ялгышларын икърар иткән кебек күренә. Дөреслектә исә ул партиягә һәм җәмгыятьчелеккә билгеле булган ялгышларын яшереп торырга ярата. Мәсәлән, Ш. Усмановның «Легион юлы»ның зарарлы якларын ачып салуда да ул үзен каһарман итеп саный. Ә тикшереп карагач, «Легион юлы» иң элек К. Нәҗми редактор булып эшләгән «Кызылармеец» газетасында басылган икәне беленде. Шулай ук бу әсәр ул редактор булып эшләгән «Совет әдәбияты» журналында да басыла...

б) Шамил Усманов турында берничә сүз. Бу — үзен зур активка санап йөрүче иде. Соңгы вакытка кадәр ул партиягә чит һәм ят элементлар белән бәйләнеш тотып килде. Мәсәлән, «Сөембикә» журналы редакторы Сөләймановага пенсия ходатае булып йөри. Чехословакиядәге эмигрант Зыя Кадермәти белән бәйләнеш тотып килде. Үзенең энесе җинаять кодексының 58 статьясы белән гаепләнгәч, ул гаепле түгел дип, аны коткару юлына керә. Мин эсперантист, дип, Төркиядәге кем икәнлеге дә билгеле булмаган студент белән языша. Без аңар, ул кешенең фашист булуы мөмкин, дигәч, «Булса ни, мин эсперантист, мин теләсә кем белән бәйләнеш тота алам», ди. Менә шуннан үзегез аңлагыз инде! Ул Кытай газеталарында эсперанто телендә мәкаләләр белән чыга. Бу мәкаләләрнең эчтәлеге безнең өчен билгеле түгел, әлбәттә. Бер елны ул Әтнә районына барып, аның колхозларында йөри. Ул китеп бераз торгач, шул колхозлар турында язылган мәкалә белән бу колхозларга «Милли юл» журналы килеп төшә. Усмановның партиягә каршы көрәшеп йөргән кеше икәне күп кенә фактлар белән раслана. Мәсәлән, партиянең Татарстан Үзәк Башкарма Комитеты янындагы башлангыч оешмасының гомуми җыелышында, ВКП(б) Үзәк Комитетының февраль пленумы карарларын өйрәнгәндә, ул партиянең зур тарихи әһәмиятле карарын тискәре аңлатырга маташа. Язучылар профсоюз җыелышында троцкийчы-фашист бандаларына суд процессын өйрәнгәндә Ш. Усманов, бездә идеяле троцкийчылар бар һәм бандит фашистлар бар, троцкийчы фашист

бандаларын ике төрле итеп күрсәтергә маташа. Бөтен хезмәт кияләре троцкийчыларның бандит булып, фашист охранкасына хезмәт иткәнлекләрен яхшы белә... Янсә менә мондый факт алыйк. Совет язучылары оешмасын тәнкыйтьләве уңае белән ул: «Тәнкыйть яхшы нәрсә, мин үзем дә тәнкыйтьтә катнашам, ләкин без үзебезнең бөтен күренекле язучыларыбызны әдәбият дөньясыннан алып ташласак, чит илдәге Гаяз Исхакыйлар нәрсә әйтерләр?»— ди. Әйтерсең лә без фашист охранкасында хезмәт эшләп йөргән шарлатан Г. Исхакыйлар алдында җаваплы! Әйтерсең лә Г. Исхакый безнең җәмәгатьчелек эшендә нинди дә булса берәр урын тота! Безнең хезмәт кияләре һәм яшь укымышлыларыбыз андый кешеләрнең дөньяда булганлыкларын да белмиләр, теләмиләр дә. Усмановка, ни өчен син партиягә каршы сөйләп йөрисең, дигәч, ул мин вак буржуа арасыннан чыккан кеше, пролетариат арасында булганым юк, ди. Ә үзенең партия документларында социаль чыгышын «эшче» дип язган. Менә моннан Ш. Усмановның нинди кеше икәнлеге аңлашылса кирәк. Аңа озак тукталып торуның кирәге юк...

Халык дошманы, буржуаз милләтче К. Нәҗми, адым саен икейөзләнеп, Ф. Сәйфи, Г. Гали, З. Гали, Ш. Усманов, Гинзбург, Толымбайский һ. б. шундый иң кабахәт дошманнарны аңлы рәвештә күтәреп, саклап килде. Үзенең хезмәт хәленнән файдаланып, халык дошманнарына астыртын җимерү эше, корткычлык эше алып барырга материаль һәм мораль ярдәм итеп килде. Барлык материаллар һәм мондагы чыгышлар моны тулысынча раслыйлар. Бу фактка каршы бәхәсләшү мөмкин түгел».

Югарыда китерелгән өзеккә аңлатма биреп торуның кирәге юк. Аннан бик ачык күренә: А. Яхин мәкаләсендә китерелгән гаепләрне Ш. Усмановка К. Нәҗми түгел, ә Т. Имаметдинов тага.

Хәзер бик күпләр шундый сорау куялар: ул елларда К. Нәҗми нинди роль уйнаган соң?

Мәскәүдәге әдәбият-сәнгать мәсьәләләре буенча Үзәк дәүләт архивы һәм Татарстан партия архивы материаллары белән, ул елларда басылган газета-журналлардагы мәкаләләр белән, шулай ук үзебезнең гаиләдәге кайбер документлар белән ныклап танышканнан соң, һәм дә әтием Кави Нәҗми һәм әнием Сәрвәр Әдһәмова хакында ТАССР дәүләт куркынычсызлыгы комитетыннан бирелгән белешмәләр нигезендә, шулай ук Фатих Кәрим, Ибраһим Салахов, Якуб Чанышев һәм дә алар бергә төрмәдә утырган башка кешеләр сөйләгән истәлекләргә таянып, мин әтинең һәм әнинең ул еллардагы тормышын түбәндәгечә күз алдына китерәм. Ул чорны шартлы рәвештә икегә бүлеп карыйм. Беренчесенә — 1936 һәм 1937 елның 2 июлендә кулга алынганчыга кадәрле чор. Икенчесе — кулга алынудан башлап партиянең XX съездына кадәрге вакыт. Бу ике периодка иркенрәк тукталып үтик.

1937 елның башыннан алып «Кызыл Татарстан» газетасында һәм «Совет әдәбияты» журналында «халык дошманнары»н тар-мар итүче мәкаләләр тагын да күбрәк басыла. Аларның күбесендә төп дошман — Кави Нәҗми. «Матур әдәбиятны дошман калдыкларыннан тазартырга!» дип аталган мәкаләдә («Совет әдәбияты», 1937 ел, 6—7 саннар) мондый юллар бар: «Ачыктан-ачык халык дошманнары икәнлекләре фаш ителгән Кави Нәҗми, Гомәр Галиев, Г. Толымбайский...»

Ә инде ВКП(б) өлкә комитеты карарыннан һәм язучыларның югарыда искә алынган зур җыелышыннан соң К. Нәҗми белән С. Әдһәмова өстендә кара болытлар тәмам куера башлый. Язучылар союзы идарәсенең 12 июньнән башлап 14 июньгә кадәрге киңәйтелгән утырышы (аны яңа председатель Л. Гыйльми алып бара) чын мәгънәсендәге инквизиторлар судына әверелә. Ул утырышта, халык дошманнары буларак, К. Нәҗмине, Х. Туфанны һәм Ф. Кәримне союздан чыгаралар. Ә бер атнадан әтине, шул ук гаеп белән, партиядән дә чыгарып ташлыйлар. Ул партиягә 1919 елда — 17 яшьлек егет чагында кергән була. 1937 елның 2 июлендә исә К. Нәҗмине кулга алалар.

Бу вакытта мин — бәләкәй малай — ерак Кустанай даласындагы бер авылда, туганнарыбызда идем. Чөнки әтине партиядән чыгаргач, алар әни белән икесе киңәшеп, вакыйгаларның ничек куерасын алдан ук күреп, мине әнә шундый ерак туганнарыбызга озаттылар. Күз күнә укырга керү өчен Казанга кайткач, әни миңа елый-елый НКВД хезмәткәрләре килеп, бөтен өйнең астын-өскә китерүләрен һәм әтине алып китүләрен сөйләде. Әти белән бергә, аның барлык кәгазьләрен дә алып киткәннәр. Өйдән алып чыкканда әти әнигә: «Тансыкны саклый күр, үзеңне дә сакла! Тиздән барысы да ачыкланыр. Мин нинди дошман булыйм, ди. Батрак малае бит мин. Гражданнар сугышында катнаштым, Кызыл Армиядә 14 ел булдым. Нык бул!»— дигән.

Әти кулга алынгач, безне, халык дошманы гаиләсе санап, шул ук йорттагы бик начар фатирга күчерделәр... 1938 елның 4 гыйнварында исә төнлә әнине дә алырга килделәр. Мине махсус урынга озатмакчылар иде, туганыбыз Хатирә апа: «Әтисе өчен баласы җавап бирми!» дип, үзе белән алып калды, мине НКВД кешеләренә бирмәде. Әле мине алырга аннан соң да күп тапкыр килгәләделәр. Ләкин безнең ишегалдындагы

танышлар мине алдан кисәтәләр дә, тиз генә яшерәләр иде. Шулай итеп, мин махсус колониягә озатылмыйча калдым.

Әтинең тикшерү эше әле тәгәлләнмәү сәбәпле, әнине баштарак хөкем иттеләр. Аны, беренчедән, Совет властена каршы контрреволюцион пропаганда алып баруда (язучылар союзы идарәсе председателе булган кешенең ялган шикаяте буенча), икенчедән, үз иренең һәм тагын башка халык дошманнарының контр эшләрен белә торып тикшерү органнарына хәбәр итмәгәне өчен гаепләделәр.

Хөкем хәзерге Ленин урамындагы Верховный суд бинасында булды. Мин әнине кулга алынганнан соң беренче мәртәбә шунда күрдем. Ул судта нык торды, ялган гаепләүнең бер генә пункты белән дә килешмәде. Хөкем карары укылгач та әле, күзеннән бер тамчы яшь чыгармастан, кулын югары күтәрде дә: «Минем гаебем юк!»— дип кычкырды. Шуннан соң аны кара машинага алып чыгып киттеләр... Икенче тапкыр мин әнине Петрушкин разъездындагы төрмәдә күрдем. Аларны Себергә озатырга тиешләр иде. Мин еладым, әни мине гел юатты, гаделлекнең өскә чыгачагына ышандырды. Ә соңрак, өстендәге йон кофтасын салып, Хатирә апага бирде дә кофтаны сатарга кушты. Мәктәпкә бару өчен миңа өс һәм аяк киемнәре алырга кушты... Бер-ике айдан безгә Себердән хатлар килә башлады. Ул Красноярск тимер юлының Суслово станциясе янындагы лагерьда иде... Әле шушы елларда хатыным белән бергә әнинең ул чакта язган хатларын укып утырганда тап булдым: әни үзенә җылы кием җибәрүләрен сораган, әзрәк балык мае табылмасмы, дигән. Чөнки салкын 60 градус чамасы икән. Ул туберкулез белән авырый башлаган булган...

Ә әти кулга алынганнан соң мин аның белән өч мәртәбә күрешә алдым. Башта МВД бинасының икенче катында. Әти бик начар хәлдә иде, бик тә ябыккан, хәлсез... Ул үзе турындагы сүзгә ышанмаска кушты. Безнең күрешү турында әниеңә яз, диде... Икенче мәртәбә мин аны Верховный судта күрдем. Аңа күп төрле уйдырма гаепләр тактылар. Имеш, ул пантюркистларның хәрби оешмасы әгъзасы икән. Ул 1925 елда, Г. Ибраһимов белән берлектә, «Татарлар һәм башкортлар Кызыл Армия сафларында» дигән китап чыгарган. 1927 елда К. Нәҗми җидегәнчеләр оешмасында катнашкан һәм Яңалиф кертүгә каршы чыккан. Язучылар союзында эшләгәндә халык дошманнарын яклаган, буржуаз милләтчеләрне бергә туплаган һ. б....

Бу гаепләрнең берсен-бер танымаса да, әтине 10 елга хөкем иттеләр. Ә язучы Мирсәй Әмирне, әтинең сүзләренә ышанып, суд залында ук азат иттеләр һәм өенә кайтарып җибәрделәр.

Суд тәмамланганнан соң, алып китү өчен машина көткәндә, әтине коридорга алып чыктылар. Без аның белән шунда күрештек. Мин аның тешләре төшкән булуга һәм итек кунычының сәер рәвештә ертылган булуына игътибар иттем. Әти миңа тешләренең Черек күлдә калуын әйтте, итек кунычын аяклары шешкәнгә ертырга туры килгән.

Өченче тапкыр мин аны Пләтән төрмәсендә күрдем. Ул тагын да бетерешкәнрәк иде. Кочаклашканнан соң мин: «Әти, сине кайчан кайтаралар инде?»— дип сорадым. Ул үзенең РСФСР Верховный судына гариза язган булуын әйтте. Чыннан да, 1939 елның 22 июнендә махсус коллегия әти эше буенча гаепләүләрне юкка чыгара.

Әтине 1939 елның 30 декабрендә иреккә чыгардылар. Ә озакламый партия сафында да торгыздылар. Бу уңайдан шунысын да әйтеп китәргә кирәк: үзе төрмәдә булуга карамастан, әти төрмәдән торып, хөкем ителгән Фатих Кәримне азат итү буенча эш йөртә, суд һәм партия органнарына гаризалар яза. Аның һәм башка кешеләрнең тырышлыгы нәтиҗәсендә, 1941 елда Фатих Кәрим иреккә чыгарыла. Әниебез Сәрвәр Әдһәмова исә 1940 елның 16 октябрендә азат ителә. Аның сөргендә күргәннәре хакында И. Салахов һ. б. язучыларның әсәрләрендә күпмедер әйтелә. Әни 1959 елда Евгения Гинзбург белән очрашкач та, алар тоткынлык турында үзләренең авыр хатирәләрен уртаклашалар. Гинзбург ул чагында: «Әле ярый мине 1937нең февралендә кулга алдылар... Ул вакытта бик нык җәзаламыйлар иде»,— дип, үзенең әзме-күпме җиңелрәк язмыш кичергәнен әйтә. Соңрак ул әнидән «Рабфак» исемле повестен татарчага тәрҗемә итүне үтенә. Алар хәзер матбугатта басылып чыккан «Хәвефле юл» («Крутой маршрут») әсәре хакында да еш сөйләшәләр.

Ә инде әтинең төрмәдә үзен ничек тотуы хакында миңа хәрби разведчик Һади Маликов сөйләде. Бик күп илләрдә Ватаныбызга ышанычлы хезмәт иткәннән соң үз төрмәбездә 19 ел буена утырган бу кеше, 1956 елда акланып, иреккә чыгарылды һәм 75 яшенә кадәр гомер кичерде.

Алар әти белән бер камерада утырганнар. Үзләре янына кыйнап кертеп ташлаган әтине башта бөтенләй танымыйлар да... Аңына килеп сөйләшә башлагач кына, аның кем икәнен беләләр. Ирексездән күзләренә яшь килә... Икенче бер вакытта әти СССРның генераль прокурорына гариза яза. Сорау алганда Усманов һәм Зыков фамилияле тикшерүчеләрнең үзен ничек итеп газаплауларын санап киткәндә, камерадагы тоткыннар шулай ук тетрәнү кичерәләр.

Әтинең төрмә истәлекләреннән тагын берсе хәтердә калган. Тикшерүчеләр, җәзаның бөтен чараларын да кулланып чыкканнан соң, ахыр чиктә болай итәргә булалар — әтине уголовниклар камерасына ябалар. Тегеләргә алдан ук: «Бу Арзамастан китерелгән прокурор», дип әйтелгән була. Тегеләр инде билгеле, «прокурор»ның күпме кирәк тетмәсен тетәләр. Ара-тирә: «Мә сиңа, прокурор!»— дип тә куялар... Аңына килгәч, әти тегеләргә үзенең прокурор түгел, ә язучы икәнлеген әйтә. Башлыкларының моңа ышанасы килми, язучы булсаң, әйдә безгә нәрсә дә булса сөйлә, диләр. Ә әтиебез телдән сөйләргә дә бик оста иде, ул боларны тәки ышандыра алган! Үткен караклар турында, сентименталь мәхәббәт күренешләрен дә куша-куша, бер хикәят сөйләгән ул. Шуннан инде тегеләрнең карашы үзгәрә, алар әтигә кәгазь һәм каләм табып бирәләр. Төрмә шартларында кассацион гаризаларны әти әнә шулай итеп кенә яза алган. Ул гаризаларны төрмәдән алып чыгып, тиешле җиренә җиткерүдә дә әтигә теге яңа «танышлары» ярдәм иткән.

Генерал-лейтенант Спильниченконың 1951 елда әтигә язган хаты да шундыйрак бер хатирәне яңарта. Хатта мондый юллар бар: «Сез инде мине хәтерләмисездер. Хәзер мин Сезнең исегезгә төшереп карыйм әле, шуннан соң кайчан һәм кайда очрашуыбыз, бәлки, хәтерегезгә төшәр. Ул очрашу бер дә гадәти түгел иде шул... Ләкин миндә Сез сөйләгән хикәят һәм әкиятләрдән бик тә көчле тәэсир калды. Мин аларны тыңларга үтә ярата идем. Бу хәл бит 1939 елның январенда, Пләтәндә булды...»

Сорау алу вакытларында әтигә тәэсир итүнең тагын шундый психологик ысулын да кулланалар: әгәр дә документка кул куймасаң, малаеңны да төрмәгә утыртабыз, диләр. Әйе, без, гаилә әгъзалары, ул елларда заложниклар идек. Һәм, гаиләләре өчен борчылып, күпләр, бик күпләр үз-үзләренә ялган гаепләр яктылар...

Билгеле булганча, 1937 елның икенче яртысыннан соң тоткыннарга карата тагын да катырак җәзалар кулланыла башлый. Бу хакта Сталинның махсус телеграммасы була. Ул анда: «Буржуаз разведка социалистик пролетариат вәкилләренә карата физик җәзаның бөтен юлларын куллана... Ә дәүләт куркынычсызлыгының социалистик органнары ни өчен алардан гуманлырак булырга тиешләр?»— дигән дәлилләү китереп, бер гаепсез кешеләргә карата тагын да шәфкатьсезрәк чаралар куллануны рөхсәт итә.

Иң югары органнардан әнә шундый рөхсәт бирелеп торгач, әлбәттә, түбәндәгеләр җан-фәрман тырыша. Урыннардагы тикшерүчеләр бөтен алымнарны куллана. Әти сөйли торган иде: тикшерүчеләр тоткынны кул белән дә, аяк белән дә кыйнаганнар. Наган сабы белән тешләрен коя торган булганнар. Тәүлекләр буе бастырып тоту... Кеше аңын югалткач, салкын су коеп, аны яңадан ушына китерү... Әтинең озак басып торатора аяклары шешеп чыга. Аны бер биш мәртәбә генә атарга дип алып чыгалар... Төрмәдә шулай ук мунча кебек эссе камералар һәм билдән салкын сулы карцерлар да булган. Болар барысы да тоткынның «телен ачар» өчен уйлап чыгарылган.

Казан университетында инженер булып эшләгәндә язмыш мине Лощилов дигән бер иптәш белән очраштырды. Ул әти белән шактый гына вакыт бергә төрмәдә утырган икән. Үзләрен Кремль астындагы төрмәдә салкын сулы карцерда тотканнарын ул җан газабы белән сөйли иде. Фатих Кәримнең әти белән бергә төрмәдә утырганда күргәннәре аның «Онытма!» исемле шигырендә дә бик тәэсирле итеп әйтеп бирелә. Бу шигырь «Кави Нәҗмигә багышлана» диелә, безнең гаиләдә аның нөсхәсе бар. Тик ни өчендер «Казан утлары» журналының 1988 елгы 6 санында бу шигырь «Хәсән Туфанга багышланган» дип басылды...

Төрмәдән әти дә, әни дә авыру булып кайттылар. Әтине шуннан соң гомер буе кан басымы борчыды, йөрәгендә аритмия булды. Әнидә исә туберкулез һәм хроник бронхит иде. Әтинең 55 яшендә дөнья белән саубуллашуына да әнә шул газаплар сәбәпче, әлбәттә.

Язмамны тәгәлли төшеп, үзем өйрәнгән бөтен документлар һәм әтинең танышлары сөйләгәннәрдән чыгып, мин биредә шуны белдерә алам: 1936 һәм 1937 елда әти газета-журнал битләрендә язучылардан бер генә кешене дә тәнкыйтьләп чыкмый, аларга гаеп ташламый һәм инде бигрәк тә политик ярлык такмый. Киресенчә, аның үзен «Кызыл Татарстан»— сигез мәртәбә, «Совет әдәбияты» журналы — дүрт тапкыр һәм «Красная Татария» берничә мәртәбә зур гына гаепләр белән бәйләп язып чыгалар. Тагын шунысы кызыклы: соңрак, 1940 елның 20 январендә, «Кызыл Татарстан» үз битендә менә шушындый белдерү бастыра:

«1937 елгы 62, 73, 84, 109, 136, 140, 175, 247 саннарда «Кызыл Татарстан» газетасы тарафыннан Кави Нәҗмигә «халык дошманы», «буржуаз милләтче» дигән гаепләүләр ташланган иде. Тикшерү вакытында ул гаепләүләрнең ялган булы ачыкланды. Суд органнары карары белән иптәш Кави Нәҗми тулысынча акланды».

1955 һәм 1956 елларда Кави Нәҗми гаепсезгә кулга алынган бик күп язучыларның эшләрен яңадан карауда катнаша, аларның шәхесен һәм язган әсәрләрен уңай яктан бәяли. Андый язучылар җөмләсеннән Г. Ибраһимов, К. Тинчурин, Г. Гали, Ш. Усманов,

Х. Туфан, И. Салахов, Г. Мөхәммәтшин, С. Рафиков, З. Сәмитов һәм башкаларның исемнәрен әйтеп була. Бу кешеләрне аклауны үтенеп, ул СССР Верховный судына һәм әлеге судның хәрби коллегиясенә мөрәҗәгать иткән.

Әти белән әнинең кулга алынган булулары минем язмышымда да авыр чагылыш тапты. Әти кулга алынганнан соң, безне начар фатирга күчергән домоуправ Борисов 1941 елда мине үзенә чакырып алды да болай ди: «Менә бу кәгазьгә кул куй!» Мин кул куярга теләмәдем. Шуннан соң ул мине куркыта башлады: «Әгәр дә син моңа кул куймыйсың икән, әтиең белән әниеңне яңадан төрмәгә утыртачакбыз!» Кул куярга туры килде. Баксаң, бу һөнәр училищесына җибәрү турындагы кәгазь икән! Шулай итеп, мин һөнәр училищесында укырга теләк белдергән булып чыктым. Анда мин ике ел буе эшләдем, өч төрле һөнәр үзләштердем. Танкка каршы гранаталар һәм авиация приборлары ясаганда хәтта өлкәннәр нормасын да үти идем... Икенче мәртәбә әти-әни язмышы минем тормышка армиядә хезмәт иткән вакытта килеп керде. 1946—1952 еллар иде бу. Бервакыт мине төрек шпионына ярдәм итүдә гаепли башладылар! Ел буе махсус бүлеккә сорау алырга йөрттеләр. Әле кайчан диген — нәкъ төн уртасында алып китәләр иде.

Менә шул чагында минем күз алдында гел әти белән әни торды. Ялган документларның берсенә дә кул куймадым! Нәтиҗәдә, әлеге нигезсез гаепләүләр явыз эшен эшли алмады.

Шәхес культы кебек чуалчык һәм авыр елларны тикшерүчеләр шуны онытмасыннар иде: теге яки бу чорга караган документлар белән гаять сак эш итәргә кирәк! Аларны ул чор контекстыннан һич тә аерып карарга ярамый. Кеше телендә йөргән имеш-мимешләргә генә ышану да хата. Берәр документ кулыңда булган очракта да, төрле-төрле чыганакларны чагыштырып карый-карый гына дөреслекне эзләргә кирәктер.

Чуалчык еллар йомгагын сүткәндә без гаделлеккә хыянәт итәргә тиеш түгел!

---

## *Котлыйбыз!*

## Шәриф Хөсәеновка — 60 яшь



Драматург Шәриф Нургали улы Хөсәенов 1929 елның 26 ноябрендә Татарстан АССРның Буа районы Өчмунча авылында туа. 1947 елда Буа Шәһәрендәге Мулланур Вахитов исемендәге урта мәктәпне тәмамлый һәм Казанга килеп медицина институтына укырга керә. 1953 елда институтны тәмамлап, Казан больницаларының берсендә врач булып эшли башлый. 1960—1962 елларда Мәскәүдә СССР Язучылар союзының югары әдәби курсларында укый. Шуннан бирле ул Казан шәһәренең 2 нче больница поликлиникасында участок врачы хезмәтендә.

Язучы-драматург буларак Ш. Хөсәенов үзенең «Профессор кияве» исемле комедиясе (1952) белән танылды. Драматург шуннан соң иҗат иткән драма әсәрләреннән «Зөбәйдә — адәм баласы» (1961) трагикомедиясе һәм «Әниемнең ак күлмәге» (беренче исеме «Әни килде», 1968) драмасы тагын да зуррак уңыш казана. «Әниемнең ак күлмәге» Татар академия театры сәхнәсендә генә дә дүрт йөздән артык уйнала, русчага һәм башка милли телләргә тәрҗемә ителеп, илнең кырыклап театры сәхнәләрендә уңыш белән бара. Әдипнең «Бирнәле кыз» (1954), «Егерме ел үткәч» (1962) һ. б. кечкенә күләмле пьесалары да күпләгән театр сәхнәләрендә уйнала, үзәк телевидение аша күрсәтелә.

Ш. Хөсәенов укучыларга «Мәхәббәт сагышы» исемле повесть (1964) һәм юмористик, сатирик хикәяләр авторы буларак та билгеле.

Ул — Татарстан АССРның атказанган врачы.

Ш. Хөсәенов — 1959 елдан бирле СССР Язучылар союзы члены.

# ИКЕНЧЕ ДӘРЕС

*Дүрткә килде бала: йөгерә, дөнья якты урамда,*
*Күрер тирә, алыр, ашыр тиң юлдашы булганда.*
*Үтәр аңар хуш холык бу чагында үскәндә,*
*Гадәт күркәм калыр, тирә күркәм булганда.*

Галимә Рәхмәтуллина

Гасыр башында иҗат иткән шагыйрә Галимә Рәхмәтуллина шигыреннән китерелгән бу юлларда барлык чорлар өчен уртак тормыш хакыйкате ята. Чыннан да, балаларыбызның киләчәктә нинди кеше булып үсүләре өчен без, аның тирә-юнендәге кешеләр, һәм барыннан да элек, әти-әниләре һәм якыннары җаваплы. Бу — тел мәсьәләсендә дә шулай. Бала бай рухи табигатьле, үрнәк әхлаклы булып үссен өчен, аның бик кечкенәдән ана теле мохитендә тәрбия алуы мөһим. Моның өчен иң элек ата-аналар гаиләдә үзләре саф ана телендә сөйләшергә тиеш. Иң мөһиме — бала гаиләдә ана телендә сөйләшүне катгый куелган табигый бер халәт итеп кабул итәргә тиеш. Шулай булганда гына балалар бакчасында, урамда иптәшләре белән русча гына аралашкан очракта да ул өйдә үз телендә сөйләшәчәк.

Балагызның теле чыннан да бай, матур булсын дисәгез, көндәлек аралашу теле белән генә чикләнмичә, аңа татар телендә китаплар укырга, әкиятләр сөйләргә, җырлар, шигырьләр өйрәтергә кирәк. Башлап, биредә китерелгән шигырьләрне өйрәтергә мөмкин.

Бала теле белән махсус шөгыльләнүнең башлангыч чорында түбәндәге алымнардан файдаланырга була:

— төрле әйберләрне күрсәтеп, аларның исемен атау. Моның өчен әйберләрнең үзләрен күрсәтергә яки төсле рәсемнәрдән файдаланырга кирәк. Бу — баланың сүзлек маясын арттыра;

— шул сүзләрне кертеп, кечкенә-кечкенә җөмләләр төзү: бу — туп. Бу зур туп. Туп сикерә һ. б.;

— бала белән урамда йөргәндә, кибеткә кергәндә, кунакка барганда, урынына карап, яхшы мөгамәлә сүзләрен өйрәтү: — исәнмесез, сау булыгыз, рәхмәт, тәмле булды, күпме булды, күпме тора? һ. б.

Сүзләрне әйткәндә башта ук баланың татарча авазларны дөрес әйтүенә игътибар итәргә кирәк. Чөнки күп кенә балаларның сөйләм аппараты инде русча әйтелеш нигезендә формалашкан була. Авазларны дөрес әйтергә өйрәткәндә төрле алымнар кулланыла:

а) авазның әйтелешен өлкәннәр артыннан кабатлау;

б) авазның ничек ясалуын һәм әйтелешен аңлатып бирү. Мәсәлән, ә авазын әйткәндә ияк аска төшә, авыз киң ачыла һ. б. Бу аңлатуны баштарак русча алып барырга да мөмкин.

в) татар авазларының әйтелешен рус авазлары белән чагыштыру алымы да еш кулланыла. Мәсәлән:

**О авазы**

| | |
|---|---|
| *татарча* | *русча* |
| он (мука) | он (ул) |

**А авазы**

| | |
|---|---|
| Казан | Казань |
| карга | карга |

**Үрдәк** сүзендәге **ү** авазы русча люблю сүзендәге **ю** авазы кебек әйтелә. Соңыннан төрле фонетик күнегүләр үткәрергә мөмкин:

өс — өс — өс    тәл — тәл — тәл    өстәл
үр — үр — үр    дәк — дәк — дәк    үрдәк

Балага тел өйрәтү белән махсус шөгыльләнүне уен рәвешендә оештырырга кирәк. Ул баланы ялыктырмый, бала никадәр кечкенәрәк булса, бу алым шулкадәр отышлырак.

* * *

— Әйдә (улым, кызым), без синең белән «Уенчыклар кибетендә» дигән уен уйныйбыз. Мин — сатучы, сиңа уенчыклар сатам.

— Биредә нинди уенчыклар бар? (**Биредә** дигән сүзнең әйтелешенә басым ясала, мәгънәсе аңлатыла).

— Сиңа нинди уенчык кирәк?

— Курчак.

— Мә, ал!

— Рәхмәт!

— Биредә тагын уенчыклар бар, бу нәрсә? Бу — **шакмак.**

(Сүз берничә тапкыр кабатлана, русча аңлатмасы әйтелә.) Капчыктагы калган уенчыклар алга куела (курчак, куян, туп, аю).

— Биредә нинди уенчыклар калган?

— Курчак, куян, туп, аю.

— Туп нишли? **Сикерә.** (Сүз берничә кат кабатлана).

— Туп сикерә, куян сикерә, без дә сикерәбез.

— Курчак нишли? Курчак **бии** (Сүз кабатлана). Без дә биибез. (Бала хәрәкәтсез ялыкмасын өчен, биеп алырга мөмкин).

— Аю нишли? Аю йөри. Аю ничек йөри? (Бала аю кебек йөреп күрсәтә).

**«Серле капчык» уены.** Уенчыклар үтә күренмәле капчыкка салына һәм бала, капшап, уенчыкның исемен әйтергә тиеш.

Уенчыклар турында шигырьләр укыла. Бала әле телне бик яхшы белмәгәндә, аңа русча таныш булган шигырьнең татарча тәрҗемәсен яттан өйрәтү дә отышлы. Мәсәлән:

### КУЯН

*Агния Барто шигыре*

*Тышта яңгыр ява коеп,*
*Утыра куян боегып.*
*Өйгә кермичә калган,*
*Бөтен җире чыланган.*

### ТУП

*Әминә елый үкереп,*
*Тубым суга төште, дип.*
*— Чү, Әминә, елама:*
*Туп батмый ул елгада.*

*Әминә Бикчәнтәева тәрҗемәләре*

Түбәндә китерелгән шигырьне сәнгатьле итеп укыгыз һәм, тәрҗемә итеп, эчтәлеген балаларга сөйләгез.

## КУЯН

*Муса Җәлил шигыре*

*Куян салкыннан*
*Туңган, куырылган,*
*Башы салынган,*
*Колагы шиңгән.*
*Әйдәгез, дуслар,*
*Аны терелтик,*
*Җылы бүлмәгә*
*Мәктәпкә илтик.*
*Куян уянды,*
*Куркып уйланды,*
*Сикереп урманга,*
*Чабып югалды,*

*— Куян, син кайда?*
*— Яшел тугайда.*
*— Куян, син кайда?*
*— Ерак чүлләрдә.*
*— Куян, син кайда?*
*— Калын урманда.*
*— Куян, син кайда?*
*— Карлы буранда.*
*Әйдәгез, дуслар,*
*Кырны, урманны,*
*Чүлне актарып*
*Табыйк куянны.*

Китерелгән шигырьләрдә:

**Куян, колагы, куырылган** сүзләрендәге к (қ) авазының дөрес әйтелешенә, **аягы, елга, егылган** сүзләрендәге г (ғ) авазының әйтелешенә махсус игътибар итәргә кирәк. Бу ике аваз да тамак төбендә, русча **хата** сүзендәге х авазы белән бер үк урында ясала. **К** авазы катырак, көч куебрак, ә г авазы йомшаграк әйтелә.

### Тел күнекмәсе:

*Карга кара, кара карга,*
*Кар-рык, кар-рык карылдама.*
*Кардан калка кара карга,*
*Кара кауры йлары карда*
*Тарала да аунап кала.*

Шәйхи Маннур.

**Фәһимә ХИСАМОВА,**
филология фәннәре кандидаты.
**Рәшидә БОРҺАНОВА,**
методист.

# Габдулла Тукай

## Бер татар шагыйренең сүзләре

**(Кыскартып алынды)**

Җырлап торам, торган җирем тар булса да,
Курыкмыйм, сөйгән халкым бу татар булса да;
Күкрәк биреп каршы торам, миңа милләт
Хәзерге көн мылтык-ук атар булса да.

Яхшылыкка эреп китәм — балавыз мин,
Мактап сөйлим изге эшне — бал авыз мин;
Бер яманлык күрсәм, сүгәм, мактый алмыйм! —
Ул тугърыда бик явыз, ай-һай, явыз мин!

Пушкин илә Лермонтовтан үрнәк алам,
Әкрен-әкрен югарыга үрләп барам;
Тау башына менеп кычкырмакчы булсам,
Биек җир бит, егълырмын дип шүрләп калам.

Максуд җитәр: бара торгач — юл кыскарыр;
Әллә кайда баткан хиссият кузгалыр;
Бөкре түгел, төзәлергә кабер көтмим,
Тәңрем фәйзы[1] минем күңлемгә эз салыр.

**Г. Тукай**

[1] Фәйзы — рәхмәте.

## بر تاتار شاعرینك سوزلری

جرلاب طورام، طورغان یریم طار بولسا ده،
قورقیم سویگان خلقم بو تاتار بولسا ده،
کوکره‌ك بیرب قارشی طورام، میڭا ملت
حاضرگی کون ملطق، اوق آتار بولسا ده
یاخشیلققه اُروب کیته‌م، بالاوز مین،
ماقتاب سویلیم ایزگی اشنی بال آوز مین
بر یامانلق کورسه‌م سوگه‌م، ماقتی آلمیم :
اول طوغریده بیك یاوز، آی هایی یاوز مین!
پوشکین ایله لیرمونتف دن اورنه‌ك آلام،
ئه‌کرن، ئه‌کرن بوغاریغا اورله‌ب بارام،
طاو باشینا منوب چقر ماچی بولسام :
بییك یبر بیت، یغلورمن دیب شورله‌ب قالام.
مقصود بیته‌ر، بارا طورغاچ یول قصقارر،
ئلله قائده باتقان حسیات قوزغالور.
بو کری توگل توزه‌لورگه قبر کوتیم؛
تکرم فیضی مینم کوڭلمگه آز صالور. (ع. توقای)

*Журнал өчен Җәүдәт Миңнуллин һәм Раиф Мәрданов әзерләде.*

# Бер сорауга бер җавап

— Сезнеңчә, туган әдәбиятыбызда сәламәтлек саклау ничек яктыртыла?

— Казан — Россиядә барлыкка килгән медицина уҗәкләренең өченчесе, быел институтыбыз 175 еллыгын бәйрәм итте. Шушы дәвердә Казан утыз биш меңгә якын доктор әзерләде. Революциягә кадәр татарлардан алты кеше генә врачлык дипломы алса, революциядән соң алар дәвалаучы белгечләребезнең утыз процентын тәшкил итте. Безнең гаиләдә, мәсәлән, эти дә, абыем белән хатыным да — врачлар.

Дәвалаучылар элек югары культуралы булулары белән аерылып торган, әдәбият-сәнгатьне яхшы белгәннәр. Әтием дә татарча күп укый иде, бездә дә туган телебезгә, туган әдәбият, театр, музыкабызга мәхәббәт уятырга тырышты. Шуның аркасында шәхси китапханәбездә татар язучыларының китаплары бик күп. Фәнни һәм оештыру эшләренә кереп чумганлыктан, мин аларның байтагын вакытында укырга өлгерә алмыйм, әлбәттә; шулай да, классикларыбыз иҗаты һәм медицина дөньясын сурәтләгән әсәрләр белән беренче нәүбәттә танышырга тырышам. Х. Вахитның «Соңгы хат» драмасы, Г. Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» романы, Н. Фәттах һәм М. Маликова китаплары нигезендә шуны әйтә алам: татар әдәбияты сәламәтлек чагылдыру өлкәсен идеаллаштырыбрак гәүдәләндерә. Үткен мәсьәләләрне кыюрак чагылдыру җитми. Врачлар әзерләү барышы, шул процесста хәл ителергә тиешле мәсьәләләр әдәбиятыбыз игътибарыннан, гомумән, читтә кала.

Казан медицина мәктәбенең тамырлары тирән, казанышлары мул. А. Терегулов, Ф. Мөхәммәдьяров, М. Корбангалиев, Х. Хәмитов һәм башка галимнәребез, халык хөрмәтен казанган бик күп докторларыбыз бар. Шуның белән бергә, бүгенге хәлебез мактанырлык түгел. Врачлар белән тәэмин ителү ягыннан Татарстан РСФСРда кырык сигезенче урында тора. Институт милли башкалабызда эшләсә дә, анда керүче татарлар өлеше һаман аз әле. Менә бу мәсьәләләрнең төбендә нәрсә ята? Нишләп аларның сәбәпләре укучыларны дулкынландырырлык дәрәҗәдә әдәбиятыбызда яктыртылмый? Әйтик, милли мәктәпләрне тәмамлаучыларга юлны киңрәк ачар өчен, бәлки, институтта нинди дер үзгәрешләр ясарга кирәктер? Җәмәгатьчелек фикерен язучы да кузгатмаса, кем кузгатыр?

Врачлар әзерләүнең сыйфатын яхшырту мөһим. Дәвалаучыларның әхлакый сафлыгы, миһербанлылыгы, аларның бай күңелле булуы әдәбият, сәнгать белән ни дәрәҗәдә сугарылуга да бәйле. Студентларыбызны татар культурасын өйрәнүгә тарту бик акланыр иде. Чит илләрдә иҗтимагый предметларны өйрәнүгә уку программасының унике проценты бирелә, бездә исә ул дүрт процент кына тәшкил итә. Мондый шартларда язучыларыбыз чаң какса, хәтта укыту программасын камилләштерүгә дә катнашса, җәмгыятебез файда гына күрер иде.

Болгар, Казан ханлыгы дәверендәге дәвалау гыйлеме үсешен, ата-бабаларыбыз казанышларын белмибез, шуларны «сикереп» узып, Әбүгалисинага табынабыз. Цивилизация яңа чирләр тудырды: һава, җир-су пычратыла, синтетик киемнәр барлыкка китерелә, алар авыру чыганагына әверелә, яңа ашламаларны ваемсыз куллану азык-төлекне агуга әйләндерә... Әдәбият бу яктан да укучыларын сәламәт яшәр өчен әзерләргә тиеш. Минем уемча, туган әдәбиятыбызда сәламәтлек саклау мәсьәләләре киңрәк урын алса һәм тирәнрәк яктыртылса, заманыбызга муафыйграк булыр иде. Моның өчен күршеләрнең — Татарстан язучылар союзы һәм Казан медицина институты бәйләнешләрен ныгытырга кирәк.

**Наил ӘМИРЕВ,**
Казан медицина институты ректоры,
медицина фәннәре докторы.

# КИТАПЛАР ДӨНЬЯСЫНДА

Татарстан китап нәшрияты соңгы вакытта түбәндәге китапларны бастырып чыгарды:

**Идегәй.** Татар халык дастаны. 256 бит. Б. 1 с. 30 т.

Ибраһим ГАЗИ. **Алмагачлар чәчәк ата.** Повестьлар, хикәяләр, әдәби парчалар. 368 бит. Б. 2 с. 10 т.

Әмирхан ЕНИКИ. **Кичке шәфәкъ.** Повестьлар. 384 бит, портрет белән. Б. 1 с. 80 т.

Нәкый ИСӘНБӘТ. **Әсәрләр.** Дүрт томлык. I том. Шигырьләр, поэмалар, драматик поэмалар. 312 бит, фотолар белән. Б. 2 с.

Нурихан ФӘТТАХ. **Сызгыра торган уклар.** Романның икенче китабы. 432 бит. Б. 1 с. 70 т.

Мәхмүт ХӘСӘНОВ. **Язгы аҗаган.** Роман. Икенче басма. 608 бит, портрет белән. Б. 2 с. 40 т.

Мәхмүт ХӘСӘНОВ. **Ут-малай.** Әкият. 32 бит, рәсемнәр белән. Б. 20 т.

Шәүкәт ГАЛИЕВ. **Илһамым-мәхәббәтем.** Лирик язмалар. 408 бит. Б. 1 с. 60 т.

Шәүкәт ГАЛИЕВ. **Камырша.** Балалар өчен шигырь. 16 бит, рәсемнәр белән. Б. 10 т.

Гариф ГОБӘЙ. **Маякчы кызы.** Повесть. «Мәктәп китапханәсе» сериясеннән. 192 бит. Б. 60 т.

Фәйзи ГАЛИЕВ. **Авылым гадәтләре.** 126 бит. Б. 30 т.

Алсу ГАЙНУЛЛИНА. **Урман җыры.** Шигырьләр. 64 бит. Б. 25 т.

Рәшит ГӘРӘЙ. **Син бер генә.** Шигырьләр. 128 бит. Б. 20 т.

Фарсель ЗЫЯТДИНОВ. **Онытылмас авазлар.** Балалар өчен шигырьләр, әкият-поэмалар. 56 бит, рәсемнәр белән. Б. 20 т.

Рәшит ИБРАҺИМОВ. **Көмеш канатлар, зәңгәр хыяллар.** Очучы хикәясе. 176 бит, рәсемнәр белән. Б. 60 т.

Нурия ИЗМАЙЛОВА. **Иң серле әкиятем.** Хикәяләр һәм повесть. 224 бит. Б. 65 т.

Кәшшаф КӘРИМ. **Куян елы.** Юмористик хикәяләр. 56 бит. Б. 15 т.

Мостай КӘРИМ. **Ярлыкау.** Повестьлар. 288 бит. Б. 1 с. 60 т.

Фатих КӘРИМ. **Илең турында уйла.** Шигырьләр, поэмалар, балладалар. 192 бит. Б. 50 т.

**Көмеш арба, көмеш ат.** Башкорт хикәяләре. 272 бит. Б. 1 с. 20 т.

Әсгать МИРЗАҺИТОВ. **Пьесалар.** 280 бит. Б. 1 с. 10 т.

Мөхәммәт МӘҺДИЕВ, Аяз ГЫЙЛӘҖЕВ, Марсель ГАЛИЕВ. **Игелек.** Әдәби-публицистик язмалар. 168 бит. Б. 45 т.

Зәки НУРИ. **Күңелле китап.** Төрле илләрдән, төрле телләрдән мәзәкләр. Икенче басма. 240 бит. Б. 60 т.

Зәки НУРИ. **Күпбелем китабы.** Балалар өчен шигырьләр. 20 бит, рәсемнәр белән. Б. 15 т.

Бикә РӘХИМОВА. **Ачыл, күңел.** Шигырьләр. 72 бит. Б. 30 т.

Ибраһим САЛАХОВ. **Колыма хикәяләре** («Тайгак кичү» романы). 256 бит. Б. 1 с. 10 т.

Кадыйр СИБГАТУЛЛИН. **Таңнар, кичәләр.** Шигырьләр һәм поэмалар. 230 бит, портрет белән. Б. 1 с. 10 т.

Ренат ХАРИС. **Хәбәр.** Шигырьләр, җырлар, поэмалар. «Шигырь китапханәсе» сериясеннән. 368 бит, портрет белән. Б. 1 с. 90 т.

Ризван ХӘМИД. **Олы юлның тузаны.** Пьесалар. 190 бит. Б. 85 т.

Рәфикъ ЮНЫСОВ. **Учтагы песнәк.** Шигырьләр һәм поэма. 80 бит. Б. 30 т.

Габдрахман ӘПСӘЛӘМОВ. **Ак чәчәкләр.** Роман. 510 бит. Б. 2 с.

**Җырлыйк та, биик тә.** Халык бию көйләре, композиторларыбызның киң танылган җырлары ноталары белән. 72 бит. Б. 50 т.

Абдулла АЛИШ. **Нечкәбил.** Балалар өчен рәсемле хикәя. 16 бит. Б. 25 т.

Газинур МОРАТОВ. **Тылсымлы тел.** Балалар өчен шигырьләр. 24 бит, рәсемнәр белән. Б. 5 т.

Гарифҗан МӨХӘММӘТШИН. **Уеннан уймак.** Балалар өчен шигырьләр. 24 бит, рәсемнәр белән. Б. 10 т.

**Нәниләргә бүләк.** Шигырьләр, хикәяләр, җырлар, уеннар, табышмаклар, мәкальләр. 128 бит, рәсемнәр белән. Б. 70 т.

Һади ТАКТАШ. **Караборынның дусты.** Балалар өчен хикәя. 20 бит, рәсемнәр белән. Б. 20 т.

Габдулла ТУКАЙ. **Шүрәле.** Әкият-поэма. 32 бит, рәсемнәр белән. Б. 60 т.

Габдулла ТУКАЙ. **Су анасы.** Әкият. 16 бит, рәсемнәр белән. Б. 25 т.

Хәйдәр. **Солдат абый.** Балалар өчен шигырьләр. 64 бит, рәсемнәр белән. Б. 15 т.

Харрас ӘЮПОВ. **Төнге кояшлар.** Шигырьләр. 160 бит, портрет белән. Б. 70 т.

Нур ӘХМӘДИЕВ. **Кояш эзләүче малай.** Лирик һәм юмористик хикәяләр. Балалар өчен. 110 бит. Б. 20 т.

Якындагы кибеттә булмаса, бу китапларны почта аша сорап алдырырга мөмкин. Адреслар: 420057, г. Казань, ул. Октябрьская, 18. Магазин «Книга-почтой». 420084, г. Казань, ул. Баумана, 19. Магазин № 1, отдел «Книга-почтой».

## ИСЛАМ ДИНЕН КАБУЛ ИТҮЕБЕЗГӘ 1100 ЕЛ

Быелның август аенда Идел буендагы Болгар дәүләтендә яшәгән бабаларыбызның ислам динен кабул итүенә һиҗри ел исәбе белән 1100 ел тулу һәм СССРның Европа өлеше һәм Себер мөселманнары Диния нәзарәте оешуга 200 ел тулу тантаналы төстә билгеләп үтелде.

Ислам динен кабул итүгә, аны Россиядә рәсми тануга бәйле юбилей тантаналары Уфа шәһәрендә киң җәмәгатьчелек бәйрәме төсендә башланып китте. РСФСР Министрлар Советы каршындагы дин эшләре буенча совет рәисе Л. Ф. Колесниковның юбилей тантанасында катнашучыларга РСФСР хөкүмәте мөрәҗәгатен укуы киң хуплау тапты. Тантаналарда катнашу өчен килгән 23 чит ил вәкилләреннән чыгыш ясаучылар — Бөтендөнья Ислам лигасы генераль секретаре доктор Абдулла Омар Нәсеф, Бөтендөнья Ислам конгрессы генераль секретаре доктор Инамулла Хан, Бөтендөнья Ислам конференциясенең культура мәсьәләләре буенча генераль секретаре Абдел Мохсин, кайбер гарәп илләренең вакыфлар министрлары һәм башка оешмалар вәкилләре, бәйрәмнең дуслык, изгелек, тәкъвалык шартларында үтүен билгеләп, бик җылы сүзләр әйттеләр.

Аннары юбилей тантаналары Татарстанга күчте. Кунаклар Бөгелмә һәм Әлмәт мәчетләрендә булдылар, истәлекле урыннар белән таныштылар, Түбән Кама шәһәрендә корылачак мәчетнең беренче нигез ташын салуда катнаштылар, Чаллы шәһәрендә төзелеп бетеп килгән мәчетне карадылар, халык белән очраштылар. Аннары Казанга юл тоттылар.

Чит илләрдән һәм СССРдагы республикалардан, өлкәләрдән җыелган дин әһелләрен каршыларга КамАЗ юлына байтак кеше чыкты. Республика башкаласына кергәндә кунакларны шәһәр Советы башкарма комитеты рәисе К. Ш. Исхаков сәламләде.

Кичен алар В. И. Ульянов-Ленин исемендәге үзәк стадионда, ун меңләгән казанлылар белән бергә, борынгы болгар-татар җырлары, бәетләре, мөнәҗәтләр, догалар нигезендә эшләнгән «Мәһди» (изге Болгар дастаны) дигән музыкаль-драматик тамаша карадылар.

Казанда юбилей тантаналары Кремльне һәм Сөембикә манарасын караудан башланды, аннары кунаклар Ленин районына юнәлделәр, Р. Мусин һәм А. Чуйков урамнары чатында төзеләчәк мәчет өчен билгеләнгән урында булдылар, Мәскәү районында төзелгән яңа мәчеттә, Зеленодольск мәчетендә, Аккош күле буендагы «Наратлык» кафесында булдылар. Сынлы сәнгать музеенда гарәп язуы үрнәкләрен, университетта Ленин мемориалын һәм тарих музеен карадылар. Габдулла Тукай музеенда да кунаклар белән күңелле аңгәмә узды.

24 августта Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында юбилейга багышланган тантаналы мәҗлес булды.

Олуг бәйрәм белән ТАССР Верховный Советы Президиумы һәм Министрлар Советы исеменнән Татарстан АССР Министрлар Советы Председателе беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов котлады.

Ул Идел буе болгарларының ислам динен кабул итүләрен җирле халыкның рухи тәрәккыятендә мөһим бер борылыш ясаган, аны мәгърифәт һәм мәдәният үсешендә, яшәеш рәвеше, традицияләре, милли үзаңы, соңрак милли дәүләтчелеге формалашуда тирән эз калдырган вакыйга дип билгеләп үтте.

Диния нәзарәте рәисе мөфти Тәлгат Таҗетдин доклад белән чыкты. Ул Идел буе халыкларының чал тарихы, үз ихтыярлары белән ислам динен кабул итүләре, Диния нәзарәтенең бүгенге эшчәнлеге, мәчетләрнең әхлаклылык тәрбияләүдәге роле турында сөйләде.

Чит илләрдән килгән кунаклардан Сүрия вакыфлар министры Абдул Мәҗит Тараблуси, Болгариянең баш мөфтие Надию Генҗев, Гыйрак вакыфлар министры урынбасары Мөхәммәт Шәриф, Финляндиядәге ислам җәмгыяте рәисе Окан Таһир, «Ислам чакыруы» дигән Бөтендөнья җәмгыяте җитәкчелеге рәисе Ас-Саих әл-Факил, Япония мөселманнары җәмгыятенең хөрмәтле президенты Әбелкәрим Сайто Секихай һәм Японияләге якташыбыз — татар-төрек җәмгыяте рәисе доктор Тамимдар Мөхит һәм башкалар котлау сүзләре белән чыктылар.

Тантаналарда катнашу өчен килгән кунакларны көннең икенче яртысында Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателе Ш. Ә. Мостаев кабул итте.

25 августта юбилейда катнашкан кунаклар теплоходта борынгы Болгар шәһәре урнашкан урынга бардылар, Шәһре Болгар истәлекләре белән таныштылар, борынгы бабаларыбыз рухына багышлап гыйбадәт кылдылар.

# ХАЛЫК РУХЫ ҖАНЛАНА

Сынчы рәссам Рада Хөсәен кызы Нигъмәтуллина агачны юнып, балчык киптереп яисә гипстан коеп сынландырылган зур булмаган нәфис композицияләр ясый. Иҗатында фольклор юнәлешенә өстенлек биргән танылган рәссамны «кече сыннар» остасы дип йөртәләр. Ул иҗат иткән әлеге әсәрләрдә — кеше йөрәгендәге иң самими, саф, нечкә олы хисләр, гүзәллек, пакьлыкка омтылу, кешеләр арасындагы асыл мөгамәлә, табигать, яшьлек, шигърият... Шул илаһи хисләргә орынудан туган кичерешләр аның әсәрләрендә кабатланмас матди форма ала. Аның күп кенә әсәрләре горизонталь яссылыкка җәелә. Моңлы, ритмик детальләр серле рухи яктылык аша тасвирлана. Яшь ананың алтынсыман агач кәүсәдән уеп-уеп ясалган, бишеккә иелгән ягымлы сыны («Бишек җыры» — 1957), өмәгә җыелган сылу кызларның шәм мае белән бергә кушылып аккан кайнар күз яше («Әллүки» — 1975)... Шушы табигый, кешелекле тойгыларның чынлыгына, яктылыгына сокланасың, иҗатчының күңел тетрәткеч осталыгы каршында баш иясең. Әйтергә кирәк, рәссамның иҗаты милли рухта, милли бизәкләр, моңлы кичерешләр юнәлешендә үсеш алды. Раданың эзләнүләре сөекле шагыйребез Г. Тукайның балачагына, В. Ульяновның яшьлек елларына багышланган әсәрләр тууга китерде. Аларда, лирик хисләр белән бергә, өр-яңа төсмерләр дә күрергә мөмкин. Олыгаю-өлгерү дә озак көттермәде. Лирик алымга алмаш булып, тирән мәгънәле, фәлсәфи эчтәлекле, уйчан, катлаулы әсәрләр иҗат ителә башлады. Йомры-йомшак сабыен баш өстенә күтәргән озын күлмәкле яшь ананың сыны әнә шундыйлардан («Үс, Татарстаным!»). Шәһәребезнең иң күренекле урыннарына куярлык бу монументаль әсәр символик мәгънәгә ия. Шул ук вакытта әсәр, пластик яктан, тотнаклы да. Сын үзенең кырыслыгы белән дә игътибарны җәлеп итә. Кыскасы, рәссамның иҗаты Роден, Бурдель, Майоль кебек Европа сынчыларына тиңләшерлек.

1980 елларның уртасында Рада Нигъмәтуллина яңа төзелеп килә торган Татар академия театрының залларын бизәү өчен милли сюжет, пластика, грация, типажларга корылган композицияләр турында уйлана. Артистларча фикер йөртә белә торган, театр сәнгатен тирәннән сөеп үскән рәссам милли драматургиянең аерым әсәрләренә дә тукталa, аларга конкрет һәм символик төсмер бирә... Аның тырышлыгы, талант үзенчәлеге аркасында Европа сәнгатендә киң урын алган гадәти алымнар монда милли бизәкләр белән өртелә. «Бию», «җырлау», «шигырь сөйләү» күренешләре халыкчан рухта, милли төстә сурәтләнәләр. Һәр сын, ул нинди генә балчыктан ясалмасын, күз явын алырлык иттереп шомартылган, төрле төсләр белән бизәлгән. Рәссам, эретелгән пыяла буяу файдаланып, кечкенә сыннарга чыдамлылык, тотнаклык бирә. Сынлы сәнгать музеенда саклана торган өч сыннан торучы «Беренче театр» композициясе әнә шундыйлардан. Бу композиция театр залына куелган әсәрләргә кереш-аңлатма буларак башкарылган. Монда рәссамның сын ясау осталыгы белән нәкышчелек осталыгы бер-берсенә нык ярдәм иткән. Нәтиҗәдә Р. Нигъмәтуллинаның эзләнүләре Татарстан сынлы сәнгатендә лаеклы урын алды.

**Р. ШАҺИЕВА,**
**Татарстан сынлы сәнгать музее хезмәткәре.**

**Тышлыкның дүртенче битендә:** Казан монастыре күренеше. XIX гасыр инглиз рәссамы Э. Турнерелли эшеннән репродукция.

**Ю. ФИЛИМОНОВ** фотолары.

## *«Казан утлары» 1990 елда*

**МӘДИНӘ МАЛИКОВА**

# ФИДАЯ

РОМАН

Хәзерге үзгәртеп кору, яңарыш чорында төрле югарылыктагы җитәкчеләргә бик күп үпкә һәм хәтта гаепләү сүзләре әйтелә, җитәкче оешмалар тәнкыйть ителә. Шул ук вакытта, алга бару юлларын билгеләгәндә, без җитәкчеләребезнең сүзенә колак салабыз, күп очракта депутатларыбыз итеп тә шуларны сайлыйбыз. Чөнки җитәкчеләрнең бик күбесе — халыкның иң актив, эшчән, уңган, акыллы уллары бит. Әгәр дә торгынлык чорында аларның эшчәнлеге, тырышлыгы, кылганнары илнең алга баруына хезмәт итмичә, киресенчә, җәмгыятебезне артка сөйрәгән икән, моңа еш кына алар үзләре түгел, ә бәлки нигып алган тәртипләр системасы гаепле.

Әйе, җитәкче урынга күтәрелгән кеше заманында шундый тәгәрмәчләр арасына барып эләккән иде ки, ул һәрвакыт намусы һәм акылы кушканча гына хәрәкәт итә алмады, шуларга көйләнергә тиеш булды. Әгәр дә көйләнмәсә, җайланмаса,— очып төште.

Романның баш герое Фидая нәкъ менә шундыйлардан — көйләнә, җайлана алмаучылардан, үз алдына куйган максатыннан ваз кичмәүчеләрдән. Шунысын да әйтергә кирәк: җитәкчеләр арасында хатын-кызлар аз безнең, аларга бу өлкәдә эшләү, үзләрен чын актив шәхес итеп исбат итү бигрәк тә кыен, чөнки җитәкчелек эшенең бөтен рәвеше, барышы, агышы фәкать ирләр холкына, ирләр табигатенә яраклаштырылган, аларның үзара кырыс, күп очракта хәтта дорфа мөнәсәбәтенә корылган. Андый мохитта, билгеле инде, хатын-кыз чәукәләр арасындагы ак күгәрчен кебек чит-ят иде.

Фидая да шул ак күгәрчен кебек. Ул бу тәгәрмәчтә озак әйләнә алмый, атылып төшә. Ләкин, үзе егылганчы, кешеләргә булдыра алган кадәр яхшылык эшләп калырга ашыга.

Бу әсәремдә мин заманыбыз хатын-кызлары язмышының бер чагылышын тасвирлап бирергә тырыштым.

---


**ЖУРНАЛНЫ АЛДЫРУЧЫЛАР ИГЪТИБАРЫНА!**

Журналның брак саны килгән очракта аны газета-журналлар нәшриятының техник контроль бүлегенә җибәрүегезне үтенәбез. Адресы: *420066, Казань, Декабристов, 2, Типография ГЖИ, ОТК.*


Редакция журнал җибәрү белән шөгыльләнми.

Әгәр журналның теге яки бу саны килми калса, «Союзпечать»нең җирле бүлекләренә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Бу мәсьәлә редакция вәкаләтенә керми.

Кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
(ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)